# Казан утлары

4.1984



КАЗАН УТЛАРЫ

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ОРГАНЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-ПОЛИТИК ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

4

1984

## *Бу санда*

ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАРЫНЫҢ X СЪЕЗДЫ АЛДЫННАН

**Яңа биеклекләр яулаганда** . . . . . . . . . . 3

И. ЮЗЕЕВ. **Кайтавазы сыман Тукайның.** Шигырь . 11
В. ТЕЛЬПУГОВ. **Биш минут.** Хикәя . . . . . . 12
Г. БӘШИРОВ. **Күзгә ачы җилләрдә.** Повесть-истәлек . . . . . . . . . . . . . . 17
Ә. БАЯНОВ. **Иделдә җәй.** Шигырьләр . . . . . 79
С. САБИРОВ. **Хатлар язам сагынып.** Повесть . . 85
А. ШАМОВ. **Язны көткәндә.** Хикәя . . . . . . 125
Р. МИҢНУЛЛИН. **Җайдаклар без.** Шигырьләр . 133

ТУКАЙНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА

**Казанда Тукай урыннары** . . . . . . . . . . 138
А. ГЫЙЛӘҖЕТДИНОВА. **Габдулла Тукай турында истәлекләр** . . . . . . . . . . . . . . 139
Х. ГОБӘЙДУЛЛИН. **Тукай автографы** . . . . 140

УНБЕРЕНЧЕ БИШЬЕЛЛЫК: КЕШЕЛӘР ҺӘМ ЭШЛӘР

К. ЛАТЫЙПОВ. **Тормыш нигезе — һөнәр** . . . 142
М. ЕЛИЗАРОВА. **«Әти кебек булыр идем!»** . . 145

ИЛЕБЕЗ ТӘНКЫЙТЬЧЕЛӘРЕ ТАТАР ЯЗУЧЫЛАРЫ ТУРЫНДА

А. КУЛУМБЕТОВА. **Әхлак проблемасы үзәктә** . 151
В. ДЕМЕНТЬЕВ. **Ялкынлану бәхете** . . . . . 157

ӘДӘБИ БӘЙЛӘНЕШЛӘР

Ф. УРМАНЧИЕВ. **Татар әдәбияты — Венгриядә** . 161

БИБЛИОГРАФИЯ

Р. ИЗМАЙЛОВ. **Партия солдаты** . . . . . . . 167
К. ТИМБИКОВА. **Өметләр аклану** . . . . . . 168

ЯЗУЧЫ УЙЛАНУЛАРЫ

Т. МИҢНУЛЛИН. **Кызыл тышлы дәфтәрдән** . . . 170

КПССның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНЫҢ ГАЗЕТА ҺӘМ ЖУРНАЛЛАР НӘШРИЯТЫ

КАЗАН

КУЛЬТУРАБЫЗ ТАРИХЫНА

С. АЛИШЕВ. **Мәгърифәт учаклары** . . . . . . 174

САМАТ ШАКИРГА 60 ЯШЬ

С. ШАКИР. **Яңгыр тамчысы.** Шигырьләр . . . . 181

ӘНҖЕ МӨЭМИНОВАГА 60 ЯШЬ

Э. МӨЭМИНОВА. **Күзге чәчәк.** Шигырьләр . . . 185

**Кызыклы хәлләр** . . . . . . . . . . . . . 189

**Культура тормышы көндәлеге** . . . . . . . . 190

**Тышлыктагы сурәтләр** . . . . . . . . . . . 192

*Баш редактор*
РЕНАТ ХАРИС

*Редколлегия:*
ШАМИЛ БИКЧУРИН
МАНСУР ВӘЛИЕВ
РАЗИЛ ВӘЛИЕВ
АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ
РӘИС ДАУТОВ
МАРСЕЛЬ ЗАРИПОВ
ЗӨЛФӘТ
САЛИХ МАННАПОВ
*(җаваплы секретарь)*
ТУФАН МИҢНУЛЛИН
ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИН
РИНАТ МӨХӘММӘДИЕВ
*(баш редактор урынбасары)*
ЗӘКИ НУРИ
РӘФЫЙК НӘФИКОВ
АТИЛЛА РАСИХ
СИБГАТ ХӘКИМ
НИЛ ЮЗИЕВ

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«В преддверии X съезда писателей». Итоги литературной дискуссии «Современная проза: герои, проблемы».
22 апреля — день рождения В. И. Ленина. Рассказ **В. Тельпугова** «Пять минут».
В рубрике «К 100-летию Тукая»: стихотворение **И. Юзеева**, рис. **Т. Зуевой** из серии «Тукаевские места в Казани», новые материалы к биографии Г. Тукая (Публикации **А. Гилязетдиновой** и **Х. Губайдуллина**).
Окончание повести **Г. Баширова** «Жгучие осенние ветры». Повесть **С. Сабирова** «Письма любви и тоски». Стихи **А. Баянова**, **Р. Миннуллина**.
Очерки **К. Латыпова** и **М. Елизаровой**.
«Всесоюзная критика о современной татарской литературе». Статьи **А. Кулумбетовой** (Чимкент) и **В. Дементьева** (Москва).
Статья **Ф. Урманчеева** «Татарская литература в Венгрии».
Рецензии на новые книги Ш. Хамматова и Ф. Гиззатуллиной.
Эссе **Т. Миннуллина** «Из записной книжки писателя».
Статья **С. Алишева** о системе просвещения татарских крестьян в XVIII веке.
Юбилейные материалы к 60-летию С. Шакира и Э. Мукминовой.
«Занимательные истории» (из жизни выдающихся деятелей татарской культуры); «Новости культуры»; «На наших обложках» — творчество художника И. Мазитова.

Безнең адрес: 420066, Казань, ул. Декабристов, 2.

Телефоннар: баш редактор — 53-07-60, баш редактор урынбасары, җаваплы секретарь — 53-07-09, проза, поэзия, очерклар бүлекләре — 53-07-61, тәнкыйть, сәнгать, хатлар бүлекләре — 53-07-63.

Техник редактор *Р. Сөләйманова.* Корректорлар *Ф. Кадыйрова, Т. Сибгатуллина.*

Производствога бирелде 30.1.1984 ел. Басарга кул куелды 26.3.1984 ел. ПФ 02143. Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12(16,8). Тираж 64184. Заказ К-44. Бәясе 90 тиен.

КПССның Татарстан өлкә комитеты нәшрияты типографиясе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1984 ел.

# ЯҢА БИЕКЛЕКЛӘР ЯУЛАГАНДА

**«БҮГЕНГЕ ПРОЗА: ГЕРОЙЛАР, ПРОБЛЕМАЛАР» ДИСКУССИЯСЕНЕҢ ЙОМГАКЛАРЫ**

Татар совет прозасының хәзерге торышына багышланган дискуссия әдәби җәмәгатьчелектә дә, укучылар арасында да киң яңгыраш тапты. Сөйләшү барышында илебезнең төрле төбәкләреннән күп санлы хатлар килде. Фикер алышуда катнашып журнал битендә мәкалә, реплика яисә хат белән чыгыш ясаган һәр автор бу сөйләшүнең вакытлы башлануын, күтәрелгән мәсьәләләрнең үтә актуаль икәнлеген язды. Соңгы елларда прозаикларыбыз сафында яшьләрнең күбәюе дә мондый сөйләшүне көн тәртибенә куйды, аның характерын һәм әһәмиятен билгеләде.

Әмма тагын да мөһимрәге: тормышыбыз үзе соңгы елларда һәм социаль, һәм рухи яктан югарырак баскычка күтәрелде. Шуңа бәйле рәвештә әдәбият алдына да яңа зур бурычлар килеп басты. Программ характердагы бу олы бурычларны КПССның XXVI съезды: «Халык интереслары белән яшәү, шатлык һәм кайгыны аның белән уртаклашу, тормыш хакыйкатен, гуманистик идеалларны раслау, коммунистик төзелештә актив катнашу — сәнгатьнең чын халыкчанлыгы, чын партиялелеге әнә шунда»,— дип күрсәтте.

Партиябезнең съезддан соңгы документларында әлеге бурычлар тагын да конкретлаша төште. «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән иҗади элемтәсе турында»гы карарда мондый юллар бар: «Совет кешеләренең яңа буыны үзләренә рухи яктан һәм вакыт ягыннан якын булган уңай герой көтә».

КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумында исә ачыктан-ачык: «Кешенең рухи ихтыяҗларын формалаштыру, югары дәрәҗәгә күтәрү, шәхеснең идея-политик һәм әхлак сыйфатларына актив йогынты ясау — социалистик культураның гаять мөһим миссиясе»,— диелде.

Партиянең әнә шундый юл күрсәткеч, иҗатка рухландыручы карарлары яктылыгында һәм тормышның үзендә булган рухи ихтыяҗлардан чыгып, бүгенге татар совет прозасы хакында сөйләшү, һичшиксез, кирәк иде.

Дискуссия журналның 1983 елгы 2 нче санында редакция куйган сорауларга җавап рәвешендә урнаштырылган ике мәкалә белән: прозаик һәм драматург Аяз Гыйләҗевнең «Тынычлану зарарлы!» һәм тәнкыйтьче Тәлгат Галиуллинның «Нәфисәләр юксындыра...» исемле мәкаләлә-

реннән башланып китте. Сөйләшү барышында уртага салынган мәсьәләләр шактый ачыкланды, күп кенә сорауларга җаваплар табылды.

Соңгы елларда (10—12 ел) иҗат ителгән роман, повесть, хикәяләребез, алардагы үзенчәлекле әдәби күренешләр һәм бары тик шушы чорда гына туа алган яңа персонажлар әдәби дискуссияне конкрет иттеләр. Әдәбият белгечләренең, тәнкыйтьчеләрнең профессиональ әзерлеге, әдәбият сөючеләрнең заман таләпләре югарылыгындагы эстетик зәвыгы фикер алышуны бөтен татар совет әдәбияты һәм күпмилләтле совет әдәбияты контекстында алып барырга мөмкинлек бирде.

Илебездә соңгы елларда дөнья күргән әдәби әсәрләрдә коммунистик төзелешнең героик пафосы, җәмгыятебезнең тарихи оптимизмы, эшчеләрнең, авыл хезмәт ияләренең, интеллигенциянең фидакарь хезмәте гәүдәләнеш тапты. Бүгенге татар әдәбияты да бу күмәк иҗади хезмәткә өлеш кертте. Алдагы ун еллыклардагы кебек, соңгы ун елда да татар совет прозасы шактый гына уңышларга иреште. Халык һәм партия куйган югары бурычлар яктылыгында иҗат ителгән, чор таләпләренә җавап биргән, укучылар яратып кабул иткән күп кенә проза әсәрләре барлыкка килде.

Заман темасына игътибарның артуы — соңгы еллар прозасындагы куанычлы күренешләрнең берсе. Эшчеләр сыйныфы вәкилләре образларының иҗатта аеруча активлык белән үзләштерелүен, әдипләребезнең бу юнәлештә һаман да тирәнгәрәк керә баруларын әйтеп үтәргә кирәк. Шундый әсәрләрнең кайберләре (Ш. Бикчурин «Каты токым», Э. Касыймов «Чулман — оныклар елгасы») ил күләмендә дә билгеләп үтелде.

Прозаның жанрлары, аерым алганда повесть төре, тагын да активлашты. Документаль, автобиографик, лирик повестьлар басылып чыкты. Повесть-уйланулар, повесть-юлъязмалар язылды. Тарихи һәм тарихи-маҗаралы романнар дөнья күрде. Шулай ук хикәя үсешендә күпмедер җанлану сизелде.

Прозабызның тематик һәм проблематик яктан колачы киңәю процессы дәвам итә. Әсәрләргә замандашларыбызның социаль һәм рухи яшәешенең яңа даирәләре, кызыклы катламнары, җитди мәсьәләләре килеп керде. Тарихи, тарихи-революцион һәм хәрби-патриотик темаларга кызыклы әсәрләр туды. (А. Расих «Ямашев», Г. Ахунов «Ардуан батыр», Н. Фәттах «Сызгыра торган уклар», Ш. Рәкыйпов «Аяз күктә карлыгачлар» һ. б.)

Алдагы еллардагы шикелле, бу елларда да прозабызның иң зур уңышлары авыл темасы белән бәйләнгән. Авыл хезмәтчәннәренең онытылмас образларын гәүдәләндергән, укучының күңеленә хуш килгән әсәрләр иҗат ителде. (Г. Бәширов «Җидегән чишмә», А. Гыйләҗев «Җомга көн, кич белән...», М. Мәһдиев «Торналар төшкән җирдә...», В. Нуруллин «Аккан су юлын табар» һ. б.)

Соңгы елларда заман тормышын әхлак проблемасы аша чагылдыру тагын да активлаша төште. Татар прозасының өлкән буын әдипләре тарафыннан күптәннән бирле уңышлы алып барылган бу юнәлеш партиябезнең әхлак тәрбиясенә багышланган мәгълүм карарыннан соң яңа җанланыш кичерде. Зур һәм кечерәк күләмдәге күп кенә проза әсәр-

ләре шушы проблеманы заманча күтәреп чыкты (Г. Бәширов «Сарут», Ә. Еники «Тынычлану», Ф. Хөсни «Гыйльмениса һәм аның күршеләре», А. Расих «Сынау», Г. Ахунов «Чикләвек төше», А. Гыйләҗев «Әтәч мengән читәнгә», Х. Сарьян «Бер ананың биш улы», М. Юныс «Табу һәм югалту», Ә. Баянов «Тау ягы повесте» һ. б.).

Татар совет прозасы соңгы елларда олы масштаблы уңай герой образын тудыру юлында эзләнүләрдә булды. Заман тормышы куйган җитди проблемалардан чыгып, аларны коммунистик идеаллар кушканчә хәл итәргә омтылып, язучыларыбыз истә калырдай калку образлар тудырдылар. КПССның XXVI съездында яңгыраган: «Производствода һәм көнкүрештә кешеләрнең үзара мөнәсәбәте, шәхеснең катлаулы эчке дөньясы, тынычсыз планетабызда аның урыны — болар һәммәсе художество эзләнүләре өчен бетмәс-төкәнмәс өлкә»,— дигән сүзләр аларга якты маяк булды.

Алдагырак елларда безнең прозада әдәби геройларның шартлы рәвештә «үрнәк геройлар»га һәм «гыйбрәтле геройлар»га бүленүе сизелгән булса, соңгы еллар иҗат практикасы алар арасында диалектик якынаю барганын күрсәтте. Нәтиҗәдә, проза әсәрләрендә шактый гыйбрәтле тормыш юлы үткән, замандашларыбыздагы бик күп уңай сыйфатларны үзләренә туплаган һәм шул ук вакытта, тирән ышандыру көченә ия гыйбрәтле язмышлы геройлар туды.

Гомумсовет әдәбиятындагы кебек үк, бездә дә бөтен җәмгыятебезне кызыксындыра торган проблемаларны художестволы үзләштерү активлашканнан активлаша бара, язучыларыбызның коммунистик төзелеш практикасы белән элемтәләре ныгый һәм тирәнәя. Нәтиҗәдә халыкның рухи энергиясен тупларга, аның хезмәт һәм социаль активлыгын арттыруга ярдәм итә торган әсәрләр барлыкка килә.

Сюжет һәм композиция ягыннан алып караганда да прозада кызыклы гына күренешләр булды. Уйлану, эссе рәвешендә язылган повестьлар иҗат ителде. Әсәрләрдә автор шәхесенең роле көчәю тенденциясе сизелде. Прозада документальлеккә игътибар артты. Болар барысы да безнең прозаның эчтәлек һәм проблематик яктан гына түгел, ә форма ягыннан да үсештә, хәрәкәттә икәнен раслый.

Социалистик реализм әдәбияты сурәтләү чараларының, алымнарының бай һәм күп төсле палитрасын булдырды. Алардан тиешенчә файдалана белү юнәлешендә дә безнең прозаиклар нәтиҗәле эзләнү алып бардылар. Ә укучы тарафыннан язучыларның бу эзләнүләре әдәби әсәрнең мәгънә тыгызлыгын, тәэсир көчен арттырырга омтылу дип кабул ителде. Әнә шул ноктадан чыгып караганда бездә шактый гына бәхәс тудырган шартлы алымнарның кайсылары чынлап та файдалы булу мәсьәләсе дә әдәби процесс барышында ачыклана килде.

Әйе, үткән ун еллыкта прозабызның казанышлары аз булмады. Күп кенә прозаикларның иҗаты республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясенә лаек дип табылды (Г. Ахунов, А. Гыйләҗев, И. Нуруллин, А. Расих, Ф. Хөсни, М. Әмир). Югары идея-художество сыйфатларына ия булган проза әсәрләре укучыларны коммунистик рухта тәрбияләү буенча зур эш башкардылар.

Болар барысы да әдәбият сөючеләрне ихлас шатландыра. Алар моны

үзләренең хатларында горурланып телгә алалар. Дискуссиядә катнашкан иптәшләрнең журналда басылган мәкаләләрендә дә татар совет прозасының алда әйтелгән уңышлары, үсешендәге уңай тенденцияләре ачык билгеләп үтелде.

Әмма үткән һәм бүгенге уңышларга карап тынычлану, булган уңышларны инкяр итү кебек үк, зарарлы. Дискуссиядә катнашучылар һәм киң катлам әдәбият сөючеләр хаклы рәвештә күрсәтеп үткәнчә, бүгенге татар прозасында шактый гына җитешсезлекләр дә яши бирә. Алар җитлеккән социализм чоры кешеләренең актив социаль тормышы, замандашыбызның тирән рухи яшәеше, югары культурасы белән чагыштырып һәм партиябезнең әдәбият алдына куйган зур таләпләреннән чыгып караганда бигрәк тә ачык күренәләр.

Соңгы еллар прозасында жанрларның күпмедер активлашуы күзәтелсә дә, әле аларның үсеше һәм бүгенге дәрәҗәсе һич тә тынычланырга мөмкинлек бирми. Заманыбыз зур политик вакыйгаларга бай, чорыбыз кешесе аларның күп яклы тәэсирен үзендә даими рәвештә сизеп яши. Ләкин татарча язылган политик роман яки повесть әле безнең укучы өчен һаман хыял булып кала. Зур күләмле сатирик әсәрләр белән дә шулайрак тора. Ә бит халкыбыз, партиябез соңгы елларда кимчелекләр белән ничек аяусыз һәм принципиаль көрәшә. Бу көрәштә татар прозаикларының үткен каләме, образлы сүзе, һичшиксез, активрак катнашырга тиеш.

Фикер алышучылар халкыбызның төрле чорларда яшәгән батыр уллары турында бик еш телгә алдылар. Алар хакында әдәби әсәрләрнең аз булуыннан ризасызлык яңгырады. Тарихи-революцион теманы тагын да үстерү өчен бездә җирлек зур. Халыкның якты киләчәге өчен көрәшкә гомерләрен багышлаган шәхесләр тормышы — бүгенге әдипләр өчен гаять бай хәзинә. Ләкин биредә шунысын да истән чыгарырга ярамый: укучыларыбыз андый әсәрләрнең күңелгә үтәрдәй һәм көчле тәэсирле итеп язылуын телиләр. Кайнар йөрәкле шәхесләр хакында шулай ук кайнар йөрәк белән, нык рухланып язылган, мавыктыргыч әдәби әсәрләр көтә алар.

Соңгы еллар прозасында сугыш турында, хәрби-патриотик темага киң полотнолы әсәрләр азрак күренә. Г. Әпсәләмовның «Алтын Йолдыз»ы, «Мәңгелек кеше»се кебек китапларны сагына укучы. Ә бит бүген бу теманың әһәмияте һич кенә дә кимемәде. Чынбарлыкта хәрбипатриотик тәрбиянең бурычлары зурайган вакытта прозаның әлеге юнәлештә активлыгын тагы да арттырасы бар.

Детектив жанры хакында да шуны ук әйтергә мөмкин. Укучыга тирән мәгънәле, коммунистик идеяләр белән сугарылган, мавыктыргыч детектив әсәрләр кирәк. Кызганычка каршы, прозаның әлеге тармагы соңгы елларда без көткәнчә үк үсмәде. Эш аерым әсәрләр белән генә чикләнде.

Әдәби дискуссиядә катнашучыларның иң зур теләкләре прозабызның тематик һәм проблематик ягына кагыла. Заманыбыз алга куйган, планета, ил, халыклар язмышына, кешенең рухына бәйләнешле, бөтен җәмгыятебезне кызыксындыра торган үтә җитди мәсьәләләр проза әсәрләребезгә акрын керәләр. Олы проблемалар, конфликтлар эчендә

генә кешенең шәхес буларак зурлыгы, рухи матурлыгы ачык күренә. Кешенең чорга тиң булып формалашуын һәм аның күңеле яңаруы процессын сурәтләүдә соңгы еллардагы татар прозасы заман таләпләренә җавап бирерлек художество югарылыгына ирешге дип әйтә алмыйбыз әле.

Сөйләшүнең үзәгендә торган мәсьәлә, әлбәттә, проза әсәрләренең герое иде. КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы заман герое проблемасының үтә мөһим әһәмияткә ия булуын ассызыклап үтте.

Кеше, бигрәк тә яшь кеше, тормыш максатларының гүзәллеген, идеялылыгын, хезмәт сөючәнлекне һәм кыюлыкны гәүдәләндергән идеалга мохтаҗ. Уңай герой гына политик культура чыганагы була ала. Уңай геройларыбыз гына укучыны кеше дигән бөек исемгә лаеклы булып яшәргә өйрәтәләр.

Дискуссиядә катнашучылар бу проблемага төрле яктан, төрле яссылыктан карарга тырыштылар. Заман һәм герой, герой һәм аның эше, герой язмышы һәм халык, безнең проза герое һәм илебезнең башка әдәбиятларындагы геройлар һ. б. Авторлар үзләре сүз алып барган яссылыктан карап бүгенге проза героена күп төрле таләпләр куйдылар.

Укучы бүгенге зур тормыштагы олы эшләр башкаручы реаль геройларны үз күзләре белән күреп тора. Ул аларның нинди олы вакыйгаларда катнашуына, бөтен кешелек тарихы өчен онытылмастай батырлыклар кылуына шаһит. М. Горькийның «Кеше — ул бөек яңгырый» дигән сүзләре инде безнең реаль замандашларыбыз тарафыннан тормышыбызның төрле тармакларында күп мәртәбәләр расланды. Социалистик чынбарлыгыбызда кеше — тормышны иҗат итүче, аны төзүче, матур якка үзгәртүче буларак,— үзе дә үсте. СССРның 60 еллыгы уңае белән үткәрелгән Тантаналы утырышта «Безнең алтмыш еллык тарихыбызның иң төп нәтиҗәсе, ул — совет кешесе»,— дигән сүзләр әйтелде.

Дискуссия барышында безнең романнардагы, повестьлардагы һәм хикәяләрдәге геройлар әнә шундый — баш хәрефтән языла торган — совет Кешесе биеклегеннән, шул югарылыктан торып тикшерелделәр. Нәтиҗәдә, безнең прозаның бик зур резервлары барлыгы, әле аларның тиешенчә файдаланылмаганлыгы күренде.

Дөрес, уңай геройлар безнең һәр әсәребездә бар. Алар асылда намуслылар, саф күңеллеләр, әхлак нормаларын ихтирам итеп яшиләр, кылган эшләре дә әйбәт. Ләкин, кызганычка каршы, тоныклар, канатсызлар, күп очракта инфантильләр, бер авторыбыз әйткәнчә «уртача статистик индивидуумнар». Бүгенге прозабызга — хикәяме ул, повесть, романмы — социаль яктан актив булган, шул активлык җирлегендә зур һәм нык булган, политик культурага һәм коммунистик әхлакка ия булган тулы канлы, кайнар рухлы герой җитми.

Әдәби геройның югары әхлаклы булырга тиешлеге — дискуссиядә катнашучы бик күп авторларның төп фикере. Алар югары әхлаклылыкны әдәби геройны бәһаләүдә төп критерий итеп карауларын яздылар, әдәбиятның тәрбияви ягына зур басым ясадылар. Кайбер әсәрләрдә күренеп киткән ямьсез, укучыны яхшыга өндәмәстәй күренешләр турында җитди сүз алып барылды.

Укучылар, һичшиксез, хаклылар. Безнең халкыбызда китап сүзенә

карата борын-борынгыдан ук килгән зур хөрмәт, ышану яши. Бүгенге әдипләр, аеруча яшь каләм ияләре, әдәбиятның әдәп сүзеннән икәнен онытмаска тиешләр.

Әхлаклылыкның иң югары дәрәҗәсе — ватандарлык. Татар совет әдәбиятының күренекле әсәрләре шушы изге хис белән аеруча нык сугарылганнар. Һәм бүгенге көн әдәбияты да бу традицияне заманча лаеклы югарылыкта дәвам итәргә, үстерергә тиеш.

Әдәби геройларыбызга социаль, иҗтимагый, әхлакый активлыкның җитмәвен дөрес билгеләгән хәлдә, без дискуссия барышында мәсьәләнең икенче ягына — әсәрнең социаль егәренә — азрак кагылдык. Югыйсә бу — әдәби әсәрнең коммунистик тәрбиядәге урынын билгеләүче төп критерийларның берсе. Ә дискуссиядә катнашучылар, әсәрләргә бәя биргәндә, еш кына башка критерийлар кулландылар. Кайберәүләр теге яки бу әсәрнең яхшы сыйфатлы булуына дәлил итеп аның үзәк нәшриятларда басылуын атадылар, икенчеләре — әсәрләрнең бөтенсоюз я бөтенроссия матбугатында телгә алынуын әйттеләр, өченчеләр — үз укучыларыбызның яратып укуы да бик җитә дигәнрәк фикер үткәрделәр...

Күрүебезчә, марксистик-ленинчыл әдәби тәнкыйтьнең төгәл критерийлары кайвакытта онытылып та тора икән һәм менә нәкъ шул чакта әдәби әсәрләргә төрле ташламалар ясау башлана. Әйтик, дискуссия барышында проза әсәрләребезнең ил күләм яңгыраш таба алмавын тәрҗемә сыйфатына кайтарып калдырырга тырышулар булды. Дөрес, тәрҗемә эшен оештыру зур әһәмияткә ия. Әмма сюжет кору осталыгы, әсәрдә күтәрелгән проблемаларның җитдилеге, характерларның гыйбрәтлелеге, конфликтларның кискенлеге тәрҗемә сыйфатына гына бәйле була алмый.

Нефтьчеләр, шинчылар, төзүчеләр, завод-фабрика эшчеләре турында язылган әсәрләргә тема хакына ташлама ясарга чакыручылар да күренде. Янәсе татар әдәбияты өчен производство сферасын өйрәнү — үзләштерү — яңа этап, «өйрәнчек этап, ташлама ясыйк, сукмик. Аңа таянып башкалар югарырак күтәрелерләр». Беренчедән, бу — яңа этап түгел, чөнки инде утызынчы еллардан башлап Ш. Камал, К. Нәҗми, И. Гази, Г. Әпсәләмов һәм башкалар үзләренең эшче сыйныф турындагы татар совет әдәбиятының классикасына кергән әсәрләрен яздылар. Моны инкяр итү — әдәбиятыбызның принципиаль казанышларын күрмәү булыр иде. Икенчедән, бүгенге укучы бездән иҗади разведка эзләрен түгел, ә фәкать җитлеккән әсәрләр генә көтә.

Дискуссия барышында еш телгә алынган «урта кул әсәрләр» мәсьәләсен дә кискенлектән качыбрак аңлатырга тырышу сизелде. «Урта куллылык» әдәбиятның нормаль халәте, дип тынычланырга чакыру да ишетелде. Әлбәттә, чынбарлык үзе ак һәм кара төстән генә тормаган кебек, әдәбият та бик яхшы һәм бик начар әсәрләрдән генә тора алмый. Әдәбият төрле-төрле сыйфатларны үзенә туплаган күп әсәрләрдән барлыкка килә. Авторларның да гражданлык өлгергәнлеге, таланты, әдәби осталыгы һәм, ниһаять, шәхесе төрле баскычта була. Бусы — иҗатның котылгысыз чынбарлыгы. Ләкин менә шушы төрлелектә иҗтимагый тормышка һәм әдәбиятка аз гына да яңалык бирмәгән, сән-

гать ягыннан түбән сыйфатлы язмалар да еш очрый. Беренче чиратта әнә шуларга юл ябылырга тиеш. Иҗтимагый һәм әдәби ихтыяҗ, әсәрнең политик һәм эстетик эффектлылыгы — әсәргә бәя бирүнең беренче нигезе.

Сөйләшүдә чыгыш ясаган бик күп авторлар дөрес күрсәтеп үткәнчә, биредә төп вазифаны әдәби тәнкыйть башкарырга тиеш. Әдәби әсәр хакында беренче сүзне иң элек ул — тәнкыйть әйтергә тиеш. КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумында да әдәби тәнкыйтьнең әнә шундый актив роленә басым ясалды. «Актив, сизгер, иҗади эзләнүгә игътибарлы марксистик-ленинчыл тәнкыйть — художество иҗатына йогынты ясауның төп методы»,— диелде анда. Бу сүзләр безнең чор әдәби тәнкыйте өчен эш программасы булып тора.

Проза әсәрләрен ил күләмендә укучы күзенә күрсәтү уңаеннан да әдәби тәнкыйтьнең ролен тагын бер мәртәбә ассызыклап үтү кирәк. Әдәби тәнкыйть лаек дип табылган әсәрне союз матбугатында талантлы итеп, әсәрнең иң уңышлы һәм көчле якларын алга куеп һәм актив рәвештә пропагандаларга бурычлы.

Эчтәлек һәм форма берлеге — марксистик-ленинчыл эстетиканың һәм әдәби тәнкыйтьнең иң мөһим принцибы. Әдәбиятның идеялелеге һәм гражданлык юнәлеше турында даими кайгыртучанлык күрсәтү аның сәнгатьлелеге, профессиональ культурасы хакында кайгыртудан аерылгысыз булырга тиеш. Шуның өчен дә әсәрләрнең сәнгатьчә эшләнеше безнең дискуссиядә дә игътибар үзәгендә булды. Беркемнән дә сер түгел, безнең проза әле бу яктан да сыната. Басылып чыккан күп әсәрләребез тиешле тәэсир көченә ия булмыйлар, аларда бәләкәй мәгънә зур күләм белән тора. Чорыбызның олы әдәбияты, сәнгате казанышларын өйрәнү, милли әдәбиятыбыз җирлегендә үзләштерү сүлпән бара. Сөйләшүдә катнашкан авторлар форма һәм эчтәлек арасындагы диспропорциянең кайбер сәбәпләрен дә күрсәттеләр. Әсәрләрнең сәнгать ягыннан йомшак булуы — әдәбиятка репортерларча килү, аны иллюстрацияләү чарасы итеп кенә карау нәтиҗәсе дип билгеләделәр. Бу сүзләрдә хакыйкать юк түгел, әлбәттә.

Дискуссиядә сүз өлкән һәм урта буын прозаиклар иҗаты турында барды. Яшь прозаиклардан берничә авторның исеме аталып кына үтте. Ә бит соңгы елларда газета-журнал битләрендә дә, китап булып та яшь язучыларның байтак әсәрләре дөнья күрде. Алар укучыда күпмедер өмет тә уяттылар. Ләкин яшь авторларның махсус тукталып сөйләшердәй, зур һәм мөһим мәсьәләләр күтәргән, әдәбиятыбызга яңалык алып килгән әсәрләре аз булу барыбызны да нык уйландырырга тиеш. Яшь иҗатчыларның иҗади һәм гражданлык ягыннан тизрәк өлгерүләренә ирешү — бүгенге татар совет әдәбияты алдында торган иң зур бурычларның берсе.

Алдарак әйтеп кителгәнчә, бүгенге проза турындагы бу сөйләшү укучыларда зур җанлану тудырды. Редакциягә әдәби әсәрләрнең, тулаем әдәбиятның нечкә хасиятләрен тоеп, аңлап язылган бик күп хатлар килде. Хат авторлары язучылар, әдәбият белгечләре белән бергә уртак мәсьәләләр өчен борчылдылар, уйландылар, татар совет прозасын үстерү юлында игътибарга лаек тәкъдимнәр керттеләр.

Әдәби бәхәстә катнашучыларның кайберләре тиешеннән артык кызыбрак китеп, шактый субъектив фикерләр дә әйттеләр. Дискуссия барышында андый җитешсезлекләрнең күбесе һәм принципиаль әһәмияткә ияләре башка авторлар тарафыннан төзәтелә килде.

Язучылар, әдәбият галимнәре һәм тәнкыйтьчеләр дискуссиядә актив катнаштылар. Шуның нәтиҗәсендә сөйләшү җитди профессиональ югарылыкта һәм дәлилле барды. Анда әдәби иҗатның һәм әдәби процессның күп кенә кызыклы, яңа яклары ачылды. Әмма, шул ук вакытта, безнең әдипләребезнең һәм иң беренче чиратта прозаикларыбызның активлыгы әле җитеп бетмәде дияргә дә урын бар. Укучылар бигрәк тә өлкән буын әдипләренең күбрәк катнашуын көткәннәр иде. Үзләренең бай тәҗрибәләреннән һәм күзәтүләреннән чыгып алар бүгенге татар прозасы өчен дә, әдәбият сөючеләр өчен дә кыйммәтле фикерләр әйтә алырлар иде. Мондый сөйләшүләрнең төп максаты әдәбиятны, хезмәт ияләренең эстетик аңын яңа биеклеккә күтәрергә ярдәм итү бит.

Һәм, гомумән, бу дискуссия барышында ачыкланганча, безнең язучыларыбызга үзләренең фикер һәм уй хәрәкәтчәнлеген, күңел активлыгын тагын да үстерү кирәк икән әле. Рухи яктан актив яшәү генә үсешкә китерә ала. Укучылар бик көткән югары сыйфатлы, тирән эчтәлекле әдәби әсәрләр дә иҗат кешесенең күңел активлыгы нәтиҗәсендә генә туа ала.

Әйе, бу сөйләшү уңаеннан, заман язучысының шәхесе алдында куелган таләпләр хакында да җитди уйланырга нигез бар. Ил, халык алдындагы җаваплылыкны тулы итеп, тирәннән аңлау җитәме? Ил, халык көткән иң мөһим сүзләр, фикерләр әйтеләме? Яңа заман, яңа чорның катлаулы тормышы алдында безнең прозаиклар ни дәрәҗәдә вәкаләтле? Бу сораулар яңа уйлануларга тарта.

Безнең чор язучыга гаять зур вазифа йөкли.

Бүгенге язучы — әхлак һәм матурлык тәрбиясе белән беррәттән, политик һәм идеологик тәрбия бирүче дә. Әнә шуңа күрә аның һәр әсәренең, һәр җөмләсенең, һәр сүзенең идеологик һәм эстетик егәре заман югарылыгында булырга тиеш.

Татар совет прозасы бүген яңа биеклекләр алдында тора. Алар — яңа чор тормышы куйган биеклекләр. Алар — катлаулы һәм үтә җаваплы заманыбызны тулы итеп һәм дөрес аңлау биеклекләре. Алар — тормышны халыкчан әсәрләрдә партияле итеп тасвирлап бирә алу биеклекләре.

Мондый югары үрләрне яулау өчен прозабызның потенциаль мөмкинлекләре зур. Проза өлкәсендә талантлы һәм югары гражданлык сыйфатларына ия булган әдипләр эшли. Алар өчен илебездә бөтен мөмкинлекләр тудырылган.

Татар совет прозасының киләчәктә яңа биеклекләр яулаячагына ышаныч зур!

**Редакция.**

## Илдар Юзеев

# КАЙТАВАЗЫ СЫМАН ТУКАЙНЫҢ

«Клячкин»да бала табу йорты...
Ник шул кадәр әле моңайдым?
Сабыйларның тавыш бирүләре
Кайтавазы сыман Тукайның.

Даһи затны югалтуы авыр,
Йөз елга бер туа торгандыр,
Тукай үлгән йортта бала елый:
Яңа Тукай, бәлки, тугандыр.

Җыр да шулай авыр, үксеп туа...
Тыңлап торам сабый тавышын.
Кем мәңгелек җырга әйләндерер
Гасырларның бөек сагышын?

Югалтулар аша туа-туа,
Киләчәккә кыю, нык атла,
Тукаеңны иртә югалтсаң да,
Тукайлыкны берүк югалтма!

«Клячкин»да бала табу йорты...
Ник шул кадәр әле моңайдым?
Сабыйларның тавыш бирүләре
Кайтавазы сыман Тукайның...

## Виктор Тельпугов

# БИШ МИНУТ

хикәя

Авыр яралардан һәм агуланган пуляларны алу операцияләреннән соң Ленинның сәламәтлеге бераз яхшыра башлаган иде. Әмма 1922 ел ахырында ул яңадан начарланды. Тагын баш авыртуы башланды, аны йокысызлык интектерде. Кайчандыр көчле булган организм хәлсезләнде. Моны барысы да күреп торды, әмма беркем дә моның белән килешергә теләмәде. Барыннан да бигрәк, әлбәттә, Ленин үзе килешмәде — начаррак булган саен, ул авыруына каршы тырышыбрак көрәште. Дулкынланырга — укырга, язарга, кешеләр белән очрашырга ярамый иде аңа. Ә ул исә, врачлар сүзенә дә карамастан, эшләргә ашкынды. «Яхшырак» булмаган һәм хәтта булырга мөмкин түгел көннәрдә дә:

— Миңа бүген яхшырак! — дип белдерде ул катгый төстә.

Шунда ук тиз генә берәр китап китерүне, я кичекмәстән кем беләндер телефон аша тоташтыруны үтенү башлана иде. Соңгы атнада гына да бу берничә тапкыр кабатланды инде. Бүген дә шулай булды.

— Үзегезне ничек хис итәсез, Владимир Ильич? Яңа порошокларымнан соң әйбәтрәкме сезгә? — дип сорады врач, иртә белән Ленин янына кергәч.

— Рәхмәт, доктор, әйбәтрәк! Сезне күргәч, үземне терелгәндәй хис итәм.

— Бик, бик шатмын, Владимир Ильич! Ифрат та шатмын! — диде врач, Ленинның кулын тотып. Ул көмеш кесә сәгате «Лонжин»ның капкачын шыртлатып ачты һәм бөтен игътибарын аның секунд угына туплады.— Димәк, миңа монда ешрак керергә кирәк икән. Мин, Владимир Ильич, бик тә рәхәтләнеп вакытлыча бу бүлмәгә күчәр идем. Сезнең белән безгә алай ук күп урын кирәкми ич, дөрес бит? Әнә теге стена буена кечерәк кенә карават та куярга була. Ризамы сез?

— Һич кенә дә риза түгел, доктор! Мөмкин булмаган эш бу.

Врач гаҗәпләнде:

— Мин сезгә комачаулык итмәс идем, Владимир Ильич. Үземне бик тәртипле тотар идем, тыным да чыкмас иде.

— Сез комачауламас идегез анысы, киресенчә, мин комачаулар идем. Үзем дә йокламыйм, кешеләргә дә тынгылык бирмим.

— Бүген тагын начар йокладыгызмыни? — дип сорады врач, болай да төннең йокысыз, тынгысыз үтүен белсә дә.

— Нәкъ менә бүген яхшырак булды. Бигрәк тә иртәнгә таба. Дүрт туларга чирек сәгатьтә төш күрә идем инде...

Ленин үзенең кирәкмәгән сүз ычкындыруын абайлап алды. Әгәр дә кеше үзенең кайчан йоклап китүен төгәл минутына кадәр белә икән, аның йоклавы, гомумән, икеле.

Әмма врач үз пациентының ялгышын сизмәмешкә салышты һәм хәттә аның кәефен күтәрергә тырышты:

— Әйтәм аны йөзегез бүген бөтенләй бүтән, кичәгегә яки өченче көнгегә һич тә охшамаган. Ошыйсыз сез миңа, Владимир Ильич.

— Ә пульс? Шактый тиз үзгәрә торган бу «иптәш» үзен ничегрәк тота?

— Пульс та әйбәтрәк. Кая, ышанычлырак булсын өчен, тагын бер кат тикшерик әле.

«Лонжин»ның көмеш капкачы тагын шыртлады һәм елык-елык килде. Ленин яңадан рухландыргыч сүзләр ишетте:

— Мин канәгать сездән, Владимир Ильич. Бу мизгелдә чынлап та ошыйсыз сез миңа.

Чак сизелерлек елмаю Ленинның аксыл яңагын яктыртып җибәрде.

— Безнең бер-беребезгә булган бурычларыбыз бетте, доктор,— диде ул.

— Аңламыйм, Владимир Ильич,— дип ачыктан-ачык әйтте доктор.

— Сез дә миңа ошыйсыз. Сез бүген һичкайчан булмаганча гүзәл, доктор. Киләчәктә сезнең барлык боерыкларыгызны колларча үтәрмен.

— Ә нигә «колларча?» — дип сорады врач.— Хәзер бездә коллар юк, Владимир Ильич.

Ленин бик аз гына вакытка уйга калды, моңсу, шул ук вакытта тантаналы карашлы күзләрен врачка текәде:

— Бу сүзләрне сезнең — партиясез интеллигентның, миңа — профессиональ революционерга әйтүегез бик шәп! Шәп! Әмма сезгә сер итеп кенә әйтергә тиешмен — шулай да Россиядә бер кол калды. Ул — мин — сезнең күндәм хезмәтчегез. Боерыгыз, доктор, мин тулысынча сезнең карамакта.

Мондый сүзләрне ишеткәч, врач табигый рәвештә авыруның чираттагы һөҗүменә әзерләнде һәм ялгышмады. Тик һөҗүмнең шундый туктатып булмаслык көчле һәм бернинди әзерлексез-нисез башлануын гына көтмәгән иде ул.

Ленин хәзер инде үзенең ярым моңсу, ярым тантаналы карашын врачтан алмады. Врач авыруның сорауларына көч-хәл белән генә җавап бирергә өлгерде.

— Доктор, минем пульсның тагын да яхшырак булуын телисезме? Кичәгегә, өченче көнгегә караганда да яхшырак булуын?

— Әлбәттә, кадерле Владимир Ильич, әлбәттә.

— Ә үз пациентыгызның азмы-күпме яхшырак йоклавын?

— Беләсез ич, нәкъ шул хакта хыялланам һәм кайгыртам бит.

— Бик тә шәп! Алайса, мине яхшылап тыңлагыз, доктор. Тик үзегезнең трубкагыз аша да, «Лонжин» ярдәмендә дә түгел. Аларга беркайчан да тулысынча ышанырга ярамый. Кешене кеше тыңлаганча тыңлагыз. Шул хакта үтенә аламмы мин?

— Әлбәттә, Владимир Ильич, әлбәттә...— дип элеккечә чын күңелennән, әмма тотнаклырак итеп җавап бирде доктор.

— Әйдәгез, болай килешик. Мин сүзегездән чыкмыйча дәваланыйм, ә миңа эшләргә ирек куелсын. Даими, әзлекле рәвештә. Әйе, әйе! Алай гаҗәпләнеп карамагыз. Бик кыска гына вакыт булса да, көн саен эшләү хокукын таләп итәм. Ул чакта бар авыруым тизрәк бетәчәк, ышандырам сезне, доктор.

— Нәрсәне күз алдыгызда тотасыз сез, Владимир Ильич? — Врачның сәгать тагып йөри торган чылбыры шунда бөтәрләнеп алды, әйтерсең лә, авыруның сүзләре аны да гаҗәпкә калдырды.

— Китаплар китерәләрме сезгә? Телефоннан сөйләштерәләрме?

— Қитерәләр, сөйләштерәләр, рәхмәт! Әмма мин тагын да активрак эшләргә тиеш. Һәм бу мөмкинлекне бирәчәксез сез миңа, доктор. Шулай булмаганда, сезнең барлык даруларыгыз...

Фикер әйтелеп бетми калды, әмма шул ук вакытта бөтенесе дә әйтелгән иде инде.

— Нәрсә бу, ультиматуммы? — дип сорады гаҗәпләнеп калган врач һәм, җавапны көтеп тә тормастан, үзенең соравына үзе җавап бирергә мәҗбүр булды: — Ультиматум. Мин сезне аңладым, Владимир Ильич.

— Аңлагансыз икән, риза булыгыз! — дип тыныч кына, әмма кискен итеп әйтте Ленин.

— Нәрсәне күздә тотуыгызны аңладым мин,— дип ачыклады врач,— әмма үтенечегезне әлегә канәгатьләндерә алмыйм, Владимир Ильич, хакым юк.

— Алайса, безнең сөйләшүләр нәтиҗәсез тәмамлана, кызганыч — безнең килешә алуыбыз да ихтимал иде.

Ленин врачка катгый таләп белән әдәпле генә үтенеч катыш, хәтта ялварулы караш ташлады. Врачка болай диде:

— Шундый вак-төяк өчен дуслыкны бозып, киреләнеп торырга ярыймы соң инде?

— Ничек инде ул «вак-төяк»? Вак-төяк түгел бу, Владимир Ильич.

Врачка әйтеп бетерергә ирек бирмичә, Ленин юрган астыннан бармаклары ныклап кысылган кулын чыгарды. Бу хәрәкәт аңлашыла иде, шулай да Ильич аны тәфсилләп аңлатырга керешә:

— Биш минут, доктор. Көненә барысы биш минут, аңлыйсызмы? Би-иш! Тагын да җитдирәк таләпләр куймас борын, килешегез. Кисәтеп куям: тагын да җитдирәкне!

«Тагын бер ультиматум,— дип уйлады врач.— Рәттән ике ультиматум күбрәк түгелме соң? Күбрәк. Моның белән генә чикләнерме әле! Бәләкәй генә ташлама ясамый булмастыр ахры».

— Биш минут, дидегезме? Мин сезне дөрес аңладыммы, Владимир Ильич? Әйткән сүз — аткан ук, төгәл биш минут!

— Дөрес, доктор, баштарак биш минут кына булса да үтенәм сездән.

— Монысына, мөгаен, ризалашмый булмас, Владимир Ильич. Тик исегездә тотыгыз: бер генә минутка да артык түгел, бары биш кенә минут. Анысы да искәрмә төсендә генә. Һәм, зинһар өчен, бернинди дә «тагын да җитдирәк таләпләр» куймагыз, Владимир Ильич. Мин бит тимер түгел.

— Тимер түгел,— дип килеште Ильич.— Бары тик әйбәт, бик әйбәт кеше. Рәхмәт сезгә, доктор, бик зур рәхмәт!

Бүлмәдә тынлык урнашты, шундый тын, хәтта «Лонжин»ның йөрүе дә ишетелә башлады.

Тынлыкны беренче булып һич тә көтелмәгән сорау белән Ленин бозды:

— Ә кайчан башларга мөмкин, доктор? Минем эшләр бик күп җыелды һәм барысы да бик тиз эшләнергә тиешле.

— Соң, һич югында бүген түгел инде, Владимир Ильич, сез арыдыгыз, мин бит күреп торам. Хәтта мин дә тирләп чыктым әле.

— Азрак бәхәсләшкән булсак, эш өчен көчебез күбрәк калыр иде, доктор.

— Димәк, барысы өчен дә стрелочник гаепле? Шулай килеп чыгамы, Владимир Ильич?

— Икебез дә гаепле. Икебез дә, доктор. Һәм икебез бергәләп төзәтик тә. Тыңлагыз, сезгә үземнең планымны ачып салам. Мин монда «Правда» өчен бер мәкалә язам. Берничә көн рәттән инде...

— Мәкалә?..— дип аптырап сорады доктор.— Кайчан язасыз?

— Күпчелек төнлә белән, сестра уяулыгын югалтканда, яки йокы килмәгәндә. Дөрес, бүген бөтенләй аз яздым.

— Дүрт туларга чирек сәгать калганчы языпмы? — дип шелтәләп алды врач.— Әйтеп бетерегез инде. Сезгә рөхсәт ителмәгән иде ич.

— Дөрес, ителмәгән иде. Мин дә сезне сүзегездә тотам, доктор. Иде! Ә хәзер миңа әйбәтрәк. Сез бит үзегез рөхсәт иттегез. Шуңа күрә язам да. Башымда, әлбәттә.— Ул тагын юрган астыннан кулын чыгарды.— Ә хәзер миңа, зинһар өчен, стенографистканы чакырыгызчы.

Врач авыру алдында тагын бер тапкыр чигенде. Әмма үтә дә сак чигенде. Стенографистканы чакырырга ризалык биргәнче:

— Материал яшерен түгелдер дип уйлыйм, Владимир Ильич? — дип сорады.

— Менә шунда да шул хикмәт — яшерен. Бик тә яшерен, доктор...

— Сез бит мәкаләне әйтеп яздырам, дидегез. Яшерен мәкаләләр буламыни?

Ленин уңайсызланыбрак калды, әмма бу бер мизгелгә генә сузылды.

— Беләсезме, доктор, кайчакта булгалый. Беренче вариантында. Шулай булгач, әйтеп яздыра башласам, сез мине гафу итәрсез инде...

— О, аңлашыла, аңлашыла, Владимир Ильич! — диде врач, һәм мәгънәле генә итеп кулына «Лонжин» чылбырын алды. Янәсе, бүлмәдән чыгуын чыгармын анысы, тик белеп торыгыз, шушыннан бер генә адым да китте юк. Чылбырга бәйләп куелгандай утырачакмын ишегегез төбендә.

Авыру тирән итеп сулап куйды. Әмма төгәлрәк әйтсәк, ул тантана итә иде: кечкенә генә булса да тагын бер җиңү бит. Биш минуттан соң ун минут, ун минуттан соң ярты сәгать үк була бит ул вакыт дигәнең. Иң мөһиме — эш бүген үк, хәзер үк башланачак.

Берникадәр вакыттан соң Ленин янына стенографистка килеп керде. Чак кына шыгырдаган ишекне ябып, врач бүлмәдән чыкты.

Озакламый ишек яңадан ачылды — бусага төбендә үзсүзле доктор басып тора иде.

— Булды, Владимир Ильич. Булды, булды, булды. Әйткән сүз —аткан ук.

Стенографистка кәгазьләрен җыйды һәм саубуллаша башлады:

— Сау булыгыз, Владимир Ильич. Сау булыгыз, доктор.

— Иртәгә кадәр,— дип төгәллек кертте Ленин һәм иртәгә әле бәлкем беразозаграк та эшләячәкләрен әйтте.

— Мин шуңа исәп тота аламмы, доктор, әллә юкмы?

— Төгәл берни дә әйтә алмыйм,— дип җавап бирде тегесе.— Бөтенесе сезгә, кәефегез ничек булуына бәйле, Владимир Ильич.

— Хәлем яхшы, йокым әйбәт, пульсым тигез һәм тулы көчендә булачак,— дип ышандырды врачны авыру. Һәм стенографистканың чыгып китүен көтеп торгач, болай дип өстәде: — Сез шундый кече күңелле булсагыз һәм миңа оста да җибәрсәгез бигрәк тә...

— Нинди оста? — дип гаҗәпләнде врач.— Кайчан һәм нигә?

— Гап-гади балта остасын. Һәм бүген, нәкъ менә бүген үк. Минем аңа бер үтенечем бар.

— Берни аңламыйм, Владимир Ильич. Аңлатып бирегез әле, зинһар, мин фәкыйрегезгә.

— Бөтенесе гап-гади, доктор. Иртәгә иртән стенографистка тулысынча язылган текст белән киләчәк. Текстны укырга кирәк. Менә шул чак миңа ноталар кую өчен пюпитр кебегрәк бер нәрсә кирәк булачак. Язылган битләрне шуңа куям да төзәтәм, һәм эшне дәвам иттерәбез. Мин инде аның конструкциясен дә уйладым.

— Тик мин бит әле белмим — сезгә эшләргә рөхсәт итәрменме, юкмы? — дип каршы төште врач.— Анысы әле, кабатлап әйтәм, бик тә, бик тә зур сорау астында, Владимир Ильич. Бүген бары тик искәрмә генә ясалды.

Авыруның кулы тагын юрган астыннан чыкты. Аның бармаклары элеккечә үк ныклап кысылган иде.

— Без бит килештек инде, доктор. Көненә биш минут — әллә күпме шул?

— Күп, Владимир Ильич. Сезнең өчен әлегә күп.

— Күрәсезме: ә-ле-гә, ягъни бүгенгә күп. Димәк, иртәгә тап-таман булачак. Ә берсекөнгә — бигрәк тә! Логика бармы?

— Бөтен сөйләшүегездә бернинди логика күрмим, Владимир Ильич. Мин бертуктаусыз сезгә юл куям, урынсызга килешәм.

Врач ышанычсыз төстә кул селтәде.

— Димәк, ризасыз? Чакырасызмы останы? Хәзер үкме? Кичекмәстәнме? Рәхмәт, доктор, бик зур рәхмәт! Сезне күргәч тә кәефемнең күтәрелеп китүе, хәлемнең яхшыруы, күпкә яхшыруы тикмәгә генә түгел икән. Бик тә шәп!

— Сез миңа бу хакта әйттегез инде, Владимир Ильич. Мине алай еш һәм алай нык мактарга ярамый — үзем турыда, кәперәеп китеп, әллә ниләр уйлавым бар.

— Рәхәтләнеп уйлагыз, доктор. Уйлагыз! Әгәр сезне мактыйм икән, димәк, моның сәбәпләре бар. Ышаныгыз, докторларга хас кайбер нәрсәләрне аңлый башладым мин. Бигрәк тә соңгы вакытларда...

Русчадан **Миргалим Харисов** тәрҗемәсе.

# Гомәр Бәширов

# КӨЗГЕ АЧЫ ҖИЛЛӘРДӘ

ПОВЕСТЬ-ИСТӘЛЕК

## XIII



Мондый кешеләр очраткан саен, зур ачыш ясаган кебек, чын күңелдән сөенә идем. Кичләрен колхоз идарәсенең шәп-шәрә бүлмәсендә, тоныкк кына керосин уты яктысында шулар турында дәртләнеп очерклар язасың. Иртәгесен таң белән, нәкъ колхозчылар торганда, уянасың да, кызык һәм дәртле тормыш белән яшәүче яхшы кешеләрне очратасы килеп, яңадан кырга, фермага, бригадага, звеноларга чыгып китәсең.

Минем «Соңгы сугышу» дигән өйрәнчек әсәремне язарга да әнә шулай колхозларда йөргән вакытта иешеткән, тормышның үзендә булган сәер генә бер вакыйга нигез итеп алынган иде.

1933 нче елның җәй башындарак булса кирәк, без өч журналист, бер шагыйрь — Фатих Кәрим, «Азат хатын» журналының редакторы Гөлчирә ханым Гафурова, «Фото-Гали»[1] һәм мин «Азат хатын» эше белән Балтач районына барган идек. Колхозларда йөргәндә бер егетнең басуда үз энесен кыйнап ташлавы турында ишеттек. Әллә ни искитәрлек хәл түгел, гади генә бер кыйнашу булса, без аны колак яныннан гына уздырган булыр идек. Хикмәт тә шунда иде шул: егет энесен колхоз җирен сөргәндә чи калдырган өчен кыйнаган!

Моңарчы ишетергә туры килмәгән, уйландыра торган гаҗәбрәк яңалык иде бу. Моны безгә җиткергән авыл кешеләре үзләре дә ничектер сәерсенебрәк сөйләделәр. Үзара ызгышып алу, кызларны «бүлешә алмыйча» көнчелектән бәргәләшеп алулар, яшьрәк егетләр арасында булгалый торган хәл. Әмма колхоз җирен чи калдырган өчен...

Моны ишеткәч Фатих Кәрим дә, кара күзләрен кыскалап, беравык үзалдына көлемсерәп йөрде. Бераздан миңа дәште.

— Сизәсеңме, сәер бит, әй!— диде. Тагын беравык башын чайкап йөрде дә миңа сөаль бирде.— Болай фикер йөртеп карыйк әле. Әйтик, әгәр энесе колхоз җирен түгел, үз җирләрен чи калдырган булса? Ул чагында да кул күтәрер идеме икән? Ничек синеңчә?

---

Ахыры. Башы 3 санда.

[1] «Кызыл Татарстан» газетасының фотографы Ибраһим Галиевне шулай дип йөртәләр иде.

Моңа ансат кына җавап бирү мөмкин түгел иде.
— Нинди егеттәр бит. Араларынданиләр булгандыр. Күреп сөйләшмичә әйтүе кыен,— дидем мин.
Бераздан ул тагын минем яныма килде. Юкка гына кызыксынмыйдыр, берәр нәрсә язарга нияте бардыр дип уйладым.
— Беләсеңме, бу бит игенче психикасында үзенә күрә бер яңалык. Моның артында тагын да бүтән бер тирәнрәк нәрсә юкмы икән?.. Әйдә барып кайтыйк авылына!
Ул авыл ерак түгел иде. Ат җиктердек, чыгып та киттек. Без ул егетне сабан сөргән җире өстендә барып таптык. Егерме ике яшьләр тирәсе булыр, таза бәдәнле, авыррак холыклы бер егет икән. Егетебез сүзгә ифрат саран булып чыкты. Ниләр генә эшләмәдек сөйләштерер өчен! Шаян сүзләр белән көлдерергә дә тырышып карадык, башка юллар белән дә телен ачарга тырыштык. Ләкин егетнең теле ачылмады.
— Бәлки энең сөйгән кызыңа сүз салгандыр, каш сикерткәндер? Шул кытыгыңа тигәндер?— диде Фатих.
Егет башын гына селекте.
Фатих аның каршысына утырып:
— Әллә энең синнән алданрак өйләнергә чамалыймы? Шуны сиздеңме?— диде.
Егет кычкырып көлде генә.
— Берәр ачуың бар идеме әллә?
— Юк ла...
Без сорауны аның саен үҗәтләнебрәк дәвам иттердек.
— Соң, тиктомалга энекәшкә кул күтәрмиләр инде. Булган инде сәбәбе, булган. Әйтмисең генә!
— Әйтәм ич җирне бозды дип...
Фатих миңа карап күз кысып алды.
— Исең киткән икән! Үз җирең түгел лә!
Егет бераз сүзсез утырды да кырыс кына:
— Булса соң!— диде. Уйланып утыра торгач.— Ә ояты?— дип куйды.
Иптәшләр янына кайткач Фатих әлеге егетнең ничек җавап бирүе турында сөйләп көлдереп тә алды. Гомумән, ул юморга бай кеше, көләргә бик ярата, анда артистлык таланты да бар иде.
Мин ул хакта уйламый башлаган идем инде. Фатих исә икенче авылдагы бер танышы белән телефонда сөйләшкәннән соң кинәт «Телефон» исемле шигырь язу белән мавыгып китте.
Шулай да әлеге егет вакыйгасы, күрәсең, аңа тынгылык бирмәгәндер, кайтыр юлга чыккач янә шуны кузгатты.
— Карале, Гомәр, синең каләмең ярыйсы гына шомарып килә. Әллә язасыңмы шул хакта берәр хикәя?
— Хикәя? Очерк түгелмени?
— Юк, хикәя! Материалы шундый.
Мин инде бу хакта Фатих мөгаен үзе язар дигән фикергә килгән идем. Чөнки Ф. Кәрим егерменче елларның ахырында ук китап чыгарган кеше. Соңгы елларда «Җиденче мич» дигән әсәре белән ул талантлы шагыйрьләрнең берсе булып танылып килә иде. Мин аннан узып язарга кыенсындым.
— Ә үзең язсаң?— дидем.
Фатих башын чайкады.
— Минем уйлаган әйберләрем бар. Миңа шигырьдән аерылуы да кыен булыр,— диде.
— Аның каруы синең тәҗрибәң баерак.
— Шулай да... Проза бөтенләй башка дөнья бит ул. Син бүтәннәр кебек шигырьдән түгел, башта ук прозадан башладың. Син яз.
Мин икеләнә идем әле.

— Булдыра алырмын дип уйлыйсыңмы?

— Әгәр чынлап тотынсаң! Бу проза материалы. Монда элекке игенченең хосусый милекчелек тойгысыннан ничек арына баруын күрсәтергә мөмкин. Инде көчең җитүгә килгәндә... Бала кайчан да булса бер тәпи басарга тиеш бит! Беренче адымнарын атлаганда аның ялгыш кына егылып китүе дә гаҗәп түгел!

Фатих тагын бер рәхәтләнеп көлде. Миңа аның шулай һич рыясыз, чын күңелдән иркенләп көлүе бик ошый, аңа ияреп хәтта кәефең болытлырак чагында да ихтыярсыз үзең дә көлеп җибәрә идең.

Уйланып йөри торгач, яздым мин ул хикәяне. Исемен «Соңгы сугыш» дип куйдым. Хикәядә тымызык колләр дә, минем күңелгә хуш килгән романтик төнге уйланулар да, комсомол егетләр белән комсомолка кызлар да — һәммәсе дә бар иде. Шулай да уйлаганча ук тирән әйбер булып чыкмавын сиздем. Мин бу хакта Фатихка да әйттем!

— Язуын яздым, тик соңгы ноктасын куйганнан соң хикәя үзенә ошамый башлады,— дидем.

Ул елларда Фатих Кәрим Татарстан китап нәшриятының яшьләр-балалар әдәбияты секторында редактор булып эшли иде.

— Укып карыйк әле,— диде.

Берәр атнадан ул миңа:

— Хикәяң басарлык, минемчә,— диде. Актаргалап утырды да берике җөмләне төзәтергә кирәген әйтте.— Теге, язып бетергәч ошамый башлады диюең... Андый үкенү синдә генә түгел, барыбызда да була. Башта шундый дәртләнеп язасың, ә соңыннан язган нәрсәңне күрәсең дә килми башлый. Инде исеме дисәк... минемчә, аңа бер генә хәреф өстисе бар. Әйдә «Соңгы сугышу» булсын!— диде.

Бер генә хәреф өстәлде, сүзнең мәгънәсе үзгәрде дә куйды! Чыннан да, сугышлар әледән-әле булгалап тора. Ә Балтач егетенең бу, бәлки, энесе белән соңгы тапкыр сугышуы булгандыр?

Хикәя аерым китап булып басылып чыккач, мин аны Нәби Мансуровка бүләк иттем. Ул әсәрне ошатуын әйтте. Шулай да:

— Очерк сыманрак язылган икән,— диде.

Бу, аңлаган кеше өчен «әсәрең нәфис әдәбият дәрәҗәсенә үк күтәрелеп җитмәгән икән» дигән сүз иде. Билгеле, үзем ихтирам иткән кешедән хикәягә карата уңайрак фикер ишеткәндә күңеллерәк буласы иде дә бит... Нихәл итмәк кирәк? Нәби ага турысын әйтә торган рыясыз, гадел кеше иде, мин аңа ышана идем. Әсәремнең ни дәрәҗәдә булуын белгәнлектән, шуннан артыкны үзем дә өмет итмәдем.

Матур әдәбият дөньясына килеп керер алдыннан миңа тагын бер баскыч үтәргә туры килде. ВКП(б) өлкә комитетының карары белән бер төркем язучылар Казанда ачылган көндезге марксизм-ленинизм институтына укырга кабул ителде. Бу төркемдә М. Әмир, Г. Мөхәммәтшин, Р. Ильяс, Ләбиб Гыйльми, Н. М. Елизарова, Н. Баян, мин, тагын берничә кеше бар иде. Без институтның аспирантурага хәзерлек бүлегендә махсус программа буенча ике ел дәвамында башлыча гуманитар фәннәр өйрәндек. Безгә ана телен профессор Мөхетдин ага Корбангалиев, рус телен профессор Брюханов, көнбатыш әдәбиятын профессор Линцер, татар әдәбиятын һәм фольклорны профессор Х. Бәдигый, тарихчы галим һәм язучы профессор Газиз Гобәйдуллин укыттылар. Институтның әдәби түгәрәгенә профессор Г. Нигъмәти җитәкчелек итә иде. Институт миңа үзлегемнән укып алган белемемне билгеле бер тәртипкә салырга һәм тагын да тирәнәйтергә ярдәм итте.

Мине «Совет әдәбияты» журналының җаваплы секретаре итеп билгеләделәр. 1936 елның декабре иде бу. Менә мин салкынча бер кышкы

иртәдә — тюлень тиресеннән тегелгән саргылт түстәге калын тун кигән бер кеше — салмак кына атлап Матбугат йортының бишенче катына менеп барам. Бу минем редакциягә беренче мәртәбә эшкә килүем. Билгеле, дулкынланам. Ниләр көтә мине? Әгәр минем күңелемдә бала чакта ук шундый хөрмәтле урын алган бу әдәбият кешеләре чын тормышның үзендә «алай» булып чыкмасалар? Ул чагында минем якты хыялларым җимерелеп төшәчәк иде.

Бәхеткә каршы, язучылар турында элек мин ялгыш фикердә булмаганмын, редакциядә эшләүче язучыларның күбесе, чыннан да, талантлы, зур белемле, киң мохитлы, үзләре сайлаган мораль принциплар буенча яшәүче акыл ияләре иделәр. Шулай итеп, язмышымның хикмәтле «шаяруы» нәтиҗәсендә, мин татар әдәбиятының нәкъ үзәгенә, әгәр шулай әйтергә яраса, аның «кухня»сына, танылган әдипләр һәм шагыйрьләр арасына килеп кердем. Бу үзе бер мәктәп булды. Редакциядә мин татар совет әдәбиятының ул елларда иң актив эшлеклесе, заманына күрә зур белемле тәнкыйтьче Гомәр Гали белән, ул вакытта ук танылган талантлы шагыйрь Хәсән Туфан белән бергә эшләдем. Ул чагында халык яратып укый торган бай телле, ифрат үзенчәлекле язучы һәм әдәбият галиме Гумир[1] Толымбайский, галим һәм әдип Фатих Сәйфи-Казанлы, Шәриф Камал, Галимҗан Нигъмәти һ. б. белән журнал редакциясендә аралашырга, теге яисә бу әдәби әсәр хакында киңәш итәргә, редколлегия утырышларында һәм җыелышларда аларның төпле фикерләрен ишетергә туры килә иде. Бу иптәшләрне мин зур ихтирам белән искә алам, аларны тере итеп күз алдына китерәм, тавышларын ишеткәндәй булам.

Ул вакытларны ничек дулкынланмыйча искә төшерәсең? Бердән, ул минем матур әдәбият дөньясына яңа гына аяк баскан, якты идеаллар белән рухланып, тормышның бу яңа юнәлешендә үз-үземне табарга, ниһаять, җитдирәк әсәрләр язарга омтылган чагым иде. Икенчедән, чоры нинди иде бит әле аның! Егерменче еллар, утызынчы елларның башы һәм уртасы татар совет әдәбиятының ифрат катлаулы чоры, эзләнүләр, яңалыкка омтылулар чоры. ВКП(б) Үзәк Комитетының әдәбият турындагы махсус карарыннан соң төрле якка тайпылулар һәм ялгышулардан арына бару чоры иде.

Журналга керәчәк әдәби әсәрләрнең зурларын, җитди мәсьәләләр күтәргәннәрен редколлегия утырышына куеп күмәк рәвештә фикер алышу кебек яхшы гадәт бар иде. Кайчагында шул фикер алышулар бик тирәнгә кереп китә, теге яки бу жанр, әдәби агымнар кебек әдәбиятның гомуми мәсьәләләре хакында кайнар бәхәскә дә әйләнгәли иде. Кайбер укучыларда шундый сорау туарга мөмкин: нинди бәхәс? Нәрсә турында шулкадәр кызу бәхәс ачарга? Эш шунда ки, ул елларда яңа аякка басып, яңа гына ныгып килүче совет әдәбиятының иҗат агымнары, гомумән, әдәбият фәне хәзерге кебек барлык нечкәлекләренә кадәр җентекләп өйрәнелеп җитмәгән, күп кенә теоретик мәсьәләләрне ачыклыйсы бар иде әле. Шул ук әдәби мираска да төрле караш яшәп килде. Борынгыдан калган бай әдәби мирастан ни рәвешле, ничек файдаланырга, аның кайсы өлеше социализм төзелеше таләпләренә җавап бирәчәк, кайсы әдип яки шагыйрь мирасыннан ваз кичәргә туры киләчәк? Алдарак язганымча, ул вакытта Фатих Әмирханны буржуаз язучысы дип танучылар да юк түгел иде әле.

Журналга тәкъдим ителгән һәрбер җитди әсәргә гомуми караштан чыгып бәя бирелә иде. Фәлән әсәр хәзерге әдәбиятка берәр яңалык өстиме, әллә элеккеләрне генә кабатлыймы? Бу әсәрдә нинди яңа образ, яңа агым, яңа сүз бар? Ул чагында ук шагыйрьләрнең, шигырь сөючеләрнең кумирына әверелгән Хәсән Туфан шигырь уку ритмына

[1] Г. Толымбай үз исемен Гумир дип яза иде.

яшь авторның кулъязмасын селки-селки анда кабатланмаган оригиналь образ, тирән философик фикер барлыгын расларга керешә. Зур белеменә, озак еллар әдәбият укыту тәҗрибәсенә таянып, сабыр холыклы Галимҗан Нигъмәти үз фикерен әйтә. Шәриф абзый да үз сүзеннән тиз генә кайта торган затлардан түгел: Фатих Сәйфи-Казанлы исә, гомумән, бәхәсне бик яратыр иде. Ул да түгел, күп мәсьәләгә ирония белән карарга, инкарь итәргә яратучан Г. Толымбай арлы-бирле йөренгәләп кычкырып көлеп җибәрә. Кайчакларны бу сүз көрәштерүләр шундый кызып китkәли, Гомәр Гали карандашы белән абажур кырыена суккалап бәхәсләшүчеләрне тынычландырырга мәҗбүр булыр иде.

Кыскасы, бу кешеләр талантлы авторларның һәр яңа әсәрләренә чын күңелдән куана беләләр, андыйларга журналда киң юл ачалар иде.

Менә шундый бәхәсләр кайчакларны ярты төнгә кадәр сузылгалый, тынып калган Казан урамнарыннан мин шул хакта юл буе уйланып кайткалый идем.

Аннан соңгы елларда мин матур әдәбиятның халык тормышында нинди әһәмиятле урын тотуы, аның эстетик тәэсиренең халыкта әдәп, әхлак тәрбияләүдә башка берни белән дә алыштырып булмый торган зур көч икәнлеге хакында күп нәрсә белдем. Бу хакта союз күләмендәге съездларда, фәнни конференцияләрдә исемнәре бөтен дөньяга танылган зур галимнәр, язучылар фикерен дә ишеттем. Ләкин болар барысы да соңыннан килеп өстәлделәр. Сәнгатькә, әдәбиятка кайнар мәхәббәт, бөек ихтирам, алар халыкның рухи дөньясында могҗизалар тудырырга сәләтле дип инану, әдәби иҗат белән эш иткәндә саф вөҗданлы, пакь куллы булу мәҗбүрилеге — болар барысы да һичбер җилләр-давыллар җимерә алмастай катгый һәм нык әхлак кагыйдәләре булып минем күңелемдә әнә шул кечкенә бүлмәдә ныгып калдылар.

Ул елларда әдәбият оешмалары башында баручы иптәшләрнең хәзерге коллегаларныкы кебек, «фән докторы», «атказанган...» дигән зур дәрәҗәле исемнәре дә юк иде, хәзерге заман белән чагыштырганда, билгеле, белемнәре дә бик үк тирәннән булмагандыр. Әмма алар идеалларына бирелгәнлек җәһәтеннән чыныккан, нык кешеләр иде. Бу иптәшләр шәхси тормышларын онытып бу авыр һәм җаваплы йөкне үз өсләренә алдылар, аңа фидакарьләрчә бирелгән хәлдә, бөтен көчләре белән яңа әдәбиятны замана таләбе югарылыгына күтәрергә тырыштылар.

Безнең редактор Г. Гали болай карап торуга бераз кырысрак холыклы кешегә охшый төшә иде. Кайвакыт ул якын танышлары янынннан да исәнләшмичә узып китә, биргән сәламеңә дә баш кагып кына җавап биргәли иде. Аның үзенең дә зарланганы бар:

— Уйланып барганда исәнләшмичә узуым өчен миңа гөрбиян исеме тагучылар да булды. Нишлим соң? Холык, холык! — дигән иде.

Асылда исә ул андый түгел иде. Г. Гали заманында талантлы яшь язучыларга чын күңелдән ярдәм итеп, аларның беренче әсәрләрен матбугатта чыгаруны кайгыртучан кеше иде.

Хәсән Туфан үзенең беренче китабы ничек басылып чыгуы турында шундый хәл сөйләгәне бар. Ул яшьлек елларында Урта Азия һәм Кавказ якларына бер-ике елга сәяхәткә чыгып киткән. Кайда эш туры килә, шунда эшкә ялланып озак йөргән ул. Шулай йөри торгач байтак вакыт узганнан соң, Урта Азия шәһәрләренең берсендә китапханәгә кергән. Аңа Назыйм Хикмәтнең яңа китабын укып карарга кирәк булган икән. Шунда үзенең беренче шигырь китабына юлыгып хәйран калган. Хәсән үзе сәяхәттә йөргәндә аның төрле елларда газета һәм журналларда басылган шигырьләрен Г. Гали китап итеп чыгарган, имеш. Әдәбиятта гына түгел, иптәшләренә мөнәсәбәтендә дә ифрат кайгыртучан,

мәрхәмәтле зат иде Г. Гали. Ул урамда бер иптәшенең костюмы начарлыгын күргән дә аңа берсүзсез үзенең яңа костюмын салып биргән...

Гомумән, тормышымда һәм иҗат юлымда миңа акыллы, талантлы һәм чын мәгънәсендә яхшы күңелле һәйбәт кешеләр күп очрады. Бу яктан мин үземне бәхетле дип әйтә алам. Кемнәр иде алар? Бала һәм яшүсмер чагында бу — минем атам һәм үзебезнең акылга бай, сүзгә тапкыр «авыл философлары»: Мөхәммәтҗан солдат, Гыйбаш, Гайнулла җизни һ. б... Өстәрәк әйткәнемчә, яшь күңелдә сүнмәстәй дәрт чаткысы кабызып җибәргән, үз-үземә ихтирам тудырырга ярдәм иткән карт большевик Кәшфеләсрар Хәмзин, укытучы Һади Дәүләтшин. Казанда эшли башлаганнан соң күпне күргән тәҗрибәле журналистлар, язучылар, галимнәр, ленинчы коммунистларның иң яхшы сыйфатларын, алдынгы татар интеллигенциясенең культура традицияләрен үзләштергән, партия һәм совет эшендә авыр сынаулар узган, гражданнар сугышында катнашкан, беренче Совет власте органнарын, Коммунистлар партиясенең беренче ячейкаларын оештырган кешеләр иде. Алар минем каршымда чын намуслык, принципиальлек һәм партия идеалларына җаны-тәне белән бирелгәнлек үрнәге булдылар. Мин партия члены һәм язучы буларак та шуларның рухи йогынтысында үстем. Алар тормышны һәм кешеләрне партия күзе белән, халык күзе белән күрә белергә, тормышның эчке мәгънәсен коммунистларча аңлый белергә өйрәттеләр.

Болар арасында Г. Ибраһимов һәм аның бай иҗаты аерым урын тота дип әйтер идем. Ул елларда инде Галимҗан абзый Ялтада яши башлаган иде. Шулай да мин аның белән берничә мәртәбә очрашып калдым.

Ул үз-үзенә дә, яшьләргә дә бик таләпчән булды. Галим башлы, шагыйрь йөрәкле бу революционер реалистик прозабызга киң юл салучы, республикадагы академик үзәкнең[1] председателе һәм РСФСР Художество академиясенең фәхри әгъзасы[2], барыннан да бигрәк, зур талант иясе булса да, аның белән сөйләшкәндә, ул үзенең өстенлеген сиздермәс һәм син үзеңне «кечкенә кеше» дип хис итми идең. Аның белән утырганда, тормыш ничектер тагын да баерак, мәгънәлерәк булып күренә, дөньяны тагын да биегрәк ноктадан күрәсең кебек тоела башлый иде. Авыру сәбәпле үзе Ялтада яшәсә дә, без аның әдәбиятыбызга йогынтысын һәрвакыт сизеп тордык. Яңа әсәрләребезгә бәя бирүен «Галимҗан ага ни әйтер икән?» — дип дулкынланып көтеп ала торган идек.

Г. Ибраһимовның зур таланты ярдәмендә татар романы, беренче рус революциясеннән соң, югары күтәрелеп, рус һәм бөтен дөнья классик романы йогынтысында, өлгереп җиткән реалистик сыйфатлы һәм күп планлы, катлаулы романга әверелде. Галиәсгар Камал, Шәриф Камал, Мәҗит Гафури, Кәрим Тинчурин, Һади Такташ, Хәсән Туфан һ. б. белән бергә, татар совет әдәбиятын Г. Ибраһимов тудырды. Безнең әдәбиятыбызда моңарчы тиңе булмаган оста стильче һәм шигъри тойгылы философ иде ул. Әгәр Тукай телебезнең иксез-чиксез шигъри сүз байлыгын, аның матурлыгын поэзиядә ачкан булса, шуларны ук Г. Ибраһимов прозада ачты. Татар совет әдәбиятын һәм шулай ук күп кенә көнчыгыш халыклары әдәбиятын, бигрәк тә роман жанрын үстерүдә, безнең һәркайсыбызның әдип буларак өлгерүебездә Г. Ибраһимовның роле әйтеп бетергесез зур булды.

Галимҗан Ибраһимовның халык каршында һәм язучылар арасында абруе ифрат зур иде. Татарстан хөкүмәте аны колхозчы-ударникларның 1933 елда уздырылган съездына Ялта шәһәреннән кунак итеп чакыр-

[1] Республиканың фән һәм сәнгать үзәге, Фәннәр Академиясенең филиалы кебегрәк оешма.

[2] Фәхри әгъза — почетлы член.

ды. Съезд делегатлары Ленин сеңелесе Мария Ильинична Ульянова, Михаил Иванович Калинин белән бергә президиумга килеп чыккан Г. Ибраһимовны да аягүрә торып тәбрик иттеләр. Ул вакытта Г. Ибраһимов байтактан бирле авыру иде инде. Аның хасталыгы йөзенә чыккан, президиумда ул башкалардан чыраеның көм-күк булуы белән аерылып тора иде. Ул Казанда озак яши алмады. Съезд тәмамлангач, үзенең замандашлары Г. Гали, Г. Нигъмәти, Ш. Камал, К. Нәҗми һәм башка өлкәнрәк язучылар белән очрашып сөйләшкәннән соң, тиз үк Ялтага китеп барды. Әмма һәрвакыт Ялтада яшәсә дә безнең белән элемтәсен өзмәде.

1936 елда җәй көне Ялтадагы иҗат йортына баргач, язучылар Гариф Галиев, Сәлах Ибраһимов һәм мин Г. Ибраһимовның хәлен белергә кердек. Ул Чехов урамындагы ике катлы йортта яши иде. Анда да ул танышып бераз хәл-әхвәл сорашканнан соң, чәй эчкәндә Татарстан хуҗалыгындагы үзгәрешләр белән таныштыруыбызны үтенде. Әңгәмә барышында мин аның кайбер тармаклар белән аеруча кызыксынуына игътибар иттем. Ул бездән:

— Республикада атлар саны кими башлаган. Сәбәбе нәрсәдә булуы мөмкин? — дип сорады.

Без белгән кадәр аңлатырга тырыштык.

— Хәзер колхоз авылында иген эшләрен башлыча тракторлар, комбайннар башкара, атларга эш азаеп бара, шунлыктан атлар санының кимүе котылгысыз процесс булса кирәк,— дидек.

Г. Ибраһимов безнең белән килешмәде.

— Иген эшенең күпме генә өлешен машина башкармасын, авылда атка эш барыбер бетәсе түгел. Атсыз авылны күз алдына да китереп булмый,— диде.

Мин әдипнең зуррак әсәрләренең һәрберсендә ат турында язмыйча калмавы нигезсез булмавы турында уйлап алдым. Игенченең иң якын ярдәмчесе һәм дусты булган бу сөйкемле хайванны әдип тә ярата, аның кими баруы Галимҗан абзыйны чын-чыннан борчый иде, күрәсең.

Ул вакытта инде әдип һәм галим буларак Россиядә генә түгел, бөтен Урта Азиядә һәм Казахстанда танылган олы дәрәҗәле кеше булуына карамастан, Г. Ибраһимовның үзен тәкәббер тотмавы да безгә ошады. Җәмәгате Хәдичә ханымнан безгә күптән түгел генә язып тәмамлаган яңа хикәясен укытуы аңа ихтирамыбызны тагын да арттырды. «Фронттан кайткач» дип исемләнгән бер-ике табак чамалы хикәя иде ул. Әдипнең башка хикәяләре кебек үк, монысы да кискен конфликтка корылган, һәйбәт, җиңел тел белән язылган иде.

Г. Ибраһимовның «демократлыгыннан» файдаланып, без тора-бара ярыйсы ук кыюландык. Хикәянең безгә кайсы ягы аеруча ошавын әйттек, кайбер урыннарының эстетик кыйммәтен шик астына да куйгаладык. Чәче агарып килә торган өлкән яшьтәге зур әдипнең әсәре турында болай бик иркен фикер йөртү, бәлки, әдәпсезлеккә дә якын торгандыр. Г. Ибраһимов, бәлки, мыек астыннан гына елмаеп та утыргандыр. Ләкин ул һич тә караңгы чырай күрсәтмәде, бер генә сүз яки күз карашы белән дә ризасызлыгын сиздермәде, гади генә терәкле урындыгында без сөйләгәннәрне тыныч кына тыңлый бирде.

Ул елны мин Галимҗан абзый янына тагын берничә мәртәбә кереп чыктым. Мин ул вакытта «Совет әдәбияты» журналының җаваплы секретаре булып эшләгәнлектән, аны кызыктырган әдәбият яңалыкларын яхшы белә идем. Теле белән әйтмәсә дә, аның минем килүемне көтеп алуын сизә идем. Ул гына түгел иде әле, тышкы диварларын яшел үрмәле гөл бизәп торган бу сөйкемле йорт мине магнит кебек үзенә тарта, мин монда килмичә булдыра алмыйм, моның бик җитди эчке бер сәбәбе бар иде. Кем иде минем кебек яшь язучы каршында Галимҗан Ибраһимов? Буй җитмәслек бөек кеше, пәйгамбәр, шагыйрь

йөрәкле философ! Аның «Қазакъ кызы», «Тирән тамырлар», «Диңгездә», «Сөю сәгадәт» кебек шедеврларын укыганда ул минем күз алдыма йөзендә иҗат дәрте балкып торган кап-кара куе чәчле, үткен карашлы курку белмәс ир-егет булып килеп баса иде. Кайчакларны мин аны өермәле давыллар өстендә киң канатларын җәйгән батыр йөрәкле бөркеткә тиңли идем. Менә хәзер өенә барган саен үзенә сиздермичә генә мин аңа карап торам. Терәкле урындыкта тын гына утырган шушы басынкы кешедән хыялымдагы бөек затның нииндидер чалымнарын эзлим, күзләрендә элекке ялкынлы дәртен күрәсем килә. Ләкин аңа күз салган саен күңелемә шом тула, шом... «Юк инде, юк, сүнеп бара»,— ди күңел түрендә кемдер. Ләкин аңа ышанасы килми, моңа бөтен барлыгым рәнҗи. Ул шикне кире кагасым килә. Әнә нинди һәйбәт хикәя язган бит әле, дим, тагын язар әле, язар!..

Казанга кайтып китәр алдыннан мин аңа соңгы мәртәбә бардым. Ул һаман да шул терәкле урындыгына утырып сөйләште. Мин аның урын хастасы булмавына да сөендем. Байтак кына сөйләшеп утырганнан соң ул мине баскыч башына кадәр озата чыкты. Баскычка терәлеп кенә чинар агачы үсеп утыра иде. Көньякның зифа буйлы чибәр иркәсе. Галимҗан абзый һаман да элеккечә басынкы, ак чырайлы иде. Ябык кулын сузып:

— Хушыгыз, Гомәр иптәш,— диде.

— Хушыгыз, Галимҗан ага...

Бу минем аны соңгы күрүем булды.

## XIV

Утызынчы елларда Казандагы язучылар арасында Шәриф абзый Камал (Шәриф Камалетдин улы Байгильдиев) яше ягыннан иң өлкәннәрдән санала иде (1884 елда туган). Хәер, ул елларда алтмышка кадәр яшәгән бер язучы да булмады шикелле. Шунысы да истә калган: Язучылар союзының партия оешмасы секретаре булып эшләгәндә, өлкән яшьтә булуын истә тотып, Шәриф абзыйга төрле эшләр тапшырудан да тыела идем. Бактың исә, ул елларда Шәриф абзыйга нибары илле яшь кенә булган икән.

Яше белән генә түгел, язучылар арасында иҗаты белән дә иң танылган һәм иң хөрмәтлесе Шәриф абзый Камал иде дисәм, шәт, ялгышмам. Аның «Акчарлаклар» повестеның, «Таң атканда» романының, «Хажи әфәнде өйләнә» һәм башка драма әсәрләренең, гаҗәеп осталык белән язылган кыска хикәяләренең иң популярлашкан чагы иде. Безнең шикелле әдәбиятка яңа гына килгән яшьләргә ул да зур ярдәм күрсәтте.

Шәриф абзый кешеләр белән мөгамәләсендә, сөйләвендә, гомумән, бөтен тормышында үзен тотуы, әдәплелеге белән дә күпләрдән аерылып тора, арада элекке татар зыялылары традициясен дәвам иттерүче санала иде. Әдәбиятка гражданнар сугышыннан соң килгән әдип һәм шагыйрьләр кием-салымга әллә ни игътибар итмәде. Кави Нәҗми, мәсәлән, ярым хәрби киемнән, яшел френч, галифе һәм кышын-җәен күн итектән йөрде. Башкалар ул вакытта модада булган вильвет толстовка, ефәк яки җәйге киндер костюм, брезент туфлидән дә баш тартмадылар. Ш. Камал исә халык арасына һәрвакыт яхшы костюм, ак күлмәк, яхшы галстуктан гына чыга иде.

Шәриф абзый үзен бик әдәпле һәм тыйнак тотты. Беренче күргән кеше аның хакында артык кыюсыз, хәтта юаш кеше икән дигән фикердә калуы да бик ихтимал. Ул, гадәттә, сак кына басып акрын йөри. Ул елларда бүтәннәрдә булмаган гадәте дә бар: кыска гына мыек үстерә иде. Җыелыш, утырышларга нәкъ вакытында килеп җитә, күп сөйләргә

яратмый, җыелышта чыга калса, иң кирәкле, принципиаль мәсьәләләр уңае белән генә сүз ала, нигезсез фикерне яклаучыларга, үзенә каршы чыгучыларга, кем булуына карамастан, сынын катырырлык итеп каты әйтә торган гадәте бар иде. Шундый бер хәл истә калган: яшьрәк язучылардан берсе, үзенең бик күп белүен дәгъва кылыптыр, күрәсең, Шәриф абзый белән социаль заказ хакында бәхәскә керде. Өлкән әдип шундый итеп аның авызын томалады ки, ихтимал, бу сүзләр әлеге яшь иптәшнең гомере буена онытылмаслык гыйбрәтле сабак булгандыр. Уфада узган бер мәҗлестә Шәриф Камалның язучы Зариф Бәширгә әйткән усал сүзләрен мәзәк урынына сөйлиләр иде.

Кыскасы, ул еллардагы язучыларның яше-карты өлкән әдип Шәриф Камалны чын күңелдән ихтирам итеп, аның киңәшләренә колак салып яшәде. Татар язучыларыннан Ленин ордены белән иң беренче бүләкләнүче дә Шәриф абзый булды.

1936 елда «Сиваш» повестен тәмамлаганнан соң, бу беренче зур әсәрем хакында өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк язучыларның фикерен беләсем килде. Дөрес, бу әсәрне мин бик илһамланып, дәртләнеп яздым, аның хакында үземнең фикерем начар түгел иде. Шулай да җитди, зур әсәрләр язарга сәләтем, хәзерлегем ни дәрәҗәдә булу хакында өлкәннәрдән ишетәсем килде. Үземә-үзем шундый сүз бирдем: әгәр дә «Сиваш» яхшы дип танылмаса, бүтән зур әсәргә тотынмаска! Чиле-пешле әйберләр язарга гарьләнә идем, андыйларны язучылар миннән башка да җитәрлек бит...

Ул елларда Литфонд вәкиле Сәмитов җәйге сезон өчен язучыларга Түбән Ослан авылыннан дачалар ала торган иде. Хәтта безне төрле өй җиһазлары, күмер, керосин, ашау-эчү әйберләре белән тәэмин итеп торулары да хәтердә калган.

Җәйнең матур бер көнендә Түбән Осланның чирәмле калкулыгына «Сиваш»тан өзек тыңларга җыелдылар. Утырышка А. Әхмәт, шагыйрь Г. Мөхәммәтшин, Муса Җәлил, Х. Ярми, дачада яшәүче язучылардан тагын берничә кеше килгән иде. Ниһаять, нәкъ билгеләнгән вакытка Шәриф абзый да килеп чыкты. Бу өлкән абзыйның килүе, билгеле, бик шатландырды. Анда җыелган язучыларның башкалары да әдәбиятка миннән элек килгән иптәшләр иде. Шулай да хәлиткеч җитди фикер әйтүне шушы өлкән агайдан көтә идем.

Мин аларга «Сиваш» повестеннан Кырым өчен барган иң авыр, иң соңгы сугышларны тасвирлаган 15—20 битлек бер өзек укыдым. Билгеле, дулкынланмыйча булмагандыр. Бу минем өлкән язучылар алдында беренче имтиханым иде.

Укып бетердем дә ни буласын көтеп тынып калдым. Абдулла Әхмәт, гадәтенчә, теленә салынып көлдереп алды да повестьта детальләрнең бик әһәмиятле урын тотулары хакында сөйләде.

— «Ботинканың тишек урыныннан песи борыны төсле кызарып күренгән аяк бармагы», тагын шундый детальләр аермачык булып күз алдына килеп баса. Әдәби әсәрдә боларның да әһәмияте бик зур...— дип башлап китте.

Фольклорчы галим Хәмит Ярмигә әсәрдә халык җырларының бик урынлы кулланылуы, Әхмәдигә килгән хатның оригиналь алым белән язылуы ошаган икән. Муса Җәлил төрле милләттән чыккан сугышчыларның иң кыен шартларда бер-берсенә туганнарча ярдәм итүләре җанлы картиналарда бирелүен мактады. Башкалар да үз фикерләрен әйтеп, әсәрнең уңышлы дип тапкан урыннарын һәм кимчелекләрен күрсәттеләр.

Ниһаять, һәрвакыт киеп йөри торган калын кысалы зур күзлеген төзәткәләп, тамагын кырып алганнан соң, Ш. Камал да сүзен әйтте. Өзек аңа ошаган икән. Бигрәк тә кайсы ягы белән? Моңа кадәр язылган әсәрләрнең күбесе, гомумән, гражданнар сугышы хакында булса,

«Сиваш» шул сугышның тарихта зур урын тоткан конкрет бер чорына — Кырымны азат итүгә багышланган булуы белән аерылып тора икән. Шәриф абзый моны хуп күрүен әйтте. Әмма аның әле «ләкине...» дә бар иде.

— Ләкин, миңа калса, Гомәр иптәш геройларның хәләте рухиясен тагын да тирәнрәк итеп бирә алган булыр иде кебек сизәм. Моңа әсәрдә мөмкинлек тә бар, авторның сәлахияте[1] дә җитәрлек. Әсәр һәр җәһәттән камил булсын өчен, аны иҗат итүгә бөтен сәләтең белән тырышлыгыңны күпме булдыра алсаң, шулкадәр истигъмал кылу мәслихәт,— диде. Шул юнәлештә тагын бераз сөйләде дә сорау бирде.— Гомәр иптәш, сез Язучылар союзына алуны үтенеп гариза бирдегезме әле?

Мин:

— Юк әле, Шәриф абзый,— дидем.

— Минемчә, мондый әсәр язган авторның союз члены булырга хакы бар. Болай булгач өметле инде, өметле,— диде.

Мин бу саран сүзләрне Шәриф абзыйның миңа зур әдәбиятка керергә фатиха бирүе дип аңладым.

## XV

Гумир Толымбайский турында мин бер мәкаләмдә кыска гына булса да язып үткән идем инде. Тормыш юлымда очраган күренекле шәхесләр белән бергә, аны тагын искә төшермичә уза алмам, ахрысы. Чөнки бу затның фаҗигале язмышы әле хәзер дә, кырык-илле ел узганнан соң да борчып тора. Әле күптән түгел генә дөнья күргән, аның барлык иҗат җимешен диярлек эченә алган китабы[2] да юкалыгы белән күңелдә ризасызлык тудырды. Минем белүемчә, Г. Толымбай әдәбиятны бик җитди проза һәм тәнкыйть мәкаләләре белән баетырга сәләтле булган акыллы, эш сөючән, үз максатына ирешү өчен төрле кыенлыкларны җиңеп өйрәнгән үзсүзле, көчле әдип иде. Ничек шулай булды әле бу? Нигә бу кискен холыклы, үз-үзенә бик нык ышанган тырыш кеше әдәбиятта талантына лаек эз калдыра алмады? Моның сәбәбе нидә? Шул сорауларга җавап бирү өчен мин аның үз күз алдымда узган тормыш юлын, әдәби эшчәнлеген яңадан исемә китерергә тырышам.

Г. Толымбайның чын исеме Габделхак, фамилиясе Шаһиәхмәтов иде. Татар әдәбиятында борынгыдан ук килгән гадәт буенча (Утыз Имәни, Укмасый, Мәрҗәни һ. б. кебек), әдәбиятта ул үзенә псевдоним итеп авылы исемен алган, Толымбайский дип, ә исемен ни сәбәпледер Гумир дип яза иде. Тора-бара аның фамилиясен кыскартып «Толымбай» дип кенә атый башладылар. Аның авылында булып туган йортын да күргәнем бар. Толымбай анкеталарда атасын «революциягә кадәр кулак иде» дип язган булса да мин күргәндә ул йорт күршеләреннән бер ягы белән дә аерылмаган гади генә урта хәлле игенче йорты иде.

Мин әдәбиятка килгәндә, ягъни утызынчы еллар башында Г. Толымбай безнең әдәбиятның башында баручы беренче бишлекнең (Ш. Камал, К. Тинчурин, Кави Нәҗми, Г. Гали һәм Г. Толымбай) берсе иде. Ул вакытта инде Һади Такташ — вафат, Г. Ибраһимов исә, үпкәсе авыру сәбәпле, даими рәвештә Ялтада яшәгәнлектән, мондагы эшләргә турыдан-туры катнашу мөмкинлегеннән мәхрүм иде. Болар һәммәсе дә диярлек Язучылар союзының идарә членнары, яисә «Совет әдәбияты» журналының редколлегия членнары булып сайланалар, яки башка шундый җаваплы эшләргә җитәкчелек итәләр. Җыелышларда боларның

[1] Сәлахияте — сәләте.
[2] Гомәр Толымбай. Түбән елгада. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1980, 256 б.

чыгышларын, гадәттә, күтеп алалар, мәсьәләнең тегеләй яки болай хәл ителүенә алар фикеренең тәэсире көчле була иде.

Г. Толымбай киң җилкәле, зур, таза бәдәнле кеше иде. Аның тышкы кыяфәте яшьлек елларында Петроградта ломовой извозчик булып эшләвен искә төшерә, гомумән аның йөреш-торышы да, үзен тотуы да авыр физик эш белән шөгыльләнүченекенә охшый төшә иде. Шәриф Камал, Фатих Сәйфи-Казанлы, Фәтхи Бурнаш, Мәхмүт Галәү кебекләр, үзләренең зыялылар катламыннан булуларын яшереп тормастан, заманасы мөмкинлек биргән кадәр, һәрвакыт европача пөхтә киенеп йөрделәр. Г. Толымбай исә кием-салымында да, үзен тотышында да «буржуйлардан калган» гадәтләргә каршы булды. Моның белән ул үзенең «түбәннән күтәрелгән», гади халык эченнән чыккан, пролетариат катламына якын торучы язучы булуын искәртергә теләмәдеме икән? Мәсәлән, ул күп вакыт галстук бәйләмәс, гадәттә эшчеләр тарафыннан яратып киелә торган туры якалы, ак сәдәфле кара сатин күлмәк кияр иде.

Бу бишлек эчендә Г. Толымбай фикеренең мөстәкыйльлеге, хөкеменең кискенлеге, иҗтимагый мәсьәләләргә карашының «кызыл»рак булуы белән дә аерылып торды. Ул ара-тирә сатирик әсәрләр дә язгалый, шул ук сатира алымын башка вакытта да куллангалый, чыгышларында, редколлегия утырышында яисә болай сөйләшеп утырганда булсын, хәтер саклап тормыйча, теләсә кемнән яки аның әсәреннән усал итеп көләргә ярата иде.

Шундый бер хәл истә калган: «Кызыл Татарстан» газетасында эшләгәндә, язгы чәчү алдыннан колхозларда йөреп кайтканнан соң, мин газетада «Кояш нурлары һәм Әхмәди» дигән җиңелчә генә бер очерк сыман нәрсә бастырдым. Шул әсәр газетада чыккан көнне редакциягә Г. Толымбай килеп керде. Мине күрүгә калын тавышы белән кычкырып көлеп җибәрде.

— Һа-һа-һа! Ну тапкансың да инде исемне! — диде.

Аңа кушылып мин үзем дә көлдем. Чөнки ярым җитди, ярым җилбәзәкләнеп язган бу шаян әсәрнең бер көнлек күбәләк кенә икәнлеген үзем дә белә идем.

— Яз кояшы җилкетеп шулай яздыргандыр, күрәсең,— дип котылдым.

Татар әдәбиятының кухнясына килеп кергәннән, бигрәк тә үземнең дә язарга сәләтле булуыма ышанганнан соң, әйләнә-тирәмдәге әдип һәм шагыйрьләр мине аеруча кызыксындыра башлады. Аларның әсәрләрен уку нәтиҗәсендә үзләрен күрмәс борын ук күңелдә туган образлары белән хәзерге кешелек сыйфатлары тәңгәл киләме? Язучы әсәрендә бер төрле, ә үзе бөтенләй башка төрле түгелме? Минем күз алдымда яшәп яткан менә бу тере язучы яки шагыйрь үз иҗатында тудырган образга, үзенең лирик героена, үзе өндәгән әхлакый, философик таләпләргә лаекмы? Матур әдәбият, гражданнар сугышы һәм, гомумән, ул заманның кырыс революцион кануннары мине шундый итеп тәрбияләгәннәр иде ки, минем күңел бу мәсьәләдә бер төрле компромисска да барачак түгел иде.

Бәхеткә каршы, мин ялгышмаган булып чыктым. Мин белгән әдип һәм шагыйрьләрнең күбесе күңелләрдә туган образларга шәхес буларак та тәңгәл киләләр иде. Алай гына да түгел, хәтта мин аларның тормыш юллары, килеш-килбәтләре, холык-фигыльләре белән иҗат үзенчәлекләрендә дә ниндидер тәңгәллек, тел белән әйтеп булмастай ниндидер уртаклык таптым. Мәсәлән, Хәсән Туфан белән Фәтхи Бурнашны табигать һәм тормыш шагыйрь итеп яратканнар. Кәрим Тинчуринны драматургиядән башка күз алдына китереп тә булмый. Аның тышкы кыяфәтендә, үзен тотуында, башка сыйфатлардан тыш, артистлык та бар иде. Г. Гали һәм Г. Нигъмәти килеш-килбәтләре, фикер йөр-

тү үзенчәлекләре, дөньяга карашлары белән — әдәбият галимнәре. Г. Толымбай исә, өстәрәк язганымча, барлык кешелек сыйфатлары, тормыш тәҗрибәсе, чыгышы, язу алымы, дөньяны аңлавы белән әдәбиятка авылдан күтәрелгән хезмәт иясе вәкиле иде. Ул авыл кешеләре тормышыннан «Мужик фәлсәфәсе», «Читән буенда», «Түбән елгада», «Егет» исемле һ. б. яхшы гына хикәяләр язды. Ул игенче агайның тормышын, гореф-гадәтен, телен тирәнтен белеп, мавыгып укырлык итеп яза белә иде. Без аннан киләчәктә шул юнәлештә тагын да зуррак әсәрләр көтә башлаган идек. Ләкин ул үзенең әдәби көчен, иҗат сәләтен кая куярга, ничек файдаланырга белмичә азапланган таркау холыклы, йомшак ихтыярлы кешеләрдәй, көтмәгәндә арлы-бирле сугыла башлады. Мәсәлән, ул «Татар буржуа теле безнең тел түгел» дип исемләнгән, теоретик яктан буталчык мәкалә язып чыкты (1931). Озак та үтмәде, «Фатих Әмирхан» исемле китабында (1934) ул аны буржуа идеологиясен уздыручы әдип дип танытырга тырышты. Йомшак кына әйткәндә дә, бу әдәбиятта волюнтаризмның үзенчәлекле бер күренеше иде. Чөнки бу очракта Г. Толымбай иҗтимагый үсеш закончалыгы, аның диалектикасы белән һич тә исәпләшмәстән, кадерле әдәби мирастан, аның нинди булуына карамастан, ваз кичү юлына басты, халыкның аңын демократик юнәлештә тәрбияләүдә, реакцион динчеләрне фаш итүдә Ф. Әмирхан әсәрләренең уңай тәэсирен бөтенләй инкарь итте. Хәлбуки Ф. Әмирханның киң сулышлы, тирән эчтәлекле яхшы әсәрләрен хәзерге заман яшьләре дә яратып укый. Г. Толымбайның бу чыгышы читләтеп кенә булса да Г. Тукай өстенә дә күләгә ташлады. Чөнки әгәр дә Ф. Әмирхан чыннан да буржуазия идеологиясен уздыручы шәхес булган икән, ул вакытта сыйнфый мәсьәләләргә карата ифрат сизгер булган Тукай ничек моңа каршы чыкмаган икән, дигән сөаль туар иде.

Халык мондыйны кирәкмәгән урында «мөгез чыгару» дип атый. Бу шулай ук үзенең оригинальлеге белән башкаларның борынына чиертергә яратучы мактанчык берәүнең «Илдә булмаганны пешер, хатын!» диюенә дә бик туры килә. Х. Хисмәтуллин моны: «Толымбай дөньяга карашындагы бу үтә суллык» шул елларда шактый көчле булган пролеткультчылык һәм «РАППчылыкның әдәбиятка һәм язучыларга тискәре йогынтысының бер чагылышы иде»,— дип аңлата [1]. Минемчә, Толымбайның «сулагайга селтәнү» сәбәбен болай гына аңлату хакыйкатьне ахырына кадәр ачып бетерә алмый. Чөнки аның бу хезмәтләре игълан ителгән елларда, «РАППчылык чире»нең тәэсире сүнеп беткән диярлек иде инде. Минемчә, бу мәсьәлә тирәнрәк өйрәнүне көтә.

Һәрхәлдә, Г. Толымбай бу чыгышлары белән Ф. Әмирханны әдәбияттан байтак еллар читләтеп торуга сәбәпче булды. Ф. Әмирхан өстенә ташланган бу урынсыз гаепне юып төшерү, аны яңадан әдәбиятка кайтару өчен Афзал Шамовка һәм башка кайбер иптәшләргә озак еллар көрәшергә, моңа күп көч салырга туры килде.

Г. Толымбай белән мин җыелышларда, проза секциясенең утырышларында, журнал редакциясендә, шулай ук 1934—36 елларда марксизм-ленинизм институтында укыганда еш очраша идем. Бу аның Мәскәүдәге кызыл профессура институтын тәмамлап, әдәбият профессоры дигән исем алып кайткан еллары иде. Әгәр ялгышмасам, ул институтта әдәбият фәнен һәм философия укыта иде шикелле.

1937 ел башында булса кирәк, мин «Совет әдәбияты» журналының редакторы вазифасын үти башлагач, Г. Толымбай, хәтсез вакыт күренми торганнан соң, редакция бүлмәсенә килеп керде. Хәзер ул элекке кебек шаулатып көлми, уйчан күренә, ничектер басынкыланган иде. Журнал тирәсендәге яңалыклар белән кызыксынды, редакциягә нинди

---

[1] Г. Толымбай. Түбән елгада. Татарстан китап нәшрияты. Казан, 1980.

яңа әсәрләр керүе турында сорашты. Шулай сөйләшеп утыра торгач, шактый күләмле кульязма чыгарып бирде.

— Менә бер нәрсә яздым әле. Бәлкем, син моны журналда басмассың да. Шулай да укып кара әле. Каян беләсең...— диде.

Мин укып чыгарга вәгъдә биреп, кульязманы квартирама алып кайттым.

«Җиде баш» дип исемләнгән ике-өч табак күләмендәге сатирик хикәя иде бу. Г. Толымбай юмор һәм сатирага саран кеше түгел, аның юмористик хикәяләре матбугатта әледән-әле күренгәләп тора иде. Әмма бу әсәре аның башка хикәяләренә һич охшамаган булып чыкты.

Хикәянең герое озак кына вакыт үзенең башыннан канәгать булмыйча зарланып йөри дә, ниһаять, аннан котылып бүтән баш алырга дигән карарга килә. Шул ниятен гамәлгә ашырып, ул талчуктан бүтән баш сатып ала. Ләкин яңа баш аны астыртын сату-алу белән шөгыльләнүче спекулянтлар, маклерлар, барышниклар оясына алып кереп китә. Хикәя герое ул башны, ошатмыйча, икенче башка алмаштыра. Әмма бу баштан да уңмый. Чөнки монысы көне-төне эчеп-исереп азгын хатыннар, фахишәләр белән чуалучы азу ярган уйнашчы булып чыга. Аны да ошатмый бу кеше. Дүртенче баш милләтче, бишенчесе бюрократ, тагын берсе дәүләт акчасын туздыручы җинаятьче башы була. Кыскасы, автор шундый алым белән НЭП чорының бозык элементларын фаш итүне максат итеп куйган иде.

Икенче көнне Толымбай белән тагын очраштык.

— Я, ничек? — диде ул.

Мин аңа хикәя турындагы фикеремне сөйләп бирдем. Бу юлы да аның күңеле төшенке иде. Әсәрен журналда бастыру турында бөтенләй сүз дә кузгатмады. Миндә ул әлеге әсәрен җаны тыныч булмаган, нигәдер борчылган көннәрендә күңелен юату өчен генә язган булса кирәк дигән тәэсир калдырды.

Берничә елдан соң миңа Толымбайның үз авылдашы, оста әкиятче Хөсәеновтан язып алган халык әкиятләрен редакцияләргә туры килде. Шунда Г. Толымбайның бу өлкәнә дә тирәнтен белүе бик яхшы тәэсир калдырды. Ул халык әкиятләрен хәзерге фольклористика фәне таләпләренә җавап бирердәй итеп, әкиятче теленең нечкә үзенчәлекләрен дә саклаган хәлдә бик пөхтәләп, тәмам җиренә җиткереп язып алган иде. Димәк, ул һәйбәт хикәя һәм повестьлар язу, тел һәм әдәбият тарихы, философия фәне белән шөгыльләнү өстенә, халык иҗаты белән дә кызыксынган икән. Хәер, бу аның әдәби әсәрләрендә дә сизелә иде.

Кызганычка каршы, үзенең субъектив карашын иҗтимагый тормыш логикасыннан өстен куюы нәтиҗәсендә, Г. Толымбай тирән белеменең, зур талантының чәчәк атуына ирешә алмый калды. Гыйбрәтле язмыш.

Истәлекләрнең күбесендә без әдәбиятны яки сәнгатьне әйдәп баручы эрерәк затлар, зуррак талант иясләре хакында язарга гадәтләнгәнбез. Ихтимал, шулай кирәктер дә. Чөнки ул затлар үзләрен генә түгел, заманнарына хас типик хәлләрне дә гомумиләштереп күрсәтергә мөмкинлек тудыралар. Ләкин ул затларга ярдәмче көчләр дә, алар янында, әгәр шулай әйтергә яраса, «кара эш» башкаручылар да кирәк була бит әле. Алар җәмәгатьчелек күзенә артык чалынмыйлар, аларның исемнәре төрле басмаларда вак хәрефләрдән генә җыела. Әмма аларның хезмәтләре ифрат зур тырышлык, түземлелек, пөхтәлек таләп итә, алар автор язган һәр сүз өчен генә түгел, һәр хәреф өчен дә җаваплылык хисе белән эшлиләр. Алар тырышлыгыннан башка бер генә басма да дөньяга чыга алмый. Болар — техник редакторлар, корректорлар, секретарь һәм машинисткалар.

Журналист Абдулла Гомәр әнә шул тыйнак һөнәр кешесе иде. Егерменче — кырыгынчы еллар арасында матур әдәбиятта һәм көндәлек матбугатта аны белмәгән, аңа ничек тә булса йомышы төшмәгән берәр кеше табылырмы икән! Ул шулкадәр «үз кеше» булып киткән иде ки, хәтта аның исемен-фамилиясен бергә кушып «Агомәр» дип кенә йөрттеләр.

Үзенә әллә ни дәгъва итмичә күп вакыт күләгәдә калып килүче шушы тыйнак кеше газета-журнал редакцияләрендә башкарган күп еллык намуслы, тырыш хезмәте белән аны белүчеләрдә яхшы истәлекләр калдырды. Элекке зыялыларча һәрвакыт пөхтә костюмнан, һәйбәт галстук бәйләп, алтын чылбырлы пенснэ киеп йөрүче бу интеллигент кыяфәтле журналистны без яратып «аяклы энциклопедист» дип атый идек. Аның, чыннан да, белмәгәне юк иде. Кайсы зур әдәби вакыйга кайчан һәм кайда булган, ул хакта каян материал табарга? Кайсы язучының фәлән әсәре беренче мәртәбә кайда басылган, аңа беренче рецензияне кем, кайчан язган? Фәлән дөнья классигының мәшһүр әсәрен кайчан тәрҗемә иткәннәр? Кайсы журнал яки газета кайчан чыга башлаган? Шуныңише тагын мең сорауга фәкать аннан гына һичбер мәшәкатьсез кирәкле җавап алып була иде.

1937 елның урталарыннан башлап «Совет әдәбияты»н Абдулла Гомәр белән без икәү генә чыгара башладык. Мин вакытлы редактор вазифасын үтим, А. Гомәр исә бер үк вакытта җаваплы секретарь да, техник редактор да, корректор да, хәтта метранпаж[1] да була иде, ул эшкә иртүк килә, журнал чыгасы көннәрдә типографиядә төнгә дә калып эшли, билгеле, эштән чыгып арый. Әмма мин Абдулланың бер генә вакытта да зарлануын ишетмәдем. Аның каруы журналның әле генә төпләнгән, буяу исе дә таралып җитмәгән яңа санын иртә белән редакция өстәленә китереп салганда аның куануын күрсәгез иде. Калын пенснэ пыяласы артында аның зәңгәр күзләре елтырый, үзе рәхәтләнеп елмая. Үз хезмәтенең матур нәтиҗәсенә куанып яшәүчеләр миндә гомер-гомергә чын ихтирам уяттылар. Шул шатлыклы вакыйга уңае белән без кара-каршы утырып бик тәмләп чәй эчә торган булдык.

Абдулла Гомәр яшь чагында ук сайлаган шушы һөнәренә гомере буена тугрылыклы булып калды.

## XVI

Көндәлек дәфтәрдән:

«Гомумән алганда, ялган — эшәке нәрсә. Ләкин гаҗәп! Ул һәркайчан да алай начар тәэсир калдырмый. Була шундый чаклар, син якын дустыңның ялганын тыңлыйсың. Ул ялганлый. Ләкин нинди максат белән? Менә шунда хикмәт. Анда усал уй юк, яхшы булып күренергә дә теләми. Юк! Ул шушы ялганы белән дустына булган мәхәббәтен белдерә, шуны белдерү өчен хыялын булган хәл итеп сөйли. Ул аңа үзе дә ышана, сине дә ышандырам дип уйлый. Әгәр дә син аңа шундый чакта «ялганлыйсың бит!» дисәң, ахмак булыр идең» (13 февраль, 1937 ел).

«Сиваш»ның «түбәсе» күренә башлады. Баштагы томан эченнән матур гына бина калкып чыга. Өскәрәк калыккан саен ул күркәмрәк, мөкәммәлрәк була бара. Үз проекты буенча салына торган йортның агач корылмалар арасыннан бөтен бер бина булып калкып чыгуын карап торучы архитекторның рухи халәтен мин аңлыйм. Ул да шулай дулкынланадыр...» (6 март, 1937 ел).

«Язасы килә бит!

Аз гына буш ара булдымы, язылачак әсәрнең аерым күренешләре күз алдына килеп баса. Алар мине үзләренә өндиләр, мин алар арасын-

[1] Метранпаж — типографиядә җыелган наборны биткә салучы, өлкән наборщик.

да яшим. Иҗат итү бит ул фәкать фикерне кәгазьгә төшерү генә, язу гына түгел, ул — уйлану, үсү дә. Билгеле бер фикерне (идеяне) тегеләй яки болай тасвирлап бирү хакында уйланганда үзеннән-үзе күп нәрсәләргә үзеңнең карашыңны ачыклыйсың. Яхшы китап ул — иҗат кешесенең рухи, әхлакый җәһәттән үсешенең конкрет нәтиҗәсе» (14 март, 1937 ел).

ҮЗЕМӘ

«Якты йолдыз калка дигәндә дә офыктан
Күренмәсә тирән шатлык син көткән —
Пошынма син, башың имә борчудан,
Бара бир нык басып туры юлдан.

Юлыңа аркылы төшсә еланнар,
Телгәләсә күңелеңне рәнҗетелгән вөҗдан —
Сатылма барабанга, ялтырауга,
Төшмә калтырап җан өчен куркудан».

(Июнь, 1937).

Мин иҗатымны, башка бик күпләр кебек, шигырь язудан башламадым. Тукай һәм башка бөек шагыйрьләрнең иҗатларына ихтирамым бик тирән, бик зур иде. Шунлыктан начар шигырь язып шигърияткә рәнҗетәсем килмәде.

Бу шигырь сымак нәрсәне нинди уңай белән язганмын, берәр сәбәбе булгандыр инде...

1937 елның соңгы сәгатьләре. Бу ел үлә, яңасы туа.

Нәрсә бирде миңа бу ел?

«Сиваш»ны «бирә язды». Мин аңа бөтен көчемне салып, төннәр йокламыйча язган идем. Анда тузан кадәр дә кер юк, чын күңелдән язылган әсәр иде. Ләкин... бюрократлар аңа дөнья йөзе күрергә ирек бирмиләр. Нигә чыкмый?

1937 ел тагын ни алып килде?

Минем бик акыллы, бик сөйкемле кызым бар. Мин аны ата булганга күрә генә түгел, акыллы булуы, ягымлылыгы өчен дә дөньядагы барлык кешеләрдән артыграк яратам... Мин эштән кайткач ул йөгереп килеп муеныма сарыла, «Әти, тәстә алып тайттың?» — ди. Мине кочакламыйча, янымa килмичә йокларга ятмый, «палашуттан төшел!» — дип сикерткәнне көтә иде.

Ул скарлатина белән авырый, яңа елны больницада каршы ала. Тазарып чыгармы, юкмы — белмим.

Тагын?

Борчу, борчу өстенә борчу.

Язасы килми. Бик авыр.

1938 ел мондый булмасын, бәхетле ел булсын, иркенләп, рәхәтләнеп, колач җәеп эшли торган уңышлы ел булсын!..» (31 декабрь, 1937).

«Үзен-үзе белмәгән кешегә дөньяда яшәве бик уңайсыздыр. Ләкин бит үзеңнең кем булуыңны белү өчен башкаларны өйрәнергә кирәк. Бу кешегә нәкъ әнә шул җитми.

Бүген редакциягә Н. килде. Ул Пушкинга багышланган шигырен укыды. Аның бу шигыре дә, элек язганнары кебек үк, мәгънәсез, талантсыз иде. Шулкадәр: хәтта мин ул шигырьнең бер генә юлын да, хәтта исемен дә хәтерләп кала алмадым. Укып чыкканнан соң: «Йә, ничек?» — диде. Мин аңа: «Шигырең бернигә дә ярамый, туган!» — диярга тиеш идем. Ләкин ул моны аңламаячак, чөнки моңарчы аңа «син шагыйрь түгел» дип әйтергә берәүнең дә кыюлыгы җитмәгән, ул инде тугыз шигырь җыентыгы чыгарган, үзенең талантлы булуына тәмам ышанган. Бик аяныч хәл...» (Май, 1938).

## XVII

Әдәбиятка шулай буй җитмәслек нәрсә итеп карауда минем холкыма хас бер йомшак як та кабатланды: хискә бирелеп, чамасыз идеаллаштыру да булды шикелле. Менә нәрсә ихтыяр көчемне тышаулап, иҗат кыюлыгымны бастырып, байтак вакытка кадәр әдәбиятка кереп китүдән тыебрак торды. Мин моны соңыннанрак кына сиздем, берничә ел узгач. Кайбер хикәяләрем басылып чыкканнан соң да, өлкәнрәк, тәҗрибәлерәк иптәшләр (мәсәлән, Шәриф Камал, Галимҗан Нигъмәти һәм Гумир Толымбайский) миңа әдәби иҗат эшенә чынлабрак керешергә берничә мәртәбә киңәш биреп карадылар.

Мин исә каләм хезмәтендә байтак тәҗрибә туплап, марксизм-ленинизм институтында укып чыкканнан соң гына җитди әсәр язарга батырчылык иттем.

«Сиваш»ны мин тарихи чынлыкка нигезләп, вакыйгалар чынбарлыкның үзендә ничек булса, шулай язарга тырыштым. Кайбер эпизодларны әһәмиятлерәк сугыш операцияләренең көннәре генә түгел, хәтта сәгатьләренә кадәр шул вакыттагыча «дөрес» итеп бирелде. Фрунзе Сиваш ярына шулай килеп чыкты, полк командиры да сугыш операцияләренә шулай җитәкчелек итте [1].

Ләкин шуңа карамастан, бу әле «Сиваш» повесте шул вакытта булып узган тарихи вакыйгаларның һич үзгәртмичә, нәкъ булганча төшереп алган чын фотопанорамасы дигән сүз түгел. Һич юк! Аның тегесе тарихның үзе, аның чыны, ә «Сиваш» исә көньязма да, елъязма да, истәлек тә түгел, бәлки сәнгать кануннары буенча язылган әдәби әсәр.

Димәк, шулай булгач, болар икесе дә бер үк манзараны бирә алмыйлар. Ничек алай була соң ул?

Мин бу әсәремне сугыш гөрселдәүләре тынганнан соң 15—16 ел узгач яздым. Табигый ки, ул вакыт эчендә мин үзем дә, минем дөньяга карашым да шактый ук үзгәргән иде инде. Сугышка мин әллә ни дөнья күрмәгән, йомыркадан әле генә борынлап чыккан гади бер авыл егете сыйфатында катнашкан булсам, «Сиваш»ны язганда инде авыр сугышлар кичкән, белемен дә арттырган, каләмен дә чарлый төшеп, язучы булырга җыенучы бер кеше идем. Димәк, хәзер инде мин теге елларда булып узган вакыйгаларны башкачарак, югартынрак торып, биегрәк баскычтан күрә башлаганмын булса кирәк.

Билгеле, беренче зур әсәремне укучының ничек каршы алуы мине бик кызыксындыра иде. Минем рус әдәбиятындагы гражданнар сугышы темасына моңа кадәр язылган кайбер әсәрләргә, мәсәлән, А. Фадеевның «Тар-мар», А. Серафимовичның «Ташкын» кебек әсәрләренә ихтирамым бик зур. Алар янында минем әсәрем югалып калмагае дигән шөбһә дә юк түгел иде. Әле бит, Сиваш тирәсендәге сугышлар турында күренекле язучылар Александр Малышкинның «Даирның алынуы», Юрий Яновскийның «Җайдаклар» дигән әсәрләре дә бар. Дөрес, повестьның өзекләрен Г. Нигъмәтигә, тагын бер өлешен Түбән Осланда проза секциясе утырышына җыелган язучыларга укыган идем. Шулай да... гомумән бөтен әсәр турында укучы нинди фикер әйтә бит әле.

Иң беренче шатлыклы хәбәрне язучы Гариф Галиевтән [2] ишеттем.

Көндәлек дәфтәрдән:

«Бүген Г. Г. бик кызык нәрсә сөйләде. Татполиграф типографиясендә «Сиваш»ның корректурасын укучы корректор кызны егете күрешергә

---

[1] «Сиваш» әсәре геройларының берсе — полк командиры Николай Яковлевич Кириченко генерал-майор дәрәҗәсендә булып, Мәскәүдә хезмәт итте. «Сиваш»ның русчасын укып чыгып, ул да үзенең фикерләрен әйтте, киңәшләр бирде.

[2] Г. Галиев ул елларда «Бригадир» журналының җаваплы секретаре булып эшләгәнлектән, типографиядә еш була иде.

чакырган. Кыз: «Эшем бар, бара алмыйм»,— дигәч, егет: «Ә син эшеңне алып кил, бергә карарбыз», дигән. Кыз «Сиваш»ның корректурасын үзе белән алып барган да алар аны оригинал белән чагыштырып укый башлаганнар. Шулвакыт болар янына бер интеллигент кеше кереп, кызның укыганын тыңлап тора башлаган, ди. Тегеләр укыганнар-укыганнар да чәй эчәргә туктаганнар. Әлеге интеллигент чәй янында вакыйганың ничек дәвам итүен сөйләп биргән. Корректор безнең Сиваштан чыгып җитү моментын укып туктаган булса кирәк. Теге кеше шуннан башлап дәвам иткән һәм корректорның әйтүенә караганда, ул хикәяне нәкъ шундагыча («Сиваш» повестенда язылганча. Г. Б.) дәвам иткән. Тегеләр моңа шаккатканнар, ди.

Бу бик кызык хәл. Моның хикмәте әсәрнең реаль булуында, халыкка якын һәм аңлаешлы булуында. Чөнки шулай булмаганда ул кеше аны дәвам иттерә алмас иде.

Мин моңа бик шат булдым. Ул кеше үзе дә Сиваш сугышында катнашкан кеше, ди». (27 гыйнвар, 1938).

Шундый күңелле хәбәрләр ишетелгәләп торса да, булачак китапның корректурасы укылганга байтак вакыт узса да, китап үзе һаман күренми иде әле. Ни сәбәп? Гади волокита гынамы, әллә бу әсәрне дә берәр шөбһә тоткарлап торамы?

Шуны ачыклау өчен Татарстан китап нәшриятының директоры Закир Вәли улы Тинчуринга кердем. Ул безгә караганда шактый ук өлкән яшьтәге кеше булганлыктан, аны Закир абзый дип йөри идек. Мин белгән директорлар арасында ул иң абруйлысы, безнең язучы халкына иң игътибарлысы иде. Тинчурин яшь чагында Саратов якларында грузчик та, ломовой да булып эшләгән таза бәдәнле кеше иде. Революция елларында ук партиягә кергән. Татар коммунистлар университетын тәмамлап чыкканнан соң, төрле җитәкче вазифалар башкарган. Ул үзенең шәхси тормышында һәм хезмәтендә бик тырыш, гадел һәм бик тә күркәм холыклы, кайгыртучан кеше иде. Закир абзыйның нәшрият җитәкчесе буларак иң кадерле сыйфаты, мөгаен, шул булгандыр: ул кайсы язучының әдәбиятка нинди өлеш кертергә сәләтле булуын сизеп тора, шуңа таянып, кайбер язучылар белән язачак әсәренә алдан ук договор төзергә дә рөхсәт итә иде. Шунлыктан, кыен хәлгә төшкәндә язучы халкы, иң ышанычлы таянычы итеп, Закир абзыйга мөрәҗәгать итә, ул исә беркайчан да язучыны кире борып чыгармый иде.

Минем гозеремне тыңлагач, Тинчурин нәшриятның производство бүлеге мөдире Исмәгыйль Хәлиуллинны дәштереп алды.

— Әйтче әле, нишләп шылай озак чыгармый яткырасың Гомәр иптәшнең повестен? — дип сорады.

Хәлиуллин бер Тинчуринга, бер миңа карап икеләнеп торды да, ишек төбендә бераз таптангач, күрәсең, турысын әйтергә мәҗбүр булгандыр:

— Соң, Закир Вәлиеч, заманасы шундыйрак бит инде. Үзегез беләсез, бастырган бер китабыбыз бракка чыгып бара. Нинди китапны чыккач нинди язмыш көткәнне алдан ук каян беләсең? Монысы да шулай...— ди башлаган иде, Тинчурин аны тыңлап та бетермәде.

— Ни сүлисең юкны! Штобы озакламыйча китап минә шушында булсын! — дип, дәү кулы белән өстәлгә сукты.

Закир абзыйга мең рәхмәт, авыр туфрагы җиңел булсын! Озак та үтмәде, «Сиваш» повесте, кызыл тышлы җыйнак кына китап рәвешенә кереп, кибетләрдә сатыла да башлады.

Кайбер сәбәпләр аркасында миңа «Совет әдәбияты»ннан китәргә туры килде. Өстәмә берәр төрле җаваплы эш алмыйча, фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнү теләге дә юк түгел иде. Ләкин мондый хәлгә мин ул вакытта тиз генә күнегә алмадым. Моның кыенлыгы материаль кыенлыкта гына түгел, мәгълүм бер җаваплы вазифа үтә-

мәгәндә үзеңне беркемгә дә кирәге булмаган сәләтсез, уңмаган бәндә кебегрәк хис кыласың икән.

Билгеле, эшсез калу тормышка һәм язу эшенә тискәре тәэсир итте. Азмы-күпме акча эшләү өчен хикәяләр дә тәрҗемә итеп карадым, кульъязмаларга эчке рецензияләр дә язгаларга туры килде. Кайчакларны нәшрияттан, я журнал редакциясеннән чиле-пешле кульъязмаларны «денгә кертергә» дә биреп җибәргәлиләр иде. Ләкин андый сирәк-мирәк кенә эләгә торган очраклы гонорар белән генә, русча әйткәндә «подножный корм»да гына тормышны алып бару җиңел түгел, гаиләдә яшь бала да бар, ул елларны «дүрт кашык күтәрә» башлаган идек инде.

Ике-өч ай әнә шулайрак узды. Бер көнне «төшемлерәк эш» эзләп белеш-танышларга сугылгалап йөргәндә, Закир абзый Тинчурин мине нәшриятның коридорында очратып кабинетына чакырды.

— Я, ничек тормышлар, ниләр язып ятасың? Эшләр кай тирәдә? — диде. Ул минем тормышымның ни хәлдәрәк булуын яхшы белә, әмма ул якка басым ясамый, юри ачык чырай, күтәренке күңел белән сөйләшә иде. Закир абзыйның шактый ук нык холыклы кеше булуын, изелеп төшүне яратмавын истә тотып, мин дә зарланмадым, шулай да дөресен әйттем. Ул авыз эченнән .«һм, һм...» дигәләп уйланып утырды да:

— Ярамый болай, язарга кирәк, синең какраз язар елларың,— диде, миңа бер бит кәгазь сузды.— Матур әдәбият секторында редактор булып эшләргә ризамы?

Риза булмаган кая инде ул?

— Кирәк чагында әйтерсең, язарга да мөмкинлек тудырырбыз,— диде.

Мин рәхмәтләр укыдым. Шундый кыенлыклар кичергәндә аның эш урыны табып бирүе үзе дә зур ярдәм иде. Әмма минем әдәби әсәр язарга тиешлегемә басым ясавы, нәшрият җитәкчесе буларак минем нинди дә булса юньле әсәр язуыма ышануы аеруча рухны күтәреп җибәрде.

Икенче көнне үк эшкә керештем. Мин монда иптәшлекнең кадерен белүче, намуслы, эшчән һәм талантлы кешеләр арасына килеп кердем. Сугыш башланганчы Афзал Шамов, Ибраһим Гази, Хәсән Хәйри, Рахман Ильяс, Гази Кашшафлар белән бергә редактор булып эшләдем. Шул ук елларда укучылар белән дә ешрак очраша башладым. Язганнарымның сыйфаты, иҗат юлымның киләчәге турында уйланырга да бик вакыт иде.

## XVIII

Көндәлек дәфтәрдән.

«Габдулла Тукай халык шагыйреме?

Бу арада кайберәүләр шуның белән баш ваталар. (Чөнки юбилее якынлашып килә.)

— Соң халык аны күптән үз шагыйре дип таныган бит инде!

— Халык таныган анысы тануын. Ай-һай, ялгыш булмагае. Ә менә кем дә булса алай түгел дип чыкса?!

— Соң, алай ышанычы нык булмагач, үзе укып карасын иде!

— Бөтен бәла дә шунда шул: укый белү җитенкерәми...

Әй, Тукай, Тукай...» (14 март, 1938).

«Я, Тукай, шатлан, Тукай!

Бу арада синең бәйрәмеңне иттек. Шәп булды бәйрәм, һәйбәт булды. Син исән вакытыңда андый хөрмәтне, андый тантананы күрмәдең.

Кичә Академиядә[1] синең тантаналы кичәң булды. Театр бинасы «тутырук» иде. Балконнар, «күгәрчен ояларына» хәтле һәммәсе тулган иде. Син андыйны (исән чагыңда) күрә алмадың, Тукай. Синең бәгъ-

[1] Татар дәүләт академия театрында.

реңнән ташып чыккан моңлы һәм үткен, ялкынлы һәм тирән шигырьләрең әйтелгән саен зал котырынып кул чапты. Бу бит синең моңнарың, ялкыннарың әле хәзер дә исән, әле хәзер дә халык йөрәгенә барып җитә дигән сүз. Бу бит син әле хәзер дә яшисең дигән сүз!

Син чын укучыларыңны, шигырeңнең чын кыйммәтен, талантыңның олылыгын аңлаучыларны хәзер генә, безнең җәмгыятьтә генә таптың.

Юк, кояшым, мин беләм, син батмагансың мәңгегә;
Син дә, вөждан, бер торырсың, ятмагансың мәңгегә.
Юк! Түбән калмас бу җан: фитратта гали булган ул;
Кисмәк өстендә кара кош — иттифакый кунган ул!

Бик дөрес, Тукай.

Бөтен иҗатыңны бергә алганда син халык моңын, аның кайгысын, сагышын җырлагансың. Син аны бик тирән аңлагансың. Син вакытына күрә (халыкның дошманнарына каршы) зур күсәк күтәреп чыккансың һәм сугышкансың. Ялгыз бер шәхес өчен бик зур эш бу, Тукай. Шундый караңгы чорда тормыш хуҗаларына каршы кылыч айкап чыгуың һәм бөек талантың өчен зур рәхмәт сиңа, Тукай...» (16 апрель, 1938).

Башта шундый һәйбәт темалар йөри! Язасы иде. Әнҗе бөртекләре шикелле итеп тезеп кенә бирәсе, сокландырырлык итеп язасы, кешеләрнең йөрәкләренә үтеп керерлек, күз яшьләрен чыгарырлык, шатланып елмаерлык, көләрлек итеп, (кыскасы), укучы чын мәгънәсе белән ләззәтләнерлек итеп язасы иде». (Апрель, 1938.)

«Әдәбият өлкәсендә эшләүче, хосусан әдип яки шагыйрь, әгәр шул исемне алырга ул чыннан да лаек булган икән, вак-төяк, чүп-чар хисләрдән, кешенең кешелеген кимсетә торган гамәл һәм гадәтләрдән арынырга тиеш. Андыйлардан өстен торырга аның көче житәргә тиеш. Ул үзен тотуы һәм белеме белән бүтәннәргә үрнәк булырга омтылырга тиеш. Шулай булмаганда аның укучыны тәрбияләрлек әсәр язуы бик мөхаль эш». (22 сентябрь, 1938).

«Яңа хикәянең «пәрәвезен корырга» кирәк иде, уйлап бетереп булмый әле. Минем өчен иң кыены шул. Аннан калган ягы җае белән акрынлап барыр иде». (26 сентябрь, 1938.)

«Бүген радиода Гөлсем апа Сөләйманова җырлаганны тыңладык. Аның тавышы, минемчә, татар халык көйләрен җырларга, халык моңын бирүгә иң лаек тавыш. Ул халыкның моңын гына түгел, аның психологиясен, көнкүрешен, тарихын, нинди халык булуын, кыскасы, аның эчке дөньясын тирәнтен сизеп, аңлап, кичереп җырлый. Ул үзе җырлаган көй аша безгә халыкның эчке дөньясын ачып бирә. Тагын бер үзенчәлеге бар: ул сүзләрне музыкага буйсындырып җырласа да, аларның әйтелешен бозмый, тулы итеп, дөрес итеп әйтергә тырыша, кайбер башка җырчылар кебек, көйнең дөрес агылышын саклыйм дип, сүзләрне тегеләй дә болай гарипләндереп ташламый. Шуңлыктан без аны чын күңелдән яратып, сокланып тыңлыйбыз. Хәзерге чор өчен Гөлсем апа Сөләйманова — гади халык таләпләрен иң оста үтәүче җырчы. Классик музыканы аңлаучылар, әйтик, Моцартны, Бетховенны, Глинканы, Чайковскийны да тыңлыйлар. Халык күңеле иркен, һәркайсының үз урыны бар». (29 сентябрь, 1938.)

«Кызыл Татарстан»да минем «Көннәрнең берсендә» дигән хикәям турында мәкалә бар. Авторларның берсе Ф. Хөсни хикәя герое Нәгыймовны «кечкенә кеше» дип атый, аны «үтерә» һәм яңадан терелтә. Күрәсең, ул үзе «кечкенә кешеләр» турында язганлыктан, башкалар иҗат иткән кайбер персонажларны да шул үз калыбына салып үлчидер...

Нәгыймов «кечкенә кеше» түгел, «кечкенә кеше» ул бөтенләй башка. Аның өчен нәрсә хас? Ул үзен бик «кечкенә» итеп куя. Олы юлга чыкмыйча, сукмактан гына йөрергә ярата. Үзенең зур эшкә кушылып китмәскә тиешлеген, чөнки зур эшкә «зур кешеләр» барлыгын сизеп

яши. Ул «кечкенә» итеп уйлый, шул тар тормышыннан канәгать булып яши. Менә әдәбияттагы «кечкенә кеше!» (29 сентябрь, 1939).

«13 ноябрьда Тел, әдәбият һәм тарих институтында фольклор җыюга багышланган утырыш булды. Миңа да сөйләргә туры килде. Тел белгече һәм талантлы, зур белемле карт профессор Хуҗа Бәдигыйның да катнашуы, фикер әйтүе утырышны ямьләндереп җибәргән иде. Тәнәфес вакытында мин аның хәлен сораштым. (Марксизм-ленинизм институтында ул безгә татар теле укытканлыктан, мин аның белән күптән үк таныш идем.) Хуҗа абзый үзенең туберкулез белән авыруы, хәзер шул авыруның көчәя башлавы хакында сөйләде. Мин аңа бик борчылуымны белдергәч, ул: «Искитәрлек берни дә юк, мин аның белән күптән авырыйм, минем өчен яңалык түгел инде ул»,— дип әйтеп куйды. Күптән түгел эштән чыгуы, хәзер инде гыйльми эшләр белән өендә генә шөгыльләнүе турында сөйләп утырды.

Менә шул галимебез 17 ноябрьда иртән торып чәй эчкән дә, хәленең яхшы түгеллеген әйтеп, ятып торырга теләгән. Җәмәгате урынга яткыра гына башлаган икән, «мин үләм»,— дигән һәм мәңгегә күзләрен йомган.

Икенче көнне күмәргә бардык. Педагогия институты бинасында озату митингысы булды. Зиратка берничә профессор, байтак кына укытучылар, иллеләп студент барды. Бу галим татар теле һәм фольклоры өлкәсендә озак еллар эшләгән ихтирамга лаеклы кеше, зуррак хөрмәт күрсәтүне көтә иде. Алай ук булмады. Хәтта үзе укыткан студентларның да күбесе озата бармады, диделәр.

Бу хәл миңа бик күңелсез тәэсир итте. Менә бит, кеше яши, тырыша, фәнгә үзеннән күбрәк өлеш кертү өчен төннәр йокламыйча эшли, үзеннән соң гыйльми хезмәтләр калдыра. Бервакыт ул эш өстендә үлеп тә китә. Ә берәүләр шул остазларын күмәргә килүне дә кирәк санамыйлар.

Речьләр сөйләнде. Күмдек.

Шулай да бу үлем дигән нәрсә бик аяусыз. Кеше кадәр кешене секунд эчендә юк итә дә ташлый». (18 ноябрь, 1939).

«Изге күңлем кагъбәсеннән көн дә бер таш җимерелә...»

М. Гафури.

Мин пессимистмы? Юк, мин оптимист. Ләкин мин моңлы кеше. Нигә алай булдым икән?

Моның сәбәбен минем тормышымның кече яшеннән үк эзли башларга кирәктер.

Кечкенә вакытта мин кичләрен егетләр урамнан гармун уйнап узганда бик бирелеп тыңлап, озак вакытлар йоклый алмыйча, тәэсирләнеп ята торган идем. Безнең бакчада кичен һәм төннәрен, бигрәк тә таң алдыннан, сандугачлар сайрый иде. Димәк, минем күңелгә алар моңы да кушылгандыр.

Укый белә башлагач, кайбер әсәрләр миңа шулкадәр көчле тәэсир итәләр иде, ул көннәрне мин, китап йогынтысыннан арына алмыйча, сәерләнеп, хыялый бәндә кебек иләс-миләс йөри торган идем. Бигрәк тә миңа «Дим буенда» дигән әсәр, Галимҗан Ибраһимов хикәяләре көчле тәэсир итте.

Димәк, миңа моңны әдәби әсәрләр дә өстәгән булып чыга.

Үзем мөстәкыйль рәвештә яши башлаганчы миңа бик зур кыенлыклар аша узарга туры килде. Гражданнар сугышы да, аннан соңгы авыр еллар да — берсе дә мине башымнан сыйпап узмады. Бу кыенлыкларны мин йөрәгем аша уздырып бик авыр кичердем. Шулай итә-итә, күрәсең, шундыйрак бер уйчан, тирән кичерүчән бәндә килеп формалашкандыр — моңлы-баш.

Хәзерге заман өчен бу бик үк кулай сыйфат түгел. Ләкин, нишлә-

мәк кирәк, характерны тиз арада гына, ансат кына үзгәртеп булмый. Мин авыл идиллиясе белән мавыгучан кеше. Авыл табигатенең гүзәллеге балачактан ук минем каныма сеңеп калган. Табигать гүзәллеге минем карашымча матур күренеш кенә түгел, бәлки рухи азык, эстетик тәрбия чыганагы да.

Димәк, авылны үз итәм, авылның һәрбер күренеше, төсе, һавасы — бөтен табигате минем өчен газиз. Шәһәрне исә алай ук якын күрә алмыйм». (23 декабрь, 1939.)



## XIX

«Сиваш» әсәре басылып таралганнан соң мине укучылар белән очрашуларга ешрак дәшә башладылар. Шәһәр һәм авыл мәктәпләренә, китапханәләргә, техникумнарга һәм югары уку йортларына барырга туры килә иде. Язучыларның Габдулла Тукай исемендәге клубында яшь язучылар белән очрашканда профессор Латыйф ага Җәләй миңа шундый сорау бирде:

— Сезнең бу повестегызның идеясе нинди?

Мин берникадәр уңайсызланыбрак калдым. Чөнки әсәрнең идеясе һәм шуның шикелле нечкә нәрсәләр турында мәсьәләне болай ялангачландырып, «кабыргасы белән» кую һәрвакытта да көткән нәтиҗәне бирмәскә мөмкин. Идеясез әсәр булмыйдыр. Әмма ул шактый ук катлаулы мәсьәлә.

Авылларда йөргәндә ничектер туры килеп, бер укытучының әдәби әсәрнең ничек язылуы турында «китапча» сөйләгәнен ишеткәнем бар. Аныңча, язучының башында иң элек язасы әсәренең идеясе туарга тиеш. Шуннан чыгып ул әсәрнең планын төзи. Шунда ук сюжет якларын кайгырта, шахмат тактасындагы шикелле, бөтен әсәр буенча геройларын кайсын кая тезеп чыга. Менә шуннан соң инде каләм тибрәтә башларга да нәүбәт җитә...

Ихтимал, алай да була торгандыр, шулай язучылар да бардыр. Әмма, минем фикеремчә, язучы белән рәссамның яки композиторның иҗат процессы, мәсәлән, конструктор яисә галимнәр иҗат эшенә һич охшамаска мөмкин. Әсәрнең идеясе, планы һәм башкалары, күрәсең, төрлебездә төрлечә барлыкка килә торгандыр. Дөньяда ничә язучы булса, иҗат алымы да, башка яклары да шунча ук булырга мөмкин. Әдәби иҗат процессы кеше рухының шундый тирән, шулкадәр катлаулы, нечкә, каршылыклы бер күренеше ки, аны язучының дөньяга карашы, индивидуаль үзенчәлеге, иҗат алымы, яшәү мохиты һәм башка бик күп яклары белән исәпләшмәстән, ниндидер бер стандарт схемага сыйдырырга омтылу, минемчә, мәгънәсез бер көчәнү генә булып калырга мөмкин.

Әлеге очрашуда куелган сорауга мин ул вакытта бик гадел, ничек булса шулай җавап бирдем: «Әсәрнең идеясе турында алдан ук махсус фикер йөртмәдем, ә бәлки язылачак вакыйгалар, сугыш һәм характерлар турында уйладым, аларның нәкъ үзләренә генә хас сыйфатларын һич «төшереп калдырмыйча» мөмкин кадәр тулырак бирүне кайгырттым»,— дидем.

Латыйф ага Җәләй ул елларда тел, әдәбият өлкәсендә иң актив, иң популяр галимнәрнең берсе иде. «Сиваш» повестена беренче рецензияне дә ул язды. Җыелыш саен диярлек без аның «тозлы» мишәр сүзләре белән бизәлгән ярым шаян, ярым җитди нотыкларын бик яратып көлә-көлә тыңлый идек.

Латыйф аганың бу җыелыштагы чыгышы да тирән эчтәлекле булды. Ул минем фикерем белән килеште, әсәрнең идеясен дә төп-төгәл итеп әйтеп бирде. Мин иҗат вакытында язучының образлар белән уйлавына басым ясадым.

Ул, чыннан да, шулай булды. «Сиваш»ны язганда 1920 нче елда баштан узган сугыш күренешләре берсе артыннан берсе күз алдына килә башлады. Әмма ул вакыйгалар бик күп иде. Нигә һәммәсе турында да язарга икән? Ташу ташыганның ничек булуын күрү өчен, елганың башыннан тамагына кадәр бөтен яр буен йөреп чыгу хаҗәт түгел бит!

Сугыш маҗаралары белән бергә, сугышчылар үзләре, командирлар, политруклар күз алдына килде. Алар да шулай ук бик күп иде. Әмма мин алар арасыннан да үзем бик яхшы хәтерләгәннәрен, барыннан да бигрәк, нинди дер төссез, исемсез кешеләрне, гомумән теләсә нинди сугышчыны түгел, бәлки башкалардан үзгәрәкләрен, күзгә бәрелеп торырлык нинди дер аерым сыйфаты, холык-фигыленең үзенчәлеге булганнарын гына сайлап алырга тырыштым. Нинди бәрелешләр була да, минем геройларымның кайсы нинди сугышта һәм ничек катнаша? Аларның башларыннан нинди вакыйгалар уза? Холык-фигыльләре, үзенчәлекләре нинди бәрелешләрдә, ничек ачыла? Алар ниләр кичерәләр, ни уйлыйлар, ничек сөйләшәләр? Шуларның һәммәсен дә кинодагы кебек кат-кат күз алдына китереп, күңелемнән кичереп яздым.

Иҗат иткәндә әдәбият-сәнгать кешесе гади сүзләр һәм чагыштырулар белән генә аңлатуы кыен булган нечкә һәм ифрат катлаулы уйланулар, сизенүләр, ярсу һәм ачынулар, кабыну һәм сүнүләр кичерә. Кайчакларны шундый сәер бернәрсә хис итәсең: әйтерсең, бөтенесен син үзең түгел, бәлки синең күңел түреңдә утыручы икенче «мин», «әдип мин» эшли: вакыйгаларны ул башлый, гаскәрнең баш командиры кебек, геройларны кайсын кая урнаштыра да бөтенесен ул хәрәкәткә китерә. Аларны сугыштыра, берсен җиңдерә, икенчесен җиңдертә, бер ишесен үтертә, бүтәннәрен исән калдыра. Һәммәсе булып та ул үзе уйлый, үзе кайгыра, үзе шатлана. Ул туган иле һәм халкы өчен дә, үзе һәм якыннары өчен дә мөкатдәслек дәрәҗәсендә торган яхшы уйлар, изге ниятләр белән яки ярсулы ачу белән рухлана, илһам канатында тормышның ыбыр-чыбырыннан югарырак күтәрелергә, гади вакыйгаларны кеше рухына тәэсир итәрлек, онытылмыйча озак яшәрлек поэтик матурлык дөньясында күрергә омтыла. Ул «эчке әдип» кайчакларны әсәрдәге вакыйгаларны шулкадәр тирән кичеренә, аның хәтта шатлыгыннан сикергәлисе, биисе килә башлый, геройлары булып кайгырганда аның күзеннән яшьләр чыга.

Әгәр шундый чакта иҗади хыялга бик артык иркенләп китәргә ирек бирмичә «аек акылны» эшкә җиксәң, ул, мөгаен, һәммәсен дә тормышның нәкъ үзендә булганча, кәфен-кәфкә, кафын-кафка китереп, «чын дөресен» генә язарга тотыныр, нәтиҗәдә, тагын бер коп-коры җансыз нәмәстәкәй барлыкка килер иде. Ләкин әдәби әсәрдә тормышның нәкъ үзен теркәп бару үзмаксат түгел бит, анысы елъязма эше. Яшәеш вакыйгалары язучыга поэтик образлар тудыру, кешенең зурлыгын, кеше күңелендәге биеклекне, матурлыкны, олы җанлылыкны мөмкин кадәр тулырак, камилрәк, кеше рухына тәэсир ясарлык итеп ачып салу өчен ярдәмче булып хезмәт итәләр. Чөнки әдәби әсәр асылда әнә шул поэтик эчтәлекне укучыга җиткерү өчен языла да инде. Шулай булгач, күңел түрендәге әлеге «әдипне» үз иркенә кую кирәк булып чыга. Ул чынбарлыкта булып узган, бөтенләй булмаган, әмма булуы ихтимал тоелган, уйлап табылган күп төрле вакыйга һәм хәлләрнең бер төрлесен берникадәр зурайта төшеп, бүтәннәрен кечерәйтеп, бер ишеләрен яп-якты итеп, матурлап, калганнарын күләгә урынгарак чигереп, ягъни үз зәвыгына буйсындырып үзгәртеп күрсәтер. Әгәр дә син «әдипкә» чын күңелдән ышанып, аңа барлык эч серләреңне ачып, күңелең хәзинәсен бөтенләе белән аның карамагына тапшырсаң, ул синең ышанычыңны аклар, «аның» теләге, фикерләре, хисләре, сүзләр булып, синең кулың аша түгелми-чәчелми кәгазьгә тезелеп китәрләр. Нәтиҗәдә,

аслы тормышка нигезләнгән, тарихи яктан дөрес язылган, әмма язучы күңелендә тормыш хакыйкатеннән күтәрелеп китеп, сәнгать хакыйкатенә якыная төшкән бөтенләй яңа бер дөнья, поэтик образлар дөньясы килеп туар.

Көз көннәрендә без алма, груша, чия, миләш, йөзем кебек җимешләрне аерым-аерым да, бер тирәгә җыелган хәлдә дә еш күрәбез. Ләкин бу хәлдә алар безнең игътибарыбызны әллә ни җәлеп итә алмыйлар. Тәмле булу ягыннан гына кызыктырсалар инде. Менә шулардан ук талантлы рәссам яхшы натюрморт ясаса, без инде аңа сәнгать әсәре буларак сокланып карыйбыз.

Әдәби иҗатның нидән гыйбарәт булуын, максатын Американың мәшһүр язучысы Э. Хемингуэй, бик үзенчәлетеп, болай аңлаткан иде: «Тормышта чын-чыннан булып узганнардан чыгып һәм чынбарлыкның үзендә ни булса, шуңа таянып, янә дә шуларга үзең белгәннәрне һәм берничек тә белә алмаганнарыңны кушып, хыял ярдәмендә боларның күчермәсен түгел, бәлки чынлыкның үзеннән дә чынрак булган яңаны иҗат итәсең. Син ул яңага җан өрәсең. Әгәр дә үз эшеңне яхшы башкарсаң, җан өреп кенә калмыйсың, бәлки аңа мәңгелеккә юл ачасың. Менә ни белән рухланып язасың. Мин шуннан башка сәбәпне белмим. Бәлки беркем дә белми торган бүтән сәбәпләр дә бардыр?»

Өстә әйтелгәнчә, әдәби әсәрне язу фикере һәм аның идеясе бик төрлечә туарга мөмкин.

Минем үземә язачак әсәрләремнең идеясен һәм темасын беркайчан да «түшәмнән» эзләп утырырга туры килмәде. Аларның һәммәсенең дә беренче яралгылары тормышның үзеннән «борынлап» чыга иде. Ләкин моның өчен сине нидер тетрәтергә, борчырга, гаҗәпләндерергә, сокландырырга яки ачуыңны чыгарырга тиеш! «Әни» дигән хикәямне язу теләге көз көне Азнакай якларында урман буеннан узып барганда уянды. Каты җилдә карт агачлар шыгырдый, шулар арасында янгыр астында утынга килгән начар гына киемле бер хатын-кыз йөри иде. Бу күренеш` мине нигәдер дулкынландырды, уйларымны балачакка алып китте, авыл ярлыларының урманнан күтәреп утын ташулары, аларның кызганыч тормышы күз алдыма килде. Бераздан шул уйларга, кичереүләргә бүтәннәре кушылып, барысы бергә куера торгач, шуннан хикәя килеп туды.

Гражданнар сугышы чорының романтикасы мине «Сиваш»ны язганчы да, аннан соң да һаман дулкынландырып торды, әле хәзер дә шулай. Бу турыда нидер язасым килеп йөри идем. Әмма ничектер башкачарак, атыш-үтерешләрне, шау-шуны, сугыш гөрелтеләрен кертмичә, ниндидер тынычрак урында тирән кичерешләр, кешеләрнең нечкә күңел кыллары чиертелүен бирәсе килә иде.

Бу хакта хикәя язу теләге миндә беренче мәртәбә Мари республикасы белән ике арадагы мәшһүр Илләт урманында уянды. Ул тирәдәге Кече Әтнә, Шурабаш һ. б. авыллардагы дусларым, танышларым хикәядәге вакыйгаларга охшаганрак төрле тормыш хәлләре сөйләгәннәр иде. Шуларның һәммәсеннән чыгып тора-бара «Кунак егет» дигән хикәя язылды.

Әгәр дә мин «Намус» романының язылуына ике-өч тәүлек килмичә көттергән Кама пароходы сәбәпче булды дисәм, билгеле, бу бик сәер ишетелер. Әмма монда дөреслек бөтенләй ук юк түгел [1].

Шул рәвешчә, әсәрнең идеясен кәгазеңнең беренче битенә үк язып куясыңмы син яки ул иҗат процессында «үзеннән-үзе ачыкланамы, минемчә, ул ягы әллә ни әһәмиятле түгел. Төп хикмәт аның әсәрдә бар булуында һәм үз чорының иҗтимагый философиясен мөмкин кадәр көчлерәк, тулырак чагылдыруында. Әсәрнең идеясе, ахыр чиктә, язучының дөньяга карашы ул. Аны ракетаның ягулыгы белән тиңләргә

[1] Кара: Әсәрләр, I том, «Бу әсәр ничек язылды».

мөмкин. Ягулыкның нинди булуы тыштан бөтенләй күренми. Әмма асылда төп көч шул бит, ракетаны ягулык хәрәкәткә китерә, омтылган максатка шул алып бара.

## XX

Баштарак мин ничек тә «матуррак» язарга тырышадыр идем шикелле. Купшы, яңгыравыклы сүзләр, күперенкерәк чагыштырулар белән чәчәкләбрәк, күтәренке тонда, тантаналырак итеп язсаң, һәрхәлдә, шәбрәк чыгар, сүзнең сәнгатьчә көче ачыларак төшәр кебек тоела иде. Ихтимал, бу минем туган телнең асыл сыйфатларын, аның нечкәлекләрен һәм мөмкинлеген кирәгенчә белеп җиткермәвемнән дә килгәндер. Ихтимал, баштарак тәҗрибәм дә, тел байлыгым да азрак булгандыр. Ихтимал, «матур» язарга тырышу Көнчыгыш әдәбияты йогынтысының үзенә күрә бертөрле кире ягы белән чагылуы да булгандыр.

Мәгълүм ки, татар халкының культурасы XVIII гасырның азагына кадәр күбесенчә, Көнчыгышка йөз тота иде. Әле шушы гасырның беренче ун елына, дөресрәге, революциягә кадәр мәдрәсәләрдә дин сабакларын гарәп һәм фарсы телендә укыдык. Бай һәм, гомумән, өстен катлау балалары, югары белемне элек-электән күбесенчә Төркиядә, Мисырда яисә башка берәр Көнчыгыш илендә укып ала торган булганнар. Хәер, ул вакыттагы татар яшьләренең Россиядәге югары уку йортларына кермичә, Көнчыгышка китүләренең җитди сәбәбе дә булган. Патша хөкүмәте «инородец» дип йөртелгән азчылык милләт халыкларны Россиянең югары уку йортларына алырга рөхсәт итмәгән. Шунлыктан, югары белем алырга омтылучылар Көнчыгыш уку йортларына китәргә мәҗбүр булганнар (мәсәлән, язучылардан Муса Акъегет, Шәриф Камал h. б.).

Шулай булгач, Көнчыгыш әдәбиятының, бигрәк тә аның көчле, бай поэзиясенең татар әдәбиятына йогынты ясавы бик табигый. Чөнки борынгы Эллада сәнгате заманында Европа халыкларына нинди көчле тәэсир иткән булса, Көнчыгыш поэзиясе дә элекке мөселман халыкларга шулай ук көчле йогынты ясады. Алай гына да түгел, Көнчыгышның Гомәр Хәйям, Фирдәүси, Низами, Һиндстанның Рабиндранат Тагор кебек бөек шагыйрь һәм әдипләре поэзия дөньясын моңарчы Европа әдәбиятлары ирешмәгән югары баскычына күтәрделәр һәм дөнья шагыйрьләренә кайбер яктан үрнәк булдылар.

Гомумән, революциягә кадәр Көнчыгыш әдәбияты бездә ярыйсы ук зур урын тота иде. Көнчыгыш әдипләренең байтак кына популяр әсәрләрен, мәсәлән, Әбугалисина турындагы хикәяләрне, гарәп халкының мәшһүр «Мең дә бер кичә»сен h. б. бик күпләрне без революциягә кадәр үк татарча тәрҗемәдә укый идек. Без, ул вакыттагы балалар, кечкенәдән үк гарәп һәм фарсы сүзләренең яңгырашына күнегеп үстек. Догалар гарәпчә укылды, мөнәҗәтләр дә фарсы яки борынгы төрки телләрдә көйләнде. Шуның өстенә, безнең үз язучыларыбызның да күбесе элегрәк елларда гарәп, фарсы һәм төрек сүзләрен күп кулланып, шактый ук чуар телдә яза торганнар иде.

Безнең халыкның иң борынгы һәм иң яратып укыган әсәрләреннән «Йосыф — Зөләйха» поэмасының һәм башка бик күп танылган әсәрләренең Көнчыгыш поэзиясенең көчле йогынтысында язылган булуы да һәркемгә билгеле.

Мин белгән, мин укуга ирешкән Көнчыгыш әдәбияты миндә соклангыч бер шигърияттлек, сәмави гүзәллек тәэсире калдырды. Көнчыгыш әдәбиятын төрле төстәге нәфис чәчәкләре, без күрмәгән һәм тәмен дә татып карамаган ләззәтле җимешләре белән хуш ис бөркеп торучы гүзәл бакчаларга охшатырга мөмкин. Мин укыган китапларда иң соң-

гы чигенә кадәр житкерелгән, әкиятләргә генә хас шартлы матурлык бик көчле иде.

Ә безнең халыкның тормышы, аның яшәү рәвеше исә, моңа капма-каршы буларак, шактый ук кырыс, хәтта кирәгеннән артык «реалистик» иде. Мәгълүм булганча, бездә шәфталу белән хөрмәләр дә, йөзем һәм башка «җәннәт» җимешләре дә үсми. Бездә зифа сынлы гүзәл җәйраннар да, алтын койрыклы тавис кошлары да юк. Табигать безне иркәләми, ул безгә тиеген килә торган рәхәтләрен, юмарт байлыгын да андагыча күпләп бүләк итмәгән. Урта һәм төньяк Россия кешеләренә яшәү өчен көн-төн көрәшергә, бөтен кирәген бил бөгеп, тырышып, маңгай тирен түгеп эшләп табарга туры килә. Шулай булганлыктан, олыгая, аңлап укый башлагач, мин Көнчыгыш әдәбиятында язылганнарның күбесен чынбарлыктан бик ерак торган, бары тик әдәбиятта гына була алырдай хыялый бер матурлык итеп кенә күз алдына китерә идем.

Әмма матур хыял дөньясы яшь күңелләрне җилкендерүче иң мавыктыргыч көчләрнең берсе түгелмени? Гарәп халкының сокландыргыч әсәре «Мең дә бер кичә» кемнәрдә генә якты хыяллар уятмаган? Каюм Насыйриның шәрык галиме мәшһүр Әбугалисина турындагы хикәяләрен укыганнан соң гомергә яшь һәм матур булып калу, бернинди патшаларга һәм залим көчләргә бирешмәслек акыллы һәм зирәк булу турында кемнәр генә хыялланмады икән?

Яшь вакыттагы шушы романтик күтәренкелекнең онытылмаслык булып истә калуы, нинди дер рәвештә телгә дә, язасы әсәреңә дә тәэсир итүе һич тә гаҗәп түгел. Сентиментализм тәэсире безнең татар әдәбиятында башка язучыларда да теге яисә бу формада, гомумән, сизелгәләп ала иде.

Мәгълүм ки, татар халкы борын-борыннан руслар белән аралашып яшәгән. Шунлыктан, рус культурасының татарларның иҗтимагый фикере үсешенә көчле йогынты ясавы бик табигый. Шул сәбәпле булса кирәк, Көнчыгыш культурасының әдәбиятка һәм гомумән бөтен культура өлкәсенә тәэсире ярыйсы ук көчле булса да (өстәвенә, әле ул ислам дине белән дә бәйләнгән иде), рус әдәбиятының реализмы безгә бик тиз күчте. Шуның өстенә, реализм чынбарлыкның үзеннән туганлыктан, безнең әдәбият исә элек-электән халык тормышына якын торып, аның уй-фикеренә җавап биреп килгәнлектән, реализм безгә үзенең асылы, эчке рухы белән дә якын булган дип әйтәсе килә. Күрәсең, без аны шул сәбәпле дә тиз үзләштергәнбез. Бу юнәлеш татар әдәбиятына чагыштырмача кыска гына вакыт эчендә ярыйсы ук алга атларга мөмкинлек тудырган дип уйлыйм.

Алдарак әйтелгәнчә, күп кенә әдәби очерклар һәм «Соңгы сугышу», «Әни» кебек әсәрләрдән соң «Сөлекләр», «Көннәрдән бер көнне», «Урман шаулый» янә башка исемдә хикәяләр һәм «Сиваш» повестен яздым. Аларның һәммәсен дә матбугатта берсүзсез бастылар, кайсыларын бераз мактадылар, кайсыберсен аз-маз тәнкыйть итеп тә алдылар. Гомумән алганда, ул әсәрләрем турында укучының да, тәнкыйтьнең дә фикере уңай булды. Әмма үземә килгәндә, бу язганнарым миндә тирән канәгатьлек хисе, башка берни белән дә чагыштырып булмаслык, зур мәгънәсендәге иҗат шатлыгы тудырып җиткерә алмадылар. Язганда шулай кирәклегенә чын күңелдән ышанып, чын-чыннан мавыгып язсам да, әсәр басылып чыкканнан соң, күңелдә ниндидер бер канәгатьсезлек хисе кузгала торган булды. Бу хикәяләремнең әдәби сыйфаты үзем яза алганнан, миндә булган иҗат мөмкинлекләреннән күп өлеш түбәнрәк кебек сизә идем. Сәбәбе нәрсәдә икән? Әйтергә теләгән уй-фикер белән аның әдәби гәүдәләнеше арасында нилектән, ни сәбәптән мондый аерма килеп чыга? Шунда әллә йөзенче, әллә меңенче мәртәбә тагын әлеге шик уяна торган иде: бәлки, мин бу язу эшенә юкка гына керешкәнмендер?

Әнә шундый күңелсез уйларга, шик-шөбһәгә бирелеп, моның сәбәпләре турында баш ватып, язарга кул бармаган чаклар да булгалады.

Күбрәк иҗат канәгатьлеге китергән, күңелдәгечә язылган беренче әсәрем «Кунак егет» исемле хикәям булды. Белгәнебезчә, әниләр үз балаларының һәммәсен дә яраталар. Ләкин кайвакыт арадан берсен артыграк та ярата торган булалар. Биредә дә нәкъ шулай. Бу хикәямдә мин үземне-үзем «таба» башладым шикелле. Шуның җимеше буларак, дөньяны танып белүемне: тормыш тәҗрибәмне, Ватанга һәм халыкка булган мәхәббәтемне бу хикәямдә, бүтәннәре белән чагыштырганда, берникадәр тулырак, көчлерәк итеп, кыскасы, үзем теләгәнгә якынрак итеп бирә алдым кебек. Бу әсәремдә бөтен язылганны ягымлы бер күңел җылысы белән, мәхәббәт белән җылытып, халыкның уйлары, яхшы гадәтләрен сөйкемле, лирик буяулар ярдәмендә әйтеп бирергә омтылып карадым.

Бу хикәядә авторның психологик анализга, геройның холык-фигылен, гомумән, аның кемлеген эчке яктан ачарга, аның күңелендәге кичерешләрне тирәнрәк тасвирларга омтылуы да ачыграк күренә башлады шикелле.

Шулай да «чын» язучы булу өчен тагын нидер җитми, «әдип» дигән зур җаваплы исемне бу әсәрләрем генә аклап җиткерми кебек иде әле.

Сәбәбе нинди генә булмасын, «матур» язарга омтылуыма карамастан, әсәрләремнең теле дә корырак булып чыга, аңа ягымлылыкмы, лирик җылылыкмы, нәрсәме җитенкерәми шикелле иде. «Бу нәрсәдән икән?» — дип уйланган, аның сәбәбен эзләгән чаклар да күп булды.

Күрәсең, тормыш үзе дә акыл биргәндер, газетада эшләгәндә халыкның сөйләм теленә соклануым да шул ук нәтиҗәгә китергәндер. 1938—40 елларда шул «җитмәгән» нәрсәне эзләп авылларда йөрдем. Билгеле, А. М. Горькийның акыллы киңәшләре дә этәргеч булгандыр. Ул язучыларның беренче съездында нәкъ шул хакта сөйләп, үз халкыңның авыз иҗатын тирәнтен өйрәнү әдәбиятны тагын да югарырак баскычка күтәрү өчен иң әһәмиятле чаралардан берсе икәнлеген искә төшергән иде.

Ул вакытта мине безнең әкиятләрнең җыелмаган булуы, Каюм Насыйридан соң, Г. Толымбайскийдан башка, фольклор җыю белән берәүнең дә җитди рәвештә шөгыльләнмәве дә бик борчыды. Хәлбуки, әкият белүче борынгы картлар һаман кими тора, алар белән бергә халыкның күңел җәүһәрләре дә мәңгегә югала бара иде.

Авылларда йөри торгач, Минһаҗ Хәмидуллин, Мөхәммәтша Дәүләтшин [1] кебек берничә талантлы әкиятче таптым. Алардан һәм башка сәләтле кешеләрдән моңарчы матбугатка чыкмаган илледән артык әкият язып алдым. Болар арасында моңа кадәр билгеле булмаган яңа сюжетлар да байтак иде. Халык әкиятләрен 1940 елда аерым китап итеп чыгардым.

Фольклор җыю мине торган саен ныграк мавыктыра барды. Шул еллардан башлап мин җәй саен СССР фәннәр академиясе Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор экспедициясендә катнаша башладым. Оста әкиятче сөйләгәнне үз колагың белән ишетеп, шуны түкми-чәчми кәгазьгә төшерү үзе бер рәхәт иде. Тукай замандашы Дәрдмәнднең мәшһүр дүртьюллыгының хикмәтле мәгънәсен шушы елларда тагын да тирәнрәк аңладым.

Урамнан һәм базардан чүплә сүзне,
Алар бетмәс борын барма еракка!

---

[1] Икесе дә Саба районыннан: М. Хәмидуллин — Максабаштан, М. Дәүләтшин — Мамалай авылыннан.

Тупас та булса тел илнең колагы,
Уенны уйдырып сал шул колакка[1].

— диган иде ул.

Безнең әдәбиятта халыкның сөйләм телен берәүнең дә бу дәрәҗәгә күтәргәне юк иде әле. Киләчәкнең әдип һәм шагыйрьләренә чын күңелдән васыять итеп әйтеп калдырган онытылмаска тиешле кадерле дүртьюллык бу!

«Уйларыңны ил колагына уйдырып» салу өчен телең сүзләргә бай булырга, шуннан тыш, халык теленең кайсы якта нинди үзенчәлеге барын, кайсы сүзнең кайда ничек әйтелүен һ. б. шундый күп нәрсәне дә белергә кирәк иде. Тора-бара оста телле кешеләрнең, гомумән, халыкның сөйләм телен игътибар белән тыңлау, аны өйрәнү гадәтемә әверелде. Телебездәге төрле шивәләрнең[2] дә үз хасиятләрен, үзләренә генә хас шигъри бизәкләрен табарга ихтыяҗ туды. Әтнә ягында Әгерҗе ягында ничегрәк сөйләшәләр? Тау ягы халкының яки Ык буенда яшәүчеләрнең телендә моңа кадәр әдәбиятка кермәгән нинди үзенчәлекләр яшеренеп ята? Яки Әлбәден, Алабуга ягы Кибәч керәшеннәренең теле ниндирәк?

Әсәреңнең теле бай булсын, үтемле булсын дисең икән, боларның һәммәсен дә белергә кирәк иде.

Авылларда йөргәндә җыелышларга һәм утырышларга, концертка йөрүчеләр кебек, тел осталарының чичән сүзен, матур итеп сөйләвен ишетер өчен генә барган чакларым да булды.

Бервакытны миңа Буа районының Шәйморза авылында өлкән яшьтәге бер картның җыелышта сөйләвен тыңларга туры килде. Сүз анда гади хуҗалык эшләре турында гына бара иде. Әмма ул агай һичбер сүз кыстырмыйча, берникадәр мишәр акценты белән шундый күңелләргә үткәреп, шундый матур итеп сөйләде, аны бөтен җыелыш тын да алмыйча тыңлады.

Икенче бер вакыт Олы Тархан авылында ике апаның үзара сөйләшкәндәге интонация байлыгы да минем өчен зур ачыш булган иде. Гаҗәп бит! «Соң» дигән гади генә бер сүзгә алты-җиде төрле мәгънә салып була икән!

Теленең байлыгы, сөйләвенең осталыгы белән сокландыручылар болардан башка да күп очрады. Минем өчен бу яңа хәзинә ачу белән бер иде. Менә кайда саклана халыкның күңел җәүһәрләре! Яхшы җыр кебек үзеннән-үзе чигелеп кенә барган бу нәфис сүз нәкышенең һәр бизәген отып каласым килде. Сүзләрнең кайчан ничек әйтелүенә, сөйләмнең сизелер-сизелмәс кенә тибрәнеп барган эчке көен күңелгә сеңдерергә тырыштым. Чөнки кешенең сөйләве ул сүзләр тезеп бару гына түгел, юк, ул халыкның акылының һәм сәнгатьчә фикерләвенең көзгесе булып та хезмәт итә.

Болар һәммәсе дә минем иҗат эшемдә бик кирәк булып чыкты. Халык иҗатын, сөйләм телен өйрәнү телемне баетты, халык поэзиясенең чыганакларына якынайтты, әйтәсе килгән фикерне артык чуарламыйча, гади сүзләр белән генә әйтеп бирергә ярдәм итте.

Телдә гадилек димәктән, тора-бара мин матурлыкның гадилектә булуын тирәнрәк төшендем.

Яшүсмер чакта Лев Толстойның гади халык өчен язылган кечкенә хикәяләрендәге сүзләрнең гадилеге, ә фикеренең тирәнлеге мине бик гаҗәпләндерә иде. Габдулла Тукайның да кайбер шигырьләре бигрәк тә шул ягы белән күңелгә сеңеп калды. «Туган тел» һ. б. кайбер шигырьләрен ул бик гади итеп яза. Мәсәлән:

---

[1] Дәрдмәнд. Иса җилләр. Шигырьләр. Истәлек-парчалар. Вак хикәяләр. Казан. Татарстан китап нәшрияты. 1980. 101 бит.

[2] Шивә — диалект.

Тау башына салынгандыр безнең авыл,
Бер чишмә бар, якын безнең авылга ул;
Авылыбызның ямен, суы тәмен беләм,
Шуңар күрә сөям җаным-тәнем белән.

— дип яза ул.

Болар барысы да көндәлек тормышта кулланыла торган гап-гади сөйләм сүзләре. Әмма шагыйрь аларны берсен икенчесе янына шундый оста китереп тезә, бу гади сүзләр безне дулкынландыра, алардан ниндидер хикмәт һәм акыл нуры балкыйдыр кебек сизелә башлый.

Гади сүзләр тормыш тәҗрибәсе белән, халык аңындагы тирән мәгънәле хикмәт һәм шигърият белән баетылганга күрә шулай көчле булалар икән.

Промышленностьта яки авыл хуҗалыгында эшләп чыгаруны арттыру хакында сүз барганда эчке резервлардан кыюрак файдаланырга өндиләр. Халык сөйләме әдәби телнең әнә шул эчке резервы инде ул. Ул резерв бик бай һәм аның төрләре дә бик күп.

Шуның өстенә, ул тере организм кебек, ил тормышы белән бергә сулыш ала, берөзлексез үзгәреп, яңарып тора. Хәзерге тормышта, көнкүрештә кирәге калмаган — искергән сүзләр телдән төшеп кала, алар урынына хәзерге заман таләп иткән яңа сүзләр, яңа тәгъбир, яңа әйтемнәр туып тора.

Халыкның сөйләм телен һәр җирдә игътибар белән тыңлау, аны өйрәнә бару миңа әнә шул җитди үзгәрешләрне вакытында белеп торырга, әсәрләремдә һәрдаим алардан файдаланырга мөмкинлек бирде.

Көндәлек дәфтәрдән:

«Бүген 1941 елның 7 гыйнвары. Димәк, миңа 40 яшь тулды. Ай-һай гомер күп узган! 40 ел бит, 40 ел! Искиткеч! Бу бит бер кеше гомере! Бу бит гомереңнең күп өлеше, яртысыннан күбрәге узып киткән дигән сүз! Бу яшькә җиткәндә кеше үзенең нинди дә булса бер аңа гына хас сыйфатын, нинди дә булса бер җитди хезмәтен күрсәтергә тиештер бит! Ул үзенең вөҗданы алдында сорау куярга тиеш: «Йә әле, иптәшкәй, әйт әле, дөньяда әниең тудыру сәбәпле генә яшәмәвеңне, бәлки чын кеше булып, кешелегеңнең мәгънәсен аңлап яшәвеңне, үзеңне табигатьнең иң югары баскычта торучы иң катлаулы заты итеп аңлавыңны аклярлык ниләр кылдың? Кешелек җәмгыяте синнән соң тагын күпмедер алгарак атларга тиешлеген аңлап яшисеңме? Кем син — «кеше» дигән бөек исемне йөртүче? Бу сорауларга мин әле авыз тутырып, үземне канәгатьләндерерлек җавап бирә алмыйм. 40 елның аз дигәндә 10 елы күңелдәгечә узмаган. Ул ун елны мин җәмгыять өчен ун кәррә[1] файдалырак итеп уздыра алган булыр идем... Язучы исеме миңа тышкы яктан гына ябышып тормасын, миңа чын-чыннан лаеклы исем булсын! Моның өчен бик тырышып эшлисе бар».

«Кайвакыт яза торгач әллә ардыра, әллә туйдыра, берәр акыллы кеше белән сөйләшеп утырасы килә башлый. Ярый ла янында шундый кеше булса! Булмаса? Булмаса, китапка тотынасың. Ләкин кулыңа алган һәр китап синең кәефеңә туры килә алмый. Кайсында сентиментальлек эчне пошыра, бүтәннәрендә акыл, фикер бик сай була. Андыйлар җанга азык бирә алмый.

Нидер эзләнеп урамга чыгып киттем. Яңа Бистә күпере янында Идел суының ничек чигенүен карап тора идем, бер танышым килеп чыкты. Аның белән моннан унбиш еллап элек бергә укыган идек. Хәзер ул заводта эшли икән. Өстендә гади эшче киеме. Юл өстендә кара-каршы басып әллә ни гомер сөйләшеп тордык. Нәрсә сөйләштек? Җыен вак-төяк тормыш маҗаралары турында. Менә бит хикмәт! Гаҗәп күңелле булып китте, җанны борчыган нәрсәләр, кәгазь өстендә хәл ителмәгән мәсьәләләр — һәммәсе каядыр очты, борчымый башлады.

[1] Кәррә — тапкыр.

Гаҗәп серле дә, бик катлаулы да бу адәми зат! Кайвакыт үзеңнең ни теләвеңне дә, рухи хәзинәңдә ниләр яшеренеп ятуын да белә алмыйсың». (Апрель, 1941).

Көндәлек дәфтәрдән:

«Сугыш, сугыш!

Башлану ихтималы искә төшкән саен сискәндергән сугыш, «тегеләй булыр, болай булыр» дип күптән үк телләрдә йөргән каһәр төшкән сугыш шушы бит инде!

Ләкин дошман без уйлаганнан көчлерәк тә, явызрак та булып чыкты. Ул безнең илгә хыянәтчел рәвештә басып кереп хатын-кызларны, балаларны аса-кисә, юлындагы барлык нәрсәне җимерә, яндыра, талый башлады. Ул хәтта иң примитив, иң тәрбиясез бәндәләрдә була торган иң гади кешелек сыйфатларыннан да мәхрүм икән! Фашистлар күсәк күтәреп кеше өенә ташланган исерек гориллалар кебек кыланалар. Ул кабәхәтләрне бөтен дөнья халкы каргый, нәләт, нәфрәт яудыра.

Барлык ышанычыбыз, иң якты өметләребез — Кызыл Армиядә. Күзебез Көнбатышка текәлгән; аннан берәр куанычлы хәбәр килмиме? Фашистларның сырт сөякләрен сындырмыйлармы? Ничек кенә булмасын, безнең иманыбыз камил: фашизмга кабер казучы тәгаен без булырга тиешбез!

Ә хәзергә аяусыз көрәш, кан, көрәш!» (25 июнь, 1941).

1941 елның 22 июнь көнен мин Октябрь Норлатының кунакханәсендә каршыладым. Бу районга «Совет әдәбияты» журналының үтенүе буенча очерк язарга барган идем.

Иртә белән караңгылы-яктылыда ук коридордагы шау-шуга уяндым. Чыгып карасам, бөтен халык ярым-йорты киенгән килеш репродуктор янына җыелган. Һәммәсенең телендә бер генә сүз:

— Сугыш! Фашистлар Германиясе безгә бәреп кергән!

Шул сәгатьтә үк район хәрби комиссариатына барып, хәрби книжкада күрсәтелгәнчә, юлга түләүсез билет алдым да Казанга кайтырга чыктым. Ул вакытта Казан — Сталинград тимер юлы салынмаган иде әле. Ульяновскига кадәр поездда, аның бирге ягын пароходта кайтырга туры килде...

Көндәлек дәфтәрдән:

«Ульяновскида пароходка күчеп утырганда күптәнге танышым Ислам Фәйзуллинны очраттым. Ул Татарстан китап нәшриятында күп мәртәбәләр партия оешмасының секретаре булып сайланды, бер тапкыр минем «Сиваш» повестен да редакцияләгән иде. Каютага кереп бераз тамак ялгап алганнан соң:

— Ну, Гомәр, киттекме фронтка?! — ди бу.

— Әйдә, китәбез. Мобилизация булган бит инде. Ә без синең белән икебез дә запастагы политсостав. Шулаймы?

— Шулай! — Ислам шапылдатып өстәлгә сугып куя.— Сволочьлар! Менә нинди әшәке җан икән ул фашистлар! Прәме, подлецлар! Чебен урынына кырырга кирәк аларны, турарга кирәк!

Ул, янында утырган бер ханыммы, туташмы белән бер-ике сүз алыша да, тагын миңа дәшә:

— Менә, бергә эләгеп булса икән синең белән фронтка! — дип куя, матур итеп, чын күңелдән якын итеп елмая, ап-ак тигез тешләре күренеп китә, ике якка аерылган куе коңгырт чәчен сыйпап ала. Ислам Фәйзуллин тәскә-башка бик чибәр, мәһабәт гәүдәле кеше иде. Ул һәрвакыт ярым хәрби киемнән бик җыйнак киенеп йөри, хәрби кием, бигрәк тә комиссарлык аңа килешеп кенә тора, моны ул үзе дә белә иде шикелле. Ул хәзер үзендәге җилкенү, ашкыну хисен кая куярга белми. Бәлки, янында утырган чибәр хатын-кыз алдында менә дигән ир-егет булып күренәсе дә килептер:

— Бергә булсак, минем кулга эләккән тыловикларны биетәм инде мин! — дип куя, үзе шаркылдап көлә.
— Син фартовый егет. Синең белән фашистның иң ерткычына да курыкмыйча каршы чыгарга була! — дим мин аңа.
Аннары, палубада сөйләшеп кайта торгач, без аның белән сугыш беткәннән соң икебез бергә китап язмакчы булдык. Чөнки беренче көннәрдә без әле сугышның әллә ничә елга сузылачагын күз алдына да китермибез, фашистларны тиз арада кырып салачагыбызга чын күңелдән ышана идек. Ислам, дәртләнеп, шахтерлар тормышыннан төрле кызык вакыйгалар сөйләп ташлады. Ул егет чагында шахтада эшләгән икән.
— Материал миннән, язу — синнән! — диде.— Син яхшы әсәрләр яза аласың. Тик нигәдер бик сирәк язасың. Ә икәү тотынсак, мин сиңа тынычлык бирмәм! Юк! Мин хәрбиләрчә эшне коры тотармын! Слушай, давай болай итәбез!..— дип нидер әйтмәкче булган иде, ләкин яңадан фронтка китү турында сөйли башлады. Чөнки фашистларның безгә хыянәтчел рәвештә басып керүләре һич тынгылык бирми, ачы нәфрәт булып әледән-әле тышка бәреп чыга иде. Ислам дәү куллары белән минем иңбашыма сугып алды.
— Слушай, Гомәр! Әгәр фронтка бергә китсәк, син аны, кара! Әгәр дә мин фашистларга йомшаклык күрсәтсәм, син миңа пуля в лоб! Әгәр син йомшаклык күрсәтсәң, мин сиңа пуля в лоб! Понятно? Рәхим-шәфкать булмас!..
Без аның белән Аргы Устьеда шушы арада, бәлки иртәгә үк, военкоматта яңадан очрашасы кешеләр буларак, бик ансат, җиңелчә генә саубуллаштык. (Июнь, 1941).
Моның Ислам белән иң соңгы күрешүебез булачагын ул вакытта кем белгән?!
Шул бер тәүлек эчендә Казан бөтенләй үзгәргән, сугыш вакыты кыяфәтенә кергән иде инде. Урамнарда яңа хәрби кием кигән, аркаларына солдат капчыгы аскан яшьләр, сафларга тезелеп, вокзалга таба атлаучы колонналар еш очрый, нидер төягән йөк машиналары өзлексез агым булып пристаньга, вокзалга таба агыла, ирләрен, аталарын военкоматка таба озата баручы хатын-кыз, бала-чага төркеменә юлыгасың. Кыскасы, бөтен шәһәр хәрәкәткә килгән, кешеләрнең чырае җитди, ираннәре кысылган, бер генә көлгән, шаяртып сөйләшкән тавыш та ишетелми.
Соңгы өч-дүрт ел эчендә җәй саен хәрби лагерьларда хәзерлек узганнан соң, миңа өлкән политрук дәрәҗәсе бирелгән иде. Димәк, запастагы политик состав буларак, мин мобилизациянең икенче көнендә иртән военкоматта булырга тиеш идем.
Иртәгә китәсе дигән көнне бөтен кичне әниләре мине юлга хәзерләде, ә мин балалар янында уздырдым. Алар сугышның нәрсә икәнен аңларлык түгел иде әле. Кичләрен һәммәбез бер диванга сыенып берберебезгә я әкият, ә берәр кызык хәл сөйли торган гадәт бар иде. Ул кичне дә шул йоланы дәвам иттердек. Башта алты яшьлек кызыбыз кыска гына әкият сөйләде. Аннан соң, кешедән калышасы килмичә, дүртенче яше белән баручы улыбыз дә әкият сөйләргә булды.
— Әби менән бабай булган, имә, эти! Аларның бер кәзәләре булган, тагын бер ипиләре булган, имә?..— диде дә туктап калды.
— Шуннан соң ничек? — дибез.
Ул үз-үзеннән бик канәгать булган кыяфәттә авызын ерып:
— Бетте!..— дип кулларын чәпәп куя.
Без тешләрне кысып булса да елмайган булабыз. Әниләре юлга сохари киптереп, тегесен-монысын әзерләп йөргән җиреннән безнең якка колак сала да читкә борылып йөзен яшерә. Стенага элгән зур кара репродуктордан Юрий Левитан берничә сәгать саен Совет ин-

формбюросының соңгы хәбәрләрен әйтеп тора. Котырынган фашистлар армиясе шушы 2—3 көн эчендә өч мең километрга сузылган фронт буенча үз юлында очраган барлык шәһәр һәм авылларны яндырып, җимереп, бөтен җан иясен рәхимсез рәвештә кырып, меңнәрчә балаларны ятим калдырып хәтсез җирне басып кергән иде инде. Сугыш шулай дәвам итсә, бу сабыйларны киләчәктә нинди язмыш көтә? Ул дәһшәтле көннәрдә бу сорауга җавап табуы кыен иде әле.

Иртәгесен иртүк йоклап яткан балаларның башларыннан сыйпап, военкоматка киттем. Җәмәгатем капчыкка сохарилар, җылы оекбаш, кружка тутыра калды.

Урамда шул кичәге шикелле үк күренеш: китәләр, озаталар, нинди-дер йөк төялгән машиналар вокзалга, пристаньга таба агыла.

Бара торгач, Тукай урамы чатындагы баганага элгән зур кара тәлинкәгә-репродукторга колак салдым. Кызыл Армия йорты каршысындагы мәйданнан үзләре теләп фронтка китүчеләрнең хушлашу митингысын бирәләр иде. Арада «батальон комиссары Ислам Фәйзуллин» дигән исем колакка чалынды. «Нәкъ юлда сөйләгәнчә эшләгән, военкомат чакырганны да көтмәгән»,— дип уйлап алдым. Таныш тавыш, аның сүзләре.

Ул русча сөйли иде:

— Фашист-сволочьларны туган илдән куып чыгармыйча кайту юк! Ант итәбез: соңгы тамчы каныбызга, соңгы сулышыбызга кадәр!..

Соңыннан радиодан шунысын да әйттеләр: ихтыярилар батальоны шуннан ук вокзалга төшеп туп-туры фронтка киткән.

Военкоматның ишеге төбенә барып житкәч, башка бер уй килде. Бу йортка барып керүем белән мине китәргә җыенучы берәр гаскәри частька җибәрәчәкләр. Ә минем китап нәшриятында эшемне тапшырасым, иптәшләрем белән саубуллашып чыгасым бар иде. Башта Матбугат йортына кереп чыгу хәерлерәк булмасмы?

Нәшриятта байтак өстәлләр бушап калган иде инде. Редакцияләнеп бетмәгән кульязмаларны сектор мөдире Гази Кашшафка тапшырып иптәшләр белән саубуллашканнан соң, нәшрият директоры Закир абзый Тинчурин белән хушлашырга кердем.

— Әһә, кайттыңмы? Хуш, яхшы булган! — диде ул.

Военкоматка барырга тиешлегем турында ишеткәч, уены-чыны белән:

— Һәммәгез дә фронтка китеп беткәч, монда кем эшләр? Фронтта җиңәр өчен тыл да нык булырга тиеш бит,— диде. «Шылай, шылай»,— дип үз алдына сөйләнгәндәй итте дә,— кирәк булгач барырсыз шул инде... Только аңарчы каршыдагы бүлмәгә кереп чыгыгыз әле,— диде.

Мин һаман да берни дә белми идем әле. Күрәсең, фронтка китәр алдыннан кадрлар бүлегендә исәп-хисапны өзәргә кирәктер дип уйладым. Ул бүлмәдә эшләүче ханым исә миңа сейфтан алып күптән үк әзерләп куелган печатьле кәгазь китереп бирде. Ул кәгазьдә минем киләчәк алты ай эчендә армиягә алынудан азат ителүем хакында язылган иде. Аны «бронь» диләр икән.

Мин аптырабрак калдым. Һич тә көтелмәгәнчә килеп чыкты бу. Мин бит инде бөтен тойгыларым, уйларым, бөтен рухым белән сугышка китәргә көйләнеп беткән идем. Бу хәл мине шатландырмады, хәтта күңелдә канәгатьсезлек хисе тудырды. Бу сары кәгазь мине явыз дошманга каршы сугышудан, аны җиңеп кайту шатлыгыннан мәхрүм итә кебек тоелды. Өстәрәк әйткәнемчә, беренче көннәрдә без сугышны бик тиз бетермәкче идек, аның шулкадәр озакка сузылачагы, бихисап корбаннар бирергә туры киләчәге турында уйлаган да юк иде. Менә тылдагы дивизияләр фронтка гына барып житсен, безнең Кызыл Армия җиңелмәс йодрык булып төйнәлеп кенә өлгерсен! Без ул юлбасарларны, тын алырга да ирек бирмичә, туздырып кына ташларбыз! Беренче

көннәрдә без шундый өмет белән рухланып яшәдек. Ислам Фәйзуллин да, меңнәрчә башка патриотлар да фронтка шундый ялкынлы дәрт белән киттеләр. Чөнки без шулай тәрбияләнгән идек.

Ләкин сугыш чынбарлыгы безнең ул хыялларыбызны беренче атнада ук челпәрәмә китереп тузгытып ташлады. Дошман без фараз кылганнан күп тапкыр көчлерәк, явызрак, кансызрак булып чыкты. Тиз үк шуны аңладык: бу сугышта сүз җиңү яки җиңелү турында түгел, бәлки үлем белән яшәү хакында гына барырга мөмкин иде.

Фашистлар җиңгән сурәттә совет кешесенә көн булмаячак. Безне, безнең балаларыбызны я ачы үлем газабы, я булмаса, мәңгелек фашист коллыгы көтә. Шул икенең берсе. Бүтән юл юк иде. Бу хәл үзеннән-үзе безнең йөрәкләрдә дошманга тиңсез нәфрәт, чиксез ачу уятты. Гәрчә безнең совет халкының әхлак кагыйдәләре беркайчан да мәрхәмәтсезлеккә өндәмәсә дә, фашистларның чиктән ашып киткән вәхшилекләренә каршы эстрадаларда һәм радиода «Канга — кан, үлемгә — үлем!» дигән җырлар яңгырый башлады. Мин дә сугышның беренче көннәрендә үк «Үч» исемле нәсер яздым. Ул халык артисты Зәйни ага Солтанов башкаруында ярыйсы ук тәэсирле ишетелә, тыңлаучыда нәфрәт һәм ачу уята иде. Озакламыйча Татарстан китап нәшриятында шул ук исемле бер китапчык та басылып чыкты.

Сугыш башлангач, «Совет әдәбияты» журналында Абдулла Гомәр белән икәү генә калдык. Мин җаваплы редактор, ул бер үк вакытта җаваплы секретарь да, техник редактор да, корректор да һәм журналны бастыру өчен кәгазь табучы да иде. Чөнки барлык журналлар ябылып, безнең журнал гына ябылмый калса да, Татарстан китап нәшриятында аңа кәгазь каралмаган иде. Журналны саклап калуда һәм аңа кәгазь табуда безгә ВКП(б) өлкә комитеты зур ярдәм күрсәтте.

Журналны вакытында чыгару бик кыенга килде. Әдәби әсәрләр язарга кеше юк, язучыларның күпчелеге сугышка китеп бетте. Шунлыктан Бөек Ватан сугышына багышланган тәрҗемә әсәрләрне күбрәк бирергә туры килде.

Көндәлек дәфтәрдән:

«Ислам Фәйзуллинның үлгән хәбәре килде. Бәхил бул, илебезнең батыр улы — комиссар Фәйзуллин. Синең үчеңне без аны белән кайтарырбыз!» (2 сентябрь, 1941).

«Моннан өч көн элек сугыш башлануга өч ай тулды. Өч ай! Белсәгез иде нинди кыен, авыр айлар ул! Бу бит бөтен Европаны диярлек «эһ» тә итмичә басып алган, бөтен дөньяны тетрәтеп торган фашистлар Германиясе армиясенең сугыш машинасына, аның танкларына, броневикларына, самолетларына, корабльләренә, котырынган солдатларның һөҗүменә бер үзең каршы тору дигән сүз!

Хәзер дөнья сугышының бөтен авырлыгы безнең Кызыл Армия өстенә төшә. Безнең сугышчыларыбыз бөтен дөнья фронтының иң алдынгы сафында сугышалар, бөтен кешелек дөньясы өчен кан коялар. Искә төшкән саен күңелдә аларга чиксез рәхмәт хисе уяна.

Кайчан без дошманны кире борып куа башларбыз икән?» (25 сентябрь, 1941).

«Байтак иптәшләр фронтка китте. Муса Җәлилдән хат юк. Алиш сугыш полосасында. Дәүли хат язмый. Мине әле һаман да алмыйлар. Хәер, мин картрак шул инде. Аннан соң яңа техника белән танышлыгым да шуның хәтле генә...» (6 октябрь, 1941).

Сугыш башланып бер-ике ай узуга, язмыш безне Абдулла Гомәр белән яңадан «Совет әдәбияты»нда очраштырды. Матбугат йортының бишенче катында кечерәк кенә бер бүлмә[1]. Уртада тимер мич. Аның бер ягында мин кулъязмалар редакцияләп утырам, Абдулла үз эше

[1] Ул бүлмәдә хәзер музей урнашкан.

белән мәшгуль. Тимер мичнең шунысы яхшы: аның янында куллар да туңмый, кара савытындагы кара да бозланып катмый. Язучылар союзының хәзер дүрт кенә кешелек булып (Хәсни Кәрим, Гази Кашшаф, Кави Нәҗми һәм мин), кечерәеп калган партия оешмасының җыелышларын да, төрле утырышларны да шул мич янында уздырабыз.

Тагын шунысын да онытмыйк, сугыш вакытында журналлар чыкмый башлады. «Совет әдәбияты» исә юкарак булып калса калды, тиражы кимесә кимеде, әмма аның бер генә саны да чыкмыйча калмады. Моның өчен, барыннан да элек, ВКП(б) өлкә комитетының ул еллардагы секретаре Самат иптәш Мөхәммәтовны, миннән соң редактор булып килгән мәрхүм Гази Кашшафны рәхмәт сүзләре белән искә алырга кирәк.



Шулай эшләп ятабыз. Ул фронтларда безнең хәлләр бик кыенлашкан чак, фашистлар армиясе Мәскәүгә һөҗүм башлаган көннәр иде. 1941 елның 16 ноябрендә иртән эшкә килсәк, Матбугат йорты гөҗ килә. Коридорлар, Габдулла Тукай клубының залы, күрше бүлмәләр — һәммәсе Мәскәү язучылары, аларның гаилә әгъзалары белән тулган. Сәхнәдәге зур рояль өстендә рәттән тезелешеп берничә яшь бала йоклап ята. Аларның әти-әниләре исә кайберләре Чистайга озатуны, бүтәннәре Казанда квартирага урнаштыруны көтәләр иде.

Безнең редакция бүлмәсенең ишеге төбендә портретлары буенча электән үк таныш булган уртача гына буйлы, чәченә чал керә башлаган, ябык кына чибәр кеше белән очраштык. Бу — Италия язучысы Джованни Джерманетто[1] иде. Аның үзенә һәм хатынына утырырга урын юк, кечкенә балалары аркасын стенага терәп чемодан өстендә йокыга киткән.

Абдулла Гомәр белән без бер-беребезгә карашып алу белән үк аңлаштык. Джерманеттоны гаиләсе белән бүлмәгә кертеп урнаштырдык та, кулларны кысышып, үзебез эшләребезне алып белеш-танышлар бүлмәсенә «өйдәш» кереп тордык.

Джерманетто үзен бик гади тотучы иркен күңелле, якты чырайлы кеше иде. Квартира табылганчы, бездән гафу үтенә-үтенә, редакция бүлмәсендә яшәп торды. Тырыша торгач аңа да квартира табылды. Абдулла аны Болак буенда яхшы кешеләргә урнаштырды.

Татарстан язучылары Мәскәүле каләмдәшләрен туганнарча якты чырай белән каршы алдылар, байтагысын үз квартираларына керттеләр. Кунакларның тормышы берникадәр тәртипкә салынганнан соң, Г. Тукай клубында очрашу кичәләре булгалады. Джерманетто язучылар союзы янында оештырылган агитбригаданың иң актив членнарыннан берсе булып китте. Ул русча ярыйсы гына сөйләшә иде. Завод-фабрикаларда, Г. Тукай клубында оештырылган кичәләрдә фашизмның ерткычлыгын фаш итеп ялкынлы речьләр белән чыга башлады. Итальян теленә тәрҗемә итеп Г. Тукай шигырьләрен дә укый иде.

Ул кичәләрдә, Джерманеттодан тыш, тагын француз драматургы Жан Ришар Блок, немец язучысы Вилли Бредель, Мәскәүдән Александр Фадеев, Алексей Толстой, Демьян Бедный, бездән Кави Нәҗми, Нур Баян һ. б. катнашуы истә калган.

Көз ахырларында миңа, «Совет әдәбияты» редакциясендә А. Гомәрнең берүзен калдырып, оборона эшләренә чыгып китәргә туры килде.

1941 нче елның ахыры, 1942 елның башы бик салкын килде. Кайбер көннәрне термометр кырык, кырык бер градус салкын күрсәтә иде. Йөк машиналары бара торган җиреннән туңып туктап кала. Казаннан барган хатын-кыз, техникумнар, училищеларда укучы яшүсмер егет һәм кызлар шакыраеп каткан туң җирне тук та тук лом белән, кирәк

[1] Джерманетто Джованни, 1885—1959. Италия Коммунистлар партиясе оешканнан бирле аның члены, соңыннан ИКП Үзәк Комитеты члены.

белән чапкан булалар, ләкин чуендай каткан җир һич бирешми иде. Моңа кадәр балта-пычкы тотып өйрәнмәгән шәһәр хатын-кызлары блиндажлар салыр өчен урман кисәргә тотыналар. Ләкин йөзьяшәр наратлар, аларны санламыйча урталай ярылып, кире якка берсе өстенә и енчесе авалар да ерып чыга алмаслык чытырман хасил була, шаулап торган нарат урманы юкка әрәм була иде.

Боларны күреп йөрәк сызлана, үзеңне кая куярга белмисең. Ләкин нишләмәк кирәк! Явыз дошманга бирешмәс өчен шундый бик күп корбан бирергә, тешне кысып булса да югалтуларга түзәргә туры килә.

Өлкән журналист Ислам Рәхми белән мин оборона эшләрен башкаручы әнә шул ун меңнәрчә кешеләр өчен күп тиражлы газета чыгарыштык. Шагыйрь Гали Хуҗи — төзелеш җитәкчесенең комсомол эшләре буенча ярдәмчесе, Хәмит Ярми кадрлар бүлеге мөдире иде.

Никадәр генә кыен булмасын, оборона эшләрен уңышлы башкардык, безгә «Төзелеш отличнигы» дигән мактау кәгазе бирделәр. Ике ай ярым чамасы эшләп Казанга кайттык.

1942 елның февраль башы иде инде бу. Өйгә кайтып коридорга кердем — караңгы. Включательгә бастым — лампочка янмый. Арлыбирле каранам — бүлмә эче буп-буш, өйдә бер җан әсәре дә юк. Хәзер әниләре囲 эштә булырга тиеш, ә ике бала кая? Аларга ни булган? Эчем «жу» итеп китте.

Аптырагач:

— Балалар, өйдәме сез? — дип аваз салдым. Җавап булмады. Кызым белән улымны исемнәре белән дәшеп карадым. Шулай ишек янында шомланып нишләргә белмичә торганда түрдәге караватка күзем төште. Караватның аргы почмагында нәрсәдер кыймылдый түгелме соң? Шундагы ниндидер карамчыктан кызымның шатлыклы тавышы ишетелде.

— Әти, кайттыңмыни? — диде ул.

Мин куанып шунда таба атладым.

— Кайттым, балалар, кайттым! Туңдыгызмы әллә?

— Юк, туңмадык әле, без бер-беребез янына утырдык та ялгыш кына йоклап киткәнбез!..

Карасам, балалар өйдәге барлык юрганнарны бергә җыйганнар да икесе бергә җылынып утырганнар икән.

— Әни кайткач өйгә ягар әле,— диде кызым.

— Утыныгыз бетмәдеме соң әле? — дидем мин.

— Беткәние, әни базардан алып кайтты,— кызым миңа мич алдында яткан 4—5 кисәк утын яркасын күрсәтте. Болар белән генә өйне җылытып булачак түгел иде. Бәхеткә каршы, мин Буадан үрәчәле чанага җиккән атка утырып кайткан идем. Сугыш елларында Литфонд вәкиле булып эшләүче Зәйнәп Исхаковадан ике кубометр утынга ордер алып Бакалтайга [1] утын складына төшеп киттек.

Складтан утын җибәреп торучы һәм аның сакчысы ул елларда картаеп килүче шагыйрь Кәрим Әмири иде. Ул заманында әдәбиятта ярыйсы ук күренекле урын тоткан, бик күп шигырь китаплары чыгарган, төрле курсларда матур әдәбият укыткан кеше иде. Мин аның хәзер утын складында эшләвенә һич гаҗәпләнмәдем. Чөнки сугыш елларында нинди дә булса хезмәттән чиркану яисә нинди дә булса эшне ваксыну дигән нәрсә юк иде. Илне фашист юлбасарларыннан коткарып калу өчен, шундый кыен елларда гаиләсен ач итмәс өчен, беркем дә кулыннан килгәнне кызганмады. Тылда яшәүчеләр, төп хезмәтләреннән тыш, нинди дә булса берәр өстәмә эш тә башкаралар иде. Мәсәлән, тарих фәннәре докторы, танылган бер профессор университетта лекция укып кайтканнан соң квартирында күршеләренә, белеш-танышларына киез

[1] Бакалтай — Иделнең Яңа Бистәдән түбәнрәк булган яр буе, андагы әрәмәлек элек шулай атала иде. Куйбышев гидростанциясен салгач, су астында калды.

итек астына сала, милициядә ярыйсы ук зур эш башкарып пенсиягә чыккан бер иптәш кибеттә ваклап керосин сата иде.

Өлкән яшьтәге шагыйрь Кәрим Әмири дә утын складында эшләвенә һич кыенсынмый иде. Ул безне землянкасына алып кереп кишер чәе белән сыйлады, әрдәнәләр арасында җиңел генә йөреп безгә коры утын сайлап бирде.

Менә без яңадан балалар белән бергә. Дөрләп янган мич каршысына җыйналышып, шушы бер-ике ай эчендә баштан узганнарны сөйләп, җылынып утыру кадерле минутлар булып истә калган...

## XXI

«Совет әдәбияты» журналын чыгаруның кыенлыкларын җиңәргә өйрәнеп кенә килә идек, мине ВКП(б) өлкә комитетына дәшеп алып Татарстан радиокомитеты председателенең урынбасары һәм баш редакторы булып эшләргә тәкъдим иттеләр. Билгеле, сатулашып торыр чак түгел. Киттем. Комитетның председателе Гариф Гобәй ВКП(б) өлкә комитетының вәкиле сыйфатында күп вакытын районнарда уздыра иде. Димәк, барлык тапшыруларны оештыруга, редакцияләүгә һәм эфирга чыгаруга җитәкчелек итү минем өскә йөкләнде. Ул вакыттагы программа буенча Татарстан радиосы эфирга көн саен өч сәгать ярымлык текст тапшырырга тиеш иде. Бу — һәркөнне калын бер томлык яңа материал әзерләргә кирәк дигән сүз. Язучылар һәм журналистларның бик күбесе, кайсы мобилизация буенча, кайсы үзе теләп фронтка китте. Тегеяки бу темага җитди итеп язардай кешеләр бик аз калган, хәлебез бик мөшкел иде. Шулай да бу кыенлыктан чыгу юлларын тапмыйча ярамый иде. Мин бүлек мөдирләренең фидакарь тырышлыгына, тәҗрибә һәм белемнәренә таяндым. Пропаганда бүлегенең җитәкчесе — танылган әдип һәм шагыйрь Кави Нәҗми, әдәби-драматик тапшырулар бүлеген шундый ук мәгълүм әдип һәм драматург Мирсәй Әмир җитәкли, музыкаль редакциядә талантлы композитор Җәүдәт Фәйзи эшли иде. Билгеле, фронтта һәм тылда көн саен диярлек кискен үзгәрешләр булып тора, шул уңайдан тапшырулар программасын кинәт кенә үзгәртеп, сәгате-минуты белән яңалыклар өстәргә туры килә торган иде. Андый кыен чакларда мин шушы иптәшләргә, барыннан да ешрак Кави Нәҗмигә мөрәҗәгать итә торган идем.

...Без бүген бөтенләй башка шартларда, житеш һәм тук тормышта яшибез. Әмма бу тормышка ирешү өчен сугыш елларында безнең ата-аналарыбыз, әби-бабаларыбыз нинди кыенлыклар кичерүен күп вакыт онытып җибәрәбез. Хәзергенең кадерен белмәүчеләргә гыйбрәт булсын өчен, сугыш вакытында баштан кичергән михнәтләрне бәлки әледән-әле искә төшергәләп торырга кирәктер?

1942 елның кышын һич онытасым юк. Радиокомитетның барлык бүлмәләре дә салкын, чөнки берсе дә ягылмый, утын җитми иде. Өченче каттагы бер бүлмәнең уртасына тимер мич куйдык та, аның морҗасын тәрәзәдән тышка чыгарып, хәзинәдә булган аз-маз утынны шуңа яга торган булдык. Радионың төп эшен башкаручы хезмәткәрләр — ун-унбишләп кеше шунда җыелдык. Баш редакторның «кабинет» дип аталган кечкенә бүлмәсе дә шул зур бүлмәгә чыга. Әмма аның үз миче булмаганлыктан, ишеге ачык тормаса, өстәлдәге язу карасы бозланып ката, өскә тун, аякка киез итек киеп утырырга туры килә иде.

Тимер мичкә өзлексез яккалап тормасаң, зур бүлмә дә тиз суына, иң алдан соңгы хәбәрләр редакциясенең редакторы Галия Гаязова аваз сала башлый иде. Кулларын угалап:

— Кави абый, туңабыз! — ди иде ул.

Күрше бүлмәдән Кави килеп чыга да:

— Ә, хәзер, Галия, бераз гына сабыр! — ди.

Кави безнең арада утын табарга, мич ягарга иң оста, иң булдыклы кешеләрдән саналды. Ул без белмәгән ниндидер баскычлардан очырмага менеп китә дә, аннан йомычкадыр, такта кисәкләредер, чүп-чардыр алып төшеп минут эчендә тимер мичне дөрләтеп җибәрә. Без исә мич өстендә берәр кружка су кайнатып өйдән алып килгән берәр телем икмәкне чыгарабыз. Әгәр кем дә булса бәрәңге-мазар алып килсә, ул мич өстендә пешерелә дә, һәммәбезгә дә бүленә торган иде. Бу — безнең көндезге ашыбыз. Тимер мич тирәсендә күбрәк фронт хәлләре турында сүз бара. Тәрҗемәче Төхфәт килеп керсә, ул безне Совинформбюроның иң соңгы хәбәрләре белән таныштыра торган иде. Әмма «тукның күзе хикмәттә, ачның күзе икмәктә» дигәндәй, сүз ни турында гына бармасын, ахыр чиктә без үзебез дә белештермәстән, күбрәк икмәк турында сөйләшүгә күчә идек. Безнең арада иң ябык, иң тиз ачыгучы Галия Гаязова булыр иде. Аның ире фронтта, ул бер малай үстерә иде. Күрәсең, бар тапканы шул малайны тәрбияләргә киткәндер.

— Их, авыз тутырып, туйганчы ипекәй ашасаң иде бер! — ди иде ул.

Минем аңа уеным-чыным белән:

— Кайгырма, Галия! Сугышлар бетеп, еллар тынычлангач, мин синең берүзеңә бер бөтен икмәк алып бирермен, туйганчы ашарсың! — дигәнем бар.

Ләкин шулай дисәм дә ул вакытта туйганчы ипи ашау буш хыял гына, сугыш бетәргә дә бик ерак иде әле. Без гади арыш икмәгенең ни сәбәпле шулай сагындыруы, аның нилектән туклыклы булуы турында сөйләшүдән ниндидер юаныч таба идек. Рус телендә чыга торган соңгы хәбәрләр редакциясе редакторы Матильда Аксенова:

— Чөнки гади арыш ипиендә кеше организмына кирәкле иң кыйммәтле матдәләрнең һәммәсе дә бар,— дип сөйләп китә.

Пропаганда бүлегендә Кави белән бергә эшләүче ифрат сәләтле журналист — латыш Герман Августович Берзин Латвия халкының икмәкне ничек кадерләве турында сөйли...

Шулай итеп, көндезге аш вакытында без, икмәкнең үзен ашыйсы урында, күбесенчә аның турында сөйләнеп кенә уздыра идек.

Әмма тамагыбыз ач булса да, күңелебез көр иде. Безне совет халкының фронтта һәм тылдагы тиңсез батырлыгы, партия һәм хөкүмәтнең дошманны җиңүгә юнәлдерелгән тарихи чаралар, Совинформбюроның белдерүләре рухландыра. Без көн саен өч сәгать ярым дәвамында ялкынлы публицистик чыгышлар, музыка, әдәби-драматик сүз ярдәмендә күтәренке күңел белән халыкны фидакарь хезмәткә, батырлыкка, борынны салындырмаска өнди идек.

Фронттагы язучы һәм журналистлар белән һәрдаим хәбәрләшеп торырга тырыштык. Фронттан кайтканда алар үзләре дә радиога киләләр, без аларның чыгышларын оештыра идек. Көннәрнең берендә радиокомитетка Гадел Кутуй килеп керде. Бу юлы ул «Туган ил» дигән шигырь һәм очерклар алып кайткан иде. Туган ил хакында ул елларда бик күп язылды. Әмма Г. Кутуйның бу шигыре әйтергә теләгән фикеренең тирәнлеге, шигырьнең нигезенә салынган лирик җылылыкның самимилеге белән аерылып тора иде. Без ул шигырьне күп тә үтмәстән радиода бирдек.

Көндәлек дәфтәрдән:

«2 нче апрельдә чыгып китеп кичә генә командировкадан кайттым. Военкомат мине яшьләр (допризывниклар) эшелонының комиссары итеп билгеләде. Армиягә алынган яшьләрне Свердловск, Төмән, Омск, Новосибирск, Новокузнецк шәһәрләренә илтеп тапшырдык. Уралның аргы ягында булганым юк иде, барып кайту күп нәрсә бирде». (Апрель, 1942.)

Эшелон унлап пульман вагоныннан оешты. Вагон саен берәр полит-

рук билгеләнде. Зуррак станцияләрдә туктаганда политинформация уздырып фронттагы хәлләр турында хәрби-патриотик темаларга әңгәмәләр уздырдым. Яшьләр юл буе җырлашып бардылар.

Фронттагы сугышчыларга өстәмә яңа көч булып өлгерергә тиешле яшьләр инде бу.

Көндәлек дәфтәрдән:

«Тизрәк сугыш бетсә, фашист сволочьларны куып җибәрсәк, бөтен эшемне ташлап авылга кайтып китәр идем дә, җир сөреп, бәрәңге утыртып, мал асрап тик эшләп йөрер идем. Язар идем. Халыкка да азмы-күпме файдам тияр иде. Бәлки, яхшырак әсәрләр дә язып булыр иде әле. Менә ничә ел язучы булып йөрим, нихәтле әйбер яздым. Ләкин берсе дә үземне канәгатьләндерми. Күңел байлыгы ничектер файдаланылмый кала, әйтәсе сүзләрем исә бик күп әле.

Воронеж яши (димәк, китмәгән!) Яшәсен Воронеж һәм данлы Дон буйлары!» (20 июль, 1942).

«Кичә ике ай да ун көн йөреп Төньяк-Көнбатыш фронттан кайтып төштем. Сугышны да күрдем, аның кешеләрен дә. Авыр чаклар да күп булды — түздек. Түземлек дигәндә, ул миндә «аллага шөкер» бит, җитәрлек.

Инде хәзер күргәннәрне оештырып тагын берәр нәрсә язып чыгарга кирәк.

Бу фронтта татар телендә чыга торган «Ватан өчен» газетасының редакторы майор Гыйльманов иде. Газета оешканнан бирле диярлек анда Хатип Усманов, шагыйрь Шәраф Мөдәррис тә эшлиләр иде. Аларның икесе белән дә мин, берничә мәртәбә һөҗүм алдыннан алдынгы сызыкта булып, сугышта нинди дә булса батырлык күрсәтүчеләр белән окопларда, блиндажларда очраштым. Шулар хакында газетага очерклар яздым. «Шулай бер көнне», «Сиксән беренче» (таҗик егете — снайпер Сабировның 81 фашистны юк итүе хакында), «Мунча», «Гармунчы егет», «Комиссар» — әнә шунда язылдылар. «Комиссар» дигән очеркның баш герое — батальон комиссары, башкортстан егете Шәйхулла Чанбарисов иде. Соңыннан ул Башкорт дәүләт университетының ректоры булып эшләде.

Рус язучылары Михаил Матусовский, Сергей Михалков, казах язучылары Жубан Мулдагалиев, Әскәров белән дә шул фронт газетасы редакциясендә танышкан идем».

Көндәлек дәфтәрдән:

«Поездда кайтканда төрле халыкларның сугышка ничек катнашулары хакында сүз чыкты да бер солдат — Украина егете болай диде: «Мин сугышның башыннан бирле фронтта булган кеше. Татарларны миңа сугышның иң хәтәр урыннарында очратырга туры килде. Алар куркуны белмәс халык. Әгәр татар белән бер дусланып алсаң, ул сине гомер буе онытмый, нинди генә кыенлыкка төшсәң дә, үзен корбан итеп булса да сине коткара. Гаҗәп батыр халык ул татарлар...»

Ул моны миңа түгел, башкаларга сөйләде. Үз халкың турында шундый куанычлы сүзләр ишетү, билгеле, бик күңелле.

Кичә көн буена җилкәгә күтәреп Яңа Бистә күпере төбеннән утын ташыдык. Иңбашлар авырта авыртуын. Зарар юк. Сугыш вакыты. Утынын таба алсаң, җәһәннәмнән ташырга да риза буласың» (31 октябрь, 1942).

«Бүген берни дә яза алмадым. Корырак итеп язарга мөмкин иде, кулым бармады. Төрле отышлы диалоглар кыстырып, эффектлы сүзләр өстәп шома гына нәрсә оештырырга була. Ләкин ул гына аз. Яза торган вакыйга яки халәтнең эченә керергә кирәк, анда үзеңне һәм укучыңны җылытып, үзеңә ияртеп алып барырлык эчке бер агым булырга тиеш. Шуның белән бергә, ясалмалык та булмасын. Укучы әсәреңнең язучы башыннан чыгарып язылган булуын бөтенләй сизмәсен, ул аны

укыганда үзен тормышның эчендә итеп, бу вакыйга китапта гына түгел, тормышның үзендә шулай булган дип хис кылсын, үзен дә шунда катнаша яки күреп тора итеп аңласын. Минем карашымча, яхшы әсәр шулай булырга тиеш.

Кайбер әсәрләрдә авторның үз уйларын кыстырып җибәрүе,— әгәр ул әсәрдә тасвир ителә торган вакыйгаларга тыгыз бәйләнмәгән булса,— бик килешсез төс ала, укучыны китаптагы вакыйгалар дөньясыннан, аның тәэссоратыннан аерып алып үз уйларыңны көчләп тагу кебек булып чыга.

Мин күп нәрсәне күңелем белән тирән һәм дөрес аңлыйм шикелле. Тик әсәрләремдә мин аны күңелем сизгәнчә образлы, тирән һәм үземне канәгатьләнерлек оста итеп яза алганым юк әле. Дөрес, кайбер хикәяләрем башкаларына караганда үземә күбрәк ошый (Мәсәлән, «Кунак егет»).

Бу нәрсәдән килә? Ихтимал, осталык җитмәүдәндер.

...Соңгы көннәрдә шатлыклы хәбәрләр күбрәк ишетелә башлады. Союзниклар Төньяк Африканы алып бетереп киләләр. Италиягә һөҗүм башлануы бик ихтимал.

Күп кан коелды, күз яше дәрья булып акты. Боларның туктар вакыты да җиткәндер бит инде!

Менә ТАСС телеграммаларын тыңларга җыенам. Без бөек тарихи вакыйгаларның шаһиты булырбыз шикелле.

Фашистларны җиңгәннән соң, халыкларның киләчәк тормышын ничек корып җибәрү мәсьәләсе кузгалачак. Сталин, Рузвельт һәм Черчилль миннән сорасыннар иде.

— Я, Бәширов, син ничек уйлыйсың? Хәзер дөньяны ничек корырга? — дисеннәр иде. Мин аларга акыллы киңәшләр бирер идем шикелле.

Мине һаман да армиягә алмыйлар әле. Хәер, әле бит Германия гаскәрен безнең илдән куып чыгарып аның үз илендә сугыша башлагач та бик күп көч, бик күп гаскәр кирәк булачак.

Без, бәлки, Берлинны алырга да кирәк булырбыз әле!» (15 ноябрь, 1942).

«Әле генә партия җыелышыннан кайттым. Өстеңдә торган бурычлар үтәлгәннән соң ничектер җиңеләеп каласың. Җыелышка кадәр бик борчылган идем. Т. И. коммунист исемен пычратырлык әллә нихәтле әшәкелекләр эшләгән. Илдә шундый авыр сугыш барганда, иң шәп кешеләребез, халыкның чәчәк шикелле өлеше фронтта туган илне саклап калу өчен меңәрләп кырылганда ничек кеше шул хәтле оятсызлыкка барып җитә, ничек аның вөҗданы шул әшәкелекне сыйдыра ала икән?! Гаҗәп! Шундый вакытта минем җенем чыга, буылам. Ихтимал, андый минутларда субъектив карашны да объектив фикер урынына куллана торганмын. Монысы инде гасабилыктан...[1].

Сугыш җәмгыять ныклыгын гына түгел, аерым шәхесләрне дә сыный. Компромиссыз, рәхимсез сынау бу. Тыныч елларда кеше тавис кошының нинди генә тәти каурыйларына төренмәсен, әгәр дә аның үзәге черек икән, сугыш елларында бөтен черене тышка бәреп чыга, иманы нык булган чын кеше исә сынаулардан тагын да чыныгыбрак кала.

Т. И. эшен тикшереп, аны партиядән чыгарганда әдәбият тирәсендә буталып йөргән тагын бер тип күз алдына килде. Шул ук кышны нәшрияттан өйгә кайтышлый колхоз базарындагы талчук яныннан узарга туры килгән иде. Спекулянтлар оясы иде бу. Кемнәр генә юк, ниләр белән генә алыш-биреш итмиләр иде монда! Атаң белән анаң гына юк, шулардан гайре һәммә нәрсә бар бирерә: яхшы чәй һәм исле са-

[1] Гасаби — нервлары какшаган кеше.

бын, алтын сәгать һәм җәйге пальтога габардин, ситсы товар белән костюмлык, хәтта кара икра! Шул эш белән шөгыльләнеп мәш килеп йөрүчеләр арасында иңбашына кыйммәтле материя элгән, кулына затлы хатын-кыз туфлие тоткан кызыл чырайлы, түгәрәк сакаллы берәү күзгә чалынды. Ул туфлиен төрлечә күрсәтеп: «Менә туфли, менә туфлинең шәбе!» — ди-ди, татлы-баллы тавыш белән товарын мактый иде. Өстендә элекке авыл байларыныкы кебек яхшы тун, билендә һәйбәт билбау, тормышыннан бик мәмнүн бәндәләр сыман, күперенке түгәрәк сакал үстереп җибәргән. Сыныйрак карасам... тукта әле, бу нинди тамаша! Х. В. бит бу! Язучылар җыелышында кайбер әсәрләргә сыйнфый сизгерлек җитмәүдә гаепләп, аларны пыр туздырып ташлаучы, Белинскийлардан, башка классиклардан яртышар битлек өземтәләр китереп хәйран калдыручы әдәбият укытучысы бит бу!..

Мин үз күземә үзем ышанмыйча баскан урынымда катып калдым. Ул да мине күрде. Минем йөземдәге нәфрәт аның кәефен кырды булса кирәк, ул ярты сүздә бүленеп миңа арты белән борылды.

Туган ил нинди генә кыенлыклар кичермәсен, гаделлек барыбер өстен чыгачак, Совет халкы, һичшиксез, җиңеп чыгачак. Сугышлар бетеп бөтен ил белән тыныч тормышка күчкәч, Казанның галимнәр йортында Татарстан язучыларының III съезды ачылачак. Менә шунда бу бәндә белән мин тагын бер мәртәбә очрашачакмын. Юкса мин бу хәлне күптән оныткан идем, телгә дә алмаган булыр идем.

Шулай, фикер алышуларга күчкәч, шул кешедән сүз бирүне үтенеп президиумга язу киләчәк. Башта бик гаҗәпләнеп, тора-бара бу нахаллыкка хәйран калып язу кисәген кат-кат укыячакмын. Һич тә шик юк, нәкъ үзе, шул Х. В.! Исемен дә фамилиясен дә нәкъ мәкаләләрендәгечә тулы итеп язган. Оялмаган, килгән! Әле алай гынамы? Канлы сугышларда йөреп, дистәләрчә иптәшләрен, көрәштәшләрен чит илләрдә җирләп кайткан сугыш ветераннары алдында оялмыйча нотык сөйләмәкче! Башкалар исәбенә корсак симертеп яткан тыл күсесе, комсыз пикүләй!

Нәфрәтем никадәр көчле булса да мин аны күзләрем белән эзләмичә котыла алмаячакмын. Ул бик горур гына уртадагы рәтләрнең берсендә утырачак. Ул елны инде элекке мәһабәт сакал юкка чыгачак, аның урынына зыялы кешеләргә хас әдәпле генә галстук пәйда булачак. Мин моңа һич гаҗәпләнмәячәкмен. Чөнки әгәр урынына карап, яшәү шартлары үзгәрү уңае белән маскасын алмаштырмаса, хамелеон-хамелеон да булмас иде.

Иң беренче омтылышым, авызымнан бәреп чыгарга ыргылган иң беренче авазлар:

— Вон моннан! Эзең булмасын! — дип кычкырып җибәрү теләге булачак.

Ләкин һәр гамәлнең үз урыны, үз җае бар. Үземне-үзем тыеп калырга туры киләчәк.

Съездда чыгып сөйләячәк мөхтәрәм әдип һәм шагыйрьләр исемлегенә бу фамилияне дә теркәргә кулым бармаячак. Съездның ахыры якынлашуын сизеп алгач, ул үзе килеп бәйләнәчәк:

— Иртәдән бирле көтеп тә миңа һаман сүз бирмисез! Бу ни эш? Кая демократия, кая гаделлек? — дип тузыначак.

Мин аны сәхнә артына алып чыгып үзенә генә шыпырт сүз әйтәчәкмен:

— Әгәр дә бу тирәгә яңадан борын сузсагыз, белеп торыгыз! Мин сезнең 42 нче елда талчукчы булуыгызны чыгып әйтәчәкмен! Ишеттегезме?!

Күзләрен челт-челт йомгалап, Х. В. пәрдә артына кереп югалачак...

Көндәлек дәфтәрнең дәвамы:

«Бүлмәләр салкын, тәрәзәләр каткан. Җыелышта бүрек һәм бияләй

киеп утырырга туры килә. Урамнарны ай гына яктырта. Трамвай көтеп торсаң, кайтмыйча гына каласың...

Шулай да урамнарда төнлә дә халык күп. Халык яши, эшли, иҗат итә, сөя һәм сугыша!» (17 ноябрь, 1942).

«Фронтта күргәннәрдән «Комиссар», «Мунча» һ. б. кайбер истәлекләрне яздым да башкаларына тотына алмадым. Башта ике нәрсә кайнаша: бәрәңге, утын. Чөнки боларның икесе дә бездә юк. Ә аларсыз яшәү мөмкин түгел. Иртәгә шуларны бераз җайласам, тынычланып тотыныр идем». (14 декабрь, 1942).

## XXII

Шәриф абзый вафат.

Бу зур фаҗигане гади сүзләр белән генә әйтеп бирүе дә кыен.

Әдәбиятыбызның хөрмәтле аксакаллары, оста каләмнәре, халык рухын тирәнтен белүләре белән ихтирам казанган ветераннары мәңгегә китеп югала баралар. Шәриф Камал шул аксакалларның берсе иде.

Аның да әле язасы әсәрләре күп иде. Без аның яңа әсәрләрен, авыр һәм гыйбрәтле, бай һәм катлаулы тормыш юлына багышланган мемуар әсәрләрен көтә идек. Кызганычка каршы, алар һәммәсе дә Шәриф абзыйның үзе белән китте. Инде ичмасам, көндәлек кенә язып калдырган булса да ярар иде.

Мин аны иң соңгы мәртәбә Союзда, Шәйхи Маннурның фронттан кайтуы уңае белән уздырылган мәҗлестә очраткан идем. . Мәҗлестә Афзал Шамов, Таҗи Гыйззәт, Гариф Галиев, Шәриф абзый булуы истә калган. Хәтеремдә, һәрберебезнең алдына юка гына берәр телем арыш икмәге, кечерәк кенә икешәр бәрәңге куелган... Шулар белән генә «сыйлансак» та мәҗлес ярыйсы ук җанлы үтте. Чөнки фронтовик иптәшебезнең безгә һәр сүзе тансык, аның исә тылдагы хәлләрне бик беләсе килә иде. Таҗи Гыйззәт, сүз арасында, фронттан кайткан язучы иптәшләребез белән менә шулай дусларча сөйләшеп, фикер алышып утыруларны бик тә хуп күрүен, тыныч елларда язучыларның бер-берсе белән болай якын итеп сөйләшеп утырулары сирәк булуын әйтеп куйды. Шәриф абзыйга бу фикер бик үк ошап бетмәде. Аныңча, Белоруссия, Украина республикалары фашистлар итеге астында газап чиккән, бөтен илебезгә шундый куркыныч янаган бер вакытта тыныч тормышның ниндидер кимчелеген искә алып утыру һич тә килешми иде.

Шулай матур гына сөйләшеп утырганнан соң, фронтовиклар белән ешрак язышып торырга вәгъдәләр бирештек.

...Кичәдән без А. Шамов, Г. Галиев һәм мин бергә чыгып, Ш. Камалны Островский урамындагы квартирына кадәр озатып, парадный ишегеннән кереп киткәнен карап тордык. Шәриф абзый юл буенча сөйләшеп кайтты, аның кәефе күтәренке иде.

Туганнарының әйтүенә караганда, ул бездән соң Матбугат йорты каршысындагы ВТОда уздырылган кичәгә дә кереп чыккан.

Иртәгесен Шәриф абзый ишегалдында утын ярган, квартирына утын ташыган. Шул эшләрдән соң «әллә нигә башым әйләнеп тора» дип кәнәфиенә яткан һәм шул ятудан инде тора да алмаган.

Иртәгесен Таҗи Гыйззәт белән без барганда аның бер ягына паралич булган иде. 22 нче декабрь кичке 5 сәгать 20 минутта Шәриф абзый мәңгегә күзен йомды.

24 декабрьда өенә барып Шәриф абзыйның аягы очында почетлы каравылда тордым. Өеннән Г. Тукай клубы залына аның мәетен Бәкер Яфаров [1], Нәкый Исәнбәт, Таҗи Гыйззәт һ. б. күтәреп бардык.

25 декабрьның төнендә (башкалар белән нәүбәтләшеп) Тукай клу-

[1] Яфаров — педагогия институтының доценты.

бы залында Ш. Камалның табуты янында мин дә фәхри каравылда тордым. Йолдызлы, айлы бик салкын төн иде. Шәриф абзыйның агара башлаган чәчләре, карт татар интеллигентларына хас рәвештә үзенә күрә эдәпле бер пөхтәлек белән төзәтелгән кыска мыегы, безнең халыкта еш очрамый торган үзенчәлекле калку борыны, гомумән, берникадәр кырыслык тәэсире калдыра торган житди кыяфәте әле дә булса күз алдыннан китми. Шушы ике сәгать эчендә баштан күп уйлар узды. Тышта үтә салкын, стеналар шартлый, тәрәзә ярыгыннан зәңгәр төннең бер сызыгы күренә. Бу салкынга Шәриф абзыйның тәне рәнжидер кебек тоела, аның яланбаш ятуына күңелнең риза буласы килми иде. Шундый тын, әйтерсең, бөтен дөньяда залның уртасындагы кызыл табутка менеп яткан Шәриф абзый да, аның янында мин генә бар кебек. Тора торгач бу тынлыкка ачу килә башлый. Менә ул инде вафат, иртә белән, көн яктыргач аны алып чыгып китәрләр, илтеп күмәрләр, моннан соң без бу юаш (кебек күренгән) тирән акыллы, әдәпле һәм йөрәкле кешене, әдәбиятыбызның бер мөхтәрәм олы агасын бүтән мәңге күрә алмабыз. Ә дөнья тын! Нигә тын?!

Мин «Совет әдәбияты» бүлмәсенә кергәндә Тажи Гыйззәт белән артист Хәким Сәлимжанов идән уртасына куеп моржасын тәрәзәдән тышка сузган кечкенә тимер мичкә ягып утыралар иде. Түрдәге диванда күптән түгел табут янында кизүдә торып кергән, көн буе кабер казыту мәшәкате артыннан йөреп арыган артист Шамильский ял итә, ишек янындагы өстәл артында Салих Сәйдәш авыз эченнән көйли-көйли нәрсәдер язып утыра иде. Х. Сәлимжанов нидер сөйләде. Бераздан Тажи абзый:

— Егетләр, таң atканчы мин берәр сәгать булса да черем итеп алыйм әле,— дип урындыкларга барып ятты.

Мичне мин кайгырта башладым. Салих Сәйдәш кулларына таянган килеш күзен йомар-йоммас һәмишә нидер көйли-уйлый иде. Ул тора-торгач күзен ача да авыз эченнән бераз көйләп ала, алдындагы кәгазенә ниләрдер сыза, «йә, монысы болай инде, ә менә монда болай булса?..» дигәндәй, үз алдына сөйләнеп тә куя иде.

Тимер мичкә утын өстәп утырам, чи утын чыртлап һәм төтенләп акрын гына яна. Сәлимжанов та йокымсырый башлады. Залдан мине алыштырган Якуб Агишевның[1] йомшак кына итеп баскан аяк тавышы ишетелгәли. Шулай тагын байтак вакыт узды.

Тажи абзый йоклый алмады, ахрысы, әллә аны борчу кузгаттымы, ул торып утырды. Салих Сәйдәшевнең күзләре бөтенләй йомылган иде инде. Тажи абзый йомшак кына аның кулына орынды.

— Салих, кара әле, малай, бетерә күр инде, Шәриф абзыйны алып чыкканчы өлгерсен инде! — диде.

Сәйдәш күзен ачты.

— Була инде, Тажи абзый, була! Өлгертәм дип әйттем бит инде. Шәриф абзый бит ул! Ничек язмыйча кала алыйм мин аны? — диде...

Сүз Ш. Камалга багышланган марш ижат итү турында бара иде. Ихтимал, Т. Гыйззәт белән С. Сәйдәш арасында бу хакта элек тә сүз булгандыр, бик ихтимал ки, С. Сәйдәш маршның кайсыдыр өлешен бәлки язган да булгандыр (аның өстәлендә ниндидер язмалары бар иде). Чөнки әле язып тәмамлаганнан соң аның нотасын күбәйтеп музыкантларга бирергә кирәк булачагын, халык алдында уйный башлаганчы берникадәр репетиция ясарга да ихтыяж туачагын искә алганда, бөтенләй хәзерлеге булмаса, С. Сәйдәш маршны берничә сәгать эчендә өлгертүне вәгъдә итмәгән булыр иде.

Көндәлек дәфтәрнең дәвамы:

---

[1] Якуб Агишев — Казан дәүләт университетының доценты, әдәбият белгече.

«Тагын берничә сәгать вакыт узды. Таң ата башлагач, мин зиратка барырга хәзерләнер өчен, өемә кайтып киттем. Яңадан килдем. Ләкин без көткән марш өлгерми калды». (25 декабрь, 1942).

«Авылга — Әтнә районының Олы Мәңгәр авылына үзебезнең хезмәткәрләр өчен бәрәңге алырга барган идем. 27 сендә чыгып китеп декабрьның 31 ндә генә кайтып җиттек. Сугышның авырлыгы авылда аеруча ачык сизелә икән. Бу колхозда сабан игенен әле басудан кертеп бетермәгәннәр иде. Чүмәләләрне кар баскан. Атлар бик ябык. Малай-шалай белән хатын-кыз эш җаен белмиләр...

Кайтышлый Тукайның туган авылы Кушлавыч аркылы уздык. Без килеп кергәндә кояш чыгып кына килә иде. Морҗалардан төтен чыга, малайлар инешкә ат эчерергә төшәләр, хатын-кызлар су китерә. Мәктәп янында атларны туктатып бер җиңгидән Тукайның туган йортын күрсәтүне үтендем. Ул ачык кына итеп әйтеп бирә алмады. Икенче бер яшьрәгеннән сорадык. Анысы белә икән. Ул безгә урамга каратып салынган буяулы тәрәзәле тәбәнәгрәк бер йортны күрсәтте. Тирә-юнен кар басып киткән моңсу гына бер өй. Мин ул хатыннан:

— Габдулла Тукайны онытып бетермәдегезме әле? — дип сорадым.

— Әллә тагын...— дип ул хатын сүзне икенчегә борып җибәрде.

Габдулла Тукай туган өйдә мемориаль такта да, бүтән билге дә юк иде. Бик күңелсез булып китте... Гаҗәп ваемсыз халык без! Борынгы грекларның җиде шәһәре Гомерның үзләрендә тууын дәгъвалап ничә еллар буе бәхәсләшкәннәр. Ә без тарихка кереп калырдай иң зур, иң талантлы шагыйребезнең туган өен дә юньләп белмибез, белгәннәребезнең ул өйгә берәр билге куярга да кулыннан килми. Оят, ләкин нишләмәк кирәк, факт!» (1 гыйнвар, 1943).

«Кичә партия җыелышы уздырдык. «Совет әдәбияты» бүлмәсендә төтен эченнән иң элек Гази Кашшаф күренде. Бүлмә салкын иде. Җыелышны башлап җибәргәнче әүвәл бүлмәнең бер кырыена өеп куйган карлы агачларны өстәлгә салып кисәргә, аны тимер көрәк белән ярып вакларга, мичне кабызып җибәрергә туры килде. Кави Нәҗми җыелышның рәисе иде. Аңа өстәмә вазифа итеп мичне яндырып тору да йөкләнде. Ул мичне кыздыра төшкәч барлык хәляикъ шул җылы янына җыелды. Тимер мич тирәсенә түгәрәкләнеп утырдык та, кулларны җылыта-җылыта барлык мәсьәләләрне шунда хәл иттек. 1918—1919 еллар искә төште.

Нишлисең, заманасы шундый. Без һәммәсенә дә әзер, без барысына да түзәрбез, тик каһәр төшкән дошман гына җиңелсен!» (20 гыйнвар, 1943).

«Өй салкын булса да эчтә җылы. Чөнки безнең эшләр шәп бара! Төн саен уникедән соң торып «Соңгы сәгатьтә»не тыңлыйбыз. Әле шушы арада гына безнекеләр Сталинград тирәсендә немецларның 6 нчы армиясен кырып ташладылар. Җәмгысы 330 мең фриц! 240 мең үле фриц, 91 мең әсир фриц, 24 пленга алынган генерал-фриц! Гитлер танавын киереп ишәк урынына акыра иде, хәзер шәт күзе акайгандыр...

Без бик күп түздек, күп корбаннар бирдек, әмма без барыбер бирешмәдек. Фашистларны кырып бетерергә, шәт, көчебез җитәр. Иң шәп бәйрәм безнең урамда булыр. Фашист-юлбасарларның арт сабагын укытыр чак җитте. Алардан безнең тол калган хатын-кызларның өйләрен салдыртырга, бәдрәфләрен тазарттырырга кирәк. Аллаларын каргый-каргый, чәчләрен йолкый-йолкый эшләсеннәр. Фашист-болванның азуы җиткән, ул шундый мөгамәләне генә аңлар, башканы аңлаудан узган.

Ибраһим Гази белән Фатих Хөсни фронтка киттеләр. Иртәгә Мирсәй Әмир белән Афзал Шамов китәләр. Мин кайчан китәрмен икән?..» (7 февраль, 1943).

«Аршарунига, Мәскәүдә хәрби нәшриятта бастырып, фронтовикларга

тарату өчен өч табаклык татар халык җырлары җыентыгы оештырып бирдек [1]. (14 март, 1943).

## XXIII

1943 елның башында икмәк, ашау-эчү белән тәэмин итү мәсьәләсе бераз җайлана төште. Язучыларны, журналистларны ИТРга тиңләделәр. Миңа икмәк 600 грамм тиешле булды. Шуның өстенә, көнгә бер мәртәбә кайнар аш бирелә иде.

Март аеның ахырларына таба булды бу хәл. Әйткәнемчә, пропаганда бүлегендә эшләүче Герман Августович Берзин белән Казан ресторанында урнашкан ашханәдә әлеге шул талонга тамак туйдырып чыктык. Караңгы төшкән иде. Бауман урамының тротуарларын түбәдән төшкән кар һәм боз баскан, тәрәзәләр маскировка пәрдәләре белән капланган, урамда бер яктылык та юк, урам уртасыннан юлны аяк белән капшап диярлек кайтабыз. Ул чагында машиналар, атлар бик сирәк очрый, гомумән, бер куркыныч та юк кебек иде.

Сөйләшеп кайта торгач, хәзерге «Родина» кинотеатрына җитәрәк, мин кинәт кенә юк булдым. «Аңымны җуйдым» дип әйтү генә ул хәләтне аңлатып бирми. Бер әгъзам авыртмады, башыма бер уй килергә өлгермәде, хәтта егылганымны да сизмәдем, баскан урынымда кинәт яшәүдән туктап, кинәт бөтенләй беттем.

Күпме вакыт узгандыр, хәтерләмим, белмим, бер мәлне ничектер күземне ачтым. Карасам, мине ниндидер биек урындыкка утыртканнар. Тирәмдә кулына шприц тоткан ак халатлы ир кеше кайнаша, мине ике хатын-кыз иңбашымнан тотып торалар. Өстемдәге пальтомның түше кып-кызыл кан, кулларым да канга буялган. Иң беренче булып аңыма килгән нәрсә — ашханәдән алып чыккан йомшак ак булки булды. Безгә һәр көнне берәр түгәрәк булки бирә торганнар иде. Мин аны кәгазьгә төреп кесәмә салам да кайткач урталай бүлеп ике балага бирә идем. Кулымны көч-хәл белән күтәреп кесәмә сузылдым: «Булки юк! Балалар бүген дә көтәләрдер, ә булки юк, төшеп калган, аталары да юк... Йөрәгем сызлап куйды. Янадан аңымны җуйганмын. Тагын күпмедер вакыт узгач, алда ниндидер куркыныч бар кебек тоела башлады. Күзләрем йомык, әмма күңелем белән сизәм, ниндидер куркыныч яный! Ул арада якын-тирәдәге кешеләрнең каушап кычкырган тавышлары да колагыма керде. Ниһаять, тырыша торгач күземне ачтым. Мин утырган йөк машинасы кырынайган да бозлы юл кырыена, ниндидер чокырга таба шуыша, машинаны чокыр ягыннан терәтеп торучы Берзин кәрәк тоткан бер хатынга кычкыра:

— Казы тизрәк, бозны чап! — ди.

Мин янадан аңымны җуйдым. Бу хәлне соңыннан Берзин аңлатып бирде: Шамов больницасына килеп җиткәндә генә машина бозлы юлдан читкә тайпылган да, тирән чокырга таба шуыша башлаган. Машинабыз белән шунда мәтәлсәк, әҗәлебез чокыр төбендә булачак икән.

Әле хәзер дә шуның серен аңламыйм: шундый куркыныч янавын ничек мин аңымны югалткан хәлдә дә сиздем икән? Гаҗәп бит!

Өченче мәртәбә аңыма килгәндә ниндидер зур ак палатада ятадыр идем. Анда башка кешеләр дә бар иде шикелле. Ләкин мин аларны күрә алмадым, башым борылмый иде, аяк очымдагы урындыкта елап утыручы җәмәгатем Кәримәне генә күрдем. Мин аны бик кызгандым, ниндидер өметле сүзләр әйтәсем, юатасым, балаларның хәлен сорашасым килде. Мин аңа: «Елама инде, тынычлан, мин исән калам, күрәсең бит, менә күземне ачтым!» — дип әйтергә теләдем. Ләкин тел тибрә-

[1] Аршаруни Аршаулис Михайлович — Мәскәүдән ПУРККАдан килгән вәкил, тәнкыйтьче, әдәбият галиме. Ул җыентык 1943 елда басылып та чыкты. Җыентыкны Я. Агишев, Г. Бәширов, А. Ключарев төзеделәр.

терлек тә хәлем юк. Башымны кузгата да алмыйм. Колак чыңлавына, баш сызлавына түзә алмыйча янадан аңымны җуйганмын.

Кайчандыр тагын күземне ачтым. Аяк очымда — шул ук Кәримә, шул ук күз яше. Мин аның беренче килүе дип аңлыйм, ә аның икенче көнне килүе икән инде бу. Ул миңа тумбочкадагы ризыкларны күрсәтә:

— Ике тәүлек буена кагылып та карамагансың, ач бит син, ач! Аз гына тамагыңа кабар идең, ярамый бит болай! — ди.

Дөресен генә әйткәндә, миндә ашау кайгысы түгел иде әле. Башны кузгату түгел, күзне ачу да бик зур газап, күз алмаларына кадәр утереп сызлый, башны аз гына селкеттеңме, укшыта башлый иде.

Шулай да өч-дүрт көн узганнан соң хәлләр бераз җиңеләя төште. Мин инде авыз ачып сүз әйтерлек, кеше сүзен аңларлык хәлгә килдем.

Ничә көннәрдер узгач, үзенең ярдәмчеләре белән профессор Нигъмәтуллин керде. Мине ул дәвалый икән, үлемнән дә шул алып калган. Минем хәзерге хәлем белән танышып берничә сорау биргәннән соң канәгать булып калды шикелле:

— Ярый, җиңәсез инде...— диде.

Күгәреп берсенә-берсе ябышкан иреннәремне кыенлык белән ачып:

— Нәрсәне җиңәм? Мин бит берни дә белмим,— дидем.

Профессор миңа сынырак карап торды да караватым кырыена утырып берникадәр аңлатып бирде:

— Сезне машина бәргән,— диде.

— Ә мин ул бәргәнне сизмәдем дә...

— Гаҗәп түгел. Чөнки ул кузов почмагы белән арт яктан нәкъ кече ми турысына китереп бәргән. Андагы ярадан, колаклардан, борыннан бик күп кан киткән. Безгә килеп җиткәндә пульсыгыз 45 кә төшкән иде. Байтак кан күчерергә туры килде. Донорларга рәхмәт инде,— диде. Хәзергә бик тыныч ятарга, селкенмәскә, кискен хәрәкәтләр ясамаска, күп сөйләшмәскә, дулкынланмаска киңәш бирде. Чөнки минем мием тетрәгән икән!

Бу сүзләр башыма суккан кебек итте. Профессорның шуннан соңгы сүзләрен мин юньләп тыңлый да алмадым. Миең тетрәсен дә дулкынланма, имеш! Мин бит каләм иясе! Күңелеңнән минут эчендә мең төрле кичерешләр уздырып, иҗат шатлыгы белән рухланып яшәмәгәч, бу дөньяның нинди яме кала? Миең тетрәгәч, бернигә яраксыз баш белән «күзле бүкән» булып яшәүнең нинди кызыгы бар?!. Бик тә күңелем төште. Әледән-әле төшеп чума торган төпсез караңгылыктан янадан менмәсәм дә һичбер үкенәсем юк иде.

Ләкин яшәеш дигән бу могҗизаның кеше аңлап бетермәстәй ниндидер эчке, яшерен серләре бардыр, күрәсең. Дөньяга килгән һәрбер җан иясе тормышын озаграк дәвам иттерү өчен бик күп төрле чараларын таба, ниндидер эчке мөмкинлекләрен эшкә җигә торгандыр.

Мин инде юк идем, янадан кайтмаска риза булып, каядыр югалган идем. Шулвакыт кемнеңдер йомшак кына кулыма орынуын тойдым, колагыма да ниндидер ягымлы тавыш килеп керде. Миңа нәкъ шулай, исемемне бераз сакаулатып, р хәрефен тел очы белән йомшартып Берзин дәшә торган иде. Күземне ачмыйча булдыра алмадым. Карасам, чыннан да шул — аксыл-зәңгәр күзләре, бөтен йөзе белән елмаеп янымда латыш иптәшем Берзин утыра.

— Мин сезне тазарып килүегез белән тәбрик итәм, бик шатмын! — ди бу.

Минем һич тә шатланасым килми иде әле.

— Кая инде ул тазарулар! Башымны кузгата да алмыйм, минем бит ми тетрәгән! — дидем.

Күрәм, Берзин уңайсызланыбрак алды. Ләкин гаҗәпләнүен, борчылуын эченә яшерде.

— Булса да булыр, сез бит йөк машинасы белән сөзештегез!— дип

шаяртыбрак сөйләргә кереште.— Тыныч кына сөйләшеп кайтканда сезнең тавышыгыз ишетелми башлады. «Бу нихәл бу?» дип борылып карасам, сез бозлавык урамда егылып ятасыз...

— Ә грузовик? — дип сорадым.

— Ул алга китКән иде инде, мин аны кире борып алып килдем дә сезне шуңа салып башта Карл Маркс урамындагы больницага алып бардым. Анда беренче ярдәмне күрсәткәч, Шамов больницасына илтеп салдым.

Берзинга мин бик күп рәхмәтләр әйтеп кулын кыстым. Бу сөйкемле латыш белән һәммәсен ачыктан-ачык сөйләшергә була иде. Мин аңа бөтен кайгымны берьюлы аудардым.

— Эшләр хәзер дә шәптән түгел бит әле, Герман Августович,— дидем.

Күрәм, Берзинның борчылуы чыраена чыкты. Әмма ул тиз үк яңадан елмайды. Миңа сыный карап торды да сәер генә сорау бирде:

— Шулай да әйтегез әле: кайтырга чыгар алдыннан без ашханәдә нәрсәләр турында сөйләштек, йә әле?

Бу сорау мине берникадәр гаҗәпләндерде.

— Онытмыгызмыни? Ленинград блокадасында калучыларны кызганып утырдык бит! — дидем мин.

— Алай да ничегрәк сөйләштек?

— Сез: «ул бичаралар кайнар ашны атнасына бер мәртәбә дә ашый алмыйлардыр» дидегез!

Берзинның бөтен йөзе яктырып китте:

— Дөрес бит, Гумер Баширович, хак шулай! Значит, ничек килеп чыга? Значит, мидәге шөрепләр һәммәсе дә үз урыннарында калган. Әйеме? Тик алар чуть-чуть селкенеп кенә алганнар. Бераздан бөтенләй тынычланырлар. Сезгә ничек кирәк? Ул хакта уйламаска! Радио өчен дә борчылмагыз. Беләсез бит анда нинди шәп егетләр утыра!

Мин үземнең шигемне белдерергә чамалаган идем, ул кулларын селтәп мине туктатты:

— Юк, каршы әйтмәгез! Сезгә бәхәсләшергә ярамый, доктор кушмый! — диде.

Тынычландырырга тырышуы өчен минем аңа рәхмәтем зур иде. Тик мин аны җиренә җиткереп әйтә генә алмадым — башым бик авырта иде.

Күземне йомып йокымсырап ята торгач, әниләре килгәнче балаларга укыр өчен берәр шаян такмаза язып куярга булдым. Кулыма карандаш алсам, уң кулымның бармаклары камыр шикелле изелеп тора, аларның карандаш тотарлык та җегәре юк иде. Тагын башка кайгы төште. Ничек эшләргә, ничек яшәргә?

Шулай үземне-үзем кая куярга белмичә ятканда палатага бер хатын-кыз килеп керде. Ул миңа таба куркынып карагандай кыюсыз гына килде дә тумбочкама газет кәгазенә салынган ике телем кара икмәк куйды. Русчалатып:

— Гафу итегез, бүтән бер күчтәнәчем дә юк,— диде.

Мин аптырабрак калдым. Бу хатынны беренче күрүем дисәм, әллә кайдадыр күземә чалындымы икән? Ләкин кайда? Минем авыру баш анысын тиз генә ачыклый алмады. Аягына кирза итек, өстенә шактый ук таушалган кара күн пинжәк кигән. Күренеп үк тора: үзенеке түгел, зуррак. Иреннән калган булуы мөмкин. Үзе бик борчылганга охшый, миңа туры карарга кыенсынып күзләрен яшерә иде. Мин аңа кулым белән утырырга ишарә иттем.

Шунда шәфкать туташы кереп ул хатынны читкәрәк утыртты да минем башка уралган бинтларны сүтәргә кереште. Канга буялган кыпкызыл марляларны, мамык кисәкләрен күргәч, әлеге хатын түзә алмады, йөзен каплап елап җибәрде:

— Ходаем! Харап кына иткәнмен! Мин гаепле, мин! Сезне бәреп еккан грузовикның шоферы бит мин! — диде.

Шәфкать туташы аны тиз генә тотып коридорга чыгарып куйды. Баштагы марляларны кубару бик авырттыра иде, аның өстенә — бу хатын.

Тагын бераздан әлеге хатын яңадан минем тумбочка янында утыра иде инде. Шунда гына исемә төште: машина чокырга шуыша башлагач Берзин шушы хатынга боз чабарга кушты түгелме соң?..

Көтелмәгән хәл иде бу. Мине нинди машина бәреп ташлавы турында уйлаганым да, аның белән баш ватарга теләгем дә юк. Минем үз хәлем хәл. Бу хатынның җанны кыйнавы өстәмә газап кына. Миңа аннан тизрәк котылырга кирәк иде.

Мин аннан:

— Сез кем соң, каян? — дип сорадым.

Ул хәзер баягы шикелле ачыргаланмый, бераз тынычлана төшкән иде инде. Шулай да ул минем күзләрне, авызны гына калдырып марляга уралган башыма карарга кыенсынгандай читкә карабрак сөйләшә иде.

— Мәскәүдән мин, эвакуация буенча килгән кеше. Ирем сугышта.

— Балаларыгыз да мондамы?

— Әйе, икәү...

— Шофер булып... күптәнме?

— Өч ай. Монда килгәч өйрәттеләр.

— Ә аңарчы?

Ул әйтергәме, юкмы дигәндәй беравык икеләнебрәк утырды.

— Аңарчы... галантерия магазинында эшли идем, сатучы булып.

Бу нечкә, озын бармаклар ислемай, запонка, паста, тасма кебекләрне күз иярмәстәй тизлек белән бик житез төргәннәрдер, бәлки. Әмма... иске-москы йөк машинасының ирләрне дә саннамый торган үшән баранкасына башкарак куллар кирәк иде шул.

Ул минем ни турында уйлавымны сизгәндәй ялварулы караш ташлады.

— Юк, сез мине кызганмагыз! Хотя мин сезне бөтенләй күрмәдем дә. Үзегез беләсез, маскировка. Ну барыбер мин гаепле. Сезнең судка бирергә хакыгыз бар.

Палатадагы барлык авырулар бу әңгәмәнең ничек тәмамланачагын бик тә кызыксынып тыңлыйлар иде. Мин үземчә гадел булырга тырыштым.

— Беләсезме сез кайчан гаепле булыр идегез? Әгәр дә мине урамда ташлап качкан булсагыз!

Шофер хатын куркынып башын чайкарга тотынды:

— Юк, юк! Аллам сакласын! Ни җаның белән?!.

Авырулар арасында сугыш башлангач ук яраланып кайткан сыңар аяклы шофер бар иде.

— Сез бер нәрсәне онытып җибәрәсез шикелле, кем, иптәш Бәширов! — диде ул.

— Нәрсәне икән?

— Кеше кадерен. Сугыш заманында сау-сәламәт кешенең кадере бинһая! Сау-сәламәт ир кеше — ул дөнья тоткасы! Ә бу гражданка кеше кадәр кешене харап итә язган!

Аңа кушылучылар тагын да табылды. Төрле яктан аның фикерен куәтләп аваз салдылар:

— Шулай, хак сүз! Киләчәктә дә шулай саксыз кыланса?!

— Закон бар бит, закон! Закон буенча җавап бирсен! Тем более сугыш вакыты!

Каршы якның да фикере игътибарга лаеклы иде:

— Ә балалар? Гражданка үзе генә булса, әле бер хәл. Балаларның ни гаебе бар?

— Әйе ләбаса! Сугыш заманында балалар өстенә ябырылган газап-михнәтнең чиге-чамасы юк. Ятим калулар, ачлык, авыру... Балалар хакы һәммәсеннән дә өстенрәк!

— Иптәшләр дөрес әйтә, закон өлешенә мин керешмим. Әмма үз исемемнән судка бирмим,— дидем мин аңа.— Ә болай, килүегез өчен рәхмәт, тыныч булыгыз!

Шофер ханым башта телсез калды. Аннары кулларымны кысып елый-елый рәхмәт әйтергә кереште.

— Ой рәхмәт! Балаларым бәхетенә. Алар исеменнән дә рәхмәт! Мәңге онытмам!

Күршедә яткан авырулар төрле яктан тавыш биреп бу гамәлне хуп күрүләрен белдерделәр:

— Шулай, дөрес, балалар хакына!..

Бер айга якын дәваланганнан соң минем хәлем яхшыра төште. Аягыма басып әйберләргә тотына-тотына палатада йөрерлек хәлгә килдем. Акрын гына, җайлап кына башны да боргалап була башлады. Чыңлавы бетмәсә дә элеккедәй чаң каккан кебек үк үзәккә үтми, бераз тавышы басыла төшкән иде инде.

Профессорга чын күңелдән рәхмәтләр укыдым.

— Сез мине үлемнән алып калдыгыз, хәзер мин савыгуыма ышанам инде. Бәлки башның чыңлавы да бетәр әле...— дидем.

Уң кулымның бармаклары язарга сәләтсез булуын профессорга әйтеп тормадым. Чөнки тәҗрибәле кешеләр бармакның җегәрсезлеге куркыныч түгеллеген әйттеләр, аны күбрәк хәрәкәтләндереп күнектерергә кирәк икән. Трамвайга, машинага утырырга ярамавына да артык исем китмәде. Җәмәгатем мине больницадан житәкләп, җәяү алып кайтты. Мине иң куркытканы — зиһен чуалу, башымның катлаулы уйлар белән шөгыльләнүгә, әдәби иҗат эшенә сәләтсез булып, зәгыйфьләнеп калуы иде. Шөкер, ул бәхетсезлек мине читләтеп узды.

Шулай да ми тетрәүнең кәсафәте больницадан чыккач та байтакка кадәр теңкәгә тиде. Кичләрен йокыга ятарга куркып тора идем. Чөнки йокыга талдыммы, муеныма бастырык юанлыгы еланнар килеп сарыла да буа башлыйлар иде. Ул газап байтакка кадәр дәвам итте.

Көндәлек дәфтәрдән:

«Узган атнада коточкыч берничә көн уздырдым. Нигәдер, каян килеп кергәндер ул бәйләнчек уй: һич өзлексез акылдан шашу куркынычы әзәрлекли башлады. Әле ярый озакка бармады, җиңдем...

Авырганнан соң мин балалар шикелле бик акрын, хәрефләп кенә яза башладым». (29 апрель, 1943).

## XXIV

«Шамовтан (фронттан) хат килде. Бик илтифатлы, җайлы иптәш. Еракган булса да кайгырта белә. Мин аны үзебез үстергән бәрәңге, чөгендер, кишер кебекләрдән пешерелгән бөккәннәр белән сыйларбыз дип көзгә кунакка кайтырга чакырдым». (24 май, 1943).

«Намус» дигән бер әсәр язмакчы булам. Сызмалары бар инде, үзе кайчан язылып бетәр, алла белсен.

Бу әсәрнең темасы минем уйга килеп керүе, гомумән, аның әдәби төскә керә башлавы бик үзенчәлекле булды [1].

Хәзер үземә уңышлар телләргә дә, вакыт табып язып бетерергә «генә» кала». (1 август, 1943).

---

[1] Кара. Әсәрләр, 1 том, 458 бит.

«Орел — бездә! Иртәгә-берсекөнгә Харьковны алырбыз дип торабыз... Аннан ары — Полтава белән Киев!» (14 август, 1943).

«Кавины, Мирсәйне, мине эштән азат итеп, әдәби иҗат белән генә шөгыльләнергә калдырмакчы булалар. Без моны бик зур рәхмәтләр белән тәбрикләп каршы алабыз. Бәлки, мин бүгенге көн сорауларына һәр җәһәттән дә җавап бирердәй житди зур әсәрне хәзер генә язып өлгертә алмам. Шулай да тора-бара андый әсәрне дә язып булыр. Монысына ышанам. Ә хәзергә беренче нәүбәттә, шәт, «Намус»ны бирә алырмын.

Хәерле юл, язучы иптәшләр! Сездән шәп әсәрләр көтәбез!» (18 август, 1943).

«Язучының эше — бик катлаулы, җаваплы, бик зур көч һәм кешеләрдән даими игътибар таләп итә торган нечкә рух эше. Бер әдип яки шагыйрь дә үзе өчен генә язмый торгандыр. Хәер, һәр эш тә шулай ахыр чиктә җәмгыять өчен эшләнә. Ләкин бүтән бер шөгыль дә әдип яки шагыйрь хезмәте кебек шулкадәр күп халыкка багышлап чыгарылмый. Бер әдәби әсәрне бит ничәмә ничә мең, хәтта миллион кеше укый!

Минем белән сөйләшүче кеше, җаваплы иптәш, язучылык эшем белән якыннан кызыксынырга, кирәк икән киңәшләр бирергә, һич югында иптәшләрчә сөйләшеп утырырга тиеш шикелле иде. Алла белсен, нинди тупаслыктыр бу. Ул миңа ниндидер бер таушалып беткән блокнот кисәге генә сузды.

— Ә, Гомәр иптәш! Килдеңме? Менә син шунда язып бир әле: нәрсәләр яздың, тагын нәрсәләр язасың. Докладка да кирәк булыр...

Чабата ясаучы белән дә болай сөйләшмиләр. Башта чабатаны кулга алып билен бөгеп карыйлар: бик каты түгелме? Җидедән үрелгәнме ул, әллә тугызданмы? Юкәме, карама юкәсеме? Карама булса, аязда чыдам булачак, юкә булса, аязга да, юешкә дә ярый. Аннары киндерәсен сузып карыйлар, кыска түгелме, тигез, матур ишелгәнме?.. Чабатачы рәхәтләнеп карап тора, чөнки аның хезмәте бит ул! Ул бит аны юкәдән чабата иткән!..

Дөрес, матур әдәбиятка һәм язучыларга мөнәсәбәтне бу кеше карашы белән генә үлчәп булмый булуын. Безнең хакимебез һәм терәгебез дип әйтер идем — ул укучы халык. Шулай да арада мондый бәндәләр дә бетәсе түгел». (21 август, 1943).

«Харьков яңадан безнеке!

Кызыл Армия Брянскига якынлашып килә. Фронтның төрле юнәлешләрендә каты һөҗүм бара. 1941 ел белән чагыштырсаң, хәлләр — искиткеч! Безнең Кызыл Армия дәһшәтле сугыш өермәләре һәм хәрабәләре арасыннан утта янмас, суда батмас баһадир шикелле яңа көч алып, җилкәләрен киереп, гигант көч булып бер аягы белән Боз диңгезе ярларына, икенчесе белән Кавказ тауларына басты. Хәзер без бу баһадирның кылычы чагылышында җиңү таңын күрәбез... Шәт, безнең урамның бәйрәме озак көттермәс инде!» (29 август, 1943).

Ниһаять, ВКП(б) өлкә комитетында эшләүче иптәшләрнең киңәше белән, без, өч әдип — М. Әмир, К. Нәҗми һәм мин — 1944 елның гыйнварында радиокомитеттагы эштән азат ителеп, фәкать әдәби иҗат эше белән генә шөгыльләнә башладык. Мин «Намус» романын язарга кирәк булырдай тормыш әхвәлләре белән тагын да якынрак танышу өчен, районнарга командировкага йөри башладым. Татарстан Верховный Советы Президиумы рәисе Гали Динмөхәммәтов иптәш мине сугыш вакытында иң яхшы патриотик үрнәкләр күрсәткән авыл Советы һәм колхозлар белән таныштырды. Мин берничә ай эчендә Арча, Кукмара, Кама тамагы, Буа, Тархан районнарында булып, колхозларның алдынгысын да, артта калганнарын да йөреп, һәммәсен үз күзем белән күреп кайттым. Җиделе лампа яктысында фронттагы улларына, сөйгән егет-

ләренә бияләйләр, пирчәткәләр бәйләүче әбиләр, җиткән кызлар белән кич утырдым, фронтлардан килгән бик күп өчпочмаклы хатлар укыдым, күтәрмәгә калган атларны, аларга алъяпкычына салып үз өеннән бәрәңге кабыклары, салам, печән алып барып ашатучы хатын-кызларны, картларны күрдем, салкын мәктәпләрдә өстенә пальто, башларына бүрек киеп утырган балаларга шәлгә уралып, кулларын уа-уа дәрес бирүче укытучылар белән очраштым. Өй тулы бала-чага белән япь-яшь килеш тол калган солдат хатыннары, тешләрен кысып, кайгыларын йотарга тырышып фронт өчен иген үстерәләр, мал үрчетәләр, ат башына буйлары да җитмәгән яшүсмер малайлар урманда утын хәзерли, иген игә, йөк ташый. Ә ашау ягы бик такыр, күбесенчә юк-бар белән туенып яшиләр.

Халыкның шушы кырыс түземлелеге, дошманны җиңү намена тылда да фронттагы уллары, ирләре кебек үк тиңсез батырлык, фидакарьлек күрсәтүе җанымны тетрәтте, халык белән горурлык хисе уятты, төн йокыларымны алды, Акком астындагы шул кечкенә бүлмәдә көннәртөннәр буена утырып, кайнар хисләремне кәгазьгә төшерергә керештем.

Ләкин берөзлексез илһам канатында гына яшәп булмый, өстәл яныннан кузгалдыңмы, алдыңа тормыш мәшәкате килеп баса. Акком астында яшәүче халыкның күбесе сугыш кыенлыгына ничектер җайланды: кайсы ит комбинатында, кайсы икмәк заводында эшли, тазарак картлар итек астына салып, утың турап, я башка шундый өстәмә һөнәр белән яши. Ул яктан мин генә булдыксыз кеше булып чыктым, нинди дә булса өстәмә табыш көйли алмадым. Рецензияләрдән килгән гонорар белән генә яшәү кыен иде. Дөрес, язучыларга ИТР паегы бирә башладылар, эш берникадәр җайланды. Әмма дүрт-биш яшьлек малайның нәкъ үсә торган чагы, аның аз-мазга гына канәгать буласы килми иде. Әнисе биргән юка гына икмәк телемен тиз генә «ялтыратып» куйганнан соң, күзен мөлдерәтеп: «Әни, тагын нәни генә юкмы?»— дию әле дә булса колак төбеннән китми.

Бераздан романның өзекләрен бастыра башлау хәлне берникадәр җиңеләйтте.

Көндәлек дәфтәрдән:

«Тукай кичәсендә булдым. Быел яхшырак узды. Гомер узган саен Тукайның кыйммәте ныграк сизелә бара, ул безгә ел саен якыная бара, халыкның аңа мәхәббәте көчәя бара.

Яшәсен Тукай!» (26 апрель, 1944).

«Намус»ны язам. Кичә алтынчы бүлеген тәмамлап куйдым да төртелеп торам әле. Хикмәт нидә?

Башта уйланган образлар иҗат барышында, конкретлаша башлагач, элек көтелмәгән бик күп өстәмәләр сорый торган булып чыгалар. Мәсәлән, Нәфисә образының характеры ярыйсы ук үзгәрде.

Иҗат эше күп нәрсәгә өйрәтә. Миндә кыенлыкларны җиңәрлек көч табылса кирәк. «Намус»та мин элекке әсәрләремдәге кимчелекләрне кабатламаска тиешмен. Шунсыз ул әсәр уңышлы була алмас». (26 апрель, 1944).

«Әле генә Сталин приказын тыңладым. Безнең гаскәрләр Бухарестка керделәр! Немецлар кача. Союзниклар Германия чигенә 140 километр гына калдылар. Без җиңәбез! Сүз бары тик сугышның кайчан бетүе хакында гына барырга мөмкин. Һәрхәлдә 1945 ел сугыш елы булмас инде.

Кешелек җәмгыяте тарихында тиңе булмаган шушы коточкыч авырлыкны җиңеп чыгып, үзенең чыдамлыгы, ныклыгы, куәте, фидакарьлеге белән бөтен дөньяны таң калдырган шушы илнең иң гади гражданины булу да күңелләрдә чиксез зур куаныч тудыра, рухландыра, көчне арттыра. Шушы бөек чорга лаеклы җитди бер эш башкарасы килә.

Бүген иртә белән Яңасаладан кайтып төштем. Урман, чикләвек, иген кырлары, төнге эш.

Төнлә белән җизни чаптырып кына станциягә китереп куйды.

Йолдызлы төн, тын кырлар, күктә йолдызлар атыла.

Бик матур безнең ил, бик матур!» (31 август, 1944).

«Бу арада күңелем төшенке. Моңа кадәр минем бер әсәремне дә басмыйча кире кайтарганнары юк иде. Менә хәзер кайтардылар. Бикбулат картның[1] хосусый милеккә ябышып ятуыннан курыктылар. Янәсе, ай-һай, бик кискен итеп күрсәтмибезме? Янәсе, өстән шомартып кына узарга мөмкин булганда нигә андый төп мәсьәләләрне шулай кискен итеп куярга?

Ярый, шайтан алсын үзләрен!

Әгәр дә әдәби иҗат эшенә теләсә кем тотына һәм гайрәте чиккәч ташлап китә торган булса, ул акчага гына кызыгып башкарыла торган шөгыль булса, әгәр дә аңа иҗат кешесенең дәрте, көчле омтылышы тартып кертмәсә, бу эшкә берәү дә үз ихтыяры белән керешмәс иде. Әдәби иҗат эшенең кыенлыгын, газабын беренинди материаль кыйммәт белән дә түләп бетерү мөмкин түгел. Материаль бәя ул фәкать иҗат кешесенең яшәешен тәэмин итү өчен генә куела, шуның өчен генә бирелә һәм бездә ул шулай аңлана да. Иҗат кешесен бу һөнәрнең материаль ягы түгел: иҗат куанычы, эзләнүләр һәм табулар, башкалар әйтмәгән яңа фикерне әйтү, яңа образ тудыру куанычы, кешенең рухи хәзинәсен баетуга үзеңнән өлеш кертү, шуңа сәләтле булуың шатлыгы канатландыра».

«Озакламый «Совет әдәбияты»на яңадан (редактор булып) керәм... Нишлисең, сугыштагы егетләр кайтканчы шулай кирәк инде. Аннан соң тагын күз күрер. Ләкин моның бер уңайсызлый торган ягы бар — «Намус» һаман кичегә.

Иптәшләрдән хат күп килә. Атнаның аз дигәндә бер көне — якшәмбе, җавап язуга китә». (12 гыйнвар, 1945).

«Бүген 17 гыйнвар, кичке 17 сәгать 45 минут!

Репродукторда Зәйнәп[2] тавышын ишетәм:

— Иптәшләр! Мәскәүне тыңлагыз! Верховный Баш командующий приказы бирелә! Иптәш Сталин приказы бирелә! Кызыл Армия Варшаваны алган! Безнең Кызыл Армия бүген Варшава шәһәрен алган! Иптәшләр, Мәскәүне тыңлагыз!

Зәйнәпнең тавышы дерелдәвен сизәм. Нигәдер күземә яшь килә. Күңел ярсый, дулкынлана, ничектер итеп бик шәп бер нәрсә язасы килә. Аны шигырь итеп язасы иде, ул шушы вакыйгага лаеклы булсын, илебезнең, халкыбызның батырлыгын, фидакарьлеген гәүдәләндерсен, җырлап торсын, бөтен дөньяга яңгырасын, Мәскәү салютлары төсле үк балкысын иде!»

«Илеңнең бөек эшләре, аның бөек киләчәге белән горурлану һәм иҗат эшеңне шуңа көйләп кору мәсьәләсе. Бу бик зур эш, зур талант һәм акыл белән белем сорый.

Бернәрсәне сизәм: үзең генә аерылып яту, коллективтан читтәрәк яшәү бик тиз мүкләндерергә мөмкин. Гадирәк тормышлы кешеләр арасында яшәүнең ике ягы бар: көнкүрешне өйрәнү өчен Акком асты җайлы. Монда һәммәсе дә күз алдында, чөнки Акком асты ярым авыл

---

[1] Бикбулат — «Намус» романындагы тискәре карт.

[2] Зәйнәп Хәйруллина — музыка белгече, сугыш елларында Татарстан радиосының музыкаль тапшырулар редакторы, аңа кадәр диктор да булып эшләгән иде.

тормышы белән яши, зур шәһәрләрнең йөзәр квартиралы биниһая зур йортларында яшәүчеләр кебек, бер-берсеннән стеналар белән аерылмаган. Мондагы халыкның «эчендәге тышында», бер йортта яшәүчеләр бер-берсен туганнары кебек якын итәләр, бер урам кешеләре бер-берсе белән кунакка йөрешә. Әмма киң колачлы тирән фикерләрне, яңа идеяләрне югарырак катлаудан, алдынгы зур коллективлардан эзләргә кирәк...

Димәк, тегесе дә, монысы да кирәк.

Хәер, кешесенә дә карый. Борын заманнарда фәнни ачышларның, әдәби образларның, поэтик шедеврларның күбесе мәгарә эчендәге ялгызлыкта туган. Акыл иясе, иҗат кешесе шаулап, гөрләп торган зур шәһәр уртасында яшәгәндә дә ялгызлыктан җәфа чигәргә, карурман уртасындагы бер тәрәзәле аучы өендә исә үзен халык тормышындагы зур вакыйгаларның уртасында итеп, шуның актив көче итеп хис кылырга һәм шуны әсәрендә гәүдәләндереп бирергә мөмкин.

Менә бит акыл сатам. Син акыл сатма! Шул уйлаганнарыңны кәгазьгә төшереп, әдәби әсәреңдә сурәтләп бир! Укучы аны синең әсәреңне укып белсен. Менә булырсың егет!»

Көндәлек дәфтәрдән:

«Намус»ны яза башлаганнан бирле миңа колхоз авылындагы яңа мөнәсәбәтләр, хосусан, аерым шәхес белән коллектив арасындагы мөнәсәбәт, колхозчының коллектив хезмәткә карашы һ. б. хакында күп уйланырга туры килә.

Уйландыра торган сәбәпләр байтак кына. Алар янынан күз йомып кына узып китү — үз кимчелегеңне күрмәгәнгә сабышу, димәк, аңа шулай кимчелек булып калырга мөмкинлек бирү булыр иде. (Ә без хәзергә күбесенчә шулайрак эшлибез.)

Матур әдәбият дөньясында беренче карауга ук күзгә чалына торган кимчелек шул: хәзерге колхозчыны озак яши торган чын әдәби образ дәрәҗәсенә күтәргән талантлы әдәби әсәрнең булмавы. Безнең татар әдәбиятында андый әсәр юк та юк инде, хәтта ул талантларга нинди бай булган рус әдәбиятында да юк. Игенченең күмәк хуҗалыкларга оешып яңача эшли башлавына унбиш елдан артып бара, ә колхозчы исә матур әдәбиятка һаман керә алмый. Унбиш ел эчендә игенче психологиясендә, бигрәк тә аның күмәк хезмәткә мөнәсәбәтендә туган яңалыкларны тирәнтен өйрәнергә вакыт җитәрлек иде. Шулай да юньле-рәтле әсәр юк. Сәбәбе нәрсәдә?

Минемчә, моның сәбәбе болай булырга охшый:

Хәзерге язучыларның күпчелеге элекке тормышта, хәтта революциядән соң да әле җирдә хосусый милекчелек чорында яшәгән кешеләр. Димәк, авыл идиллиясе, гомумән авыл үзенең бөтен консерватив һәм поэтик яклары (айлы төннәр, сандугачлы урманнар, салкын чишмәләр, игенченең ата-бабасыннан ук сузылып килгән төрле гореф-гадәтләр, уңай һәм тискәре йолалар, бичуралар, мунча париләре һ. б.) авыл тормышының төрле шомлы, фаҗигале һәм драматик вакыйгалары белән буталып аның күңелендә билгеле бер поэтик формага салынган хәлендә яши. Яңа авылга хас сыйфатлар һәм күренешләр исә андый поэтик формага кереп өлгермәгәннәр әле. Шунлыктан, хәзерге язучылар иске авыл турында ярыйсы гына язсалар да, аларның яңа авылны әдәбиятта тиешенчә гәүдәләндерергә көчләре җитми, чөнки ул аларның күңеленә сеңмәгән. Яңа авыл турында язса да, ул аны акылы артыннан ияреп кенә, акылы кушуы буенча гына яза, ә күңелендә поэтик хис ташып торудан түгел.

Кыскасы, күп уйланасы, бик күп эшлисе бар. Бервакыт «Авылга — йөз белән!» дигән лозунг чыккан иде. Менә хәзер дә чын-чынлап авылга йөз белән борылырга кирәк. Авылда әдипнең игътибарын җәлеп итәрлек

яңалыклар азмыни? Күмәк хезмәтнең илһам бирүче, дәртләндерүче тәэсире, Бөек Ватан сугышы чорындагы фидакарьлек мисаллары һ. б. Тик аларны күрә белергә, күңелең аша уздырып укучыга җиткерергә кирәк». (16 март, 1945).

М. Горькийның бик акыллы тирән фикерләре арасында мондыйлары да истә калган: кешене экономик, сәяси һ. б. җәһәттән азат итү генә җитми, аның рухы, җаны да азат булырга тиеш.

Гаҗәп тирән мәгънәле һәм акыллы фикер!

Гасырлар буена монархия табаны астында яшәгән халыкларга карата бу бигрәк тә дөрес. Андый халыкларда коллык хисе, патшага, аның түрәләренә буйсынуның мәҗбүрилеге, хәтта зарурилыгы буыннан-буынга каннарына сеңеп килгән. Бу хис крестьян психологиясенә бигрәк тә тирән сеңгән. Элек авылда: «Күктә алла, җирдә патша»,— диләр, моны мәңге шулай булырга тиеш дип аңлыйлар, хәтта моңа каршы килү гөнаһ санала, андый кешене «киртә сикергән» кешегә саныйлар иде. Шул сәбәпле, игенчеләрнең наданрак, динлерәк өлеше Октябрь революциясенең әһәмиятен дә тиз генә аңлап җиткерә алмады. Үзеннән көчлеләргә һичсүзсез буйсынырга кирәклек хисе кешенең ихтыяр көчен богаулап асрый, аңа үзен чын мәгънәсендә хөр кеше итеп хис кылырга уңайсызлый, ул үзен җитди эшләрне мөстәкыйль рәвештә башкарырга сәләтсез дип, аңа көче җитми дип саный, ул аның кыюлыгына комачаулый.

Безгә матур әдәбиятта әнә шул борынгыдан канга сеңеп калган коллык хисенә каршы да көрәшергә, хөр җанлы кешеләр образы иҗат итәргә кирәк. «Хөр җанлы» дигәннән, анархистлар аңлый торган чиксез-чамасыз, йөгәнсез «хөрлек», ягъни башбаштаклык, бертөрле законга яисә тәртипкә дә буйсынмый торган зимагурлар үстерү турында сүз бармый. Социализм җәмгыятенең хөр кешесе үзенең җәмгыятьтә нинди урын тотуын яхшы аңлап эш итәргә, кешелек дөньясын тагын да алга әйдәү үзенең изге бурычы дип санарга, әмма үзенең кешелек горурлыгын һәрдаим югары тотарга, теләсә нинди авторитетлар алдында да «изелеп» төшмәскә, үзен түбәнсетүгә юл куймаска тиеш. М. Горький юкка гына: «Кеше дигән сүз горур яңгырый!» — дип әйтмәгән!

Чит илләрдә йөргәндә шундый бер рәсем күргән идем: дәүләт җитәкчесе янында батырлыгы белән бик күп сугышларда танылган мәшһүр генерал сурәте бирелгән. Дәүләт җитәкчесе күкрәген киерә төшеп генералга нindидер әмер яисә күрсәтмә бирә, генерал исә бер кулына блокнот, икенче кулына карандаш тоткан хәлдә җитәкчегә текәлгән. Ул аның авызыннан чыгачак сүзне шундый бер түбәнлек, шундый ялагайлык кыяфәте белән көтеп тора ки, аның үзен болай түбәнсетүе хәтта ачуны китерә башлый. Кая генералда кешелек горурлыгы, кая аның меңнәрчә сугышчы белән идарә иткәндәге ихтыяр көче, кая аның данлы исеме? Бу рәсемдә сугышчан генерал үзенең чын асыл сыйфатын, авторитетын аяк астына салган ялагай кыяфәтендә бирелгән иде.

Менә шулай эшләр. Ай-һай күп үсәсе бар әле!

«Безнекеләр Берлинда сугышалар. Менә кайчан икән ул җиңү көннәре! Шушы бер атна эчендә сугыш бетәр шикелле.

Бүген иптәшләргә бик күп хат яздым.

Иртәгә демонстрация. Ләкин мин чыга алмыйм, аягым йөрми, тромбофлебит. Теге әсәрне язып бетерәсе иде. Юкса бит тәмамламыйча «ычкынып» китүең дә бик мөмкин. Әгәр дә бу әсәремне бетермичә китеп барсам, язучы исемен күтәрү бик кыен булачак». (30 апрель, 1945).

## XXV

Сугыш бетте, конец!

Ул көнне мин Пелэтән шифаханәсендә аягымны дәвалап ятадыр идем. Төнге икеләр чамасы булгандыр, безнең палатада ятучы Шакир абзый каяндыр шаулап кайтып керде. Палата уртасында арлы-бирле йөренеп кычкырып җибәрде:

— Нишләп шундый вакытта йоклап ятасыз! Торыгыз хәзер үк! Сугыш бетте, әйдәгез барыгыз да урамга!

Шакир абзый өстенә халатын элде дә башкаларны да ияртеп каядыр чыгып китте. Палатада мин калдым, минем шикелле аягына баса алмаган тагын бер-ике авыру калды. Без көч-хәл белән «тыраклап» палатаның урамга караган тәрәзәсенә барып ябырылдык. Караңгы иде әле. Шулай да урамдагы кешеләр шәүләсен аерып була иде инде. Бөтен урам халык белән тулган. Берсен-берсе кочаклыйлар, тәбрик итешәләр, нидер әйтеп кычкыралар, кемнәрдер елый иде. Кыскасы, халык дүрт ел буена җыелып килгән кайгысын-хәсрәтен, моңын-зарын, тулып ташырга торган күз яшен шушы шатлыклы сәгатьләрдә берьюлы тышка чыгара иде.

Аз-маз аягына басарлык авырулар, больница халатлары кигән килеш урамга ташландылар да, үзеннән-үзе оешкан демонстрациягә кушылып, шәһәр уртасына киттеләр. Алар яктыргач кына кире кайттылар. Күбесе шактый ук «кәефле» иде. Чөнки аларны урам чатларында аракы, бал, сыра, самогонка белән сыйлаучы кешеләр каршы алган. Андый кешеләр капка төпләренә кечкенә өстәлме, урындыкмы куеп, узган бер кешене сыйлап озаталар.

— Әйдә, туган. Бу шатлыклы минутларда минем сыемнан авыз ит! Җиңү көненә дип күптән әзерләгәнием! — дип кыстыйлар икән.

9 Майны көн буена бәйрәм иттек, шифаханәгә киенеп-ясанып туганнар килде, сыйландык, шатлыкның иге-чиге булмады. Әмма берәүләр шатлана, икенче берәүләр кайнар күз яше түгә иде. Чөнки сугышта үлеп калучыларның хатыннары, бала-чагалары үзләрен бик нәүмиз хис итәләр, бу аларның соңгы өметләре өзелгән көн, алар кайгыларын күз яше белән юалар иде. Ул бәйрәм көненең миңа иң авыр тәэсир иткән ягы шул булды.

Мин шифаханәдән чыгуга, Шәрәф Мөдәрриснең төсле открыткасы килеп төште. 1942 ел көзендә аның белән Төньяк-Көнбатыш фронтының газетасы «Ватан өчен» редакциясендә чагында алдынгы сызыкта йөргән идек. Ул миңа шунда һәм аннан соң язган хатларында «Берлинны алгач, мин сиңа рейхстагтан хат салырмын»,— дигән иде. 1942 елда ул вәгъдәнең гамәлгә ашуына ышану ансат түгел иде әле. Ул вәгъдәне үтәү өчен күпме кан коярга туры килде. Әмма хәзер шушы таушалган открытка мине ифрат дулкынландырды. Рейхстаг баскычына утырып җимерекләр арасында язылган бу открытка Шәрәф хаты гына, нечкә күңелле шагыйрьнең дулкынлану җимеше генә түгел, ифрат зур әһәмияткә ия булган тарихи документ иде. Ул безнең ил кешеләренең үз юлыбызның хаклыгына, кайчан да булса җиңәчәгебезгә сугышның башлангыч чорларында ук ышанып торуыбызның җанлы шаһиты иде.

Көндәлек дәфтәрдән:

«Бу арада А. Шамов, А. Әхмәт, Ш. Маннур кайттылар. Күпне күргәннәр, бик арыганнар. Кайттылар, ләкин озакка түгел, китәргә дип кайттылар. Сугыш бетте дә, бетмәде дә...» (29 май, 1945)

«Намус» намуссызланып язылмыйча ята. Чөнки акча юк. Бүтән эшләргә ялланып хезмәт итәргә туры килә.

Кешене язгы кыяр яки помидор шикелле теплицада үстерү зарарлы. Көрәшеп үссен! Бу җәһәттән казах халкының бер гадәте миңа бик ошый. Алар, малайлары 7 яшькә җиткәч, аны айгырга атландыра-

лар. Айгыр котырынып малайны далага алып чаба. Ат өстендә ябышып калырга тиеш малай! Юкса аны айгыр җиргә атып бәрәчәк.

Яшүсмер егет булып, мөстәкыйль кеше булып яшәү юлына аяк басканда аңа олылар аркасына ышыкланмыйча үз юлы белән атларга тиешлеген сиздерерлек шундый берәр чара күргәндә һич тә зарар итмәс иде. Сугыш та моның кирәклеген раслады». (19 июнь, 1945).

«Эшләп утыра идем, бастырыбрак куйган репродукторда Юрий Левитан тавышы ишетелгән кебек булды. Бардым, тыңладым. Без Япония белән сугыша башлаганбыз икән. Хәерле булсын. Ләкин тиз бетә күрсен. Сугыш бик ардырды». (8 август, 1945).

«Мин исән-сау һаман язып ятам. «Кайчан бетерәсең?» дип сорыйлар. Һай, яза башлавымны баштарак әйтмәгән булсамчы! Кайчан бетерермен икән соң? Бәлки декабрьда, бәлки февральдәдер. Бер язучыдан: «Бүген күпме яздың?» — дип сораганнар. Ул әйткән:

— Бүген мин элекке нокта урынына нокталы өтер куйдым,— дигән.

Икенче көнне янә шул сорауны биргәннәр. Ул әйткән:

— Кичә куйган нокталы өтерне бүген сызып ташладым, чөнки анда нокта гына куярга кирәк булган икән,— дигән.

Миндә дә шундыйрак хәл.

Бер нәрсә мине тынычландыра. Ул да булса, иҗатыма зур таләп куюым. Кайбер урыннар өчәр вариант языла. Ләкин берсе дә ошамый, мин теләгәнне әйтеп бирә алмыйм. Аларны аяусыз, миһербансыз сызып ыргытам. Хәтта дүртенчесе дә ошамаска мөмкин. Анысын да сызам. Күңел тынычланганчы шулай. Ә күңелем канәгатьләнерлек сурәт туганнан соң аны шулай язуыма моңарчы үкенгәнем юк әле. Шаять, монда да ялгышмам.

Бүген ял иттем. Бәрәңге бакчасына бардым. Балалар белән музейга барып кайттык.

А. Шамовтан хат килде. Кытайда йөрибез, дигән. «Мондагы тормышны күргәннән соң, үзебезнең Россиянең өтек чыпчыгы да мондагы сандугачлардан мең өлеш артык икән, дип әйтәбез»,— дип язган». (29 сентябрь, 1945).

«Үземне-үзем бик ватам, кирәкмәгәнгә, мәгънәсезгә ватам. Нервлар, гасабилану. Әгәр дә тиела төшеп үземне бу акылсыз талаулардан котыла алмасам, ахыр чиктә «сары йортта» һәлак булачакмын. Бер генә юл бар: тизрәк язып бетер! Шуннан соң һәммәсе дә көйләнергә мөмкин». (7 ноябрь, 1945).

«Әйбер урлаган кешене, акча туздыручыны хөкемгә тартып төрмәгә ябып куялар. Бик дөрес эшлиләр! Меңә мине һәм тагын өч язучыны 150 километрдагы бер колхозга ике көнгә командировкага җибәрү алдыннан 4 көн һәм 4 төн йөрттеләр. Инде бишенче көнгә чыгабыз дигәндә генә әлсерәп, телләребез чыгып сәгать 12 дә генә кәгазь алып кайтып кердек. Әйтеп кеше ышанмас, ләкин — факт!

Без көпә-көндез үзебезнең алтыннан кыйммәтрәк вакытыбызны урлыйбыз! Ә «без — үзебез» җыя торгач әллә ничә миллионга тула бит!

Без һаман да бик булдыксыз, сәләтсез әле». (9 гыйнвар, 1946).

«Язып кына утырыр идем, кесәдә бер генә тиен дә акча калмады. Шунлыктан Махьянга[1] ялландым. Әрлән, чикерткә, зилзилә һәм гоберле бакалар турында язылган җыен шурум-бурумны «денгә» кертеп утырам». (31 гыйнвар, 1946).

«Мәскәү җырлый. Гаҗәп бу рус халкының көйләре! Белмим, кечкенәдән ишетеп үскәнгәдерме, белмим, башка сәбәп, ни генә булмасын, рус халык көйләре, үзебезнең татар халык җырлары кебек үк, күңелнең иң нечкә кылларын тибрәтә. Никадәр моң, нинди киң сулыш!

---

[1] Махьянов — Татарстан китап нәшриятының ул еллардагы баш редакторы.

Халыкның музыкасына, һичшиксез, аның яшәү шартлары, шул җөмләдән яшәү урыны, аның табигате дә зур йогынты ясый булса кирәк. Моңа казахлар да мисал була ала. Казахның даласы иксез-чиксез, очына чыгарлык түгел. Сәхрәсенә чыкса, дүрт ягы да әллә кайларга җәелеп киткән киң дала, күккә караса, күгенең чиге юк. Казахның күз карашын берни дә чикләми. Шуңа күрә аның тыны киң, җыры да озын. Никадәр наданлыкта, караңгылыкта яшәсә дә, аның рухы иркенгә күнеккән. Чөнки шундый кырыйсыз-чиксез киң далада аның үзен зинданга ябып, уен-фикерен бикләп, богаулап куярга берәүнең дә мөмкинлеге булмаган.

Инде үзебезнең татарны ал. Ул, бичара, чокыр-елга арасына, кырын-кырагай җиргә килеп поскан да шунда йомылып та калган. Ни аяк сузарлык урын, ни иркенрәк суларлык киңлек — берсе дә юк. Аның өстенә, алпавыты, түрәсе, уряднигы. Кая барсын да нишли алсын? Шул морзалар, алпавытлар арасында нишләргә белмичә кагылып, сугылып йөри торгач, аның җыр, бию сәнгате дә бик күп хасиятләрен югалтып «тәк сибә» диярлек кенә булып кала язган. Нә горурлык анда, нә кыю хәрәкәт, нә бүтәне...

Аның көенең, җырының, биюенең дә күбесе яшәгән җирләренә охшаган. Чокырдан-чокырга, сикәлтәдән-сикәлтәгә сикергәләп чапкан арба тавышы кебек тырылдый-тырылдый да өзелә, башлый да тагын өзелә...

Ярый әле революция булган. Юкса, татар халкы Владивостоктан Петроградкача төрле җирләргә сибелеп-чәчелеп җилгә очып беткән булыр иде». (19 май, 1946).

Көндәлек дәфтәрдән:

«Күңел тыныч түгел, чөнки дөньяда тынычлык юк.

Хәтта сугышның өченче, дүртенче елларында да тынычрак яши идек, чөнки ул елларда бу каһәр төшкән сугыш беткәннән соң без инде тыныч яшәрбез, иген игәрбез, яңа завод-фабрикалар сала башларбыз, тормыш элеккесеннән дә матуррак булып балкып китәр, совет иленең халыклары үз бәхетләрен кайгыртырлар дип хыялланган идек. Шулай хыялланырга, ямьле киләчәк өчен хәзергенең кыенлыкларын юкка санарга безнең мең мәртәбә хакыбыз бар иде.

Ни килеп чыкты? Ул вакыттагы хыялларыбыз торган саен сүнә бара. Сугыш беткәнгә әле нибары ел ярым гына, ә яңа сугыш — менә ул, ындыр артында гына! Әгәр үзеңнән-үзең яшерергә теләмәсәң, ул сугышның хәтта кемнәр арасында булачагын да, фронт сызыгының кайсы тирәдән узачагын да әйтеп бирергә мөмкин...

Әгәр шушы бер-ике ел эчендә яңа сугыш башланып китми икән, ул фәкать безнең ил җитәкчеләренең зирәклеге, акыл белән эш итүләре, Советлар иленең хәрби куәте ирек бирмәү аркасында булмый калачак.

«Аерым шәхес тарих ясый алмый»,— диләр. Шулайдыр. Әмма Трумэнның чиктән ашкан явызлыгы сугыш утын кабызып җибәрү өчен бик җитә...

Бик гаҗәп, акыл җитмәслек хәл: кеше дигәнең мәдәнияте үскән саен рәхимсезләнә бара. Ярым кыргый вакытында ул дошманын таш яки күсәк белән берәм-берәм генә үтергән булса, хәзер империализм дигәннәре атом бомбасы ташлап халыкны бөтен шәһәре белән берьюлы кырып ташларга җыена. Коточкыч кыргыйлык түгелме соң бу?!

Боларның барысы өстенә җитмәсә быел иген начар булды. Яз көне җебетә башлаганнан соң яңадан кар явып, арышның аз дигәндә өчтән ике өлеше кар астыннан череп чыкты. Июль урталарына кадәр яңгыр булмады. Шул барлы-юклы игенне җыя гына башлаганнар иде, менә сиңа тагын бер афәт: коеп ява торган яңгырлар башланды. Аязып та тормады, октябрь башларында ук (кайчаннан бирле булмаган хәл!)

кар яварга тотынды, туңдырып җибәрде. Димәк, бәрәңгенең җирдә калуы, урылмаган ашлыкның коелып бетүе ихтимал.

Үзен генә кайгыртып яшәүчегә кыен түгел. Әмма язучыны һәммәсе дә борчый. Аның күңеле термометр кебек һәммәсен сизеп тора, ил өстендәге яхшы һәм кыен хәлләр һәркайсы аның халәте рухыясына үзләренең эзләрен салып үтәләр». (31 октябрь, 1946).

## XXVI

«Ниһаять, «Намус»ны тәмам итеп журнал редакциясенә тапшырдым. Гомеремдә беренче мәртәбә бугай, күңелемдәген үзем хис иткәнчә, үземне канәгатьләндерерлек итеп әйтеп бирә алдым шикелле. Язучының бу бик зур куанычы. Бу үзенең идеалына якынлашып килү дигән сүз.

Хәзер аны укыйлар. Әле берәүнең дә кире фикер әйткәне юк. Бәлки андый фикер булмас та?» (24 ноябрь, 1947).

«Беркөннәрдә мине Язучылар союзына яшь язучылар белән очрашуга чакырдылар. «Иҗат эшләрең белән таныштырырсың, тәҗрибә уртаклашу булыр»,— диделәр. Очрашуга унбиш-егерме яшь язучы катнашачагын әйттеләр.

Бардым. Союз бүлмәсенә сыеп булмады, Тукай залын ачарга туры килде. Бераздан зал да тулды. Күпчелеге яшьләр — егетләр-кызлар, арада берничә әдәбият укытучысы да, бүтәннәр дә бар иде. «Намус» романын ничек язуым хакында сөйләдем. Илле-алтмышлап сорау бирделәр. Арада «Татар совет прозасын яңадан аякка бастыруыгыз өчен бик рәхмәт Сезгә!» — дигән запискалар да бар иде.

Гомумән, бик күңелле һәм җанлы үтте.

Морквашта укытучыларның ял йортында да шундый ук очрашу булган иде. Анда да әсәр турында бик яхшы фикерләр әйттеләр, котладылар.

Мәскәүдән шатлыклы хатлар килә. Төрле өлкәләрдән, районнардан килгән хатларда шулай ук әсәрне яратып укулары хакында язалар.

Бөек Октябрьның 30 еллыгы уңае белән игълан ителгән конкурста «Намус» романына 1 нче бүләкне бирергә карар иттеләр. (Утыз мең сум).

Камил Якуб типографиясенең цех мастеры зарлана: «Наборщиклар «Намус»ны җыя башлагач эшләрен туктатып елап утыралар, «Совет әдәбияты»ның тиражын җиткерә алмыйча аптырыйбыз»,— ди.

Кызык! һәм шатлыклы хәл. Димәк, йокысыз төннәрем бушка китмәде». (Май, 1948).

Ләкин болар әле роман хакында өзек-төтек әйтелгән аерым фикерләр генә иде. Тәфсилләп язылган «подвал» ярымлык озын мәкалә дә озак көттермәде. «Намус» романына төрле яктан бәя бирүгә багышланган бу мәкаләне язучы Ф. Хөсни, журналистлардан Ф. Балыкчы һәм Ф. Мөсәгыйт язганнар иде [1]. Бу мәкаләнең моңа кадәр роман турында әйтелгән фикерләрдән аермасы шунда иде ки, аның авторлары нигәдер «Намус»ның бер генә уңай ягын да «күрмәгәннәр», аларча, әсәрнең теге ягы да, бу аспекты да «тиешле югарылыкка» күтәрелмәгән, шунлыктан, алар бөтен осталыкларын, каләм үткенлеген романның кимчелекләрен «фаш итүгә» сарыф кылганнар. Бу мәкаләне мин, бәлки, телгә дә алмаган булыр идем, чөнки аның тупаслыгын, фальшь икәнлеген тарих үзе фаш итте. Миңа аның «сөземтәсе» бик тә «гыйбрәтле» кебек күренде. Әлеге авторлар романның шундый-шундый кимчелекләрен өсте-өстенә өеп санап чыкканнан соң, әдипне кызганыпмы, аңа миһербанлы булуларын күрсәтү өченме, әллә үзләренең зерә дә алдан кү-

[1] «Намус» романы турында. «Кызыл Татарстан», 1948 ел, 13 октябрь.

рүче «зирәк тәнкыйтьчеләр» булуларына кинaя ясапмы, бу китап, кимчелекләре тулып ятуга карамастан, бригадирларга һәм дә звено башлыкларына кулланма буларак ярап куяр бәлки дигән сыман нәтиҗә чыгарганнар иде.

«Язмыш бер алдын күрсәтсә, биш артын күрсәтә»,— диләр. Шуның шикелле, Казан матбугаты минем әсәрнең башта ни сәбәпледер гел тискәре ягын гына күрергә тырышты. Романның русча тәрҗемәсен дә шундый ук караңгы чырай белән каршы алдылар. А. Ясницкая дигән ханым «Красная Татария» газетасында «Тормыш хакыйкатен бозып күрсәтмәскә!»[1] дигән хәтәр мәкалә белән чыкты. Укып карасам, исем китте. Әнә нәрсәне «бозып күрсәткән» икән автор! Яңа гына рәис итеп сайланган Тимери картның җигеп йөрергә дип беркетелгән атны үз хуҗалыгына алып кайтып аякка бастыруын да бик тырышканда идеологик хата дип атарга була икән ләбаса!..

Шулай итеп, Казан матбугаты мине романның киләчәгенә әллә ни өметләр багламаска, «өлешемә чыккан көмешем» дип, биргән бәягә канәгать булып яшәргә күндермәкче булса да күңелемнән мин моңа ризá түгел идем. Романның чын әдәби кыйммәтен кем дә булса аңлар, кемдер һич югында Нәфисә образына игътибар итәр, яисә халыкның сугыш елларындагы патриотик хезмәтен күрми калмаслар, дигән өмет бар иде. Ләкин ул фикерне иң беренче булып Казан түгел, Мәскәү әйтте. «Советский писатель» нәшриятыннан Сергей Бородинның[2] романга рецензиясе килеп төште. Бу иптәш романның бик күп уңышлы якларын күрсәтеп узган, гомумән, әсәргә югары бәя биргән дә, берникадәр пәйгамбәрлек итеп, бу «зур пароходның» киләчәктә зур дәрьяларга чыгачагына ышануын белдергән иде.

Роман «Советский писатель» нәшриятында басылып чыкканнан соң авторга төрле өлкәләрдән бик күп хатлар килә башлады. Язучылар союзының ул вакыттагы рәисе Әхмәт Ерикәй хәтта К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романы белән «Намус»ны Сталин премиясенә[3] тәкъдим итүне кайгыртып йөрде.

Республика китапханәсенең зиннәтле матур залында «Намус» романына багышланган укучылар конференциясе булды. Конференцияне китапханә мөдире мөхтәрәмә Рәисә ханым Мөхитдинова[4] ачып бик җылы кереш сүз сөйләде. Аннан соң бер-бер артлы чыгып китапханәнең даими укучылары романның художество кыйммәте, теленең үзенчәлеге хакында фикерләрен әйттеләр. Бик күп сораулар бирелде. Авыл җирендә уздырылган мондыйрак конференцияләрдә, гадәттә, әсәрдәге геройларның прототиплары турында күбрәк сорыйлар, «Геройлар кемнәрдән күчереп язылган, нәкъ тормыштагычамы, әллә үзгәрешләр дә бармы, Нәфисә Хәйдәргә кияүгә чыктымы, туйлары булдымы?» кебегрәк сорауларны күп яудыралар иде. Очрашу монда да шундыйрак дәрәҗәдә бармагае дип шикләнгән һәм кыенсынып көткән идем, бәхеткә каршы, республика китапханәсенең укучылары ул примитивлыктан өстен торалар икән. Бу мине бик шатландырды. Чөнки бу укучыларыбызның культура дәрәҗәләре үсүен күрсәтә иде.

Сорауларга җавап биргәндә, бик үк алга чыкмыйча уртадарак кына утырган Гомәр Галигә күзем төште. Ул бик игътибар белән тыңлый,

---

[1] «Красная Татария», 1950 ел, 11 апрель.

[2] Элек Әмир Саргиджан псевдонимы белән билгеле булган рус язучысы. Соңгы елларда Ташкентта яшәде. Урта Азия халыклары тарихына багышланган тарихи романнары белән танылды.

[3] Хәзерге СССР Дәүләт премиясе ул елларда шулай атала иде.

[4] Хатын-кызлардан революциянең беренче елларында күтәрелеп чыккан күренекле совет һәм җәмәгать эшлеклесе, зур стажлы педагог, ТАССР мәгариф комиссарының ярдәмчесе, В. И. Ленин исемендәге республика китапханәсенең директоры булып эшләде.

чыраена караганда фикер алышуның эчтәлегеннән канәгать кебек күренә иде.

Җыелыш тәмамланганнан соң, мин аннан конференция хакында, гомумән, монда әйтелгән фикерләргә ничегрәк каравы хакында сораштым. Ун ел дәвамында әдәбияттан аерылып торган күренекле тәнкыйтьченең хәзерге әсәрләр хакында фикерен беләсе килү бик табигый иде. Укырга өлгергән әсәрләр анда яхшы фикер тудырган. Соңгы елларда әдәбиятка яшь авторлар килүе аны бик куандырган икән.

— Якын киләчәктә Бөек Ватан сугышы темасына язылган бик җитди, зур әсәрләр пәйда булса кирәк. Хәзер әдип һәм шагыйрьләрдән тормыш шуны таләп итәчәк,— диде ул.

Аның белән сөйләшүдән мин аның хәзер дә матур әдәбият мохиты белән, аның уңышлары белән рухланып яшәвен аңладым. Әмма аның сүз сөрелешендә, фикер йөртүендә элекке кискенлек, яшьрәк вакытындагы катгыйлык сизелми башлаган иде инде.

Көндәлек дәфтәрдән:

«Бүген көндезге концертта Нәҗип Җиһановның «Кырлай» поэмасын бирделәр. Бәлки минем музыканы аңлавым бик беркатлы, берьяклыдыр, ихтимал, шулайдыр, әмма минем аңлавымча, безнең композиторларның соңгы елларда язган әсәрләре арасында бу поэма иң талантлысы, халыкчаны, иң озак яшәргә тиешлесе булса кирәк. Ниләр генә юк монда! Башта бер гаилә эченә, аерым кеше кичерешләренә генә хас интим ягымлылык һәм йөрәк җылысы белән башланып китә дә шуңа ияреп әсәрнең төп темасы ишетелә башлый. Менә сиңа һәркайсыбызның күңелендә уелып калган яшел болыннар, кечкенә инешләр аһәңе, һәркайсыбыз җиләк җыйган, чикләвеккә йөргән сөйкемле урманнар, челтерәп аккан чишмә тавышлары, болын өстендәге иртәнге томан. Табигатьнең бу гүзәл манзараларын авазлар ярдәмендә күз алдына китереп бастыру өчен күрәсең, бик зур талант кирәктер, өстәвенә ул талант иясенең лирик җылылыкка бик бай булуы заруридыр.

Ул гына да түгел, бу әсәрдә авазлар шигърияте шундый соклангыч борылышлар ясый, шундый көйләр булып яңгырый, алар татар халкының узгандагы мескен тормышын да, кысан һәм аяныч авыр язмышын да чагылдыралар кебек. Никадәр күңел сызлануы, нинди авыр моң яңгырый монда.

Поэманың төп темасы уйналганда ничектер үзеннән-үзе минем күз алдыма шундый бер манзара килә: әрәмәле инеш буендагы калку чирәмлектә беркат күлмәк кенә кигән яланаяклы кыз бала инеш аръягындагы салам түбәле ярлы авылга карап утыра. Аның уйлары бик моңсу. Зур коңгырт күзләре авылның аргы башындагы яшел зиратка төбәлгән. Ул бала бик озак шулай моңаеп утыра да авыр сулап куя. Тукай әнисе Мәмдүдә зиратына карап шулай моңаймыймы икән ул? Әллә ул кыз бала түгел, ятим малаймы икән?..

Бу поэма шул ук вакытта йөрәккә нииндидер ягымлы, өметле якты хисләр дә иңдерә. Аны тыңлаганда бик моңсу да, бик рәхәт тә булып китә. Поэманы тыңлаганнан соң күңелең нәрсәгәдер, ниндидер бер яхшы хисләргә баеп калган кебек сизәсең.

Бу әсәр формасы белән милли, эчтәлеге белән исә бөтен җәмгыятьнең рухи байлыгына күркәм өлеш булып килеп керә». (26 февраль, 1950).

Уйлыйсы, очына чыгасы һәм «мыекка чорныйсы» мәсьәләләр бетәсе түгел. Җәмгыять тормышы ифрат катлаулы һәм дә тиз алмашынучан, үзгәрүчән. Әгәр дә шул катлаулы иҗтимагый тормышның төп агымына юлыгып, шуңа игътибарыңны юнәлдермәсәң, вак-төяк тема белән чикләнеп калырга мәҗбүр булачаксың.

Нәфисә образы шәп-шәрә урында барлыкка килмәде. Аның мәхәббәте, ирләргә мөнәсәбәте, гомумән хезмәткә, әхлак мәсьәләләренә кара-



*Т. Хажиәхмәтов рәсеме.*

шы электән килә торган гореф-гадәтнең, традицияләрнең хәзерге замандагы дәвамы рәвешендә килеп тудылар. Нәфисә — хезмәт иясе хатын-кызларыбызның хәзерге заман тәрбияләп үстергән, замана һавасын сулап үскән сеңелләре. Нәфисә — «Татар хатыны ниләр күрми»дәге һәм «Кара йөзләр»дәге изелгән, кешелек сыйфатларын югалткан хатын-кыз образларының антиподы, аларга протест сыйфатында туган хәзерге заман кызы.

Игенче агай борын-борыннан үзенең хосусый милке — аты, сыеры, иске арбасы, йолкыш кәҗәсе өчен сызланып яшәде. Күмәкләшү ул чирне аннан каккалап-суккалап бәреп чыгарырга тырышты. Колхозчы хәзер җәмәгать милкен кайгырта башлады. Ләкин ни дәрәҗәдә? Колхозларны берләштергәндә аңа әле хәзер дә үзенең туган авылының җире, болыннары, чишмәләре газизрәк түгелме? Игенче агайның элекке җиргә-суга булган кайнар мәхәббәте колхоз милкенә карата да шулай кайнармы? Буыннан-буынга килгән шул хис күмәк хуҗалыкка күчкәч сүрелмәдеме? Бу — мәсьәләнең иң җитди ягы.

Колхоз милкен үз милке кебек кайгыртуы элеккегә караганда бик зур бер адым алга атлавы булды игенче агайның.

Ләкин шулай да ул әле коммунар ук түгел. Ул баскычка менеп җиткәнче тагын бик күп үтәсе бар.

Тракторчылар кызык категория. Алар — колхоз әгъзалары, әмма шул ук вакытта дәүләт оешмасында эшләп, аннан хезмәт хакы алалар.

Тагын шундый бик күп мәсьәләләр.

Һай яратам да инде кешене! Теләсә кемне түгел, катлаулы, бай эчке тормыш белән яшәүчеләрне, шигъри җанлы кешеләрне!

Авылдашым Сәет Гарипов белән кичен Эрмитаж бакчасында йөрдек. Караңгы төшкән, әмма тулы ай балкып тора иде. Ай нуры агач ботаклары аша җиргә бик тә катлаулы сихри бизәкләр төшергән иде. Анысы яңалык түгел. Мине авылдашымның гап-гади чокырларга игътибар итүе кызыксындырды. Эрмитажның ике ягында да тирән чокырлар бар, алар кайсы да булса урамга алып чыгалар. Аларның кырыйларында һәм төбендә төрле куаклар, озын үләннәр үсә. Болай карауга гади генә чокырлар. Кичен караңгыда узганда хәтта аларга бераз куркыбрак та карап узалар. Кем булмас, ниләр булмас ул тирән чокырларда!.. Сәет исә минә шул чокырларга, гомумән, кердәле-чыктылы бу ландшафтка үзенчә сокланып, аларның тирә-юньгә ямь биреп, тигез урыннарга үзгәреш кертеп, матурлап торулары турында бик яратып, хәтта дулкынланып сөйләде.

— Мондый чокыр-чакыр безнең Яңасалада да күп бит. Без синең белән шул чокырларда уйнап үскән малайлар. Бәлки шул чакта күңелеңә матур булып кереп калгандыр? — дип карадым.

— Юк, аннан гына түгел,— диде Сәет. Ничек итеп аңлатырга икән дигәндәй, як-ягына каранып барды.— Тигез урын кеше күңеленә болай тәэсир итә алмый, чөнки тигезлектә битарафлык бар, ул гел бер төрле, анда үзгәреш, күз туктар урын юк. Ә чокыр — ул инде үзгәреш, һәр чокыр бер форма. Аның кырыйлары, калку ярлары, тирән яки сай төбе бар...

Як-ягыма мин дә игътибар беләнрәк, күңел күзе беләнрәк карый башладым. Чыннан да... Ай нуры чокырларның төрле урынын төрлечә яктыртып, аларны ниндидер серле итеп, моңарчы күренмәгән матурлыклары белән баетып күрсәтә иде.

Тагын шундый серле һәм гүзәл күренешләр.

Табигать матурлыгын минә шулай бергәләп күрү, аны икең дә тирән аңлау кешеләр арасында ягымлы, җылы мөнәсәбәт тууга да сәбәп була, күңелеңне баета, бер-береңне тагын да тирәнрәк аңлый башлыйсың, иптәшеңә яки дустыңа ихтирамың да арта.

«Беркөннәрдә «Культура и жизнь» газетасы «Намус» турында һәйбәт бер мәкалә биргән иде. Менә шундый ук уңай бәя биргән мәкалә кичә «Правда» газетасында басылып чыкты. Бер үк әсәр турында шундый авторитетлы ике үзәк газетада бер-бер артлы шундый мәкаләләр басылып чыгу ул бит бик сирәк була торган хәл. Мин андый югары күтәрүләргә гадәтләнмәгән, үземне һәр шөгыль һәм вакыйганың иң кире һәм авыр ягын күрергә, тискәре нәтиҗәсен көтәргә күнектереп килгән кеше.

Шуннан бирле телефон бертуктаусыз чыңлап кына тора. Галимнәр, язучы иптәшләр, артистлар, әдәбият укучылар янсә иң гади шәһәр кешеләре чылтыраталар, тәбрик итәләр, куаналар, киләчәктә шатлыклы хәбәрләр көтүләрен әйтәләр.

Әмма иң гаҗәеп яңалыгы тагын шунда — минем әсәр белән Каби Нәҗминең «Язгы җилләр» романын Сталин үзе укыган, имеш, диләр. Ул бит илебезнең иң җаваплы, иң беренче урынында торган житәкчесе. Менә шул кеше үзенең иксез-чиксез партия һәм дәүләт эшләре арасында Казанның Акком астында яшәүче гади генә бер язучы белән кызыксынырга, аның әсәрен укырга ничек вакыт тапкан икән? Гаҗәп бит!» (11 март, 1951).

Сергей Бородинның «пәйгамбәрлеге» дөрес булып чыкты. К. Нәҗминең «Язгы җилләр» романы белән «Намус» 1951 елда Сталин премиясенә лаек дип табылды.

Шатлык митинглары, тантаналы җыелышлар, банкетлар да узды. Тормыш үзенең элекке эзенә төшкәннән соң, Татарстан радиокомитетының ул вакыттагы рәисе булып эшләгән иптәш элек колакка чалынып узган хәбәрләрнең тәфсыйлен сөйләде.

1950 елның көзендә ул ВКП(б) өлкә комитеты секретаре Хажи Рәхмәтуллин янында утырганда кич белән кабинет хуҗасына Мәскәү Кремленнән чылтыратканнар.

— Сезнең белән Иосиф Виссарионович сөйләшәчәк,— дигәннәр.

Хажи Рәхмәтуллин сикереп торган да өстәлдәге кәгазьләр арасыннан ашлык хәзерләү сводкасын эзләргә тотынган. Чөнки беренче секретарь Зиннәт Моратов белән икенче секретарь Казанда булмаганлыктан, Сталин бер дә бүтән белән түгел, ашлык хәзерләү белән кызыксынып дип уйлый икән.

— Билгеле, секретарь бераз дулкынлана башлады,— дип дәвам итте аңгәмәдәшем.— Үзегез беләсез, Сталин белән сөйләшү уен түгел. Сталинның авторитеты элек тә бик югары йөри иде, Бөек Ватан сугышында Советлар Союзы җиңеп чыкканнан соң ул тагын да күтәрелде. Ул елларда, ихтимал, Сталиннан да популяррак бөтен дөньяда бүтән беркем дә булмагандыр.

Бераз көткәннән соң:

— Сөйләшегез, телефонда иптәш Сталин,— дигәннәр. Менә трубкада Сталин тавышы ишетелгән. «Исәнмесез!» дигән. Бу яктан Х. Рәхмәтуллин: «Исәнмесез, Иосиф Виссарионович!» — дип җавап биргән. «Сезнең фамилиягез ничек әле»? — дигән Сталин. Ансат кына да бит, тел очында гына, ләкин әйтә генә алмый ди бит Рәхмәтуллин фамилиясен. Тотлыга торгач, көч-хәл белән генә әйтеп җибәргән. «Сез, иптәш Рәхмәтуллин, Нәҗми белән Башировның романнарын укыдыгызмы?» — дип сораган Сталин. Бәхеткә каршы, укыган икән, Рәхмәтуллин батыраеп киткән, көр тавыш белән: «Укыдым, Иосиф Виссарионович, укыдым!» — дигән. «Сезнеңчә, ниндирәк ул әсәрләр?» — дигән Сталин. «Минемчә, ул иптәшләр ничего гына әсәрләр язганнар»,— дигән Рәхмәтуллин. «Ничегомы, әллә яхшымы?» — дип кабатлап сораган Сталин. «Яхшы әсәрләр язганнар ул язучылар, иптәш Сталин»,— дип җавап биргән секретарь. Шуннан соң Сталин: «Алай булгач, сез аларны премиягә тәкъдим иттегезме соң?» — димәсенме! Менә нәрсә кызыксындыра

икән аны! Хажи Рәхмәтуллин: «Шулкадәр белеп сөйләшә, неужели үзе укыды икән?» — дип уйлап алган. Ничек җавап бирергә дип торганда Ә. Ерикәйнең шул мәсьәлә белән өлкә комитетына килеп йөрүе исенә төшкән. «Язучылар союзы премиягә куйгач, без инде шул җитәдер дип уйлаган идек, Иосиф Виссарионович»,— дигән Рәхмәтуллин. Сталин бу җавапны ошатмаган. «Тагын уйлап карагыз әле, уйлагыз, иптәш Рәхмәтуллин. Хушыгыз»,— дигән Сталин.

Берникадәр вакыттан соң Хажи Рәхмәтуллин башка эшкә күчкәч, мин бу хакта аның үзеннән дә сораштым.

— Әйе, дөрес, фамилиямне әйтә алмый торуым да хак. Шулай да Иосиф Виссарионович белән сөйләшү миндә онытылмаслык истәлек булып калды,— диде ул.

Башта бу хәл мине бик гаҗәпләндерде, СССР кебек зур дәүләтнең башында торучы, шул ук вакытта дөньякүләм әһәмиятле вакыйгалар белән, зур политика белән шөгыльләнүче житәкче ничек әдәби әсәрләр укырга вакыт таба ала икән? Ләкин үзем белгән башка шуңа охшаш вакыйгалар белән чагыштыргач, мин моңа ышандым. Бу безнең ише әдәбият әһелләрен куандыра торган, шуның өстенә, бүтән җитәкчеләргә дә үрнәк булырлык ифрат игелекле мисал түгелме соң?

Үзеннән-үзе шундый сорау килеп туа: ни сәбәпле бу әсәрләргә Казанның көндәлек матбугаты «якты чырай» күрсәтмәгән, нигә ул аларның фәкать тискәре якларын гына күрергә тырышкан? Сүз арасында гына әйткәндә, бу бит бер генә факт түгел, андый язмышка дучар булган әсәрләр бар. Моның сәбәбе нәрсәдә? Казанда әдәби әсәрләргә бәя биргәндә чамадан тыш таләпчән булуданмы, әллә күңел тарлыгыннанмы? Яисә, бездәге гадәт буенча, «кешене тыйнаклык бизи» дигән мәкальне күпертеп аңлап, кирәгеннән артык «тыйнак» булып күренергә омтылуданмы? Яисә кыю фикерне беренче булып әйтүдән сакланып, аны башкалар әйткәнне көтеп яту нәтиҗәсеме бу?

Шундый көннәрнең берендә Кәримәнең комод янында минем сугыш елларында киеп тә хәзер гамәлдән чыккан иске пижама, пинжәк кебекләрем белән мәшгуль булуына игътибар иттем.

— Менә, җыеп куям әле, бәлки кайчан да булса бер кирәкләре чыгар,— диде ул. Бераз уйланып утырды.— Әгәр дә шундый мактаулардан башың әйләнеп масая-нитә калсаң, алып күрсәтермен, дим. Болар китабыңны язганда нинди шартларда яшәвеңне күз алдына китереп айнытып җибәрерләр...

Гәрчә андыйларга беркайчан да башым әйләнгәне булмаса да, бик урынлы һәм вакытлы кисәтү иде бу. Чөнки бу мәсьәләдә безгә бик сак булырга кирәк. Нинди талантлы шагыйрьләрнең дә үзенә-үзе соклану нәтиҗәсендә түбәнгә таба тәгәрәгәне бар. Масаю чиренә бирештеме, ул инде иҗат кешесе буларак үсүдән туктады дигән сүз.

Миңа исә моңарчы язганнарым белән генә һич тә канәгатьләнергә ярамый, мине киләчәктә язачак тагын да җитдирәк яңа әсәрләрем көтә, аларга элеккеләренә караганда да күбрәк көч салырга туры киләчәк. Чөнки әдип моңарчы язган әсәрләрен иҗатының иң яхшы үрнәге, иң югарыгы ноктасы дип исәпләми. Юк. Ул иң яхшы китабын менә хәзер яза. Монысы инде аның иң талантлы әсәре, иҗатының үрнәге булачак, ул халыкның иң тирән тойгыларына, иң бөек омтылышларына җавап бирәчәк. Гомере буена эзләп, җыеп килгән иң кадерле, күңелгә иң якын сүзләрен дә ул әнә шул яңа китабында әйтәчәк...

Мин дә әнә шул зур максатның гамәлгә ашачагына чын күңелдән ышанып, шуның белән рухланып яшим.

*1983*

# Әхсән Баянов

## Иделдә җәй

Идел шулай мәңге агар микән?
Онытмасмы дулкын чабышларын?
Тал-тирәкләр иелеп суга һаман
Сөйләр микән сөенеч-сагышларын?

Кояш тирәсендә Җир әйләнә
Белер микән, әллә белмәс микән?
Яшим дә мин, яшәмим дә кебек —
Кояш исән чыкса, шөкер итәм.

Черки чәнчү, чебен бимазасын
Һәм дус-ишнең ыгы-зыгыларын
Яшенле су тиз төшерә юып,
Юыла бергә шатлык-кайгыларым.

Көчен җуя барча гүләү-күкрәү,
Көчен җуя яңгыр, чык һәм кырау.
Яшим дә мин, яшәмим дә кебек —
Алмаштыра барысын ялгыз сорау.

Бакчаларым ярыр микән яфрак?
Онытмасмы чәчәк атуларын?
Безелдәшеп, бал кортлары таҗның
Җыя белер микән якты балын?

Сәрби кузаклары шартласа да
Маза җуям: син иминме, дөньям?
Җиде төндә өзелеп алма төшсә,
Җирне, күкне, суны барлап куям.

*1983*

## Моң сурәте

Көзге яфрак сибелеп очкан чакны
Без сурәткә күчермәкче булдык.
Агачларның сынмый сыгылганын
Без сурәткә төшермәкче булдык.

Болытларның явып калырга дип
Ашыкканын тиз үк иттек сурәт.
Мәңгелеккә калдырмакчы идек
Далаларда учак януын дөрләп.

Шулай ясап ут, болыт һәм яфрак,
Хыял иткәнбездер төрлерәкне.
Гомер буе ясаганбыз ләкин
Тик бер генә сурәт — җил сурәте.

Хатирәләр чиксез, дәрья хәтле.
Тик бер генә, тик бер генә гомер.
Яфрак, болыт, ут шикелле калган
Бәлки җилдер... бәлки моң сурәте?

*1983*

## Галим белән Залим турында баллада

Хыял корган Залим: «Булса икән даим
Даһи хикмәт ясап —
Дәүләт төзек машинадай гөрләп
Торсын иде һәрчак.
Куркытмасын ил корабын океан,
Җил, давыл, гарасат.
Таш риф дигән, тәшвиш дигән афәт
Һәм бүтән төр дәһшәт.
Елгыр булсын, бәрелеп ватылмасын,
Батмый йөзсен, йөзсен.
Имин дәүләт бөек койрыкчысын
Изге данга күмсен.
Кая барсаң бер генәме Кояш?
Илдә шуңа мин тиң.
Тик бер кодрәт, бер ихтыяр белән
Алга бару мөмкин».

Шулай мәңге хыял иткән Залим.
Камчы, төрмә, кистән,
Дар, әләкче, гильотина, куштан
Бушамаган эштән.
Мәйданнарда тәртип парадлары —
Күптән булган гадәт.
Залим мәгәр булалмаган һаман
Риза вә канәгать.
«Урап Кояш вә үз күчәрендә
Тәгәл әйләнә Җир.
Әй, кем, Галим, табигатьтән алып
Шундый бер кодрәт бир!»
Әләкче һәм куштан аша тиз үк
Фәрман юллый Залим.
Йөрәк-җилкә ышкый-ышкый гәрчә,
Риза була Галим...

Мәйдан.
Анда җир актара үгез.

Тузан, алкыш ява.
Япма тоткан ирләр бер-бер артлы
Кан күленә ава.
Җиңүчегә тау-тау алтын вәгъдә.
Тик калгандыр акыл.
Инде берни юктыр түләтерлек
Кан коелу хакын.

«Бәхет сынаучылар бармы тагын?» —
Мәйдан гүя үлгәч,
Калка Галим: «Чыга минем кызым!» —
Дәвам итә көрәш.

Мәйдан буйлап атлап китә бала,
Кулга тоткан чәчәк.
Гөлчәчәге-нисе белән үгез
Болытка чөячәк.

Курка белми бала. Тыныч Галим
Сәер пультта тора.
Нәрсәнеңдер кай төшендер үзе
Чыелдата-бора.
Кыз каршына үгез атлый горур...
Җитте, туктап калсын!
Юк, атлый да... ята килеп... Бала
Сыйпый аның башын.
«Ah!» дип кабат, үлгән мәйдан, терелеп,
Үкерә үгез өчен.
Ә Галимне кочып үбә Залим:
«Таянычым бул син!»
Галим аңа суза серле төргәк:
«Будыр менә кодрәт —
Шуның белән, әйдә, син илеңне
Үгез мисле өйрәт.
Гаделлек дип, намус диеп халкың
Һич тә чикмәс җәфа.
Яшәп гел шат, акырып җырлаячак,
Елау тиеш гәрчә.
Илең гәрчә төрмә булса, халкың
Санар үзен азат.
Мә, ал супер-эшче, итче һәм терлекче,
Ал һәм супер-солдат».

Җитәкләде кызын: «Кирәк түгел бүләк,
Дан да алмыйм»,— диде.
Бу чакта ул ләкин Галим түгел,—
Залим иде.

*1983*

## Демон

Ул әллә минем миемдә,
Әллә ерак тауда, кырда...
Каяндыр кара күләгә
Мине көн-төн саклап тора.

Кичәгемнең бүгенгесе,
Бүгенгемнең кичәгесе,
Дөресемнең ялганыдыр,
Ялганымның чын дөресе.
Мәхәббәтнең — нәфрәт төсле,
Нәфрәтемнең мәхәббәттәй
Күренеше — аның эше.

Икейөзле булмаса да
Үзе мең-мең төрле гүя.
Кайчак бәлки мин тыямдыр,
Тик күбрәк ул мине тыя.

Кемне булса бик яратсам,
Ишетәмен сак тавышын:
«Бу вакытлы сәгадәтең,
Алда көтә чын язмышың».

Шатлансам, куша: «Ашыкма!»
Кайгырсам, бик бирешмә ди.
Нигә булса ышанмасам,
Көн үтәли мең шелтәли.
Ышансам да — мин дивана:
«Сизгер яшә бу дөньяда!»

Кирәгеннән артык юаш,
Кирәгеннән артык усал.
Тавыш-тынсыз түзеп тора,
Мин түземем җуеп кусам.

Ул минем кире фәрештәм,
Ул минем уңай җенемдер.
Төссез һәм тәнсез күләгә
Минем икенче «мин»емдер...

Миемдә бәхәс, тарткалаш...
Әйтә алмыйм әле шуны:
Ул минем ыруг башымы,
Әллә алгы ачышыммы?..

*1979*

* * *

Яшь көннәр узган, чыр-чулар тынган.
Таралган алар кайсы кай якка.
Эзләрне яңгыр, су юган чакта,
Капланып комга көймәләр сыман,
Ухылдый елга, шыңшып көз ята.

Яраткан-кочкан җил булып очкан.
Тавышсыз сагыш — кабырчыклар буш.
Сагышлы тавыш: «Дәверкәем, хуш!» —
Әйтерсең тормыш киткән тарихтан...
Йөрәк, чыда, түз, кычкырма ялгыш.

Төш күрер елга: «Җырым, такмагым,
Очтыгыз кая? Чайкалган, чая,
Уйсыз чакларым, актыгыз кая?
Яшь гомер кебек шаулагыз тагын,
Нинди мул суым акмасын зая!»

Кабырчыкларга җан тулсын шулай:
Әй, узган җаем, кайт син, кире кайт!
Наз кайтсын җилгә, көлсен кояш шат.
Ышанып шуңа, ялгыз юлчыдай,
Комда мин йөрим, гүя соңгы кат.

*1979*

## Мин риза

Бармагың димәстән, сөюнең
Яңасын бумаса балдагың,
Кичәге алтының тиз ара,
Имештер, төс җуя —кызара.
Туй биргән алтының ахырда
Әйләнә, имештер, бакырга.

Тыелган язуклы үбешү,
Тыелган гаепле күз яше,
Тыелган гонаһлы җыр башы
Әйләнә, имештер, алтынга.
Тоташа, имештер, елларга —
Һәм көмеш, һәм алтын туйларга.

Аларга син мине чакырма.
Без хаклы күгәрмәс көмешкә,
Без хаклы үзгәрмәс алтынга.
Үзгәрсә, күгәрсә, ахырда
Мин риза бакырга...

*1979*

* * *

Бәхетлеләр — кыска гомерлеләр,
Бәхет бераз тартым йокыга:
Төштәгедәй ашыгып чаба еллар,
Хатирәләр хәтта онтыла.

Бәхетсезләр һични оныта алмый,
Минут — айдай, сәгать — ел кадәр.
Хатирәләр җыя-җыя еллар
Гасыр сымак акрын үтәләр.

Тәкъдиремнән зәңгәр һәм ал көннәр
Миңа сирәк һәм аз бирелде.
Хатирәләр белән булырмын тик
Мин бәхетле, озын гомерле.

*1983*

* * *

Син минем бәйләнчек уем,
Яшьлеккә тоташтырган.
Яшел кыр, яшел урманым,
Сафлыкка охшап торган.

Давыл, янгын чәчәкләре,
Кабынган, кабынмаган.
Үрмәле гөлләр, кылганнар,
Чабылган, чабылмаган.

Төшләремдә кайтып көн дә
Йөрим мин шулякларда.
Кәрешкәләр тышау булып
Чолгана аякларга.

Тышауланган килеш чабам
Таңдагы очрашуга.
Талчыгып, арып егылгач,
Төсләр тиз юкка чыга.

Әй дөрес тә төш күрдем дип,
Әйләнчек уем кайта...
Күрмәдем зиһен тышавын,—
Шул гына бугай хата.

*1983*

# Сафа Сабиров

# ХАТЛАР ЯЗАМ САГЫНЫП

ПОВЕСТЬ

*Беребез исән булганда без икебез дә яшәрбез.*

Э. Хемингуэй



Нурислам абый!

Сезгә бу хатны язаргамы, юкмы дип байтак вакыт уйланып, икеләнеп йөрдем, берничә мәртәбә язып та, почтага илтмичә, ертып ташладым. Сәбәбе шунда: сез мине дөрес аңламассыз дип уңайсызландым, әйтер сүземне кирәгенчә әйтә алмам, хәтерегезне калдырырмын, сезне үпкәләтермен кебек тоелды. Шулай да, һич кулым бармаса да, ниһаять, бу юлы язарга, хатымны җибәрергә булдым.

Озын сүзнең кыскасы, Нурислам абый, мин сездән моннан соң безгә килмәвегезне үтенәм. Элеккечә бәйрәм-җыеннарда, туган көн мәҗлесләренә чакырмасак, зинһар, үпкәләмәгез. Тормыш шулай куша. Чөнки сез килеп киткән саен безнең гаиләдә үпкәләшү килеп чыга. Хөснулла атналар буе беркем белән сөйләшмичә кара көеп йөри, андый көннәрне ул хәтта бәләкәй улы Кәбиргә дә якты чырай күрсәтми.

Сезгә тагын бер үтенечем бар: бу хат турында берүк Хөснуллага сиздерә күрмәгез; тырнак астыннан кер тапкандай, аңа тагын бәйләнергә, авызын-борынын турсайтып, тузынып йөрергә сылтау булмасын иде.

Менә бар сүзем шул. Зинһар, үпкәли күрмәгез. Мине дөрес аңларсыз дип уйлыйм. М-м.

Нурислам абый, тагын мин борчыйм әле сезне.

Мин сезгә югыйсә бүтән язмаска тиеш идем. Соңгы вакытта сез килми башлагач, безнең тормыш бераз рәтләнгән, Хөснулланың сәбәпсезгә вакланулары, юкка-барга бәйләнүләре кимегән сыман иде.

Әмма теге көнне без сезнең белән пароходка утырып кайтканнан бирле Хөснулла тагын өйдә һичкем белән сөйләшмичә кашларын җимереп йөри башлады. Аның мондый кыланышларын баштарак мин авыр кичерә идем, һаман саен кабатлана торгач, хәзер инде мондый хәлгә акрынлап күнегеп тә килəм бугай. Мөмкин кадәр тынычрак булырга, үземне кулга алырга, артык борчылмаска тырышам.

Хәтерлисездер, ул көнне пароходта кайтканда террасада икебез генә калган бер арада сез Хөснулланың ник бәйләнүен, ник безгә килергә яратмаганны белергә теләгән идегез. Әмма мин ни дә булса әйтергә өлгермәдем, нәкъ шул мәлне Хөснулла килеп комачаулады. Бу хәл сәер

тоелмасын, икеле-микеле уйланырга урын калмасын дип, мәнә сезнең шул соравыгызга җавап язуым.

Ул чакны Хөснулла белән сез, гадәттәгечә, якын дусларча ачылып сөйләшмәдегез, ике арагыздагы киеренкелекне бер-берегезгә сиздертергә теләмәгәндәй, вахтадан буш сәгатьләрдә гел шахмат уйнап кайттыгыз. Улым Кәбир дә (ир бала — ирлеген итә бит) һаман сезнең янда чуалды, әтисе берничә тапкыр ачулануга да карамастан, алдыгызга утырып, китель төймәләрегезне санап, фуражкагызны киеп уйнады.

Бу хәлгә Хөснулланың кәефе бик бозылды, чырае торган саен караңгылана барды, рәттән берничә тапкыр уенын оттырды. Соңынтын, үзебезнең каютага чыккач, таякның юан очы тагын миңа төште: баланы теләсә кемгә сыенудан тыя белмисең, әтисеннән биздерәсең, имеш... Синең алда рәтлерәк кылмак кигән өчен дә, артык ачык йөз күрсәткән өчен дә мин гаепле.

Ярар, ул хакта калып торсын. Сүз уңаенда бәләкәй генә бер яңалык та хәбәр итим: быел көз мин су транспорты инженерлары институтының читтән торып уку бүлегенә керергә булдым, бу көннәрдә кабул итү имтиханнарына әзерләнәм. Миңа уңышлар телэгез.

Улым Кәбирдән сәлам сезгә. Мәнә хәзер сезгә хат язуымны белгәч, Нурис абый (сезнең исемне ул үзенчә шулай кыскартып әйтә) ник безгә килми, аның пароходына тагын кайчан барабыз, дип гел сораштырып тора.

Сезгә сәламәтлек, эшегездә уңышлар теләп калабыз. Мәрьям.

Нурислам абый, исәнмесез!

Сез белмисездер әле, улым белән мин Чистай кешеләре булдык бит, хәзер без шунда яшибез. Яңа урында эшемнән, тормыш шартларыннан зарланырга сәбәп булмаса да, күңел никтер урынында түгел, башка әллә нинди борчулы уйлар килә, сез безгә килеп йөргән чаклар искә төшә.

Соңгы вакытта еш искә алудан, ахры, кичә кич ачык тәрәзә янында йокыга талып барганда пристань ягыннан сезнең «Владимир Маяковский» пароходы тавышы ишетелгән кебек тоелды. Аның Иделдә йөрүен, бу якларга килүе бик икеле икәнлеген яхшы белсәм дә, таныш гудок тавышыннан күңелем җилкенеп китте, байтак вакыт йоклый алмыйча яттым.

Шулай да мин дөрес ишеткәнмен бит, кичә пристаньга чынлап та сез туктаган булып чыкты. Ремонтка туктаган ниндидер бүтән пароход урынына сезне Кама линиясенә күчергәннәр икән. Ул хакта мин иртәгесен безнең затонга эш белән килгән таныш диспетчердан очраклы рәвештә ишетеп белдем.

Ел буе диярлек хәбәрләшми торганнан соң сезнең бездән якында гына булып та күрешмичә китүегезне белү миңа бик аяныч тоелды, һәм мин, җилкенеп китеп, мәнә шушы хатны язарга керештем.

Безнең Чистайга күчүебез, сезнең өчен көтелмәгән хәл булып, сәер тоелуы ихтимал. Мәгәр ул чыннан да шулай, җәй башыннан бирле биредә яшибез.

Безнең бирегә күчеп килүебез әтинең нахак бәлагә таруы аркасында булды. Бәлкем, инде үзегез дә ишеткәнсездер (андый хәбәр озын аяклы була бит), быел техникумда язгы имтиханнар вакытында ни өчендер гаепләп, әтине директорлыктан алдылар, төрле комиссияләр килеп тикшерә, төпченеп казына башладылар. Аның сәбәбен мин соңыннан, байтак вакыт үткәч кенә белдем.

Шул ук вакытта минем үземә карата да кешеләрнең мөнәсәбәте кинәт үзгәрде. Эшкә барып керсәм, сизәм, кайберәүләр очраганда, күрмәгәндәй, читкә карап яки ашыккан кыяфәт белән коры гына сәлам биреп үтәләр. Хәтта әти урынына техникум директоры булып калган

«безнең Хөснуллабыз» да бүтәнәйде, абруена тап төшүдән куркып булса кирәк, миннән күрәләтә читләшә, әнисе каты авырый дип, кунарга да өйгә кайтмый башлады. Әнә шундый күңел өшеткеч атмосфера эчендә калдым мин.

Хәер, мине һәрвакыттагыча үз итеп, теләктәшлек күрсәтүче, кирәк чакта киңәшләре белән эчкерсез булышучылар да аз булмады. Техникумның суднолар йөртү бүлеге начальнигы, гражданнар сугышы чорында минем әти белән бергә флотилиядә сугышучы Матвей Михайлович Белоусов жылы мөнәсәбәтен һич тә яшермичә, теләсә кем алдында ачыктан-ачык дусларча исәнләшә, хәлемне сораша, мине тынычландырырга тырыша иде. Гадәттә, үзен бераз рәсми тотучан, корырак күренсә дә, хәлемнең кыенлыгын башлап сизүче һәм авыр вакытта ярдәм кулы сузучы кеше — шул карт коммунист дисәм, һич тә ялгыш булмас.

Беркөнне, техникумда сынаулар тәмам булганнан соң, юлыбыз туры килеп, кичкырын эштән кайтып барганда әнә шул дәдәй:

— Мәрьям, син ялыңны кайда үткәрергә уйлыйсың? Башка җәйләрдәге кебек, быел да пароходта эшләргә җыенасыңмы? — дип кызыксынды.

— И Матвей Михайлович, ял кайгылары түгел әле миндә,— дидем, ачыну белән.— Күрмисезмени, ятьмәгә эләккән балык кебек, кая барып бәрелергә белми йөрим.

— Күрәм, күгәрченкәем, бик яхшы күрәм, хәлеңне дә аңлыйм. Әйтергә теләгән сүзем дә шул хакта... Минемчә, сиңа климатны үзгәртергә, бу имеш-мимеш гайбәт оясыннан бераз вакытка китеп торырга кирәк. Чистайда минем бертуган сеңлем яши. Үз өе бар, ире үлгәннән бирле ялгызы тора... Улыңны үзең белән ал да, туп-туры шунда кит, җәеңне шунда тынычта үткәр. Камада су коенырсың, кояшта кызынырсың, карлыган, гөмбә җыярсың, нервыларың ныгыр... Син монда барыбер әтиеңә әллә ни ярдәм итә алмассың, ул хакта без, хәрби флотилия ветераннары, үзебез кайгыртырбыз. Васил Билаловичның кем икәнен беләбез без. Якын арада барысы да ачыкланыр дип уйлыйм.

Бу киңәш башта ничектер бераз сәер тоелса да, һәрьяклап уйлаганнан соң, мин аны хуп күрдем һәм берничә көннән улым белән Чистайга барып төштек.

Кайгыртучан Матвей Михайлович безнең хакта сеңлесенә хәбәр иткән һәм, Казан пристанена озатып калганнан соң, телефоннан да сөйләшкән икән. Аның сеңлесе — урта яшьләрдәге ачык йөзле, бөтерчек кебек хәрәкәтчән Марина Михайловна — пристаньда безне бик җылы каршылады, өйгә кайткач та, якын туганыдай, кадерләп кунак итте.

Ул үзе затонда суднолар ремонтлау заводында кадрлар бүлеге мөдире булып эшли икән. Аның затон турында, шунда үткәргән еллары турында сөйләгәннәрен тыңлый-тыңлый ул кичне без чәй янында озак утырдык.

Улым белән мин урнашкан шактый иркен бүлмәнең түр тәрәзәсе Камага караган, ян тәрәзәдән якында гына тау астында озын күл сыман елга култыгы — затонга күренеш ачыла. Кичләрен, тын су өстенә төн пәрдәсе иңгәч, яр өстендәге завод тәрәзәләрендә, биек кран башларында утлар җемелди, пристаньнан ара-тирә кычкырткан пароход тавышлары сезне искә төшерә, ямансулата.

Менә без шулай Чистай кешеләре булдык инде. Яңа урында рәтләп ияләшергә өлгермәдем, заводта Марина Михайловнаның ярдәмчесе — йөкле хатын декретка чыккач, аның урынына вакытлыча мине кадрлар бүлегенә инспектор итеп куйдылар.

Башта кызыксыз булыр сыман күренсә дә, бу эшкә мин бик тиз бирелеп киттем. Кешеләрне заводка, пароходларга эшкә кабул иткәндә төрле язмышлар, гыйбрәтле хәлләр белән очрашулар күп нәрсәгә күземне ачты; тормышны, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне тирәнтен-

рәк аңларга, тагын да мөһимрәге — кайгы-хәсрәтләр астында сыгылмыйча, нык тора белергә, гаделлек өчен, хакыйкать өчен көрәшергә кирәклеген төшендем мин биредә...

Шулай да дөнья мин уйлаганча ук тоташы белән караңгы түгел икән. Беркөн Казаннан Матвей Михайлович шалтыратты һәм әтиемнең нахак бәладән имин котылуын әйтеп, мине бик сөендерде. Озак та үтмәде, алар үзләре дә бергә килеп, берничә көн бездә ял иттеләр.

Ни өчен эштән алынуы турында әти үзе бернәрсә дә сөйләмәде, тик болай аңлашылмаучылык аркасында дип әйтү белән генә чикләнде, ә мин төпченеп сораштырырга кыенсындым. Аларның үзара сөйләшкәндә өзек-өзек колакка кергән сүзләреннән шуны аңладым: пароходчылык идарәсендә һәм безнең техникумда оялаган бер төркем карьерачы, интриганнар әтине ниндидер җинаятьчеләр белән якын элемтәдә булуда, кемнәргәдер техникумны тәмамлау турында законсыз диплом бирүдә һәм кода-кодагыйлыкта (монысы, мөгаен, аның кызы — мине күздә тотыптыр инде) гаепләп, аның өстеннән ялган әләк язган булганнар икән. Азактан, доносның нигезсезлеге ачыклангач, тикшерүне шундук туктатканнар һәм, хаталык өчен гафу үтенеп, әтине элекке эшенә чакырганнар.

Ул чакны мин шунда әти белән бергә Казанга кайтып китә алмадым, Марина Михайловнаны эшендә кинәттән генә ярдәмчесез калдырудан уңайсызландым. Аннары бу адымнан мине анда Хөснулла белән очрашырга теләмәү дә тоткарлый, юлымда киртә булып тора иде.

Әтине озатканнан соң күп тә үтмәде, һич уйламаганда-көтмәгәндә безгә Хөснулла үзе килеп төште. Күчтәнәчләрен, Кәбиргә алып килгән уенчыкларын ачып салды, безне бик сагынып килүен һәм хәзер үк үзе белән өйгә алып китәргә ниятләвен әйтте. Бу юлы аның Казанда миннән читләшеп йөргән чактагы салкын һавалыгы бөтенләй юкка чыккан; хәзер ул кайгыртучан, мөлаем, шул ук вакытта аның үзен тотышында, сагаюлы күз карашларында яңа чалым — ниндидер аптыраулы кыюсызлык та сизелә иде.

Хәер, безнең мөнәсәбәтләр инде Казанда ук салкынайган иде. Монда килгәч, мин аннан тагын да ераклашуымны, тәмам бизүемне аңладым һәм, үземне ирексезләп, аңа якты чырай күрсәтмәдем. Минем халәтемне Хөснулла үзе дә сизде, ахрысы. Һәрхәлдә сөйләшеп аңлашу турында сүз кузгатмады, ашыгыч эшләрем бар дип, шул ук көнне кичке пароход белән кире кайтып китте.

Менә шул, яза торгач, хатым озынга китте. Хушыгыз, безләрне бөтенләй онытып бетермәгез. Мәрьям.

Сөекле Нурисым!

Дөньяда шундый да зур якты бәхет, сөю һәм сөелү бәхете булуы мөмкин дигән уй моңарчы беркайчан башыма килгәне юк иде. Синең белән соңгы мәртәбә пристаньда очрашканнан бирле минем әле һаман айный алганым юк, бәхеттән исергәндәй, рәхәтлектә йөзәм, гел елмаеп йөрим. Марина Михайловна да гаҗәпләнә, Мәрьям, бу арада син балкып киттең, канат куйган кебек, очып кына йөрисең, ди.

Тик шунысы үкенечле, ул көнне күзгә-күз карап бер туйганчы рәхәтләнеп сөйләшә алмадык. Үч иткән кук шуннан элек кенә минем улым Кәбир белән Казанга киткән чагым иде. Өченчекөн кичкырын өйгә кайтып керсәк, өстәлдә хат ята. Синнән икәнлеген күрүгә йөрәгем каты тибә башлады. Юл киемнәремне дә чишенеп тормастан, өлгерми калудан курыккандай, тиз генә конвертны ачып, шундук түземсезлек белән укырга керештем.

Менә хикмәт, мин Казанда булган вакытта сез Чистай затонында тәүлек буе торып, пароходыгызның пар казанын чистарткансыз икән.

Шул вакыт эчендә син безгә ике тапкыр килеп, мине өйдә очрата алмагач, менә шушы хатны язып калдыруыңны белдем һәм шатлыгымнан чүт кычкырып җибәрмәдем.

Бу вакытны Марина Михайловна өйдә түгел иде. Мин бераз тынычланып тегә-бу иткән арада ул кайтып җитте һәм ишектән керү белән:

— Әһә, кайткансың икән, шәп булган... Укыдыңмы, белдеңме кем килгәнен?— диде ул, минем кулдагы хатны күреп.— «Владимир Маяковский» әлерәк кенә затоннан чыгып китте. Хәзер ул пристаньда, расписание буенча сәгать алтыда рейска китәчәк... Димәк, утыз минут вакыт бар, яр буйлап турыдан йөгерсәң, өлгерәсең әле. Бар, элдерт. Һич югында үзен күреп, озатып калырсың.

Мин нәкъ шулай эшләдем дә: озын-озак уйлап тормастан, улымны Марина Михайловнага калдырдым да, яр өсләп кенә пристаньга чаптым. Инде кич кергән вакыт булса да, әле һаман һава бөрку иде. Тирләп беттем, сулышым капты. Чокыр-чакырлы яр читендә абынып, берике мәртәбә чүт егылмадым. Әмма үзем, һичнигә карамастан, һаман йөгердем, кош кебек очтым.

Син дә мине көткәнсең, тау өстеннән йөгереп килгәнне күргәнсең икән, дебаркадер басмасына чыгып каршыладың. Җан-фәрманга ашыгуым бушка булмады, пароход беренче гудок кычкыртканда мин причалга килеп җиттем һәм тау өстеннән йөгереп төшкән шапкә инерция белән синең кочагыңа барып та кердем.

Причал тулы кеше күз алдында болай тору уңайсыз иде, без синең каютаңа кердек. Анда барыннан элек күземә ташланган нәрсә — синең өстәлеңдә пыяла астына куелган үз фоторәсемем булды. Улым Кәбирне алдыма утыртып төшкән бу рәсемне әлегә тикле күргәнем дә, һичкемгә биргәнем дә юк иде. Күзләремә ышанмыйча, бер мәл карап торганнан соң:

— Ни күрәм мин?!. Берәр могҗизамы, әллә миңа күренгән кебек тоела гынамы?...— дип бик гаҗәпләндем.

— Һичнинди могҗиза юк, Мәрьям җаным,— дип иңемнән кочаклап, иркәләргә керештең.— Былтыр безнең пароходта барган чакны үзең дә күрмәгән бер арада төшереп алган рәсем бу. Шуннан бирле ул рәсем, аерылмас юлдашым кебек, гел минем белән.

Син сүзеңне әйтеп бетерергә өлгермәдең, китәргә вакыт җитүен хәбәр итеп, югарыда икенче гудок кычкыртты. Шунда мин аерылышуның нинди авыр газап икәнлеген бөтен рухым белән тойдым, күзләремә яшь тулды.

— Мәрьям, акыллым, болай кинәт кенә аерылышырга ярамый бит. Әйдә, Балык Бистәсенә хәтле безнең белән бар, каршы килүче пароход белән кире кайтырсың,— дип яшьле битләремнән үбә-үбә син мине бераз озата барырга үгетли башладың.

Әмма безгә, тиздән тагын очрашырга сүз куешып, аерылышырга туры килде. Бик кыен булса да, үзем бер дә теләмәсәм дә, пароходтан төшеп калдым. Юкса өйдәгеләрнең борчылуы бар иде.

Сез кузгалып киткәнне мин тау өстеннән карап калдым, пароходыгыз күгелҗем еракта эреп күздән югалганчы озак карап тордым. Бик ямансу булса да, сагышым якты, күңелем синең сөюең белән тулы, чиксез шат идем мин.

Аннары мин шундук вокзалга кереп расписаниене карадым. Горькийда булганнан соң, «Владимир Маяковский» Пермьгә барышлый бирегә тагын дүрт тәүлек үткәч, шушы вакытта киләчәк икән. Дүрт көн, дүрт төн көтәсе бар, ничек түзмәк кирәк?!. Сине пароходта озата бармавыма да үкенеп куйдым.

Пристаньнан өйгә мин әнә шундый уйлар эчендә кайттым. Иртәгесен дә шул: күңелемдә гел син, гел синең белән сөйләшеп йөрим, Пушкинның шигъри юлларын кабатлыйм:

*Ямансу һәм җиңел миңа монда,*
*Тик син генә бөтен сагышым.*
*Тик син генә... Күңел сыза, тынмый,*
*Сыза борчымыйча, көймичә,*
*Иөрәк тагын сөя, чөнки — булмый,*
*Булдыра алмый йөрәк сөймичә.*

Ниһаять, мин түзмәдем, эштән кайтып кичен бүлмәдә ялгызым гына калгач, үзең белән сөйләшкәндәй, сиңа менә шушы хатны яздым. Мин аны Казан пристанена адреслап җибәрәм, пароходлар почтаны шуннан алалар бит.

Тиздән очрашуны түземсезлек белән көтеп калучы Мәрьямең.

Нурис, бердәнберем минем!

Бүген беренче июль, ниһаять, беренче хәбәрең килде. Кыска гына ачык хат, син аны юлдан салгансың. Хәзергә үз адресың юк, анысын билгеле булгач та хәбәр итәрмен дип әйткәнсең. Мин барыбер сиңа язарга утырдым әле. Адресың мәгълүм булгач, салып җибәрермен.

Менә бит нинди хәлләр: шат күңел белән сине каршыларга әзерләнеп йөргән вакытта ил өстенә кинәт коточкыч сугыш афәте килеп төште, күпме халыкның бәхетен, матур тормышын, якты хыялларын җимереп ташлады. Хәзер монда ир-егетләр хәрби комиссариатка ашыга, минем кебек хатын-кызлар сөйгән ярларын яуга озата.

Шулай да мин сине алай бик тиз китәрсең дип уйламаган идем. Шул өмет белән пристаньга «Владимир Маяковский»ны каршыларга төштем. Ул нәкъ расписаниедә билгеләнгән вакытта килеп җитте. Әмма анда син юк идең; Казанда төшеп калып, үзең учетта торган хәрби комиссариатка китүеңне әйттеләр. Албасты саташтыргандай, нишләргә белмичә, кинәт гаҗиз калдым, күз алларым томаланды. Тәмам миңгерәгән, хәлдән тайган килеш кичкә өйгә кайтып җиттем, йоклый алмыйча төн буе газапланып чыктым. Ә иртәгесен, эштән ике көнгә рөхсәт алып, беренче очраган пароход белән Казанга киттем. Ниятем — ничек тә үзеңне күрү, фронтка киткәндә сине озатып калу иде.

Юл буе ут йотып, соңга калмагаем дип, бик борчылып бардым. Пароходтан төшкәч тә, өйгә дә кереп тормастан, пристаньнан туп-туры военкоматка йөгердем. Әмма безгә очрашу насыйп булмаган икән. Военкоматта дежурный командир кемгәдер телефоннан шалтыратып белешкәннән соң, синең шул көнне иртәнге эшелон белән китеп баруыңны әйтте. Бик аяныч, аз гына соңга калганмын. Биш-алты сәгатькә иртәрәк килеп өлгергән булсам, тәгаен күрешәчәкбез, вокзалга хәтле сине озата барасы икәнмен.

Шул ук көнне бер уңайдан техникумга да сугылдым. Хәзер анда беркем дә юк диярлек: студентлар җәйге практикага пароходларга, пристаньнарга таралган, укытучылардан кулына корал тотарлык бар ир заты военкоматта карала, фронтка китәр алдыннан ашыгыч рәвештә расчет алып йөри. Шулай да Матвей Михайловичны очраттым. Чал мыегын кыскартып кырыккангамы, хәтта бераз яшәреп киткән сыман күренде. Һәрвакыттагыча формадан, пөхтә киенгән, хәрәкәтләреннән энергия, ихтыяр көче бөркеп тора. Мине күрү белән үз бүлмәсенә алып керде, Чистай хәлләрен сораштырды, аннары:

— Килеп шәп иткәнсең... Хәзер син монда бик кирәк, тизрәк Казанга кайт,— диде.— Укытучыларның күбесе фронтка китә. Пароходларга чыгып практикантларның хәлен белүче, кирәк очракта ярдәм итүче кеше юк.

Мин аңа тәгаен ышандырып берни дә әйтә алмадым, уйларга, эти белән, Марина Михайловна белән киңәшергә кирәк, дидем. Затонда да кешегә кытлык, эш муеннан. Үзеңне җылы кабул иткән кешеләрне шундый вакытта капылт кына ничек калдырып китәсең?

Азактан, инде саубуллашып чыгарга кузгалганда, Матвей Михайлович минс туктатып:

— Чыгып китәргә ашыкма, тагын бер эш бар,— диде һәм, минем Хөснуллага мөнәсәбәтем, ничек торуыбыз турында кыскача гына сораштырганнан соң, эчке борчылу белән дәвам итте: — Мин сиңа бер күңелсез хәбәр әйтергә мәҗбүрмен: әтиең өстеннән ялган әләк язуда Хөснулланың да кулы уйнаганлыгы мәгълүм булды... Хәзер, хаинлыгы ачылгач, ул ах-вах килә, елан кебек боргалана, үкенә: аңа кемнәрдер югарыдан басым ясаган, мәҗбүр иткән, имеш... Менә шул. Авырткан җиреңә тигән булсам, үпкәләмә, сине үз итеп, белеп тор дип әйтүем.

Хөснулланың комагайлыгын, карьерачы икәнлеген инде яхшы белсәм дә, бу тикле түбәнлеккә, хыянәтчелеккә барып житәр дип һич уйламаган идем. Бигрәк тә әти каршында үземә уңайсыз, тормыш юлдашым булган кешенең аңа карата кылган әшәкелеге өчен минем дә гаебем бар сыман тоелды.

Ул көнне Казанда минем тын алырга да вакытым булмады. Техникумнан чыгу белән әти янына ашыктым.

Аның сәламәтлеге ныгый төшкән, сөбханалла, кәефе дә әйбәт күренә. Техникумга тагын элекке эшкә чакыралар икән. Мондый вакытта өйдә кул кушырып утырырга исәбе юк, иртәгә үк эшкә керешергә җыена.

Хәзер һәркемнең телендә фронт хәбәрләре: фашист илбасарларының котырынып алга баруларын, безнең җирләрне басып алуларын ишетү авыр тәэсир итә, борчулы уйлар уята. Шул хакта сүз кузгалгач, әти минем халәтемне сизгәндәй:

— Юк, алай өметсезлеккә бирелергә ярамый, без алай ансат кына баш ия торганнардан түгел,— диде, өстәл өстендәге китапны алып.— Син кайтып керер алдыннан гына Пушкинны карап утыра идем әле. Александр Сергеевич менә болай ди: «Россия үз өстенә төшкән бөек вазифаларын үтәп килә, аның иксез-чиксез киңлекләре монгол көчләрен йотты һәм Европа читендә туктатты...» Мин моңа өстәп Наполеон белән дә нәкъ шулай булды, дип әйтер идем. Ә гражданнар сугышы елларында, илнең дүрттән өч өлешен дошманнар басып алган вакытта да без югалып калмадык, ач, ялангач көе, бөтендөнья империалистларының кара көчләрен һәм эчке бандаларны тар-мар итеп, куып чыгардык. Менә бераз баш-күз алгач, болары да тиешлесен алырлар, ник керүләренә үкенерләр...

...Нурлы кояшым, адресың һаман килеп җитмәсә дә, менә тагын язарга утырдым әле. Башымда һаман бер уй: без ник болай бик соң табыштык?.. Кайта-кайта үземнән-үзем шуны сорыйм.

Без бер-беребезне инде күптән, яшүсмер чактан бирле беләбез бит. Әле дә исемдә, минем алтынчы класска күчкән җәем иде, көннәрдән беркөнне әти сине безгә алып кайтты да:

— Менә дустым Алимҗан улы табылды бит, ниһаять,— диде. Мин аны әллә кайлардан эзләтеп йөрим, ә ул үзебезнең шәһәрдә, күрше район мәктәбендә генә укып яткан икән. Безнең техникумга керергә килмәгән булса, тәки табасы түгел иканмен.

Ул чакта әти безне моторкасына утыртып Иделдә йөртте, «Ваня-коммунист» корабында синең әтиең белән бергә ак бандаларга каршы сугышкан урыннарны күрсәтте, каһарман комиссар Маркин турында сөйләде... Шул ,көзне син техникумда укый башладың. Ял көннәрендә безгә килә идең, агалы-сеңелле бертуганнар кебек, икәү бергә Черек күлгә тимераякта шуарга йөри идек. Җиденче классны тәмамлагач, мин дә техникумга кердем. Әтием анда директор булганга, очраклы рәвештә генә түгел, ә кечкенәдән Иделне яратып, шунда пароходлар йөртүче булырга теләп кердем. Пароход йөртү хатын-кыз эше түгел дип,

эти башта бу ниятемне хупламаса да, соңынтын көнде, минем һөнәремне кызым дәвам иттерәчәк дип, хәтта горурланып та куя иде.

Исеңдәдер, ул вакытта безнең техникум үзешчәннәре бик шәп эшлиләр, Мәскәүдә үткәрелгән конкурсларда призлар алып кайталар иде. Һәр шимбә саен диярлек кичләрен концерт яки спектакль була, аннары хәлдән тайганчы биеп идек. Бу инде мин үсмер кыз булып җиткән, егетҗилән күз сала башлаган вакыт. Ул җәһәттән син мине бар дип тә белмәдең, бертуган сеңлеңдәй, баласытып кына карадың, бугай.

Хәер, син гомумән кызлар белән бик аралашучан булмадың бит. Кулыңнан китап төшмәде, җыелышларда да, трамвайда барганда да, хәтта ашаганда да — һаман укуда булдың, китаптан гайре берни күрмәдең шикелле.

...Хатымны дәвам итәм.

Мин хәзер һаман синең хакта уйлыйм, икәү бергә булгандай, эчтән гел синең белән сөйләшеп йөрим, бу авыр көннәрдә башымда туган уйфикерләремне уртаклашам, киңәшәм. Юлдан салган бәләкәй генә ачык хатыңны (бу икенчесе) алып укыгач, үзеңне күргәндәй сөендем һәм менә тагын язарга утырдым. Адресың мәгълүм булгач, шул чакны барысын бергә салып җибәрермен.

Хәзер монда бөтен тормыш үзгәрде. Кулына корал тотарлык ир затлары хәрби хезмәттә; завод цехларында, пристаньда һәм пароход, баржаларда өлкән яшьтәге агайлар, хатын-кыз һәм яшүсмерләр генә калды. «Ургыл» пароходында, пенсия яшенә җиткән карт капитаннан кала, бөтен команда китеп барды. Алар урынына шундук яңа команда тупладык. Күбесе моңарчы пароходка аяк басмаган кыз-кыркын. Идарәдән сәгать саен диярлек шалтыратып ашыктыралар: ничек капитанга ярдәмче табарга да, тизрәк рейска озатырга... Кадрларга шундый кытлык чакны бу бик кыен эш, өй саен йөреп, инде ялдагы карт лоцманнарны ялынып-ялварып эшкә чакырырга кирәштек.

...Сөеклем, бүген өченче хатың, ниһаять, синең адресыңны алып килде, хәл-әхвәлләреңне белеп бераз тынычландым. Юкса күңел урынында түгел, үземне Чехов хикәясендәге билгесез адрес буенча бабасына хат язучы ятим малай хәлендә хис итә башлаган идем.

Син анда барып җитеп, хәрби штурманнар хәзерләү курсларына эләккәнсең икән. Минем уйлавымча да шулай булырга, Идел штурманы хәрби флотта хезмәт итәргә тиеш иде. Ярар, хәерлегә булсын, укуыңда сиңа уңышлар телим.

Монда мине дә кузгаттылар бит әле. Теге «Ургыл» пароходына капитан ярдәмчесе таба алмагач, мине җибәрергә булдылар. Балам бар, аны кем белән калдырыйм дип, башта карышып та маташкан идем. Кая ул тыңлау! Авыз ачарга да ирек бирмәделәр. Кыен булса да, күнәргә туры килде. Улымны үзем белән алып китәм, шулай тынычрак булыр дип уйлыйм.

Бүген безнең бик мәшәкатьле көн, коры җир белән араны өзеп, барыбыз да пароходка күчтек. Төштән соң рейска китәбез. Шунлыктан сүземне кыска тотам, гафу ит, юлга чыккач, пароходтан иркенләбрәк язармын. Син хатларыңны һаман шушы адреска, Марина Михайловна исеменә сал. Мин ничек тә аның белән элемтәдә булырга тырышырмын, җай туры килгән саен белешеп торырмын.

Сине сагынып, бик юксынып калучы Мәрьямең.

P. S. Чистайда соңгы көнне эшебез бик тыгыз булды, язганнарымны конвертлап почта ящигына илтеп салырга да вакыт таба алмадым. Шунлыктан хатымны бераз соңгарып юлдан җибәрәм. М-м.

Нурискаем, менә без юлда инде, бу хатымны пароходта язам. Чистайда чакта хәл җиңелрәк булган икән. Хәзер без еракта йөрибез, хатларың килгәнме-юкмы икәнлеген дә белеп булмый. Һәрхәлдә, бер җае табылыр, якын арада мин аларны ничек тә кулга төшерермен дип өметләнәм.

Башта үзем турында, эшләребез турында берничә сүз. Мин затонда, кадрлар бүлегендә эшләгән чакта «Ургыл» пароходына яңа команданы бик төпченеп, кешеләрнең ярау-ярамаулыгын артык тикшереп тормаган идем. Менә хәзер шул пароходка үзем капитан ярдәмчесе булып килгәч, кем әйтмешли, чәчләрем үрә торды. Моңарчы пароходны яр буеннан гына күреп белгән яшь кызлар, солдаткалар белән ничек эшләрбез дип, хәтта бераз шүрләп тә калдым. Ярый әле капитаныбыз, инде пенсиягә чыгу яшеннән узган агай Трофим Григорьевич, җайлы кеше, кайберәүләр кебек, пароходта хатын-кыз эшләүгә тискәре карамый. Минем ярдәмче булып килүемә бер дә ризасызлык күрсәтмәде. Яңа команда турындагы борчулы сүзләремә дә хафаланмыйча, тәҗрибәле картларга гына хас сабырлык белән:

— Берни кылыр хәлең юк,— диде.— Шул булган халык белән эшләргә, белмәгәннәрен өйрәтергә туры килер. Башка чара юк, тормыш шулай куша.

Эш арасында берәр житешсезлек өчен кинәт кызып китеп, кайчак каты орыша, сүгенә торган гадәте булса да, Трофим Григорьевич күңелендә ачу сакламый, бик тиз суына һәм, урынсызга чәпчегән өчен акланырга теләгәндәй: «Менә шундый инде безнең эш, искедән калган начар гадәт, һич ташлап булмый»,— дип үзалдына зарланып куя.

Мин бигрәк тә үзем өчен борчылам. Улым туганнан бирле пароходта эшләмәү аркасында гел үзгәреп торучан фарватерны, әлбәттә, шактый оныткаммын. Шунлыктан һәрвакыт сизгер булырга, елга картасына ешрак карарга, кыен участокларда ярдәмгә капитанны да рубкага чакырырга туры килә.

Ә менә бөтен машина өчен җаваплы кеше — өлкән механигыбыз үз урынында түгел бугай. Былтыр гына техникум тәмамлаган бу хатын безнең заводта мастер булып эшләгән. Бу җыйнак гәүдәле, тулы алсу иренле яшь чибәрне мин күреп белә идем, ул һәркөн иртән эшкә ире белән култыклашып килә, кичен култыклашып кайтып китә, үзешчән сәнгать концертларында, халык җырларын оста башкарып, тыңлаучыларны үзенә карата иде. Ирен сугышка озаткач, ике-өч көн үтмәгәндер, без аны «Ургыл» пароходына өлкән механик итеп күчердек. Менә шул яшь-яшь хатын үзе кебек үк тәҗрибәсез машинист, майлаучы, кочегар кызларны җитәкләп эшләтә, бөтен машинаның тоткарсыз эшләвен тәэмин итә алыр микән?

Аның караве боцманыбыз шактый тәҗрибәле һәм эшкә уңган булып чыкты. Сугышка хәтле ире белән шушы пароходта матрос булып эшләп йөргәндә ярыйсы гына шомарган Мәрфуга барча эшләр белән үзе белеп командалык итә, матрослардан берәрсе ялкауланса-нитсә, ир-ат боцманнардан кимен куймыйча, суганлап-борычлап кыздыра да белә. Мәгәр дә аңа беркем дә үпкәләми, читләшми үзеннән, киресенчә аңа елышалар, кеше җанлы, ярдәмчеллеген тоеп булса кирәк, матрослар, койрыкчылар гел аның тирәсендә кайнашалар.

Идарә җитәкчеләре безне бик ашыктырып, «Ургыл» зур пароход түгел, якын тирәдә генә йөрисе, кирәкле ярдәмне һәрвакыт күрсәтербез дип, сыйпап-юмалап озатканнар иде. Чынлыкта исә беренче рейстан ук ерак юлга, Түбән Кама төбәкләреннән яңа гына армиягә алынган һәм әле хәрби форма киярга да өлгермәгән ир-егетләр белән Югары Идел якларына китеп бардык.

И мондагы моң-зарны белсәң икән! Туган улларын, кадерле ирләрен, сөйгән егетләрен озатканда пристаньнарда елап калган аналарны,

яшь киленнәрне, кызларны күреп күзләр яшьләнә, тын кысыла. Аларга карап, Нурис җаным, синең өчен шомланып, үзем дә өзгәләнәм.

Хәзер без юлда. Туган-үскән җирләреннән, якыннарыннан яңа гына аерылып киткән кайбер егетләр моңланып, үзәк өзгеч сагышлы көйләргә көйләп баралар...

Капитан Трофим Григорьевич миңа бик үк ышанып бетми бугай. Кама тамагыннан кузгалып киткәннән соң, кичке караңгыда минем вахта башлануга карамастан, ул байтак вакыт рубкада торды, гәрчә телдән аны-моны сиздермәсә дә, минем ничек эшләвемне игътибар белән күзәтеп барды. Ярдәмчеләренә ышанмыйча тәүлек буе диярлек рубкадан төшмәүче капитаннар турында моңарчы да ишетеп белә идем. Әгәр Трофим Григорьевич та шулар кебек нервыда уйный торган тынгысыз командир булса, бер дә шәп түгел, әлбәттә.

Ярар, аныңына ничек тә түзәрмен, юкка-барга бәйләнергә урын калдырмаслык итеп эшләргә тырышырмын.

Хуш, сау бул, сөеклем.

Сиңа кайнар сәлам һәм якты теләкләр юллаучы Мәрьямең.

Кадерлем, затоннан чыкканнан бирле синнән килгән хатларны һаман күргән юк әле. Чистайга кайтып, аларны алу мөмкинлегенең кайчан буласын хәзергә чамалап әйтүе дә кыен.

Шактый озакка сузылган беренче рейсны бары тик бүген тәмамладык, шөкрана, эшелоныбызны әйтелгән шәһәргә бәла-казасыз илтеп җиткердек. Шулай да юлда булган бер сәер вакыйганы сиңа да язып әле. Беркөн иртәнге вахтага менәр алдыннан аскы палубаны йөреп чыкканда боцман Мәрфуга мине туктатып:

— Әнә теге парга игътибар беләнрәк карагыз әле,— диде, башкалардан читтәрәк торган ике егеткә ишарәләп.— Сезнеңчә ничек, аларның берсе хатын-кызга охшаган түгелме?

Алар алгы якта иңгә-иң сыенып сул як бортта торалар һәм бер-берләренә үпкәләшкәндәй, сүзсез генә суга карап баралар иде. Берсе калку яңаклы, базык гәүдәле җирән егет, икенчесе — чынлап та хатынкыз. Чәчен алдырткан, егетләрчә чалбар, кепка кигән булуына карамастан, зифа буе, күлмәк астыннан калкып торган күкрәк йомрылары, кыйгач кара кашлары — барысы да аның буй җитеп килгән матур кыз икәнлеген әйтеп тора иде. Бик гаҗәпләндем:

— Моны кем оештырган, нинди әкәмәт бу?!.

Безнең үткен зиһенле боцманыбыз Мәрфуга ул кыз белән инде танышып өлгергән, аны каютасына алып кереп, чәй янында сораштырып, барысын да белеп өлгергән иде. Боцман кыскача гына сөйләгәннән шуны ачыкладым: алар икесе дә бер авылныкылар, бер-берсен яратышып өйләнешергә булалар, туйга әзерләнү мәшәкатьләре башлана. Әмма көтмәгәндә сугыш чыгып, егет хәрби хезмәткә алына һәм күп мәшәкатьләр белән әзерләнгән туй булмый кала. Гашыйк кәләш озын-озак уйлап тормастан, кияү егете белән бергә үзе дә фронтка китәргә карар кыла. Әбисе дә, кияү егете дә аны кулдан килгәнчә тынычландырырга, бу тиктомал ниятеннән түндерергә тырышалар. Ә кызый һаман үзенекен итә. Военкомат кире какканнан соң да, чигенми. Яшертен генә чәчен алдырып, кемнеңдер чалбарын, кепкасын һәм ирләр күлмәге кия дә пристаньга йөгерә, төнге ыгы-зыгы арасында китүче райондашлары белән бергә пароходка кереп утыра. Үзенең кияү егетенә ул бары тик пароход пристаньнан кузгалып киткәч кенә күренә.

Бу хакта инде безне озата баручы эшелон начальнигы да белә икән.

— Менә сиңа көтелмәгән сюрприз... Шул гына җитмәгән иде,— диде ул, борчылу белән.— Хәзер безнең алда ул шашкан кызны ничек тә аерып калдыру бурычы тора. Күренә, кызның башы-күзе әйләнгән, бик

иләс-миләс чагы. Димәк, моны саклык белән, берәр бәла-каза чыгармаслык итеп, җайлап кына эшләргә кирәк. Сезнең пароход кызлары бу четерекле эштә, зинһар, безгә булышсыннар инде.

Нишлисең бит, кирәк булгач, булышырга туры килде. Башта ничектер уңайсыз булыр кебек тоелса да, бик ансат эшләнде тагын. Моның өчен боцман Мәрфуга, сиңа ир-ат арасында ипсездер дип, кызны төнгә үз каютасына алып кереп яткырды. Ә иртәгесен качак кәләш йокыдан торып каютадан чыкканда гаскәриләр инде төшеп киткән, пароход яр буеннан шактый еракта якорьда тора иде.

И шулчак бичара кызның ачыргалануын күрсәң икән. Тәмам шашты, үзен-үзе белештермәс хәлгә җитеп ярсыды. Ярга йөзеп чыгам дип суга ташланудан көчкә тыеп калдык без аны.

Бераздан, пароходны чистартып чыгаргач, без дебаркадер янына барып туктадык һәм әлерәк кенә көнбатыш өлкәләрдән килеп төшкән качакларны — юлда дошман бомбалары астында газиз балаларын югалткан аналар, ятим калган сабыйлар, яралы карт-карчыкларны кабул итә башладык. Алар барысы да коточкыч йончыган, кайберләре акылдан язар хәлгә җиткән, үз аягы белән пароходка керерлек түгел иде. Андый бичараларны пароходка җитәкләп, каты яралыларны носилкага салып кертергә туры килде.

Әлегә хәтле без сугыш фаҗигасын газеталардан укып, радиодан ишетеп кенә белә идек. Аның аяусыз куркынычын, бөтен ил өчен коточкыч һәлакәтлеген бүген беренче мәртәбә үз күзебез белән күреп тетрәндек. Бу куркыныч хәлгә әлеге кияү егетеннән аерылып калган кыз Зәкия дә бик әсәрләнде, үз кайгысын читкә куеп, шундук ярдәмчесез сабыйларны, яралыларны кертеп урнаштыруда булыша башлады һәм шуның белән ул үзе дә безнең команда члены, үз кешебез кебек якын булып китте.

Пароходта бер ялгызы калган ул кызны без башта ничек тә юллык акча юнәтеп туган авылына озатырга уйлаган идек. Пароходтан төшеп киткән вакытта кызның кияү егете дә боцманга шундый киңәш әйтеп калдырган булып чыкты. Әмма Зәкия үзе мондый сәер сәяхәттән соң, авылдашларына кайтып күренергә уңайсызланды бугай.

— Юк, мин анда кайтмыйм...— диде ул, безнең киңәшне катгый рәвештә кире кагып.— Зәкинең (кияү егетенең исеме шулай икән) адресы табылу белән мин барыбер аның артыннан китәчәкмен, аның белән бергә иңгә-иң торып фашистка каршы сугышачакмын. Миңа бүтәнчә тормыш юк...

Янында бернинди документы һәм рәтле өс-башы булмаган бу яшь кызны без таныш түгел шәһәрдә төшереп ялгызын калдырмаска, үзебезнең штатта буш урынга вакытлы рәвештә матрос итеп алырга булдык; аны матрослыкка өйрәтергә боцман Мәрфуга үзе теләк белдерде.

...Күз нурым!

Кичә яза башлаган хатымны менә бүген көндезге вахтадан бушагач дәвам итәм.

Теге көнне пароходка кабул иткән халыкны Казанга алып кайтырга приказ булды. Мең газаплы хәтәр юлдан соң бичара качаклар пароходта бераз хәл алдылар, тынычланган кебек булдылар. Елый-елый шешенеп беткән ятим нарасыйлар гына, кайгыларын аңнарына сыйдыра алмыйча, әле һаман өзгәләнеп әниләрен эзлиләр.

Яңа матросыбыз Зәкия эштән буш сәгатьләрне гел шулар арасында: берсенең кайгысын уртаклаша, икенчесен тәмле теле белән юата, үзләре йөри алмаган яралыларга чәй китереп бирә. Әнисез калган өч яшьлек бер ятим малайны мунчада коендырып, үз каютасына алып кер-

гән, ашатып-эчертеп, йокларга яткырган. Хәзер шуның белән мәшгуль, аны үзенә уллыкка алырга ниятләнә дип сөйлиләр.

...Бүген рубкада көндезге вахтада торганда кайдандыр түбәннән бик таныш һәм җанга якын көйгә хатын-кыз җырлаганы ишетелә башлады:

*Бөдрә чәчкәй, зәңгәр күз,*
*Әйтмә лә, бәгырькәем, авыр сүз...*

«Зәңгәр күз»— безнең техникум студенты чыгарган, авыр истәлекләр белән бәйле бик моңлы һәм популяр җыр, мәхәббәт сагышыннан үзенең яшь гомерен харап иткән егет җыры бит. Хәтерлисеңдер, атна саен клубта үткәрелгән әдәби-музыкаль кичәләрдә бергәләп тә, күңел ямансу вакытларны аерым-аерым да без ул җырны еш башкара идек. Мин аны хәзер дә дулкынланмыйча тыңлый алмыйм.

Башта бу җыр миңа радиодан Казан концерты кебек тоелган иде. Әмма ялгышканмын. Штурвал көпчәге янында торучы рулевой кыз Җәмилә минем уйларымны бүлде:

— Ишетәсезме, безнең Зәкия нишләтә... Бу тикле дә моң булыр икән, күздән яшьләр чыгара...

— Радиодан түгелмени бу?! Шул җырлыймыни?!— дип бик гаҗәпләндем.

Бераздан, вахтадан бушап аскы палубага төшкәч, мин юри алгы яктан әйләнеп үттем һәм анда Зәкияне күрдем. Түгәрәкләп өелгән сүс чалка өстенә алга карап утырган хәлдә, кемгәдер моң-зарын сөйләгәндәй, әле һаман җырлый, аның янында җыелган качаклар да, безнең пароход кызлары да, сихерләнгәндәй тынып, аны тыңлыйлар иде. Шунда бер читтә шыпырт кына туктап, мин дә китә алмыйча байтак вакыт дулкынланып тыңлап тордым... Хәер, бу көннәрдә мин гомумән җырларны, бигрәк тә ямансу көйләрне бирелеп тыңлаучан, үзем дә авыз эченнән көйләп йөри торган булып киттем әле; һәр моңсу, сагышлы җыр сине хәтерләтә.

Гаҗәп хәл, шушы яшемә җитеп әлегә тикле мин гомумән чын мәхәббәтнең, җан-тән белән сөю-сөелүнең нәрсә икәнлеген белмәгәнмен. Шуңа булса кирәк, китапларда тасвирланган шашкын гашыйкларны, янып-көеп гыйшык тотуларны мин шагыйрьләр уйлап чыгарган ялтыравык сүз, төче телләнү дип кенә кабул иттем. Әгәр инде иптәш кызларымнан берәрсе үзенең сөю-сөелү шатлыгы белән уртаклашса, яраткан егетен күкләргә чөеп мактаса, мин аны баш әйләнүдән килеп чыккан чамасыз күпертү, төчеләнү дип уйлый идем. Менә хәзер үзем шундыйга әвереледем, гел синең хакта уйлап йөрим, син һаман минем белән.

Күптән түгел генә пароход Рязаньда торган вакытта яр буена чыккан идем. Шунда пристань каршында ыгы-зыгы килгән халык арасында бер елгачыны күреп шаккаттым. Буе-сыны, кителе, фуражкасы, йөреше — барысы да нәкъ синеке, шатлыктан чүт кычкырып эндәшмәдем үзенә. Бераздан, артыннан куып җитеп, яннан карап узгач кына үземнең ялгышуымны аңладым.

Бүгенгә хуш, сау бул, дускаем.

Сине һәрчак күңелендә йөртүче Мәрьямең.

Нурисым!

Соңгы вакытта безне өйдән еракта, гел Иделнең югарыгы агымында, Ока елгасында эшләттеләр. Ике ай буе синнән бернинди хат-хәбәр алмаудан, билгесезлектән борчыла-борчыла тәмам гаҗиз булган, интегеп беткән идем. Ниһаять, бу юлы Казанга кайттык. Пристаньга килеп туктау белән диспетчер бүлмәсеннән Чистайга шалтыраттым. Минем

бәхеткә, квартира хуҗам Марина Михайловна эш урынында туры килде. Исәнләшеп хәл-әхвәл белешкәч тә, синнән биш хат бар дип, мине бик сөендерде. Хатларыңның берсе — ул бүген эшкә барганда таныш почтальон урамда биреп калдырганы — шунда, үз янында икән. Түзмәдем, хатыңны шундук ачтырттырып, телефоннан укып бирүен сорадым. Марина Михайловна хатны зур кыенлык белән, абына-сөртенә укыса да, һәр сүзеңне үз авызыңнан ишеткәндәй булдым, әйтеп бетергесез куандым. Иң мөһиме — син исән-сау, шуңа сөендем. Мине бик сагындым, мәхәббәтең сугыш кыенлыкларын җиңәргә ярдәм итә дип, минем күңелне күтәргәнсең. Җылы сүзләрең өчен мең рәхмәт сиңа, кадерлем.

Казанда этине дә күрдем. Без киләсене белешеп торган икән, мин өйгә шалтыраткачы ук пристаньга ул үзе төшеп җитте. Кәбирне бик сагынган, аңа уенчык, күчтәнәчләр алып килгән.

Әтине тагын техникум директоры иткәннәр. Күз тимәсен картка, хәзергә бирешми, әйбәт кенә йөреп тора. Без рейстан кайтканчыга тикле дип Кәбирне үз янында кунакка алып калды.

Әти сөйләгәннәрдән тагын бер яңалык — Хөснулланың пристаньга тәэминат начальнигы итеп күчүе мәгълүм булды. Техникумнан расчет алган көнне салмыш хәлдә әти янына кереп тагын бер кабат зинһарлап гафу үтенгән, минем белән килешергә, бергә тора башларга ярдәм итүен сораган.

Безнең монда хәзергә әллә ни зур яңалыклар юк. Һаман шул линиядә — Иделнең югарыгы агымына йөрибез: моннан азык-төлек, киемсалым, сугыш кирәк-яраклары һәм гаскәриләрне төяп барабыз, аннан тылга күченүче завод-фабрика җиһазлары, каюталарда эшчеләр һәм яралылар алып кайтабыз. Хәзер бөтен флот диярлек шунда эшли, Мәскәү янындагы хәлнең кискенлеге шуны таләп итә.

Эш муеннан, буш вакыт юк диярлек. Кеше җитмәү аркасында тәүлегенә уникешәр сәгать (алтышар сәгатьтән ике тапкыр) вахта торабыз. Ә миңа таныш түгел Ока елгасында ярым сукыр лоцман белән эшләве баштарак бигрәк тә читен булды. Тик бераздан, фарватерны азмы-күпме үзләштергәч кенә җиңелрәк сулыш алдым. Шөкрана, капитаныбыз Трофим Григорьевич та, беренче көннәрдәге кебек, эчпошырып янымда тормый, хәзер ул миңа тулысынча ышана. Үз сәгатьләре тәмам булганнан соң, миңа хәерле вахта теләп, тыныч күңел белән рубкадан төшеп китә.

Менә рәхимсез сугышның авырлыгы безнең команда өстенә дә төшә башлады. Кичә Чистай белән сөйләшкәннән соң, шатланып пароходка кайтып керсәм, мине Трофим Григорьевич чакыртып алды да авыр сулап:

— Военкоматтан күңелсез хәбәр бар, безнең боцман Марфаның (Мәрфуганы үзенчә шулай йөртә) ире һәлак булган,— диде.— Менә шуны үзенә ничек әйтергә белмичә аптырап торам. Хатын-кыз кеше, сез шуны җайлабрак, ничек тә йомшаграк итеп әйтә алмассызмы...

Бу минутта Мәрфуга үзе, зәңгәр майкасының җиңнәрен сызганып, шлангтан су сиптерә-сиптерә палуба юдырта, артыннан швабра белән сөртә баручы кызларны ашыктыра, көр тавышыннан, җиңел хәрәкәтләреннән аның ныклыгы, кыенлыкларга бирешмәүчәнлеге күренеп тора иде. Шулай да бу кайгылы хәбәрне аңа үзем генә әйтергә телем бармады, ул-бу булудан курыктым; кызыл почмакка чакыртып, капитан белән бергәләп белдерергә туры килде.

Кулдан килгәнчә җайлап, мөмкин кадәр йомшаграк итеп әйтсәк тә, бу хәбәрдән Мәрфуга кинәт миңгерәүләнде, өянәк тоткан кебек, иреннәре калтырый башлады, төсе китте. Тиз генә салып биргән суны берникс йотым эчкәч кенә телгә килеп, ишетелер-ишетелмәс тавыш белән

— Бар таянычым син идең, башыңа житкәннәр икән, ләгънәтләр,— диде һәм, үзе генә калырга теләп булса кирәк, алпан-тилпән атлап кызыл почмактан чыгып китте.

Мәрфуганың кайгысы бөтен командага тәэсир итте, һәркайсыбызның күңелендә сугыштагы якыннары турында борчулы уйлар уятты. Яшерен-батырын түгел, үземнең дә йөрәгем жу-у итеп китте: син дә шунда ут эчендә йөрисең бит. Син анда, зинһар, алдыңны-артыңны карап йөр, якты киләчәгебез хакына сак була күр.
Сине һәрвакыт юксынучы Мәрьямең.

Нурисым, жан кисәгем минем!

Әлегә тикле һич булмаган хәл, бу арада сиңа атна буе хат яза алмадым. Син анда көтә-көтә миңа үпкәләп беткәнсеңдер инде. Зинһар, үпкәли күрмә. Мин гаепле түгел, бу көннәрдә иркенләп ашарга, мендәргә баш төртеп алырга да вакыт булмады. Соңгы рейс азагында затоннан еракта — ачык елга уртасында — кышка катып калудан көчкә котылдык.

Ярар, ул хакта азактарак язармын. Башта сине Бөек Октябрь бәйрәме һәм бүләкләнүең — орден алуың белән котлыйм! Синең өчен мин бик шатмын, батыр бөркетем, молодец! Сугышчан дустың Суранов белән бергә төшкән фоторәсемеңне рамка эченә куеп стенага элдем. Нинди хәтәр «эш» өчен бүләкләнүең турында фронт газетасында басылган мәкаләңне кисеп алып жибәрүең бик яхшы булган. Без аны кызыл почмакта бөтен команда белән укыдык, шуннан соң бу арада байтак өшәнгән кызларымның зарлану-сыкранулары шактый кимеде, ул көнне без аеруча тырышып эшләдек.

Без затонга бәйрәм алды кичендә генә кайтып кердек. Синнән килгән хатларны мин Чистайга кайткач барысын берьюлы алдым. Кайсы карандаш, кайсы кара белән аяк өсте генә язылган бу конвертлар, өчпочмаклап бөкләнгән дәфтәр битләре, берничә жөмләдән генә гыйбарәт кыска-кыска ачык хат-хәбәрләрне Марина Михайловна өеме белән алдыма китереп салгач, башым күккә тигәндәй булды. Минем өчен болар гади хат-кәгазь генә түгел, дәһшәтле сугыш эченнән синең күңел жылыңны чәчми-түкми саклап китерүче, безнең ерак араларны якынайтучы тылсымлы жепләр бит алар.

Әнә шулай рәхәткә чумып шул хатларны укып утырганда бүлмәгә көтүе белән безнең пароход кызлары килеп керде. Авыр сугыш вакыты булса да, барысы да бәйрәмчә киенгән, йөзләре шат. Арада боцман Мәрфуга гына моңлы-зарлы, ире һәлак булганнан соң ул бичара һаман искә килә алмый әле.

Жырчы Зәкия өстәл өстендәге хатларны күрүгә сагаеп калды: «Үзе бер почта ич бу... Бөтенесе дә шушы офицерларданмы, боларның кайсы сезнеке?»— дип стенадагы фоторәсемгә текәлде. Башкалар да, моны ничек аңларга дигән сыман, бер миңа, бер рәсемгә сораулы карап алдылар.

Сизәм, күңелләрендә шик тугандай, сагаеп калды болар. Мин аларга синең турыда берни дә әйткәнем юк бит әле. Жәен Казан пристанендә туктап торган чакларны Хәснулланың берничә мәртәбә пароходка кергәнен, Кәбирнең әтисе шул иkәнлеген алар беләләр, һәм менә хәзер мине ир өстеннән башка берәүгә гашыйк тота дип, гаеплиләр иде бугай. Бөтен кыяфәтләреннән шул күренә, сәгате-минуты белән күз алдында үзгәреп, читсенеп карыйлар... Андый аңлашылмаучылыкка, имеш-мимеш гайбәтләргә урын калдырмас өчен, инде елдан артык Хәснулла белән тормавымны, якын арада рәсми рәвештә аерылышачагымны шундук аларга кыскача гына әйтеп бирергә туры килде.

Әйтергә мөмкин. Октябрь бәйрәмен без барыбыз бергә ярыйсы гына күңелле үткәрдек. Мәскәү янында фронт хәлләре гаять кыен булуга карамастан, Кызыл мәйдандагы хәрби парад, куәтле танк колонналарының шуннан туп-туры яуга китүен радиодан ишетү барыбызны да канатландырды, күңелләрдә җиңүгә ышанычны ныгытты.

Марина Михайловна безне бәйрәмгә пешергән тәмле балык пирогы белән сыйлады, кара карлыган вареньесы белән чәй эчерде. Аннары Зәкиянең моңлы җырларын тыңладык, аңа кушылып үзебез дә җырладык.

Марина Михайловнаның шәһәр Укытучылар йортына бәйрәм кичәсенә чакыру билеты бар икән. Үзенә ияртеп ул безне дә алып барды һәм, таныш администраторы белән сөйләшеп, барыбызга да залга керергә ярдәм итте. Без пароходта йөргән вакытта бирегә Мәскәүдән күп кенә атаклы язучылар, артистлар күчеп килгәнен мин ишетеп беләидем. Бүгенге кичәдә шулардан К. Федин, Н. Асеев, М. Исаковский катнашты, яңа әсәрләрен укыдылар, кызыклы истәлекләр сөйләделәр, күп санлы сорауларга җавап бирделәр. Атаклы әдипләрнең, сәнгать осталарының шигырьләрен, җырларын тыңлаганда үземнең бөек совет иле гражданины икәнемне, халкыбызның какшамас бердәмлеген бөтен җаным-тәнем белән тоеп, дулкынланып утырдым.

Менә хәзер шул кичәдән соң тын бүлмәдә сиңа хат язып утырам. Айлар буе юлда йөрүдән, ыгы-зыгылы пароход тормышыннан соң күп төрле эш-мәшәкатьләрдән азат хәлдә тын, җылы бүлмәдә утыруы үзе зур рәхәт. Ә бит без бер атна элек Чистайдан еракта бөтен кыш буена боз эчендә катып калу куркынычы астында идек.

Ул чакны Идел суы әле суынып бетмәгән, һәркайда пароходлар йөри, пристаньнарда калган соңгы йөкләрне ташыйлар иде. Ә безне исә, Кама елгасының дүрт-биш көнгә элегрәк катуын исәпкә алып, ашыгыч рәвештә Чистайга кайтып, затонда кышка туктарга приказ бирделәр.

Әйе, ашыгырга кирәк иде. Чөнки төньяк җиле көннән-көн кырачлана бара, кышның салкын сулышы үзен нык сиздерә.

Казанда затонга керергә приказ алгач та, без бернинди йөксез, пассажирларсыз шундук юлга кузгалдык һәм, һичкайда туктамыйча, шул ук кичне Кама Тамагына төшеп җиттек. Анда да пристаньга туктап тормастан, барган шәпкә Лобач тавы турында гудок кычкырта-кычкырта Идел белән саубуллаштык та, агымга каршы борылып, Камага керүгә көзге зим[1] агымына тарыдык.

Инде эңгер-меңгер куерган, күз бәйләнгән вакыт иде. Рәтләп күренмәгәнгә булса кирәк, башта ничектер ышанасым килмәде. Әле иртә, мөмкин түгел, миңа гына шулай тоеладыр дип тынычландырырга тырыштым үземне. Әмма үзем сизәм, пароход рульне начар тыңлый, әле уңга, әле сулга чалулый башлады. Пөреше дә сизелерлек авырая төште, әйтерсең авыр баржа тартып барабыз инде.

Әйләнә-тирәдә төн карасы тагын да куера төште. Су өстендә бер генә йөзмә маяк та юк; елга борылышларын күрсәтүче яр өстендәге парлы-парлы перевал утлары гына анда-санда күзгә чалынып киткәли.

Шул арада сөйләшү трубасы буенча алгы пролеттан матрос Зәкия борчулы тавыш белән:

— Мәрьям Васильевна, сез ничек анда, күрәсезме?!. Боз килә башлады бит,— дип хәбәр итте.

Тиз генә рубка өстендәге прожекторны кабызып карасам, ике күзем дүрт булды: су өстендә, ярдан-ярга тоташ җәелеп, итле аш өресе төсле зим ага. Әмма бу, Зәкия хәбәр иткәнчә, боз түгел әле, кайдадыр елганың югарыгы агымында яуган карның салкын суда эремичә, ботка ке-

---

[1] Зим — су өстеннән ага торган кар катнаш вак боз.

бек куерып килә башлавы гына. Шулай да, һава суыкка китсә, берничә сәгать эчендә аның боз булып ката башлау куркынычы бик ихтимал.

Шундук капитанны уяттырып рубкага чакырырга туры килде. Һәрьяклап уйлашканнан, киңәшкәннән соң, мондый караңгы төндә маяксыз юлда шуннан ары бармаска булдык. Лаешка җитәрәк сулъяк яр чыгынтысы ышыгында якорьга туктап, төнне шунда үткәрдек.

Иртән яктырганда, үч иткән кебек, һава отыры суыта төшкән, кичәге юеш кар боткасы боз кисәкләренә әверелгән, көпчәк канатлары арасына тулып каткан иде. Лом һәм кәйлә белән ике як көпчәкне боздан әрчү шактый озакка сузылды, сәгать унбердә генә кузгалып китә алдык.

Авырткан башка тимер тарак дигәндәй, бер кирегә китсә — китә бит. Вак бозлардан ачык җылуларны сайлый-сайлый өч сәгать бармаганбыздыр, төньяктан чыккан ачы җил иләмсез тавышлар белән мачтага, ванталарга[1] бәрелеп сызгыра, ак чебеннәр очыра башлады, берничә минут эчендә күз ачкысыз кар бураны күтәрелде. Фарватердан читкәрәк тайпылып, без тагын якорь салдык һәм көннең калган өлешен шунда үткәрергә мәҗбүр булдык.

Кар бураны кичке караңгы төшкәндә генә туктады, соры болытлар таралып, чалт аяз салкын төн башланды. Болай суыкка киткәч, яктырганны көтеп, иртәгә хәтле монда тору хәтәр, хәлнең кыенлашканнан-кыенлаша баруы көн кебек ачык. Руль һәм көпчәкләрне мең бәла белән боздан арындырып, без тагын юлга кузгалдык.

Башта баруы бик кыен булды. Елга һәм тугайлар кар белән капланып, ак ятьмә ябынгандай, барысы да тоташ бер төстә, кайда су, кайда яр кырые икәнен дә аерырлык түгел иде. Шулай да, күз өйрәнә төшкәч, тонык ай яктысында боздан ачык урыннарда су өсте каракучкылланып ачыграк күренә башлады, наметка белән тирәнлекне үлчи-үлчи, төн буе акрынлап бардык.

Иртәгесен таң беленгәндә без инде Балык Бистәсе турысына менеп життек. Җил басылса да, көнне тагын да катырак суыта төште, күз алдында калыная, зурая барган бозлар корпуска дөбердәп килеп бәрелгән саен бөтен пароход шомлы калтыранып куя; боз кантарлары бәрелүдән көпчәк канатлары чатный башлады.

Шундый суыкта, көпчәкнең ватык канатларын алып, яңаларын гайкалар белән беркетеп кую — безнең эше хатын-кызга гына түгел, тәҗрибәле ир-егетләр өчен дә шактый кыен эш. Ул көнне безгә бу авыр эшне ике тапкыр башкарырга туры килде. Тайгак бозлы көпчәк тырнаклары арасында өзлексез чайкалып торган суык судан өс-башыбыз, гипсланган кебек, бөгелмәс булып катты, кул-аяк күшегеп бетте.

Шөкрана, тырышуыбыз бушка китмәде. Мең газап белән булса да, көн яктысында Чистайга кайтып җитеп бик зур бәладән — кышка юлда катып калудан котылдык.

Тагын шунысы гаҗәп, затонда безнең урын син эшләгән «Владимир Маяковский» пароходы белән янәшә туры килде. Аны күргәч, кайчандыр бергәләп Ульяновскига барган, пристаньда синең белән соңгы тапкыр саубуллашкан минутлар күз алдыма килеп басты, бик ямансу булып китте.

Менә шулай, кадерлем, атна буе хат яза алмасам да, син һаман минем күңелемдә булдың, гел синең хакта уйлап, сагынып эшләдем.

Сиңа саулык-сәламәтлек теләп һәм сагынып калучы Мәрьямең.

Кадерлем! Берничә көн элек кенә сине Яңа ел белән котлап инде бер хат җибәргән идем. Яңа елны без бик шатланып каршыладык. Гаскәрләребезнең Мәскәү янындагы тиңдәшсез җиңүе безнең янган

---

[1] Ванта — мачтаны як-яктан тарттырып беркетә торгач бау.

йөрәкләргә шифалы май булып ятты, барыбызны да канатландырды, рухи көч бирде. Кешеләрнең борчулы йөзләрендә өмет яктысы балкыды. Бу зур шатлык белән сине дә тәбрик итәм һәм сезнең тарафларда да яңа җиңүләр теләп калам.

Бераз гына үзем дә мактанып алыйм әле: үткән навигациядә хәрби йөкләрне ташу заданиеләрен уңышлы үтәгән һәм гаять авыр метеорологик шартларда юлда катып калмыйча, пароходны төзек-имин хәлендә затонга алып кайткан өчен (каты суыклар кинәт башлану нәтиҗәсендә затоннардан еракта елга уртасында катып калучы пароходлар байтак быел) безгә пароходлыкның күчмә вымпелын тапшырдылар, барыбызны да кышка берәр пар киез итек һәм акча белән бүләкләделәр.

Бу көннәрдә без барыбыз да ремонт белән мәшгуль, җаен бер семьядай тату эшләгән команда членнары кышын да гел бергә эшлибез, шатлык-кайгыларны бергә уртаклашып яшибез.

Хәер, бер кешегә кимегәнбез икән. Яңа ел алдыннан гына яраткан җырчыбыз матрос Зәкия кемтмәгәндә авылына кайтып китәргә булды. Шәһәрдә кемнәндер кияү егетенең фронттан яраланып кайтуын ишетү белән кызый тәмам иләсләнде: «Ул минем монда икәнемне белми торгандыр, юкса килеп җитәр иде. Бәлкем, минем ярдәмемә мохтаҗдыр»,— дип күз яшьләре белән зинһарлап китәргә рөхсәт сорый башлады.

Дөрестән дә, үлеп яраткан кияү егетеңнең сугыштан кайтып төшүе — бу сиңа уен эш түгел бит. Мин шулай уйладым һәм бичара кызның хәленә кердем, капитанны да шуңа күндердем. Затонда эшче кулларга зур кытлык булса да, Зәкия белән саубуллашырга туры килде.

Быел затонда шундый хәл — һәр команда үз судносын үз көче белән ремонтларга тиеш. Завод цехларына ышаныч аз: анда квалификацияле эшчеләр җитми, кирәкле материал һәм инструмент яклары да бик кысан. Аннары пароход ремонтлау — безнең кызларның күпчелеге өчен бөтенләй таныш булмаган яңа шөгыль бит. Турыдан-туры ремонтка керешкәнче, башта кызларны тиешенчә инструмент тотарга өйрәтергә, һәр нәрсәне бәйнә-бәйнә аңлатырга, эшләп күрсәтергә туры килде. Хәзер инде бераз рәтләндек шикелле, эш темпы көннән-көн тизләнә бара. Безнең өчен хәзер иң мөһиме — машина; якын арада цехта поршень боҗраларын кырдырып бирсәләр, калган эшләрне ничек тә үзебез ерып чыгар идек.

Син, зинһар, минем хакта кыенлыклардан зарланып яза дип уйлый күрмә. Юк, һич тә аннан түгел, сине үзебезнең хәлләр белән таныштыруым гына. Ничек кенә авыр булса да, без монда чыдарбыз, фронт өчен кирәкнең һәммәсен дә эшләрбез. Бар ышаныч сездә, безнең өметләр сезнең белән, анда сез нык тора күрегез... Тагын менә нәрсә, андагы хәлләр, сугышташ иптәшләрең турында син бушрак вакытларда мөмкин кадәр тулырак язарга тырыш. Без монда һәрчак фронт турындагы уйлар белән яшибез.

Әмма радио һәм газеталар бу көннәрне сезнең якларда фашист юлбасарларының бик тә яман котырынуын, Севастополь өчен сугышларның көннән-көн кыза баруын хәбәр итә. Бәгырькәем, син дә шул дәһшәтле ут астында йөрисең бит. Гәрчә хатларыңның берсендә: баштарак куркыныч иде, хәзер инде алай ук түгел, күнектем дип язсаң да, мин бик борчылам. Син берүк анда гамьсезләнмә, алдыңны-артыңны карап йөр, яме.

Соңгы хатыңда син Кәбирнең хәлен сораштырып, киләсе җәйдә аны үзем белән пароходка алып чыкмаска, синең әниеңдә калдырырга әйтеп язгансың. Ярар, анысын яз җитәрәк хәл итәрбез. Ә малайга күз тимәсен, әйбәт кенә үсеп килә әле. Бар белгәне сугыш уены, фашистны тукмау. Мин кулга кәгазь, каләм алып утырсам, шундук: «Нурис абыйга хат язабыз»,— дип ул да килеп сызгаларга тотына. Сиңа хат язып утыруымны күреп, әнә улым тагын үзалдына: «Нурис абый, тизрәк фа-

шистны җиң дә миңа тасмалы бескозырка алып кайт»,— дип сөйләнә-сөйләнә нидер сызгалап утыра. Үз хатым белән бергә менә аның кәгазен дә конвертка салып җибәрәм.

Хуш, сау бул, бәгырькәем. Гомерлеккә синең Мәрьямең.

Күз нурым, ай буе хатың килми торуы бик авыр булды, тәмам зарыктырды. Аптырагач, берәр хәбәрең юкмы дип, Казанга әниеңә да шалтыраткан идем. Әмма аңа да берни килмәгән, ул бичараны да, нәкъ минем кебек, билгесезлек борчый булып чыкты.

Менә бүген хатыңны алып укыгач, эчкә җылы керде, исән-сау икәнлегеңне белеп бик сөендем, дөнья яктырып китте. Шундый ук хатны, шәт, әниеңә дә салгансыңдыр, аны да тынычландыргансыңдыр бит? Әгәр язмаган булсаң, тизрәк язып сал, тынычландыр үзен. Үз тарафымнан, мин дә бүген үк хәбәр итәрмен.

Хатыңда ачык итеп язмасаң да, сизәм, син анда каты яралангансың бугай. Югыйсә, ай буе хәбәр бирми тормас идең... Ярар, анысы инде үткән хәл, азагы хәерле булсын. Госпитальдән соң атна-ун көнлек ял бирерләр күк язгансың. Менә монысы бигрәк тә шәп булыр иде.

Шатлыгым йөземә чыккандыр, күрәсең, эштә кызлар бик тиз сизеп алдылар, минем өчен алар да куандылар. Ә нечкә күңелле җырчы матросыбыз Зәкия көндез ашханәдән чыкканда сер әйтергә теләгәндәй, миңа якынрак елышты: «Мәрьям апай, әгәр ачуланмасагыз, сезгә бер соравым бар,— диде.— Зинһар, әйтегез әле, ул дустыгыз турылыклы кешеме, сез аңа чын күңелдән ышанасызмы?.. Урынсыз сорау биргән булсам, гафу итегез, берни дә әйтмәгез...»

Хәтерлисеңдер, элекке хатларымның берсендә ул кызның кияү егете янына авылга кайтып китүе турында язган идем бит. Менә шул кыз бездән киткәннең иртәгесен, буранлы караңгы кичтә, бик туңган хәлдә туп-туры минем бүлмәгә кайтып керде. Бөтен өс-башына, каш-керфекләренә ап-ак булып кар сырышкан иде, көчкә танып алдым үзен. Марина Михайловна белән мескен кызның күшеккән кулларын спирт белән удык, кайнар аш ашаттык, тир чыкканчы мәтрүшкәле чәй эчертеп җылы урынга яткырдык һәм, суык тиеп авырудан, әнә шулай көчкә саклап калдык үзен. Ниләр булганын мескен кыз иртәгесен чәйдән соң гына сөйләп бирә алды.

— Мәрьям апай, җаным, бу авыр хәлне мин бары тик сезгә генә, бертуган апам кебек якын күргәнгә генә сөйлим,— дип, башлап китте ул, өстәл янында икебез генә калгач.— Юлда кайтып барганда ук әле, ниндидер күңелсезлек буласын алдан сизенгәндәй, кинәт эчем поша башлады.

Шулай ут йотардай булып кайтып барганда юлда атлы юлчы куып җитте үземне. Безнең авыл хатыны, ире фронтка киткәч, аның урынына почта ташучы булып калган Хәлимә түти икән. Үткән җәйдән бирле авылыбыз кешесен күргәнем юк бит, чанасына бик рәхәтләнеп менеп утырдым. Күп сүзлелеге белән дан тоткан Хәлимә түти шундук авыл хәлләрен сөйләп китте. Фронттан яраланып кайтучылар арасында ул минем кияү егетем Зәкине дә телгә алды һәм аның кибетче Хәдичә белән буталуын әйтүе — эрнүле йөрәгемә очлы ук булып кадалды.

Без авылга кичкырын, ут алган вакытта кайтып кердек. Яшерен-батырын түгел, дөресен әйтим, ул чакны мин аны-моны уйлап эш итәрлек хәлдә түгел идем, тилебәрән орлыгы ашаган кебек, тәмам ярсыган идем. Кибетче Хәдичә өе турына җиткәч, түзмәдем, почтальонга рәхмәт әйттем дә, чанадан төшеп калдым. Бәйдән ычкынган кебек өенә атылып барып керсәм, болар икесе тәмләп кенә түр сәке өстендә сыйланып утыралар. Хәдичәсе мине күрүгә буш шешә янындагы аракылы ике стаканның берсен тиз генә самовар артына алып куйды, яртылай ачык изүе аша күренеп торган кукрәгән каплый-каплый, поч-

мак якка кереп китте. Тегесе — мин сагынып, ярдәмгә мохтаҗдыр дип кайгыртып кайткан кияү егетем — бурлат кебек кызарган, маңгаена, битләренә бөрчек-бөрчек тир бәреп чыккан.

Хәрби флотта хезмәт иткән булса кирәк, өстендә буй-буй сызыклы матрос күлмәге, җирән мыек җибәргән. Мине күргәч, күзләренә ышанмагандай, текәлеп катты бу. Аннары күзләрен челт-челт итеп, почмак якка карангалады: «И синмени әле бу... Әйдә, табынга рәхим ит,— ди.— Хәдичә киң күңелле ул, әйдә утыр, утыр... Әни шәһәргә, түтиләр янына күчеп киткән булгач, мин менә шушында туктадым әле...»

Әйткәнемчә, минем хәтәр ярсып, бу вәгъдәсезне әллә нишләтердәй булып керүем иде. Ә аның почмак якка шикле карана-карана боргалануын күргәч, үземдә җирәнү хисе туды, үпкә сүзләр әйтеп, үземне кимсетүдән көчкә тыелып калдым һәм, ләм-мим сүз катмыйча, чыгып киттем.

Шуннан соң инде, төрле гайбәтләргә азык биреп, авылда кеше-кара күзенә күренмәдем. Мин ятимне кече яшьтән карап үстергән әбиемдә төн кундым да, иртән таң белән кире юлга чыктым... Әле кичтән үк, кая китәргә дип борчылып, пароходтан китүемә үкенеп, йоклый алмыйча озак яттым. Әмма йокыга киткәч, төн буе төшемдә сезне, пароходны күрдем, мине кире кайтырга чакыргандай, хәтта сузып-сузып аның гудок кычкыртканын ишеттем... Шул гудок мине кире монда кайтарды... Мин җилбәзәкне тагын үз гаиләгезгә алуыгызны сорыйм. Минем бүтән барыр җирем юк, сезнең белән бергә яшәргә, бергә эшләргә телим.

...Зәкия ачынып сөйләгән бу аяныч вакыйганы мин дулкынланып тыңладым һәм кулымнан килгәнчә ул кызны ничек тә юатырга, хәленә керергә тырыштым. Марина Михайловна белән киңәшкәннән соң, әлеге күңелсез хәлне бүтән кеше-карага сиздермәскә сүз куешып, Зәкияне без элекке эшенә алдык һәм, тулай торакта урын бушаганчы, вакытлы рәвештә боцман Мәрфуга квартирасына урнаштырдык. Ә мин әле һаман тынычлана алмыйм, Зәкияне күргән саен аның еш кабатлый торган бер сагышлы җыры исемә төшә:

*Яр сөюне чыгарганнар*
*Йөзне саргайтыр өчен...*

Тормышта әнә шундый газаплы, бәхетсез мәхәббәт тә була икән.

Үзем турында сүз чыккач, тагын шуны да хәбәр итим: мин, ниһаять, Хөснулладан рәсми рәвештә аерылдым, хәзер аның белән һичнинди бәйләнешем юк. Ул Кәбирне үзенә калдыруны дәгъвалап, минем сиңа булган якынлыкны гаепләп, бала тәрбияләргә мораль хокукы юк дип, судлашып та караган иде. Әмма барыбер пычагым да чыгара алмады, тагын бер тапкыр үзенең кара эчле икәнлеген, күңел биздергеч хөсетлеген генә күрсәтте.

Ярар, хәзергә хуш, сөеклем. Тизрәк кайтып житүеңне көтеп Мәрьямең.

P. S. Син, мөгаен, юлдан туры Казанга, башта әнең янына кайтырсыңдыр инде. Шулай да, җан кисәгем, анда артык озак чуалмаска, бераз безгә дә вакыт калдырырга тырыш инде. Мин моны көнләшү-күпсенүдән әйтүем түгел, үзеңне бик юксынып, бик күрәсем килүдән искәртүем генә. М-м.

Нурис җаным, язгы Кама буйларыннан кайнар сәламнәремне юллыйм сиңа.

Соңгы хатыңда Казанны сагынам, Идел, Кама язын, шаулап боз киткәнен, пароходларның гудок кычкырта-кычкырта затон белән саубуллашып беренче рейска чыгуларын, елгачыларның тантаналы-эшчән йөзләрен күрәсем килә дип язгансың.

Әйе, кышның гомере бетте. Яз кояшы, аның кар-бозларын эретеп, тау битләрен ача, гөрләвекләр йөгерешә, инеш-ерганакларда ташкыннар уята, җылы яклардан чакыртып кайтарган купшы сыерчыкларын сайрата.

Дөнья мәшәкатьләре белән мин елганың кышкы йокыдан уянуын рәтләп күрми дә калганмын. Бүген ул, ярсып китеп, калын боз тауларын бер-берсенә бәрә-суга көньякка сөрә башлады, биек ярларыннан ташып чыгып, киң тугайларга җәелде. Безнең затон да су белән тулды; түбәндә, тау астында кышлаган йөзләрчә пароход, дебаркадер, баржалар, елга төбеннән үсеп чыккандай, яр өстендәге завод корпуслары, безнең урам йортлары белән бертигез биеклеккә күтәрелеп, үзләре бер йөзмә шәһәрчеккә охшап калды. Аларның мачталары очында елгачыны ерак юлларга чакырып кызыл флаглар җилферди, әле анда, әле монда күңелле гудок тавышлары яңгырый.

Хәзер бөтен затон, кырмыска оясы кебек, мәш килә. Завод цехларында, пароход, баржаларда соңгы эшләр төгәлләнә, һәркайда флотны эксплуатациягә тапшыру бара. Безнең «Ургыл»ны бүген кабул иттеләр. Иртәгә барыбыз да кышкы квартиралардан пароходка күчеп, каюталарда тора башлыйбыз һәм менә-менә боз китеп бетү белән беренче рейска чыгабыз.

Навигациягә әзерләнгәндә башта бөтен командабыз үзгәрешсез калыр, быел да былтыргы составта эшләрбез кебек иде. Әмма иң соңгы чиктә һич уйламаган-көтмәгән яктан күңелсез хәл килеп чыкты — врачлар командага смотр үткәргәндә капитаныбыз Трофим Григорьевичның «тавык күзе» чире белән авыруы, караңгыда начар күрүе беленде, шул сәбәпле аңа пароходта эшләргә рөхсәт бирмәделәр. Вакытлы рәвештә капитан булып миңа калырга туры килде. Командада бер үзгәреш — матрос Зәкияне үзе соравы буенча машина бүлегенә кочегар итеп күчердек. Механик ярдәмчесе, бөтен пароходта бердәнбер егет Исәнбаев, аны үз вахтасына алып, эшкә өйрәтергә теләк белдерде.

Менә шулай мең мәшәкать, тынгысыз ыгы-зыгы арасында көн артыннан көн үтә, баш кашырга да вакыт юк.

Нурискаем, син бездә торып киткәннән соң мин гомумән ничектер үзгәреп, яңа энергия өстәлгәндәй, ару-талуны, төшенкелеккә бирелүне белми торган булып үзгәрдем әле. Син һәрчак күңелемдә минем. Вакытвакыт хәтта китмәгәнсең дә, янымдадырсың кебек хис итәм, синең белән бергә үткәргән ләззәтле дөньяда яшим. Чын мәхәббәтнең ләззәтен, сөю-сөелүнең әйтеп бетергесез зур бәхет икәнлеген бөтен җаным-тәнем белән хәзер генә белдем. Без бер-беребез өчен яратылган бәхетле җаннар бит...

Шатлыкны кеше күзеннән яшереп булмый дип әйтәләр. Миндә дә шундый хәл, эчемә сыймаган куанычым йөземә чыккан, күрәсең, хезмәттәшләрем, якын танышларым, бу шатлыкның чыганагын сизгәндәй, очрашканда дусларча кызыксыну белән синең хакта сораштыралар, сиңа сәлам әйтәләр.

Син әниеңә мине күккә чөеп, бик мактап сөйләгәнсең, ахры, миңа язган хатыннан шуны сиздем. Ничектер шулай килеп чыкты, без аның белән бер-беребезне күреп белешкәнче үк хат аша танышып, үз кеше булып, дуслашып өлгердек инде. Синнән хат озаграк килми торса, берәр хәбәр-хәтер юкмы дип, миңа борчылып яза. Син аңа карата игътибарлырак булырга, озак-озак көттереп зарыктырмыйча, берничә сүз генә булса да, мөмкин кадәр ешрак язарга тырыш инде. Ана күңеле шуңа да бик шатлана ул.

Куптән түгел улым Кәбир белән берничә көнгә Казанга әти янына кайткан чакны без сезгә дә кердек. Разия апайга рәхмәт, безне бик җылы каршылады. Очлы күзле Кәбир стенада синең фоторәсемеңне күрүгә, үзеңне очраткандай, шатланып кычкырып җибәрде:

— Әнием, карале, бу безнең Нурис абый ич... Чыннан да шул үзе, ул монда ничек эләкте икән?.. Ә менә монысы...— дип, аннары әтиең портреты каршында бер мәлгә аптырап калды.— Монысы мыеклы моряк, ул да Нурис абыйга охшаган.

Разия апайның күңеле нечкәреп китте бугай, күзләре яшьләнде. Кара син аны, күрү белән таныды, балакаем Нурислам абыйсын яратә икән дип, сөйләнә-сөйләнә Кәбирне башыннан сыйпап сөйде. Ул кичне без синең хакта сөйләшеп, әтиеңне искә алып төн уртасына кадәр утырдык.

Минем җәй буена пароход белән китеп баруым турында сүз чыккач, ул инде күптән уйлап куйгандай: «Теләсәң — теләмәсәң дә, Мәрьям җаным, Кәбирне бездә калдырырга туры килер,— диде.— Мондый хәтәр вакытта баланы үзең белән пароходта йөртү ярамас. Бу — бер минем сүз генә түгел, киткән чакта Нурислам да шуны әйтеп калдырган иде».

Аннары Разия апай безне синең бүлмәңә алып кереп, «Ваня — коммунист» корабының син ясаган моделен күрсәтте. Идел-Кама картасында калын кызыл сызык белән шул кораб үткән сугыш юлын күрсәткәнсең, Пьяный Бор янында комиссар Николай Маркин белән бергә яуда әтиең һәлак булган елга култыгында һәйкәл-обелиск галәмәте ясап, траурлы кара рам эченә «1918 елның 1 октябре» дип язып куйгансың. Шул ук стенада кара тасмасына көмеш буяу белән «Юнгштурм» дип язылган бескозырка эленеп тора иде. Ул бескозырканы кечкенә малай вакытта син яратып кия идең, дип әйтте Разия апай һәм аны Кәбиргә бүләк итеп бик сөендерде.

Китап тулы шкафың белән танышканда Разия апай, бер тартмадан алып: «Менә монда Нурисламның миңа язган хатлары саклана, эчем пошкан чакларда мин аларны еш кына алып укыйм,— диде.— Ә менә болары, тасма белән аркылы торкылы бәйләнгән бу төргәктә фронтка килгән хатлар саклана. Нурислам аларны үзе белән алып кайтты һәм югалтмыйча сакларга кушты».

Шул чак мин өске конвертның адресы минем кулым белән язылган булуын күрдем һәм ул төргәктә барысы да минем хатлар икәнлеген шәйләп алдым. Шатлыклы дулкынланудан йөземә кызыллык йөгергәнен тойдым.

Көнозын аяк өсте йөреп Кәбир тәмам изрәгән икән. Разия апай белән мин синең бүлмәдә чөкердәшеп утырган арада ул бичаракай түр якта кырын яткан җиреннән эреп йокыга киткән. Аны уятмас өчен ул төнне без сездә куна калдык. Иртәгесен дә көн буе бергә булдык. Разия апай кайчандыр син тыңлаган маҗаралы әкиятләрне, Сак-Сок бәетен, Тукай шигырьләрен сөйләде. Кәбир аларны бик яратып тыңлады, кайберләрен кабат-кабат сөйләтте һәм, шул кыска гына вакыт эчендә Разия апайга иләшеп, күптән белгән әбиседәй, аны үз итеп өлгерде. Шуңа күрә ул, мин саубуллашып китеп барганда да көйсезләнмәде, Разия апай белән бергә миңа тәрәзәдән кул болгап озатып калды.

И, сүземнең иң кирәген онытa язганмын, әнием дә шуны әйтергә кушкан иде ләбаса: син анда, зинһар, сакланыбрак йөр, ялгыш авыр күтәреп-нитеп әле ныгып җитмәгән иңбашыңны кузгата күрмә.

Сиңа өчебез исеменнән дә хәерле теләкләр юллап һәм үбеп Мәрьямең.

Күз алмам, син нихәл анда, исәнлек-саулыкмы?

Мин монда капитан булырга ризалык биреп ашыктым бугай, аның моңарчы ничектер күреп җиткермәгән кыенлыклары, тынгысыз мәшәкатьләре бик күп, җаваплылыгы зур икән. Хәзер, капитан булгач, мин тәүлек буе вахта торам кебек: хәтта каютада ял иткән сәгатьләрдә дә пароходның һәр гудогына колак салып, кыен перекатларны үткәндә корпус астында су сайлыгын тоеп борчылып барам. Трюмнарда товар

ящигы ватылса да, пароход расписаниедән соңга калса да, берәр холыксыз пассажир ризасызлык белдерсә дә,— барысы өчен дә капитан җаваплы бит. Шуның өстенә, ярдәмчем Мидхәт агай укый-яза белми торган бер карт лоцман, аның өчен бөтен контора, исәп-хисап эшен үземә башкарырга туры килә. Күрер күзгә баһадир кебек зур таза гәүдәле агай булса да, үзе бик тә кабаланучан, юлда аз гына катлаулы хәл килеп чыкса, шундук аны-моны уйлау-шәйләү сәләтен югалта, караул... харап булабыз дип акырып, бөтен пароходта паника куптара. Аның каравы хатыны Гарифә түти молодец, гомер буе ире белән пароходта йөри-йөри остарып беткән, чын ирләрчә батыр йөрәкле хатын, эшне дә яхшы белә. Ире вахта торганда рубкада ыгы-зыгы чыкса, ул инде миннән алда менеп җиткән, тиешле чараны күрә башлаган була. Гаҗәп хәл, аның алдында карт лоцман үзе дә бик тиз тынычлана һәм, урынсызга каударлануы өчен уңайсызлангандай, мыек астыннан үзалдына нидер мыгырдана башлый. Шуңа күрә телгә чая штурвалчы кыз Җәмилә үзе юкта Мидхәт агайны «Мыеклы түти» дип йөртә... Берни кылып булмый, нужа кушкач, әнә шундый ярдәмче белән дә эшләргә туры килә.

Быел без затоннан чыкканнан бирле хәзергә һаман бер линиядә — Казан белән Уфа арасында йөри бирәбез. Минем өчен моның уңай ягы шунда, атна саен Казанда булганда синең хатларыңны алырга, улым Кәбир белән күрешергә мөмкинлек бар. «Ургыл» пристаньга якынайганда Разия апай белән Кәбир инде причалда булалар һәм безне кул болгап каршы алалар. Кәбир мине капитан күперчегендә күрүгә, пароход туктаганны да көтмәстән, балаларча түземсезлек белән кулындагы конвертын селки-селки: «Әнием!.. Менә сиңа хат. Нурис абыйдан килгән...»— дип, бар көченә кычкырып причалдагы халыкны көлдерә.

Монда безнең хәлләргә килгәндә, болай ярыйсы гына эшлибез, зарланырга урын юк шикелле. Июнь планын арттырып тәмамладык, расписаниене төгәл үтәп киләбез. Быел кызларны да, былтыргы кебек, адым саен өйрәтеп торасы юк, барысы да үз эшен белеп башкара.

Хәер, бар эш тә шома гына бара дип әйтү дә дөрес булмас, ара-тирә команда тормышында киртәгә сыймаган күңелсез хәлләр дә булгалый. Минем белән бергә вахта торучы штурвалчы кызыбыз Җәмилә Казаннан алып килгән төрле чүпрәк-чапракларны он, ярма кебек азык-төлеккә алыштырып маташканда беркөн Бирски пристаненда милициягә эләкте. Үз җаваплылыгыма алып кызны судка эләгүдән көчкә коткарып калдым. Соңынтын пароходта ныклап сөйләшкәндә бичара кызый үзенең гаебен аңлады шикелле. Бу алама эшен ул, өйдә ачлы-туклы яшәүче ятим энекәшләремә бераз ярдәм итәргә теләгән идем дип, аңлатты һәм бүтән һичкайчан алай эшләмәскә сүз бирде.

Соңгы вакытта мине тагын теге җырчы кочегар кыз Зәкия борчый башлады. Күрәм, кияү егетенең хыянәтен авыр кичерә, бичаракай. Ишкәксез көймәгә эләккән кеше кебек, нишләргә белми, күз алдында ябыга.

Ахыр чиктә түзмәдем, Зәкияне үзен генә очраткан бер арада:

— Син, сеңелкәем, артык газапланма... Алай җебеп төшәргә ярамый, кулга алырга тырыш үзеңне,— дип үгет биреп карадым.

— И, Мәрьям апай җаным, ярамаганын үзем дә беләм,— диде бичара, күз яшьләренә буылып.— Нишлим соң, бизеп булмый бит... Күңел ярамыйга карамый бит, һаман үзенекен итә, йөрәк яна.

Моңа каршы мин ни әйтергә белмичә аптырап калдым һәм мондый хәлдә акыл өйрәтеп, үгет-нәсихәт белән генә ярдәм итеп булмавын аңладым. Мәхәббәт тоташ шатлык кына түгел шул. Бәхетсез мәхәббәт әнә нишләтә, дәвалап булмый торган авыру кебек, кешене саргайтып киптерә, бөтен тормышын агулый. Җан яраткан, күңел тарткан яр бер генә була ул дип, тикмәгә җырламыйлар, күрәсең.

Менә язә торгач, кызып китеп, үзебезнең хәлләр турында тулы бер отчет килеп чыкты бугай. Син үзең хатларыңда эшең, тормышың, иптәш кызларың хакында күбрәк яз, барысын да беләсем килә дип әйткәнсең бит. Әгәр бу вак-төякләрне тутырып бик арыткан булсам, син, зинһар, гафу ит.

Чү, сиңа әйтергә тагын бер хәбәрем бар ич. Үткән рейстан соң Казанда торган чакны елгачылар клубында пристаньга Дәүләт Оборона Комитеты байрагын тапшыруга багышланган тантаналы җыелыш булды. Анда без дә катнаштык. Җәй буе эштән башы чыкмаган безнең кызлар өчен үзенә күрә бер бәйрәм сыман күңелле вакыйга булды ул. Кичәнең рәсми өлешеннән һәм концерттан соң, танецлар башланып китте. Госпитальдән савыгып чыккан яшь командирлар, сугышчылар безнең кызларны күп тапкырлар биергә чакырдылар. Шул арада кайбер җитезрәкләре хәтта хат язышырга вәгъдәләшеп, адреслар алмашырга да өлгерде шикелле.

Клубның буфет бүлмәсендә хезмәт алдынгылары хөрмәтенә кечерәк кенә чәй мәҗлесе әзерләгәннәр иде. Безнең пароходтан профорг Мәрфуга белән мине дә дәштеләр. Хөснулла да шунда, тәэминат начальнигы буларак, чәй мәҗлесен оештыручы шул икән. Өстендә өр-яңа зәңгәрсу бастон китель, җиңнәрендә сары укалы нашивка җемелди. Идарәдән килгән начальникларны зур тырышлык белән сыйлаганын күрсәң, исләрең китәр инде. Тәэминат эше килешкән күрәсең, күзгә күренеп симергән,ияк аслары сөтләч сыер җилене кебек салына башлаган. Берничә тост күтәргәннән соң битләре кызарды, чигә тамырлары бүртеп чыкты. Башта игътибар итмәгән кебек булса да, таралышырга кузгалганда бу мине бер читкәрәк алып китте дә:

— Карале, без бала-чага түгел,— диде.— Болай киреле-мырлы йөрүдә ни мәгънә, безнең уртак улыбыз бар бит. Давай, тагын бергә тора башлыйк...— Мин тыңларга теләмичә китә башлагач, беләгемнән тотып өстәде: — Туктале, серьезно сөйләшкәндә алай чәпчемә әле... Нәрсәсенә исең китте шул Исламның?.. Син аны сөттән ак, судан пакь дип беләсеңме? Аның мәхәббәт маҗараларын сөйләсәм, чынлап әгәр, чәчләрең үрә торыр...

— Тузга язмаганны сөйләмәгез! — дип, мин аны шундук кырт кистем.— Исергәнсез, юк белән саташасыз. Ул хакта миңа бүтән әйтәсе булмагыз.

Хөснулланың кызарып бүрткән битләре агарып китте, кашлары җимерелде. Әмма гадәти сабырлыгын җуймады, ярсып китмәде. Кешекара ишетүдән шикләнгәндәй, як-ягына тиз генә сагаюлы караш ташлап алды да әйтте:

— Ләкин белеп тор: үзем исән-сау вакытта мин барыбер законлы улымны әллә кемнәр кулына бирмәм... Мин моны болай гына калдырачак түгелмен.

Хәзер, авызым бер пешкәч, мин аның икейөзлелеген, явыз ниятле гайбәтче икәнлеген яхшы беләм, шунлыктан синең хактагы гайбәтенә аз гына да ышанмыйм.

Бу урында аның белән бәхәсләшү, ни дә булса исбат итү, аңлашу — мәгънәсезлек булыр иде. Мин бүтән берни әйтмичә, Мәрфуганы култыклап алдым да, пароходка кайтып киттем.

Менә шундый хәлләр, дускаем. Беләм, ул сүзендә торачак, аңа хас зәһәр үҗәтлек белән этлек итәчәк. Ләкин мин аз гына да курыкмыйм, хаклыгыма иманым камил.

Ярар, ул хакта калып торсын әле, сиңа әйтергә мөһимрәк сүзем бар. Колагыңа пышылдап кына: «Мин сине көннән-көн якынрак, үз итәм, тирәнтенрәк сөям»,— дип әйтәм һәм, ниһаять, сине табуыма, сине яратуыма шатланам.

Безнең кечерәк кенә китапханәбездә Александр Блокның бер томы бар. Сине бик юксынган минутларда шуны укырга яратам, ямансу уйларыма шуннан үземә аваздашлык табам. Бүген шунда: «... Только влюбленный имеет право на звание человека»,— дигән сүзләрне укып уйга калдым. Беренче карашка сәеррәк тоелса да, асылда бик дөрес әйтелгән бит. Мин моны үземнән беләм. Моңарчы мин кызыксыз, сыр-хау кебек, сүлпән тормышта яшәгәнмен. Тик синең белән табышкач кына, Блок әйткәнчә, яшәү шатлыгын тоеп яши башладым, үземнең чын мәгънәсендә бәхетле кеше икәнемне сиздем. Еллар авыр, кайгы-хәсрәтле булуга карамастан, тормышның матурлыгын хәзер мин ачыграк күрәм, кавышу хыяллары белән өметләнеп яшим.

Сине һәрчак юксынучы Мәрьямең дип белерсең.

Сөеклем, бердәнберем, менә икенче ай инде хат-хәбәрең юк. Сиңа ни булды? Бу билгесезлек безне авыр кайгыга салды, күңелдә борчылу көннән-көн арта бара.

Бу билгесезлеккә бүтән түзәр хәлебез калмады. Шушы хат белән бергә, хәлеңне хәбәр итүләрен сорап, командирыңа һәм икегез бергә фоторәсемгә төшкән хезмәттәш иптәшең Сурановка да язам. Чөнки әниең бик өзгәләнә, күз алдында бетешә, йөзенә карарга кызганыч.

Әлегә хәтле Уфа — Казан линиясендә эшләгәндә, атнага бер тапкыр булса да, мин аларны күрә идем, кулдан килгәнчә булышкалый идем. Соңгы вакытта, Иделнең түбәнге агымына йөри башлаганнан бирле, ул мөмкинлек тә кимеде, хәзер без Казанда элекке кебек еш булмыйбыз.

Бу көннәрдә Сталинградтагы хәлләрне, мөгаен, ишетеп беләсеңдер. Хәзер анда кыямәт көне: бөтен шәһәр, яр буендагы пристаньнар — барысы да ут, кара төтен эчендә, бомба, снарядлар өзлексез шартлаудан су өсте кайнап тора. Дөресен әйтим, беренче мәртәбә, барып төшкәч, башта бик курыктык, янар тау авызына эләккән кебек булган идек.

Шул утлы гарасат эчендә безнең гаскәрләр батырларча сугыша, һәр сталинградчы: «Безгә Идел аръягында чигенергә җир юк!» — дип, дошманның коточкыч басымына бирелмичә каршы тора. Безнең елгачылар да шунда: ут яңгыры астында баржаларга, пароходларга, баркасларга төяп Идел аша гаскәр һәм корал ташыйлар, причалларда янгын сүндерәләр, дошман уты астыннан яралы сугышчыларны алып чыгалар. Әмма шунысы гаҗәп: берсенең дә йөзендә курку-шүрләү галәмәте юк. Аларга карап, без дә кыюландык.

Хәер, беренче көнне анда безгә озак булырга туры килмәде. Төнге караңгыда алып килгән солдатларны һәм йөкләрне бушатып бетерүгә, пароходны җыештырырга да бирмичә, шундук причал тулы каты яралыларны төяргә керештеләр... Инде яктырып, каты бомбалау башлангапда, без хәтәр зонадан чыгып өлгергән идек.

Шулчак безнең «Ургыл»ны күрсәң, чын мәгънәсендә йөзмә госпиталь дип әйтер идең. Бөтен каюталар, коридорлар, хәтта палуба һәм трюмнар да яралылар белән тулы. Озата баручы врач һәм медсестралар каты авыруларга ашыгыч ярдәм күрсәтергә кереште. Безнең сандружиначы кызлар да шунда: яралыларны карашалар, аш-су пешерүдә булышалар. Эштән буш сәгатьләрдә үзем дә күбрәк алар арасында булам, каты авыруларның хәл-әхвәлләрен сорашам, юатырга, күңелләрен күтәрергә тырышам. Күпме харап булган яшь гомер, җимерелгән якты хыяллар... Үлем хәлендә ыңгырашып ятучы каты яралыларны, гомергә гарип калган яшь егетләрне күреп күңел тула, йөрәк сызлый.

Шундый күңелсез уйлар белән баш түнгән килеш коридор буйлап барганда күрәм: беренче класс салоны ишеге төбендә әлеге җырчы кызый Зәкия басып тора. Күзләре тулы яшь, елый-елый шешенеп беткән, бөтен гәүдәсе дер-дер калтырый.

— Ни булды,— мин әйтәм,— ник елыйсың?

Рәтләп сүзен дә әйтә алмый бичара.

— Үлем хәлендә... Ә-әнә шунда алып кереп киттеләр... Мине кертмиләр...— дип үкси бу.

Кемне алып кергәннәр, кемгә ни булган? Белеп сөйлиме, саташамы? Һич аңлап булмый. Тик бераздан, кызны тынычландырып сөйләткәннән соң гына, ниһаять, хәл ачыкланды. Зәкия бер командирга «су эчергәндә яралылар арасыннан кемдер аңа исеме белән Зәкия» дип эндәшкән кебек була. Иелеп карася, ни күрсен: идәндәге матрас өстендә газапланып яткан кызылармеец аның кияү егете Зәки икән, төшендә моның исемен әйтеп саташа икән. Күп кан югалтуданмы, бүтән сәбәптәнме, егет тәмам хәлсезләнгән, йөзенә үлем аклыгы кунган була.

Зәкия шундук тревога күтәрә, врачны, медсестраны аякка бастыра. Авыруны тиз генә операция өстәленә салып, ашыгыч ярдәм күрсәтәләр. Вакытында күрсәтелгән ярдәм егетне үлемнән йолып кала.

Иртәгесен ул йокыдан уянганда кризис инде үткән була. Егет акрынлап тернәкләнә башлый, кем аркасында исән калуын белеп, бик гаҗәпләнә, дулкынлана. Хәзер ул кәләшенә мең рәхмәтләр укый, бик үкенә, гафу итүен үтенә, диләр.

Мин еш кына шулай итәм: кайгылы уйлар белән ялгызым калмас өчен, юк эшне бар итеп дигәндәй, профорг Мәрфуганы дәштереп алып, икебез бергә вахталар арасында ярыш нәтиҗәсен тикшерәбез, яки затонга кергәч башкарасы ремонт эшләрен ачыклыйбыз. Мәрфуганың тырышлыгын, һәр эшне дәрт белән башкаруын, оптимистлыгын күреп, мин үзем дә ничектер җиңеләеп киткәндәй булам, күңелемдә ныклык тууын сизәм.

Шулай көннәрдән бер көнне команда арасында аның хакында механик ярдәмчесе Исәнбаев белән чуала, егет аңа гашыйк булган, өйләнергә җыена икән дип сөйләнә башладылар. Мин башта ышанмасам да, бер җае туры килгәндә, сүз ара сүз чыгып, аның үзеннән:

— Исәнбаев белән йөрешәсең икән, дөрес сүзме шул, әллә гайбәт кенәме? — дип сорадым.

— Аңа ник гаҗәпкә калдыгыз әле, дөрес булса, гөнаһ эшмени...— диде Мәрфуга, сүзне уенга борган сыман.— Сезнеңчә ничек, мин инде бер дә ир-ат күз салмаслык әбимени?!

— Юк, гайбәт итүдән түгел, дусларча якын күреп кызыксынуым гына... Исәнбаев бик төпле, акыллы егет.

— Якын күреп булса, мин дә дөресен әйтим... Исәнбаев әйбәт егет, мине үзенә кияүгә чыгарга соравы да бик дөрес. Турылыклы тормыш иптәше һәм балаларыма кайгыртучан әти булачагына да ышанам. Шулай да мин отказ бирдем, яшьрәк кызлар табарсың дип әйттем. Сигез ел буе бергә торган иремне, ике улымның әтисен алай тиз генә оныта алмыйм, зинһар, үпкәләмә дидем... Аннары үзегез дә күрәсез, хәзер андый эшләр белән маташа торган вакыт түгел. Киләчәктә, сугышлар бетеп, еллар тынычлангач, анда күз күрер әле.

Бу аңлашудан соң Мәрфугага ихтирамым тагын да артты, көнозын шуның тәэсирендә дулкынланып йөрдем... Тыштан кешегә сиздермәскә тырышсам да, мин үзем дә газаплы билгесезлек эчендә бит. Тизрәк Казанга кайтып җитеп, анда синнән килгән хатны алып укырга ашкынам.

Нурискаем, үлеп сагынам үзеңне, тел белән әйтеп аңлата алмаслык өзгәләнгән вакытларым була. Әмма ничек тә түзәргә, сагышымны кешегә сиздермәскә тырышам. Бик үзәк өзелгән минутларда эчтән генә көйләп йөрим:

*Бик сагындым, бәгырем,*
*Бик сагындым сине,*
*Әле дә ничек түзәм мин!*

Хуш, сау бул, җан кисәгем. Мәрьямең.

Нурисым, йөрәк парәм, ни булды сиңа, кайда син?..

Өченче көн хатыңны күрергә өметләнеп Казанга кайтсам, миңа аяусыз авыр яңалык — синең хәбәрсез югалуың турында әйттеләр. Хәер, мин моны причалга килеп җиткәнче үк, Кәбир белән Разия апайның яр буенда канаты каерылган кош кебек нәүмиз кыяфәттә басып торуларын күрү белән үк сиздем һәм пароходны көч-хәл белән китереп туктаттым.

Разия апай күп елаудан тагын да бетешкән, аягында көчкә басып тора иде. Минем каютага керү белән төптән киселгән тал чыбыгы кебек, диванга сыгылып төште һәм бераз хәл алгач кына, күз яшьләренә буыла-буыла әйтте:

— Нурислам харап булган, югалган... Ятим калдык ич...

Мин бу куркыныч хәбәрне башта бер мәл аңыма сыйдыра алмый тордым, кинәт миңгерәүләнеп киттем. Ниһаять, аңыма барып җиткәч, йөрәгем алынды.

— Юк, юк, мөмкин түгел, ышанмыйм...— дип, ачынып кире кактым.— Беренчедән, хәбәрсез югалу — ул әле харап булу түгел. Аннары ничек, нинди шартларда югалуын тиешенчә белешергә, ачыкларга кирәк. Кайдан белдегез, аны кем әйтте?

Сораштыра торгач, бу кайгылы хәбәрне Хөснулла килеп әйткәнен белдем. Ә аңа сезнең уртак танышыгыз — фронтта синең белән бергә фоторәсемгә төшкән иптәшең Суранов язып җибәргән, имеш. Разия апай сүзләренә караганда, болай да авыр кайгылы бу хәбәрне Хөснулла тагын да шомландырып әйткән, дошман тылына разведкага барган җиреннән Нурислам үзе кайтырга теләмәгән дип шик-шөбһә тарата башлаган. Хөсетле җаһил Хөснулланың тел төбе кая тартканын да, сәбәбен дә яхшы аңлыйм. Бер сүзенә дә ышанмыйм мин аның.

Хәер, Сурановтан хат алуы дөрес булуы да ихтимал. Тиздән аның безгә җибәргән хаты да килеп җитте. Әмма анда, Хөснулла әйткәнчә, сине гаепләү, шикләнү турында берни дә юк. Киресенчә, синең өчен якын дусларча бик борчылып, дошман тылына разведкага барганда эзәрлекләп килүче фрицларны тоткарлау өчен, калган җиреннән кайтмады дип көенеп язган. Хатның азагында, имза куйганнан соң, өстәп язылган тагын шундый юллар бар: «Безнең частьта Нурислам Алимжанович үзенең каһарманлыгы һәм зирәклеге белән танылган офицер, бик авыр хәлләрдә дә югалып кала торганнардан түгел. Бу юлы да бер җаен табар, иртәме-соңгы табылыр, исән-сау кайтыр дип ышаныйк».

Мин үзем дә шулай уйлыйм, Разия апайны да шул өмет белән юатырга тырышам. Бик читен миңа, хәлемне үзем генә беләм. Кеше алдында әллә ни сиздермәсәм дә, эштән буш сәгатьләрдә каютада ялгыз башым тәкатьсез булам, албасты каплагандай, тын кысыла, күз яшьләрем төер кебек тамагыма тыгыла. Өстәвенә Казанда кайгы-хәсрәткә баткан хәлдә калган Разия апайның газаплануын уйлап борчылам. Ул анда япа-ялгыз бит.

...Хәзер без, корал һәм гаскәриләр төяп, тагын Сталинградка барырга чыктык. Бер без генә түгел, анда каты сугышлар башланганнан бирле хәзер бөтен Идел, Кама флоты шул якка йөри.

Пароход пристаньда чакны гадәттә эш күп була, мәшәкать өстенә мәшәкать өстәлеп тора һәм шул ыгы-зыгы арасында кайгы-хәсрәт нечектер бераз басылган, арткы планга чигенгән сыман тоела. Ә менә хәзер, юлда барганда, эштән буш сәгатьләрдә каютада бер ялгызым калу белән күңел тула, берсеннән-берсе сагышлы, авыр уйлар борчый башлый. Мондый авыр сәгатьләрдә мин дәфтәр, каләм алам да, көндәлек язгандай, уйларымны, башымнан кичкәннәрне синең белән уртаклашам, шуның белән юанам.

Без монда барыбыз да фронт турындагы уйлар, фронт хәбәрләре белән яшибез. Кызыл почмакка кергән һәркем иң әүвәл стенадагы картаны карарга керешә. Ул картада фронт сызыгы Кара диңгез, Азов буйларыннан сузылып Дон далалары аша үтә һәм, йөрәккә кадалган канлы хәнҗәр кебек, очлы башы белән Сталинград янында Идел ярына килеп терәлә. Хәзер сугыш язмышы шунда хәл ителгәнен без һәммәбез дә яхшы беләбез һәм җиңү хакына бөтен тырышлыгыбызны куеп эшлибез.

Шул ук вакытта пароход тормышы үз юлыннан бара бирә, ара-тирә һич уйламаган-көтмәгән күңелсез хәлләр дә булгалый. Беркөн шулай рубкада вахтадашым Җәмилә (ул безнең артельчебез дә) штурвал көпчәге янында сүзсез генә күз яшьләрен агызып тора, тыны кысылгандай, әледән-әле авыр сулап куя. Мин борчылып сорашты ра башлагач, бичаракай кычкырып еларга ук кереште һәм көч-хәл белән:

— Бәла-бәла... Азык-төлек карточкаларымны югалттым...— дип әйтә алды.— Теләсә нишләтегез, мин гаепле...

— Ярар, бик өзгәләнмә,— дим, аны тынычландырырга теләп.— Илдә чыпчык ачтан үлми диләр, син дә ризыксыз калмассың. Уртак казаннан бер кешегә генә ничек тә өлеш чыгарырбыз әле.

— Үз карточкам гына түгел шул, бөтен команданыкын югалттым. Барысын бергә җеп белән бәйләп куйган идем... Ух, бар икән күрәселәрем...

Аның ник шулай өзгәләнеп елавын мин шунда гына абайлап алдым һәм, хәзер инде ни әйтергә белмичә, үзем дә исәңгерәп калдым. Бөтен команданы азык-төлексез калдыру уен эшмени?! Карточкасыз бер грамм азык алып булмаячак. Ай буе шул тикле халыкка нәрсә ашатмак кирәк... Ул карточкаларны Җәмилә чыннан да югалтканмы, әллә берәр комсызлык-фәлән бармы,— анысын кисеп әйтүе кыен. Акчага хирыслыгына, һәр тиенен саклап тотуына карап кына кеше өстенә гаеп ташлап булмый бит.

Һәрхәлдә, башны ташка орып булмый, ай-вай килеп ачыргаланудан мәгънә юк. Бер әмәлен табарга, бу авыр хәлдән ничек тә чыгарга кирәк.

Профорг Мәрфуга белән уйлашканнан, киңәшкәннән соң, хәзергә бу хакта командага аны-моны әйтмәскә булдык. Ә үзебез икмәк карточкаларын югалту турында администрация һәм профсоюз оешмасы исеменнән рәсми акт төзеп, икебез дә кул куйдык, ышанычлырак күренсен өчен, аны пароход печате белән расладык. Аннары Саратовта туктап торган арада шул документ белән пристаньның тәэминат бүлегенә ярдәм сорап мөрәҗәгать иттек. Анда кеше җанлы агайлар утыралар икән, безне игътибар белән тыңладылар һәм, пароходчылык идарәсенә телефоннан шалтыратып сөйләштеләр дә, Казан пристане исәбенә безгә шундук икмәк һәм башка ашамлыклар карточкасы бирделәр. Башта бик катлаулы күренгән бу проблема әнә шулай хәл ителде.

...Нурлы йөзем, синең эзсез югалуыңны мин берничек тә аңыма сыйдыра алмыйм, һаман синең хакта уйлап йөрим. Бераз эштән бушап каютада үзем генә калгач, менә тагын хатымны дәвам итәм.

Бу юлы без Сталинград зонасына көндез барып төштек. Алып килгән хәрбиләрне һәм йөкләрне шәһәрдән шактый читтә, Ахтуба тармагына кереп сөзәк яр буена бушатырга приказ булды. Чөнки ике ярусл ы «Ургыл» белән көпә-көндез шәһәр пристанена барып туктау — күрәләтә ут астына керү булыр иде. Фашист козгыннары хәтта монда да ябырылып килеп җиткәннәр иде. Зенитчыларга рәхмәт, якын да җибәрмәделәр.

Моннан караганда кое төтен белән капланган Сталинград үзе күренми диярлек, андагы каты сугышлар авазы, өзлексез күк күкрәгән-

дәй, шомлы гөрелдәп тора, әлсерәткеч эссе һавада әледән-әле шартлау дулкыннары яңгырап үтә. Йөкләрне бушатып бетергәннән соң төнге караңгыда без дә шул ут эченә барып кердек.

Ярым җимерек дебаркадер каршында яр буе тулы яралы халык. Озын-озак маташыр чак түгел, вакытның һәр минуты кадерле. Килеп туктау белән тиз генә трапны рәтләдек тә, шундук кешеләрне утырта башладык. Минем белән бергә пролетта басып торган эшелон начальнигы үз аяклары белән йөри алырлыкларны кергән берен өченче, дүртенче классларга, трюмнарга җибәрә торды; носилка белән күтәреп кертелгән һәм ашыгыч ярдәмгә мохтаҗ булган аеруча каты яралыларны медпунктка — салонга якынрак булган каюталарга, коридорларга урнаштырдык. Күп дигәндә кырык-илле минут эчендә бөтен пароход халык белән шыгрым тулды. Хәтта аскы палуба, терраса һәм коридорларда атлап йөрер урын калмады диярлек.

Инде бар эш тәмамланып, чалкаларны ычкындырыр вакыт житкәч кенә каршы тау артыннан ыжгырышып немец самолетлары килеп чыктылар һәм безнең причалга бомбалар яудырып үттеләр. Бәхеткә каршы, бомба безгә тимәде. Шулай да берсе, янәшә генә төшеп, без туктаган, инде болай да ярым җимерек агач дебаркадерны челпәрәмә китерде, шартлау дулкыннары, колак пәрдәсен чатнатып, китереп бәрелде дә бөтен пароход каты сикереп куйды... һавага күтәрелгән ләмле су баганасы һәм такта кисәкләре безнең өскә ишелеп төште. Яшеренбатырын түгел, дөресен әйтим, бер мәл исәңгерәп тордым, шартлау дулкынының җиленнән күперчек өстеннән чүт егылып төшмәдем. Бу коточкыч шартлау башкаларны да нык куркытты бугай, рубка астындагы террасада тәртипсез ыгы-зыгы, шау-шу кузгалды һәм кемдер җан ачысы белән:

— Караул, харап булдык... Батабыз...— дип бар көченә кычкыра-кычкыра күперчеккә йөгереп менде.— Чынлап әйтәм, батабыз, су палубага җитте... үзем күрдем...

Курыкканга куш күренә диләр. Янәшәдә генә бомба шартлаудан күтәрелгән су баганасы караңгыда куркып калган матроска батабыз кебек тоелган булса кирәк. Ул дөрестән дә бик курыккан, күзләре акайган, бөтен гәүдәсе бизгәк тоткан кебек калтырый иде.

Штурвал көпчәге янында торучы Җәмилә аны, әле генә танығандай, бер мәл шаккатып карап торды:

— Үскәнем, син монда ялгыш менгәнсең... Батып харап буласың килмәсә, әнә шунда йөгер...— дип, ярга таба төртеп күрсәтте.

Куркудан әле һаман айнымаган мескен егет иронияле кинаяне аңламады, як-ягына тиз генә каранып алды да:

— Әй... Ашыгычлык белән ялгыш менгәнмен...— дип траптан йөгереп төшеп тә китте.

— Күр инде бу җен өшкергән нәрсәне...— Җәмилә аның артыннан суганлы-борычлы сүзләр әйтеп, мыскыллы көлеп калды.— Күр инде бу куяннан туган бәндәне. Харап булдык, батабыз, имеш...

Әмма Сталинград гарәсатын кичергән яралылар моңа әллә ни әһәмият бирмәделәр. Хәл ачыклану белән пароходта тынычлык урнашты. Мин дә тиз генә үземне кулга алдым һәм шундук аска шалтыратып, тизрәк машинаны эшләтергә команда бирдем. Анда сөйләшү трубасы янында механик Тамара Федоровна үзе тора икән. Гадәттә сабыр холыклы, һәрвакыт ягымлы механик бу юлы танымаслык булып үзгәргән кырыс тавыш белән:

— Юк, машина эшләрлек түгел,— диде.— Безнең монда ут сүнде. Кайдадыр труба чатнады бугай, сызгырып пар чыга. Аварияның кайда икәнлеген ачыклагач, нәтиҗәсен хәбәр итәрбез.

— Хәбәр итәрбез түгел... Мөмкин булмаса да, хәзер үк эшләтегез!.. Ишетәсезме, самолетлар кабат әйләнеп килгәнче бу хәтәр упкыннан тизрәк ычкынырга кирәк. Юкса, эш харап...

Югарыда ниләр барын, хәлнең ни дәрәҗәдә куркынычлыгын түбәндә эшләүче механиклар күрми бит. Тамара Федоровнаның машина эшләтерлек түгел дип сөйләнүе, мөгаен, шуннан булгандыр. Мондый хәтәр хәлдә машинаның чыннан да сафтан чыккан булуы да бик ихтимал. Әмма минем командам катгый яңгырады бугай. Моны сизеп алган механик:

— Аңлашылды! Мөмкин булмаса да, машинаны эшләтермен...— дип приказны кабатлады һәм пароход шундук причалдан кузгалып китте.

Ашыгыч кузгалып бик дөрес иткәнбез. Берничә минуттан фашист козгыннары өерләре белән тагын килеп чыктылар һәм әле генә «Ургыл» торган причалны котырынып бомбага тота башладылар. Тончыктыргыч ачы төтен катнаш шартлау дулкыннары безнең өстән өермәдәй ыжгырып үтте.

Шул кузгалудан без туктаусыз бар көчкә бара бирдек. Дүрт йөздән артык яралы тулы пароходны һәлакәттән саклап калу өчен төн карасы астында сугыш зонасыннан мөмкин кадәр ераграк китеп өлгерергә кирәк. Чөнки дошман авиациясе Сталинград белән генә чикләнми, аннан шактый ерак пристаньнарны да еш кына бомбага тота, килү юлларына йөзмә миналар ташлый.

Агымга каршы бик акрын барабыз кебек тоелган минутларда мин механикка шалтыратып, парны җәлләмәскә, машинаны катырак эшләтергә команда бирәм. Ә өлкән механик Тамара Федоровна, киресенчә, тизлекне акрынайта бара, әледән-әле шалтыратып, тизрәк якорьга туктарга, машинаны кararга рөхсәт сорый. Ниһаять, аның түземе бетә, таң алдыннан ул үзе рубкага күтәрелә һәм майлы кулларын сөртә-сөртә ишектән керүгә:

— Менә үзем менеп сөйләшергә мәҗбүр булдым, бүтән барыр хәл юк. Аңлагыз, хәзер үк туктарга кирәк,— ди ул, ялварулы таләп белән.— Причалда бомба шартлаганда какшаган болтларны нығытмыйча бүтән барып булмый, югыйсә елга уртасында бөтенләй туктап калуыбыз ихтимал... Аннары корпуста кайдадыр тишек булса кирәк, машина бүлегенә кергән суны насос бушатып өлгерә алмый...

Шул тикле ялварып сорамаса да, хәлнең мөшкелләгән мин күрәм, бу эшне бүтән сузарга ярамаганлыгын да аңлыйм. Аннары без инде шактый ерак китеп өлгергән идек. Эшелон начальнигы лейтенант Габбасов белән киңәшкәннән соң, елганың сул ярындагы өянкеле култыкта якорь салып, какшаган механизмнарны бераз нығытырга, корпус тишекләрен ямарга керештек.

Бераздан, инде эш бетте, хәзер кузгалып китәрбез дигәндә бәлаңең тагы да хәтәррәге — пар казанынннан топкага су саркып керүе мәгълүм булды. Үзең беләсең, аны туктатыр өчен бөтен парны бушатып казанны, топканы суытырга һәм тик шуннан соң гына ремонтлап, яңадан пар күтәрергә мөмкин. Моның өчен кимендә бер тәүлек вакыт кирәк бит.

Дөресен әйтим, нишләргә, нинди чара күрергә белмичә, барыбыз да хәвефкә төштек. Ә өлкән механигыбыз Тамара Федоровна бер мәл уйланып торганнан соң үзенә хас тәвәккәллек белән форсунканы сүндерде, кранны ачып казандагы пар басымын бераз киметте. Аннары сырма фуфайка, чалбар, колакчынлы бүрек, бияләй киде дә, топка эченә кереп торбаларны ремонтларга тотынды. Адәм түзгесез эсседә фуфайкасы көйри башлагач, без аны тартып чыгарып, өстенә су койдык. Соңгы мәртәбә кергәннән соң, инде эшен тәмамлап, топка эченнән

чыкканда аның киемнәре генә түгел хәтта каш, керфекләре дә яртылаш өтелгән, борын очы, битләре пешкән иде.

Моны күреп таң калган эшелон начальнигы лейтенант Габбасов тәэсирләнүен тыя алмыйча:

— Молодец, чын фронтовикларча булды бу!.. Мондый батыр йөрәкле механик белән утлар-сулар берни түгел...— дип мактады һәм тиз генә Тамара Федоровнаны машина бүлегеннән күтәреп чыгып, врач карамагына тапшырды.

Ә без шундук юлга кузгалдык.

...Көндезге вахтадан соң бераз черем итеп алмакчы идем. Юк, күңел тыныч түгел. Күзгә йокы керми, борчулы уйлар кайный. Менә торып утырып сиңа язуымны дәвам итәм.

Хәзер без юлда, пароход тормышы акрынлап үз эзенә керде. Төшке аш вакытында, күрәм, үткән төнне генә Сталинград гарасатын кичергән кызлар инде тынычланганнар, берни дә булмагандай, өстәл янында шау-гөр килеп утыралар. Әнә ак халат, цилиндр кебек зур калпак кигән, колакларына асылташлы алка таккан мөлаем йөзле кок Ольга Казакова камбуз тәрәзәсе янына килеп баскан берәүне, гадәтенчә, кунакчыл елмаеп каршылый һәм тәлинкәгә аш салып биргәндә әйбәт аппетит теләп яки дусларча берәр ягымлы шаян сүз әйтеп кала. Менә тәрәзә янына боцман Мәрфуга килеп баса, ул, күзләренә ышанмагандай, ишек ягына карап ала да:

— Чү, ник әле син бүген үзең генә, Исәнбаең кермәдемени?!— дип гаҗәпләнгән була.— Гадәттә сез гел бергә ашыйсыз бит, шуннан гына әйтүем...

— И, Ольга җаным, ул җәһәттән син үзең дә бер дә кимен куймыйсың ләбаса,— диде Мәрфуга, шундук повар кызның үзен дә дусларча чеметтереп.— Бая монда су эчәргә кергән сары мыеклы яшь офицер белән бик мутланып торучы син түгелме? Чынлап әгәр, шаклар каттым, кай арада лейтенантның башын әйләндереп өлгергәнсең. Менә бу чын сихерче икән, мин әйтәм, хәтта көнләшеп куйдым үзеңнән...

Барысы да, чәй эчүләреннән туктап, дәррәү көлеп алдылар. Бу көтелмәгән төрттерүдән каушап калган кокның болай да алсу битләре тагын да кызарып китте.

...Тормыш дигәнең гаҗәп нәрсә, мең төрле вак-төяк мәшәкатьләре, кайгы-хәсрәтләре, мәхәббәт-нәфрәтләре белән үз юлыннан бара бирә. Мин моны кичә телгә алып үтелгән повар кыз Ольга Казаковага гаҗәпләнүдән әйтүем. Боцман Мәрфугага ашханәдә төрттерүе нигезсез булмаган, соры мыеклы лейтенант Габбасов кыска гына вакыт эчендә дөрестән дә Ольга белән дуслашып, бер-берсенә гашыйк булганнар икән.

Бүген кичке аштан соң ремонт эшләренә затонга заявка язып утыра идем. Ишекне шакылдатып каютага Ольга белән әлеге лейтенант Габбасов килеп керделәр һәм, әйдә син башла, әйдә син әйт дигәндәй, бер-берсен әйдәкләп, хәрәкәтсез калдылар. Алар икесе дә шат йөзле һәм никтер каушаганнар иде. Сталинградта хәтәр ут астында яралыларны пароходка төяү вакытында кыю командалык иткән яшь лейтенант, ниһаять, кыяр-кыймас телгә килеп:

— Мәрьям Вәсилевна, зинһар га-гафу итегез,— диде.— Б-без зур үтенеч белән... Сездән рөхсәт сорарга кердек...

Әле берни дә аңламыйча мин үзем аптырап калдым:

— Нинди рөхсәт, ни өчен гафу итәргә?!

— Эш шуннан гыйбарәт, Ольга белән без бер-беребезне яратабыз,— диде Габбасов, кыюлана төшеп.— Ягъни без өйләнешергә булдык. Иртәгә Казанга кайткач, мин Оляны әниемә күрсәтергә, аның фатихасын сорарга алып барам.

— Әгәр бер-берегезне чынлап сөйсәгез, рәхим итеп, өйләнешегез... Мин, чит кеше, бу эштә сезгә каршы килергә хакым юк...

— Юк, Мәрьям Васильевна, сез чит кеше түгел... Ольганың этисе-әнисе дә, якын туганнары да юк, ул кечкенәдән ятим, балалар йортында үскән бит. Ул, сез рөхсәт итсәгез генә миңа кияүгә чыгам, ди.

— Мәрьям Васильевна, мин сезне, бертуган апам кебек якын күрәм, ихтирам итәм,— дип, Ольга үзе миңа килеп сыенды.— Сез дә миңа туган апам булыгыз. Даутка кияүгә чыгарга фатихагызны бирегез.

Ольганың мине туган апасыдай үз итүен сизеп килсәм дә, эти-әнисез үскәнен белми идем. Менә хәзер, шулай олылап, киңәш-фатиха сорап кергәч, ул миңа тагын да якынрак булып китте. Егете дә төпле, тәүфыйклы күренә, төскә-биткә дә чибәр генә. Үзләре инде аңлашкан, килешкән булгач, мин ни әйтим?

— Алайса ярар, хәерле сәгатьтә булсын... Сезгә бәхетле тормыш телим,— дидем.— Шулай да күңелемдә булганын әйтим: сез бер-берегезне бик аз беләсез әле, ашыкмыйсызмы?.. Әнә шул борчый мине. Аннары күрәсез, елларның да бик авыр чагы.

— Ольга да шуны әйтә: бер-беребезне әле аз беләбез, вакыты да ул түгел, дөньялар иминләнгәнне көтик, ди... Әйдә шулай итик, мин ашыктырмыйм. Киләчәктә гомерлек яр булырга ныклап сүз куешсак, ярәшсәк, миңа шул җиткән.

— Дөресен әйтәсең, шулай эшләгез... Синең әниең дә хәер-фатыйха биргәч, шунда кияү-кәләш булырсыз, күгәрченнәрем.

Менә шулай кодагый-капитан булып киттем мин.

Тагын шунысы гаҗәп; соңгы вакытта безгә фронтлардан күп хат килә башлады. Бөтенләй күрмәгән-белмәгән сугышчылар, командирлар эшебезне мактап, уңышлар теләп, кайберләре кызлар белән якыннан танышырга, хат алышырга теләп язалар. Башта бу хәлгә бераз аптырап калган идек. Соңыннан шул мәгълүм булды: безнең команда турында хәрби газетада очерк басылып чыккан, фронтовиклар безнең тормышны, эшебезне шуннан укып белгәннәр икән. Ул хатларга каршы безнең кызлар бик теләп җавап язалар, кайберләре арасында хәтта якын дуслык җепләре дә ялганып килә бугай.

*

...Күз нурым, синнән һаман берниндн хәбәр юк, без һаман кайгы-хәсрәттә, сине көтеп яшибез.

Бу юлы Казанда торган көннәрем бик ачынулы һәм ыгы-зыгылы үтте, җан теткеч әшәкелек белән миңа тагын күзгә-күз очрашырга туры килде.

Рейстан кайтып кергәндә синнән берниндн хат-хәбәр килмәве зур бер авырлык булды, болай да түнгән кайгылы башымны тәмам миңгерәүләндерде.

Аннан бераз айнырга өлгермәдем, көтмәгәндә пароходка әлеге җан көеге Хөснулла Каюмов килеп керде. Үзе белән бергә конторадан ревизор һәм бер милиционер да алып килгән. Бик ашыккан чагыбыз иде, пристань белән бәйле эшләрне тиз генә бетереп, Аракчино затонына пар казанын чистартырга, Сталинградта ватылган механизмнарны ремонтларга, корпус тишекләрен яматырга барырга ашыга идек. Хөснулла безне туктатты, профорг Мәрфуга белән артельче Җәмиләне һәм мине ашыгыч рәвештә кызыл почмакка чакыртты да:

— Өчәү бергә бөтен команданың айлык паегын мыштым гына үзләштерүче шайка менә шушы инде, оят түгелме сезгә...— дип, безгә җикеренергә тотынды һәм портфеленнән бер кәгазь тартып чыгарды.— Азык-төлек карточкаларын югалтканнар, янәсе. Шул хакта акт төзеп, алдау юлы белән Саратовта яңа карточкалар алгансыз. Менә ул акт, рәсми рәвештә кул куелган. Моны болай гына йом[illegible] алып булмый, өчегезне дә катгый җавапка тартырга туры кил[illegible]

Без ни әйтергә, ничек акланырга белмичә гаҗиз калдык. Артельче Җәмилә кычкырып еларга тотынды:

— Капитанның да, боцманның да монда катнашы юк. Ант итеп әйтәм, икмәктер менә, мин югалттым, мин генә гаепле...

— Җитте, шаулама, анысын милиция ачыклар.— Каюмов портфеленнән тагын бер кәгазь чыгарып салды.— Менә прокурордан ордер, бу милиционер пунәтәйләр белән хәзер өчегезнең дә каюталарын тентер. Кладовая ачкычларын миңа бирегез, хәзер үк ревизия ясатабыз.

Каюмов, натурасы белән кулы үзенә кәкре кеше, бик ихтимал, бу очракта безне чынлап та хәрәмләшкән дип уйлагандыр. Һәрхәлдә аның шуңа ныклы ышануы һәм, форсаттан файдаланып, миннән үч алырга ниятләнүе ачык сизелә иде.

Бу нахак гаепләүне ишетү ифрат кыен һәм бөтен команда алдында оят булса да, тешләрне кысып түзәргә, кызарырга туры килде. Чөнки безнең гаепле түгеллегебезне исбат итәрлек, акланырлык бернинди дәлилебез юк.

Каюмов әйткән сүзендә тәки торды. Каюталарны тентү һәм ревизия ул көткән нәтиҗәне бирмәсә дә, барыбер безнең эшне тикшерү органнарына тапшырды. Мәгълүм ки, тикшерү астындагы кеше капитан булып эшли алмый бит. Затонга ремонтка кергәннең иртәгесен миңа алмашка бүтән капитан — инде күптән ялга чыккан такыр башлы бер мәзәкчән агай килде.

Безнең эшне ашыктырырга, пароход затонда торган вакытта ачыклап бетерергә кушылган икән. Шул ук көнне тикшерү башланды. Мин яңа капитанга пароходны тапшырган арада команда членнарыннан байтагы, шул исәптән Җәмилә белән Мәрфуга да инде допроста булып өлгергән, һәркайсы югалган карточкалар турында үзе белгәнен сөйләгән иде. Тик шуннан соң гына миңа чират җитте.

Тикшерүче — ярым хәрби формадан киенгән, саргылт кыска чәчен артка яткырып тараган урта яшьләрдәге хатын — бик вакчыл һәм бәйләнчек булып чыкты, казына-казына нервларны талкып бетерде. Ул допрос протоколына кул куйдыргач та тәгаенләп берни әйтмәде. «Тикшерү нәтиҗәсен прокурор раслаганнан соң үзем хәбәр итәрмен»,— диде дә, йөрәккә шом салып, килгән юлыннан китеп барды.

Аның артыннан мин дә барлы-юклы әйберләремне чемоданга тутырып пароходтан китәргә җыена башладым. Елдан артык бергә эшләгән, шатлыгын-кайгысын уртаклашып яшәгән бертуганнардай якын иптәшләрдән аерылып китү җиңел булмады. Кызларым да бик көенеп, әгәр суд була калса, бөтен командабыз белән сезне яклап чыгачакбыз дип озатып калдылар.

...Бәла ялгыз йөрми, диләр.

Минем белән дә шулай булды. Команда белән саубуллашып пароходтан чыгып барганда таныш түгел бер яшүсмер кыз килеп мине яр өстендәге цехка телефонга чакырды. Барып тыңласам, безнең квартирадан синең әниең шалтырата икән.

— Уф, көчкә эзләп таптым үзеңне...— диде ул, авыр сулап.— Мәрьям җаным, хәзер үк өйгә кайтып җит. Әтиеңә әллә ни булды... Кәбир белән мин барып кергәндә ул өстәл янында утырган җиреннән кинәт гырылдап...

Инде байтактан бирле эти йөрәк өянәге белән азаплана, берничә мәртәбә больницада дәваланып, үзе әйтмешли, «моторын» төзәттереп чыкканы да бар иде. Разия апай сүзен әйтеп бетерә алмыйча, үксеп елый башлау белән йөрәгем жуу итеп китте, бу юлы хәлнең хәвефле икәнлеген шундук сиздем. Кинәт бөтен барлыгымны курку биләп алды. Ни булганын ачыклап сораштырырга телем әйләнмәде, дөресрәге, батырчылык итмәдем. Хәзер кайтам дип әйттем дә шундук юлга чыктым.

Хәлбуки, күңелем сизеп хәвефләнгәнмен икән. Кичкырын мин кайтып кергәндә өй тулы кеше, якын танышлар, техникум кешеләре җыелган; әти, әләрәк кенә йокыга талган кебек, үз караватында ак мендәр өстендә чалкан ята иде. Матвей Михайлович аның хәрәкәтсез кулларын кушырып куйгач кына, әтинең инде үле икәнлеге аңыма барып җитте.

Шунда минем зиһенем чуалды, күз алларым томанланды. Аннан соң булган хәлләр: иртәгесен әтине җирләү, дус-ишләр һәм күрше-күләннең кайгымны уртаклашулары, юатулары — һәммәсе дә саташулы авыр төш сыман күз алдымнан уздылар.

Мин әнидән бик яшьли калганмын. Әтием сөйләгәннәрдән аның гражданнар сугышы вакытында Идел хәрби флотилиясе йөзмә госпиталендә медсестра булып хезмәт иткәнен беләм, әмма үзен бик тонык төсмерлим. Шулай да ятимлекне белмәдем. Мине үгилектә калдырмас өчен, әтием бүтән өйләнмичә, тол яшәде, мине үзе кадерләп үстерде. Шуңа күрә дә аның үлеме минем өчен гаять зур югалту, бик авыр кайгы, әледән-әле күзләрем яшьләнә. Андый минутларда улым Кәбир, уенынан туктап, битләремне сөртә, әнием, елама, дәүәти урынына мин сине үзем яратырмын, һичкемгә рәнҗетмәм дип, үзенчә юаткан була.

Күрәм, Разия апай да минем өчен җан атып йөри. Әтине җирләгәннән бирле бу көннәрдә ул һаман бездә вак-төяк эш, төрле сүз белән мине мавыктырырга, хәсрәтле уйларны оныттырырга тырыша.

...Болай йончыткыч кайгы-хәсрәткә чумган хәлдә әле кайчандыр буласы судны көтеп көннәр буе өйдә утыруы бик авыр. Кая да булса эшкә урнашырга, ни беләндер шөгыльләнергә, хәрәкәтләнергә кирәк...

Әнә шундый уйлар белән бүген иртән Аргы Устьега төштем һәм, паромда аргы якка чыгып, кайчандыр әти белән бергә йөргән яр буйларыннан үттем, Ослан тавы өстеннән чал Иделгә, мәһабәт Кремль диварларына, шәһәр урамнарына гомеремдә беренче мәртәбә күргәндәй озак карап тордым.

Мондый киеренке вакытта артык шикләнүчән буласың икән. Иртән өйдән чыкканда эш эзләргә уйлаган булсам да, пристаньда кадрлар бүлегенә керергә дә, техникумга барырга да ояладым. Күргән-белгән кеше миңа нәфрәт белән, гаеп итеп карар кебек тоелды.

Ахыр чиктә мин бүген беркая да бармаска, прокуратурага кереп, эшебезнең барышын белешергә дә, өйгә кайтып китәргә булдым. Теге чакны бездән допрос алган караңгы чырайлы тикшерүче хатынның каядыр ашыккан чагына тарыдым бугай, мин барып кергәндә ул кабинетыннан чыгып килә иде.

— Мин бит сезне кичкә чакырткан идем, ничек болай ашыгып киләсе иттегез? — диде ул, ризасызлык белән. Аннары, мин бернинди чакырусыз үзем эшебезнең барышын белешергә килүемне әйткәч, ул кире борылып бүлмәсенә керде.— Мин дә сезне шуны әйтергә чакырткан идем. Сез килгәнсез икән, рәхим итеп утырыгыз, әйдә сөйләшик.— Ул өстәл өстендәге сары тышлы делоларның берсен ачып, иң азактан теркәлгән кәгазьне тиз генә күздән кичерде дә әйтте: — Озын сүзнең кыскасы шул: гаебегез расланмау сәбәпле, прокурор сезнең эшне туктатырга, тәэминат бүлегеннән кергән материалны нәтиҗәсез калдырырга карар чыгарды. Чөнки карточкаларның югалу фактын җинаятьчел максат белән артельче урлаган, профорг белән сез шуны яшереп калган дип инкриминировать итәргә, ягъни кемне дә булса җинаятьтә гаепләргә нигез тапмадык. Тикшерү нәтиҗәсе пароходчылык идарәсенә хәбәр ителде... Ә артельче кызыгызга гамьсезлеге өчен үз властегыз белән шелтә бирергә мөмкин. Киләчәккә сабак булыр. Менә бар әйтер сүз шул. Борчыган өчен гафу итегез. Бу күңелсез хәлне уңышлы ерып чыгу белән котлыйм сезне.

Бер көн затонда сорау алганда артык рәсми, бәйләнчек күренгән тикшерүче хатын күз алдында иң ягымлы кешегә әверелде. Өстемнән авыр йөк төшкәндәй җиңел сулап куйдым. Шатлыклы дулкынлану белән:

— Гадел булуыгыз өчен сезгә бик зур рәхмәт...— дип тикшерүченең кулын кыстым.

Тикшерүче яныннан мин, яңа гына анадан туган бала кебек, бүтән кеше булып, адәм күзенә туры карарлык хәлдә кыюланып чыктым.

Өйгә кайтып керсәм, анда пароходтан артельче Җәмилә килгән, бик җанланып Кәбир белән уйнап утыра. Мине күрүгә тантаналы тавыш белән хәбәр итте:

— Мәрьям Вәсилевна, шатлык... Югалган карточкалар табылды...

Колакларыма ышанмагандай:

— Чынлапмы, безнең карточкалармы? — дип сорадым.— Ничек табылды, кайдан килеп чыктылар?..

— Мин аларны Куйбышевта йөзмә магазиннан азык-төлек алганда төшереп калдырганмын. Шуннан почта белән җибәргәннәр... Менә алар, үзем теркәп куйганча, берсе дә югалмаган...

Дөресен әйтим, үзем дә бик сөендем. Күзем белән күреп торсам да, әле һаман ышанмаган кебек, карточкаларны кулым белән капшап, актарып карадым.

Үз чиратымда мин дә Җәмиләгә әле генә тикшерүче янында булуымны һәм безнең эшнең туктатылуын әйттем. Аннары без, күңелендә шик калмасын дип, ул карточкаларны конверты, хаты белән шундук тикшерүчегә илтеп тапшырдык. Болай эшләү башта миңа ничектер балаларча кылану, инде эш туктатылганнан соң артык ваклану булыр сыман инде. Тикшерүче исә, киресенчә, хуп күрде.

— Азык-төлек карточкаларын безгә китереп бик дөрес эшләгәнсез,— дип хәтта мактап куйды.— Югыйсә тәэминат начальнигы, безнең нәтиҗә белән килешмичә, җинаятьчеләрне яклыйсыз дип ризасызлык белдергән иде. Менә хәзер, бу карточкаларны күрсәткәч, бернинди җинаять юклыгын, без хаклы икәнлекне ул да танырга мәҗбүр булачак.

...Менә мин тагын үз «Ургыл»ымда, пароходчылык идарәсеннән алынган телеграмма-приказ белән үз урыныма кайтып, яраткан эшемә керештем. Хәзер «Ургыл»ның тышкы күренеше элеккечә тоташтан зәңгәрсу-ак түгел, ә яшькелт-сары төскә ала-кола чуарлап буялган һәм сирәк урманлы тау битенә охшап калган. Моны хәрби командование кушуы буенча маскировка максаты белән шулай эшләгәннәр. Хәзер Иделдә бөтен флот шундый төскә буялды.

Команда кызлары мине шатланып каршыладылар. Аларның җылы исәнләшүләрен күреп күңелем нечкәреп китте. Бу эчкерсез якынлыкны минем урынымда калып торган карт капитан да сизгән булып чыкты.

— Сезне пароход командасы галәмәт якын күрә икән,— диде ул, мине мактап.— Тиз кайтып бик әйбәт иткәнсез, чөнки сизәм, саулыгым чамалы, иске баржа кебек, шыгырдап, ыңгырашып кына йөрим... Алмашка кеше юк дип, бик зинһарлап сорагач кына килүем иде.

Кешенең уңганлыгы, эшкә тырышлыгы бер караудан күренә бит. Капитан агай, минсез затонда торган бер атна дәвамында пар казанын чистартудан тыш, команда көче белән корпус һәм машинаны ремонтлатып өлгергән, пароходны тышкы яктан буятып, яп-яңа төскә керткән. Моның өчен чын күңелдән рәхмәт әйттем үзенә.

Команда тормышында тагын бер яңалык мин пароходка кайткан көнне булды. Шуның алдыннан гына без — боцман Мәрфуга белән мин — койрык якта яңа ремонтланган шпильне эштә сынап маташа идек. Шул мәлне алгы пролеттагы кызлардан берсе:

— Әй, боцман!..— дип кычкырды.— Монда чык әле, әнә анда сине сорап ниндидер солдат килгән...

Каерылып карасак, пароходтан ярга сузылган такта трапта чынлап та баһадирларча киң җилкәле бер солдат елмаеп тора: ул кызыл йолдызлы пилоткасын көяз егетләрчә чак кына кыңгыр салган, гимнастеркасының буш җиңен бил каешына кыстырган иде.

Мәрфуга исә аны күрү белән, тораташ кебек катты, кинәт хәрәкәтсез калды, төсе китте, бизгәк тоткандай иреннәре калтырый башлады. Ниһаять, ул телгә килде:

— Сәлим бәгырем, чынлап син ич...— дип кычкырып җибәрде һәм абына-сөртенә солдат янына йөгерде.

Мәрфуганың сугышта үлде саналган иренең көтмәгәндә кайтып төшүе бөтен команда өчен күңелле бәйрәмгә әверелде, яраткан боцманыбыз өчен барыбыз да ихлас күңелдән сөендек. Кичен кызыл почмакта җыелып, фронтовикның үзен дә сөйләттек, күп төрле сораулар белән йөдәтеп бетердек. Сәлим көр күңелле, бик җор солдат икән, сугышта күргәннәрен, төнлә дошман тылында каты яраланганнан соң, партизаннар землянкасында кулын ампутацияләүләрен берниндн сыкрану-зарсыз сөйләп барыбызны да дулкынландырды. Арадан кемдер бер кулсыз кыен түгелме дип кызыксынгач, Сәлим җор кешеләргә хас шаярту белән:

— Юк, бер дә кыен түгел... Хәтта уңайрак та әле,— дип, җиңелчә көлдереп тә алды.— Сөйләгәндә кулыңны болгама дип, әлек Мәрфуга гел теңкәгә тия, ачуны китереп бетерә торган иде. Хәзер, күрәсез, ләммим, бал капкан кебек, елмаеп кына утыра.

Аңа сыенып утырган Мәрфуганың шатлыгы йөзендә балкый, ул көне-сәгате белән күз алдында яшәреп, шатлыгы эченә сыймагандай, гел елмаеп йөри торган булып китте. Шунда мин ирексездән: «Ярый әле теге чакны ашыгычлык белән иргә чыгудан тыелып кала белдең, молодец!» — дип, аның өчен ихлас күңелдән куанып утырдым.

Тиздән җиңү белән сугышлар бетеп, безгә дә менә шундый бәхетле кавышулар насыйп булсын иде.

...Затонда ремонтланып чыккач безгә пристаньда күп торырга туры килмәде. Сталинград ашыктыра. Причалга килеп туктауга пароходка үзләренең сугыш припаслары белән хәрбиләр төялде. Шул арада бөтен яр буе озата килүчеләр белән тулды, соңгы үгет-нәсихәтләрне әйтеп, һәрвакыттагыча күз яшьләре түгеп саубуллашулар башланды.

Безнең кайчан китәсене алдан белешеп торганнар булса кирәк, мине озатырга Разия апай белән Кәбир дә төшеп житте. Моңарчы бер дә болай булганым юк иде, бу юлы әллә нишләдем, алардан аерылып киткәндә күңелем тулды, күзләрем яшьләнде... Юлга кузгалып, пароход елга уртасында агым уңаена борылгач, мин бинокльдән причалга караганда анда халык инде таралган, яр өстендә минем бәгырькәйләрем — Кәбир белән Разия апай — бөтенләйгә саубуллашкандай, әле һаман кул болгап торалар иде.

Бераздан, көндезге вахтадан бушаганнан соң ашханәгә төшсәм, анда бөтен команда тын да алмыйча профорг Мәрфуганың кычкырып нәрсәдер укыганын тыңлап утыра иде. Мин ачык ишектән керү белән Мәрфуга укудан туктады.

— Казанда культбазадан алган газета-журналлар арасыннан менә бу пакет килеп чыкты,— диде ул, кулындагы кәгазьне күрсәтеп.— Сталинградтан, флотилия Хәрби советыннан хат. Үткән рейста хәрби эшелонны фронтка хәвеф-хәтәрсез вакытында китереп житкергән һәм ут эченнән йөзләрчә яралыларны эвакуацияләгән өчен безгә рәхмәт әйтеп язганнар.

Тын гына тыңлап утырган кызлар, кинәт җанланып, теге чакны Сталинградта күргән хәвефле эпизодларны кабат башларыннан кичергәндәй, бер-берсенә сөйләргә тотындылар. Ә мин хатны үзем укып чыккач, көтмәгәндә башыма килгән бер сәерсенү белән:

— Ул чакны бездә хәрби флотилиядән беркем дә булмады кебек. Моны кем шулай белеп, үзе күргәндәй, тәфсилләп язды икән? — дип кызыксындым.

Бу сорауга шундук җавап бирүче булмады. Чак кына соңрак, мин өстәл янында ялгызым калгач кына, үзенә дә чәй салып каршыма повар Ольга килеп утырды һәм сер итеп кенә:

— Баягы хәбәрне газетага минем Даутым җибәргән булса кирәк,— диде.— Мөгаен, шулдыр, безнең кешеләрнең исемен, фамилияләрен, кем булып эшләүләрен шул язып алган иде.

Күр инде бу кызыйны, минем Даутым, имеш. Кай арада Даут инде аныкы булып та өлгергән.

— Теге безне озата барган яшь лейтенантмы, сиңа өйләнергә теләгән мыеклы егетне әйтәсеңме? — дип гаҗәпләндем.— Я ничек, ул чакны әнисенә барып күрендегезме соң?

— Бардык, Мәрьям Вәсилевна, күрендек... Мондый хәвефле вакытта сугыштан улы исән-сау кайтып төшү шатлыгыннан әни карчык чүт сыгылып төшмәде, күз яшьләре белән елый башлады... Мин үзем бер дә кыймыйча, уңайсызланып кына барган идем. Иске карашлы карчык, мине — бүтән милләт кешесен — өнәмәс, кире кагар дип шикләнгән идем. Әмма ялгыш уйлаганмын. Даут минем хакта: «Әнием, менә сиңа килен, үземә тормыш иптәше алып кайттым... Исеме Ольга, туган кызың итеп кабул ит»,— дип әйткәч, әни карчык икебезне дә кочаклап, безгә тигез гомерләр теләде.

Тормыш, мин әйтәм, тоташ кайгы-хәсрәттән, кыенлыклардан гына тормый икән. Менә тагын бер кызыбыз, үз парын табып, оя корды. Хәерле сәгатьтә булсын, аларга без дә бәхетле тормыш телик.

Анысы да монысы, менә тагын кара көз керде бит. Идел отыры суына, көннәр кыскара бара, күп вакыт дөм караңгыда эшләргә туры килә. Быел бу безнең соңгы рейсыбыз булыр инде. Былтыргы кебек юлда боз әсирлегенә эләкмәс өчен тизрәк Казанга кайтып җитәрбез дә кышка туктарбыз.

Бу көннәрдә безнең монда өметле хәбәрләр йөри башлады. Сталинградта оборона сугышлары алып бару белән бергә, шул ук вакытта кайдадыр далада безнекеләр зур көч туплый, тиздән хәлиткеч һөҗүмгә күчәчәкләр икән дип сөйлиләр. Берүк шулай була күрсен, тизрәк башларына җитсеннәр иде шул явызларның.

Ә син, Нурис бәгырем, һаман юк, бернинди хат-хәбәрең дә юк... Шул хакта уйлый башласам, күңелем тула, тамак төбенә сагышым төер булып тыгыла.

...Казаннан алынган приказ буенча без беркайда туктамыйча туптуры Сталинградка төшәргә тиеш идек. Әмма юлда бер кечерәк кенә үзгәреш килеп чыкты: без алып бара торган хәрби часть командиры соравы буенча беразга гына Саратовта туктарга, селектордан шалтыратып, Сталинград зонасына кай вакыттарак барып керергә, анда тыкшысы урынны ачыкларга туры килде. Шул кыска гына вакыт эчендә безнең кызлардан кайберләре фронтка якыннарына язган хатларын почта ящигына салырга, ә профорг Мәрфуга хәтта культбазадан яңа газета, журналлар да алырга өлгерде.

Пароход пристаньнан кузгалып киткәннән соң чирек сәгать үтмәгәндер, рубкага боцман Мәрфуга атылып килеп керде. Траптан ашыгып менгәнгә булса кирәк, ул еш-еш сулый, кулында газета, бөтен кыяфәтеннән никтер бик исәренгәне күренеп тора.

— Мәрьям Васильевна, әйтегез әле, сезнең Нурисламыгызның фамилиясе, әтисенең исеме ничек аның? — диде ул, ишектән керүгә.

Хәрби часть командиры белән мин яңа алынган приказны ничек үтәү турында киңәшеп, Сталинград районында туктыйсы урынны карта буенча аныклап тора идек. Һәр эшнең вакытын һәм җаен белә торгач зиһенле Мәрфуганың чит кеше алдында тиктомалдан шундый сүз кузгатуын ошатмадым.

— Ул хакта соңынтын сөйләшербез... Комачаулап йөрмә, бар эшеңдә бул,— дип, аның сүзен бүлдем.

— Ачуланмагыз, әйтегез инде...— диде Мәрфуга, үҗәтләнүен дәвам иттереп.— Алимҗанов Алимҗанович түгелме?

— Эш вакытында урынсыз сораулар белән комачаулап йөрисез. Я, шулай булса нишләгән?..

— Алайса мин тәбрик итәм сезне... Шатланыгыз, Нурисламыгыз табылды, менә ул! — дип, Мәрфуга кулындагы газетага бармагы белән төртеп күрсәтте.— Саратовта алган менә бу газетада шул исемне күрү белән, чү, мин әйтәм, безнең Мәрьям Васильевна Нурисламы түгелме бу... Табылган, димәк, исән-сау, орден белән бүләкләнгән... Менә монда шул хакта язганнар.

Искәрмәстән капылт килеп төшкән куанычлы хәбәр дә кешене мингерәйтә икән. Мәрфуганың бу сүзләреннән башым әйләнеп китте, күрмәс күзләремне газетага төбәгән хәлдә бер мәл аңыма килә алмый тордым.

Хәрби часть командиры татарча аңламаса да, минем хәлемне сизде булса кирәк, карыйсы эшләрем бар дип, рубкадан төшеп китте. Ә мин, тиздән вахтадан бушап, каютада бераз тынычлангач кына газетадагы ул хәбәрне укый алдым һәм разведкадан кайтканда ээзрлекләп килүче дошман отрядын тоткарлап, иптәшләреңне коткаруыңны, зур кыенлыклар белән үзебезнең якка исән-сау чыгуыңны белеп, әйтеп бетергесез сөендем. Вакыт-вакыт хәтта күңел ышанмый, саташмыйммы мин, төштә генә түгелме бу дип, үземнән үзем сорап куям.

Юк, төш түгел, реаль чынлык бу! Күңел күгемне каплап торган авыр хәсрәт болытлары, ниһаять, таралды, сулышым җиңеләюен бөтен барлыгым белән сизеп шатланам... Бүген соң инде, иртәгә Сталинградтан әйләнеп чыгу белән бу хакта ничек тә тизрәк Разия апайга ашыгыч телеграмма бирергә, тизрәк аны да сөендерергә кирәк...

Хөрмәтле Нурислам абый, исәнмесез!

«Ургыл» командасы исеменнән сезгә бу хатны пароходның штурвальные, Мәрьям Васильевна белән рубкада вахта торган, соңгы ел ярым эчендә гомумән тормышның ачысын-төчесен бергәләп татыган Җәмилә Бәхтиярова яза.

Иң әүвәл Мәрьям Васильевнаның безнең өчен таләпчән һәм гадел капитан гына түгел, һәркайсыбыз турында аналарча кайгыртучан, хәзерге кыен көннәрдә ярдәмчел юатучыбыз да булуын әйтеп үтәсем килә. Шул ук вакытта ул үзе дә кыенлыкларны аз күрмәде. Сезнең югалу хәбәренә күңеле белән ышанмаса да, ул аны бик авыр кичерде, нәкъ шул айларда аның әтисе үлеп китте. Өстәвенә, җәрәхәткә тоз салгандай, нахак гаеп тагып, аны хөкемгә тартырга маташучылар да табылды.

Мәрьям Васильевна исә, кыенлыкларга бирешмичә, һаман эштә янды, кайгы-сагышларын эштә басарга тырышты. Ә сез табылгач шатлыгын күрсәгез икән!.. Ул көнне безнең пароходта, зур бәйрәм кебек, күңелле булды, сөекле капитаныбызның сугышта югалган кадерле кешесе — сез табылуга барыбыз да сөендек.

Шул кичне караңгылык куергач, без Сталинградка төшеп житеп, төн пәрдәсе астында алып килгән хәрби эшелонны бушаттык һәм шун-

дук яралыларны кабул итәргә кирәштек. Әйләнә-тирә дөм караңгы булса да, гадәттәгечә, бар эш һичнинди матавыксыз, оешкан төстә барды. Ниһаять, чалкаларны ычкындырып причалдан кузгалган вакытта дошман безне һавадан ракета белән яктыртты һәм шундук биек тау башыннан урнашкан туп, минометлардан өстебезгә ут ачты; караңгы күктә утлы эз калдырып яуган яктырткыч пулялар рубка стенасын тишкәләп үтте.

Шулчак рубканың ачык тәрәзәсе каршында басып барган Мәрьям Васильевна кинәт нидер кычкырып, күкрәгенә тотынды. Мин борчылу белән: ни булды, яраландыгызмы әллә дип, сорарга өлгермәдем, ул шундук тураеп машинаны катырак эшләтергә, рульне уңга борырга команда бирде. Тиз генә кузгалып, утыз-кырык метр китәргә өлгермәгәнбездер, әле генә без торган урынга килеп төшкән снаряд шартлавыннан пароход бөтен корпусы белән сикереп куйды... Һавада ракета сүнү белән әйләнә-тирәне тагын коткаргыч караңгылык каплады. Шул форсаттан файдаланып, без, алдау маневрлары ясый-ясый, бар көчкә хәтәр зонадан читкә, елганың сул ярына ташландык.

Бернichә минуттан «Ургыл» дошман урнашкан куркыныч таулар турысыннан хәвеф-хәтәрсез үткәч, мин җиңел сулап куйдым. Ә Мәрьям Васильевна пароходка командалык итеп барган җиреннән:

— Уф-ф... Бүтән түзәр хәлем юк...— дип, ишетелер-ишетелмәс ыңгырашып штурвал өстенә яны белән ава башлады.

Мин аны көч-хәл белән тотып калдым һәм арткы стена буендагы такта топчанга яткырдым. Караңгыда кулым җылы юешкә тиде, һәм мин аның бөтен юбкасы, китель итәге манма кан булуын шәйләп алдым... Минем тавышка шундук менеп җиткән кешеләр аны медпунктка алып төшеп киттеләр...

Бераздан яралыларны озата баручы хәрби врач, тикшереп карагannan соң, аның күкрәген ике урында пуля тишкәнлеген һәм бик күп кан акканлыгын әйтте... Мәрьям Васильевна әле пристаньда ук каты яраланган булуына карамастан, коточкыч авыртуга бирешмичә, хәвефле моментта үз постында торуын дәвам иттергән һәм, пароходны һәлакәттән алып чыгып, тәмам хәлдән тайгач кына аяктан егылган. Ә мин аның белән янәшә торып шуны күрмәгәнмен.

Вахтада һаман бергә торгангамы, Мәрьям Васильевна мине аеруча үз итә сыман иде. Шуңа булса кирәк, бераздан медпунктта аңына килгәч, ул иң әүвәл мине чакыртып алды.

— Җ-Җәмилә, синме бу... Якынрак кил...— диде ул, мине кыенлык белән танып.— Менә үләм инде, хушыгыз... Сүземне бүлмә, хәлем барда әйтеп калыйм... Минем өстәлдә Нурислам абыеңа язган берничә хатым бар, син аларны ничек тә тапшыр инде... Үзеңнән өстәп шуны яз, әгәр очрашырга туры килсә, телдән дә әйт: Кәбиргә әти булсын, аны Туган илгә тугрылыклы, намуслы кеше итеп тәрбияләп үстерсен...

Соңгы сүзләрен ул бик кыенлык белән пышылдап кына әйтә алды һәм, хәле бетеп, бөтенләй тынды, йокыга талды. Күзләрен йомган хәлдә беравык яткannan соң ул тагын кузгалырга теләгәндәй, бөтен гәүдәсе белән талпынып, кипшенгән иреннәрен көч-хәл белән кыймылдатып, авыз эченнән нидер сөйләнә башлады. Мин аның авызыннан буылып-буылып чыккан саташулы сүзләрен аңламадым, бары тик берничә мәртәбә улы Кәбир һәм сезнең исемне әйткәнен генә ишетеп калдым.

Шул һушсызланудан Мәрьям Васильевна бүтән аңына килмәде, хәле авырайганнан-авырая, ул күз алдында сүнә барды. Доктор аның яраларын яңадан бәйләп, хәзинәдә булган даруларны биреп тә хәлен җиңеләйтә алмагач:

— Гангрена башлану куркынычы бар, ашыгыч операция кирәк. Пароход шартларында аны эшләү мөмкин түгел, беренче пристаньда туктап, тизрәк больницага салырга кирәк,— диде.

Башта без Мәрьям Вәсилевнаны ничек тә Казанга, дәвалау мөмкинлекләре күбрәк булган шәһәргә алып кайтырга уйлаган идек. Әш болайга киткәч, планны үзгәртергә, врач таләбе буенча Камышинда туктарга туры килде. Батыр капитаныбыз Мәрьям Вәсилевнаны без шунда, ашыгыч ярдәм машинасы чакыртып, һушсыз хәлендә больницага озаттык.

Шушы конвертка салып Мәрьям Вәсилевнаның соңгы көннәрдә язып та, озатылмый калган берничә хатын сезгә җибәрәбез һәм барыбыз өчен дә авыр булган кайгыгызны уртаклашабыз.

## Соңгы сүз

Бөек Ватан сугышы вакытында Сталинградта һәлак булган Идел капитаннарының фотопортретлары, пароходчылык музееның үзәк залында путаллы рамнар эченә алынып, иң күренекле урынга куелган. Музейга килүче экскурсантлар — күп санлы мәктәп балалары, яшьләр, өлкән буын кешеләре — Туган ил азатлыгы өчен гомерен фида кылган батыр командирларның рәсемнәрен караганда шундагы хатын-кыз капитан портреты янында озаграк тукталып, соклану һәм ихтирам белән тын гына торалар.

Бирегә беренче мәртәбә килгән көнне бу портретны күрүгә мин дә ихтыярсыз тукталып калдым һәм шунда язып куелган кыскача биографик белешмәне дулкынлану белән укып чыктым. Сәбәбе шул: аның исем, фамилиясе, төсе-бите миңа таныш кебек тоелды. Хәтерем ялгышмаса, кайчандыр, мин елга техникумында укыган вакытта ул безгә кышларын сигнализациядән дәрес бирә, ә җәйге айларда пароходта капитан ярдәмчесе булып эшли иде.

Әле дә исемдә: мин күргән-белгән елларда ул зифа буйлы, бик чибәр яшь ханым иде, елмаючан ачык йөзле булгангамы, хәтта бераз җилбәзәк сыман күренә иде. Хәзер исә елгачы капитан киеменнән пароход күперчегендә аяк өсте басып төшкән бу рәсемдә яшьлеккә хас гамьсезлекнең инде эзе дә юк. Шулай да ул элеккечә мөлаем, өстендәге ак kителе җыйнак гәүдәсенә килешле сыланып тора; зур түгәрәк күзләренең төбәп каравы, матур иреннәренең сизелер-сизелмәс кенә елмаюы белән ул кемгәдер сөенечле хәбәр әйтергә тели сыман иде.

Тик шунысы кызганыч, рәсем астындагы биографик белешмә бик кыскача язылган, аннан капитан Билалованың эшчәнлеге һәм һәлакәте турында тулырак мәгълүмат алуы мөмкин түгел иде. Шунлыктан мин, аның хакында бүтән документлар юкмы дип кызыксынып, музейның фондлар бүлегенә кердем.

Бүлек мөдире, инде өлкән яшьләрдәге бик ихтирамлы бер агай, зур шкаф эчендә байтак вакыт актарынганнан соң бер төргәк табып чыгарды.

— Күптән түгел моны безгә яшь эзтабарлар тапшырган иде,— диде ул, төргәкне аркылы-торкылы бәйләгән ал тасманы чишеп.— Тышына язылган исем-фамилиясенә караганда, шул капитан хатлары булса кирәк. Алар татар телендә язылган. Әле һаман һич кул җитми, берәрсенә укытып ачыклаган да юк... Менә карагыз әле, укып чыккач эчтәлеге белән, бәлкем, безне дә таныштырырсыз.

Төргәкне ачып карау белән аның эчендә шул безнең техникум укытучысы штурман Мәрьям Билалованың Бөек Ватан сугышы вакытында фронттагы якын дусты Нурисламга язган хатлары икәнлеге беленде. Ул хатларда тасвирланган вакыйгалар, телгә алынган кешеләрнең гыйбрәтле язмышлары, җанлы картинадай, күз алдыма килеп басты.

Дөрес, сугыш елларында мин үзем Иделдән еракта, илебезнең диңгез чикләре сагында булдым. Сталинградта каты сугышлар барган

көннәрдә, бер төркем коралдашларым белән бергә, фронтка китәргә сорап гариза да биргән идем. Ләкин җибәрмәделәр, бөтен кешене фронтка озатып булмый, Ватан кушкан җирдә хезмәт итәргә кирәк, дип әйттеләр.

Хәер, ул вакытта анда да җиңел булмады. Япон самурайлары, рәсми нейтралитет саклаган булсалар да, ил чигендә әледән-әле коралды провокация ясап тордылар, океан юлларында каракларча яшеренеп күпме пароходларыбызны батырдылар, кешеләрне һәлак иттеләр. Кыскасы, гел уяу булырга, дарыны коры тотарга туры килде, коралды провокация — һөҗүм була-нитә калса, шундук җимергеч җавап бирергә әзер тордык. Без һәрвакыт тылдагы якын туганнарыбыз, сөйгәннәребезнең күңел җылысын тоеп яшәдек, алар җитештергән хезмәт җимеше белән туклandык, киендек, коралландык. Шул какшамас бердәмлек безне көчле итте.

Ул көннәрдә без барыбыз да күңелләребез белән Иделдә, Туган ил язмышы хәл ителгән Сталинград фронтында булдык. Шул тарафтан килгән һәр хатны, һәр газета, радио хәбәрен түземсезлек белән көтеп ала идек. Ул кайнар көннәр күңелләргә беркайчан да онытылмаслык булып сеңгән.

Шуңа булса кирәк, Идел капитаны Мәрьям Билалованың яңалифчә язылган, еллар үтү белән саргаеп, күп урыннарда хәрефләре танымаслык дәрәҗәдә уңып беткән хатларын мин тирән дулкынлану белән укыдым, һәм героик көрәш елларының кайнар сулышын безнең көннәргә алып килгән ул җанлы сәхифәләрне әдәбият сөючеләр игътибарына тәкъдим итәргә булдым.

## Афзал Шамов

# ЯЗНЫ КӨТКӘНДӘ

хикәя



Март урталары иде. Көн кояшлы, жылы. Түбә кырпуларыннан тамчылар тама, һавадан яз исе, кар исе, кояш исе килә. Вокзал бакчасындагы талларда чыпчыклар чыркылдый,— үзләренчә нидер сөйләшәләр,— язның, кояшлы көннәрнең башлануына шатланалар булса кирәк.

Авылдашлар, таныш-белешләр юкмы икән дип, як-ягыма караштыргалап торган арада мине алып кайткан поезд, урыныннан кузгалып, соргылт шәлен болгый-болгый китеп тә барды, вагоннардан төшкән юлчылар да таралышып беттеләр, платформада бары ике агай белән берничә малай гына калды. Агайлар ямщиклар булса кирәк,— миңа таба кызыксынып карап торалар, хәтта берсе, чыбыркысын изәп, мине үз янына чакырды шикелле.

Мин шактый бушаган, жиңеләеп калган бөрмәле капчыгымны иңемә асып, аксый-аксый, аларга таба киттем. Алар да, бер-берләреннән, уздырып, миңа таба килә башладылар. Берсе, озын буйлысы, ерактан ук:

— Әй, чибәр егет, кая кайтабыз?— дип кычкырды.

Икенчесе, тәбәнәк буйлысы да аңардан калышмады:

— Безнең яккамы әллә?—дип, кулындагы чыбыркысын көньякка таба изәде. — Кайтсаң, жилдәй очыртып алып кайтам үзеңне...

Яннарына барып туктагач, агайлар очлы күзләре белән мине башымнан алып аягыма чаклы сөзеп карап чыктылар, иңемдәге капчыкка да күз төшерделәр. Өс-башым әллә ни яхшы тәэсир калдырмады булса кирәк,— шулай тоелды. Хәер, ничек яхшы тәэсир калдырсын. Өстемдә шактый тузган, сизрәгән шинель, аягымда обмоткалы ботинка, башымда яңа дип мактанырлыгы булмаган шлем. Яшермим, аягымдагы ботинка да яңалардан түгел, ләкин шулай да калын олтанлы, таза ботинка. Әмма гимнастеркам белән чалбарым өр-яңа, госпитальдән чыкканда гына бирделәр, анысы белән мактана алам, тик, кызганычка каршы, күзләре аңа хәтле барып житмәде. Шулай да алар минем белән кызыксынуларын дәвам иттеләр.

Мин, юл хакы турында сүз кузгатырга ашыкмыйча, кызыксынып биргән сорауларына кыска-кыска жавап биргәләп, алар белән бергә вокзал артына, атлар торган урынга киттем. Анда артсыз чаналарга жигелгән ике карт алаша, кояш жылысында башларын түбән иеп,

аскы иреннәрен иләмсез салындырып басып тора иде. Шундый ябык, шундый мескен, кызганыч иде алар,— күзем төшү белән үк йөрәгем «жу!» итеп китте, дәһшәтле ачлыкның зәмһәрир суыгы йөземә килеп бәрелде сыман.

Юл хакы турында сүз кузгалгач, авылымның исемен ишетү белән үк агайлар:

— Һай, ерак икән! Бик ерак икән!—дип берьюлы кычкырып җибәрделәр.

— Ерак түгел,— дидем мин аларга каршы. — Егерме биш чакрым еракмыни ул!

Озын буйлы агай ераклык-якынлык мәсьәләсен, заманның авырлыгыннан чыгып, фәлсәфи хәл итте:

— Әй, энем, энем, үзең болай карап торырга башлы егет сыман күренәсең, сугышларда булгансың, дөньяның әчесен-төчесен татыгансың, ә үзең бүгенгесе көнне егерме биш чакрымның электәге йөз чакрымнан даераграк икәнен белмисең. Хәер,— диде ул аннары, кулын селтәп,— ул як миңа юл уңае түгел. Беләсең килсә, чибәр егет, ул якка мин ат буе алтын бирсәң дә бармыйм. Кире як ул миңа. Менә Хәмидулла илтеп куйсын үзеңне... Аның ни... андый-мондый гына түгел, ә чаптар алаша. Җилдәй очыртып алып кайтыр үзеңне. Хи-хи-хи!..

Хәмидулла абзый дигәне, элеге базык гәүдәле агай, юл хакы өчен ат буе алтын сорамаса да шактый каерырга исәпләде:

— Ярты пот солы белән бер ипи,— диде.— Шуннан бер мыскал да ким түгел.

Каян алыйм мин аны? Юк бит миндә андый байлык. Өйдә хәлләр ничектер, күптән хат-хәбәр алганым юк. Ай-һай, ул чаклы солы булырмы икән анда? Аннары ипие... Капчыгымдагы ипи дә башланган ичмаса.

Агай минем шулай уйланып торуымны сиздe булса кирәк, шинелемнең итәген күтәрде дә, бик кызыксынып, гимнастеркам белән чалбарымны капшап карады:

— Болары да ярый... Икесен бергә салып бирсәң, дигәндәй...

Риза түгеллегемне белдереп, башымны чайкадым. Юк, боларны берничек тә бирә алмыйм мин. Берничек тә! Чалбарым да, гимнастеркам да үземә кирәк. Ансыз мин ничек итеп Кызыл Армия сафына яңадан барып басыйм?! Кызылармеец бит мин. Ялда гына. Яраларым гына төзәлсен... Гражданнар сугышы бетте дигәч тә, ил тыныч түгел әле. Кайдадыр бандитлар айкалып йөри, басмачылар тынгылык бирми, авылларга, кечерәк шәһәрләргә һөҗүм итәләр, совет оешмаларын талыйлар, җимерәләр, яндыралар, коммунистларны, активистларны үтерәләр, канга батыралар. Ил чикләре дә бик шомлы. Ерак Көнчыгышта интервентлар белән сугышлар бара. Юк, совет властен яклыйсым бар әле минем, кулыма корал тотып яклыйсым бар... Яраларым гына төзәлсен, бераз хәл керсен, көчем кайтсын. Гимнастеркасыз, чалбарсыз ярамый миңа...

Шулай уйлана-уйлана, вокзал бакчасында аунап яткан бер таякны алдым да авылыбызга таба җәяү генә киттем. Исән булсам, болай да кайтып җитәрмен. Мондый юлларны гына күрмәгән егетмени мин!

Көчемә артыграк ышанганмын икән. Аксый-аксый бер ун чакрым җир китәргә өлгермәдем, аякларым бөтенләй эштән чыкты, атлый да алмый башладым. Яралысы аеруча сызлый.

Баштарак, станциядән чыккач, чакрым саен туктап, ял иткәләп барган булсам, инде егерме-утыз адым саен туктарга, хәл җыярга мәҗбүр була башладым. Ичмасам, безнең якка таба баручы олаулар да очрамый. Җәяүлеләр дә сирәк... Нәрсә соң ул җәяүлеләр! Ничек ярдәм итә алсыннар алар миңа? Очрасалар, кызганып, бер-ике сүз әйтәләр дә үз

юллары белән китеп баралар, тормышка ашыруы мөмкин булмаган киңәшләр бирәләр...

Кыр буш, тын, моңсу. Дөнья үлгән, мәрткә киткән диярсең. Алдагы авыл әле ерак. Төнгә чаклы шуңа барып җитсәм ярар иде.

Кич якынлашып килә, кояш, кызгылт чаткыларын сибеп, кансуланып, офык итәгенә таба төшеп бара, карга төренеп яткан җир өстенә кара пәрдә җәелгән.

Салкынайта башлады, җил көчәйде, аяк астындагы кар да катырак, ачуланыбрак шыгырдарга кереште.

Яралы аягымны инде өстерәп кенә барам.

Мәмәткол авылына барып кергәндә караңгы төшкән, аяк атларлык хәлем калмаган иде. Шуңа күрә мин кыр капкасыннан керү белән үк күземә чалынган беренче ут чаткысына таба юнәлдем.

Тәрәзәләре бәсләнеп каткан, салам түбәле өй иде ул. Караңгы чоланда ишекне таба алмыйча азапланганда өй эченнән балаларның шатланып кычкырган тавышлары ишетелде. «Әни кайтты!.. Әни!..» Ләкин бусаганы атлап керергә дә өлгермәдем, алар, пырылдашып, каядыр качып беттеләр, өй эче тынып калды, — әниләре түгел икәнен сизделәр.

— Әниегез түгел әле бу...— дидем мин аларга.— Солдат абыегыз... Госпитальдән кайтып киләм. Бик арыдым, аякларым сызлый...

Сүземә каршы эндәшүче булмады.

Өй эче караңгы, тынчу. Шылт иткән тавыш та юк. Шулай да өйдә җан ияләренең барлыгы сизелеп тора, почмак яктан ара-тирә ут шәүләсе чагылгалап китә.

Балалар төнлә килеп кергән ят кешедән курыктылар булса кирәк, тыннарын да чыгармыйлар.

— Курыкмагыз, балалар, курыкмагыз,— дидем мин аларга, мөмкин чаклы ягымлы итеп.— Кызылармеец мин. Авылыма кайтып барам... Кайда соң сез?.. Нигә күренмисез?..

Шуннан соң гына балаларның кыштырдаган тавышлары ишетелде. Тугыз-ун яшендәге бер кыз бала, олысы булса кирәк, кулына бакавыз лампа тотып, түр ягына чыкты да, аны мич кашагасына куйгач, җәнлек баласыдай шикләнеп, куркып, миңа карап тора башлады. Бәгырьне өзәрлек ябык гәүдәле, җыерчык битле бала иде ул. Өстендә шалама бишмәт, — ул да үзенеке булмаса кирәк, бик озын, җиңнәре, иңбашлары салынып тора, — аягында иске киез итек, башында ертык яулык, яулыгы астыннан тузма чәчләре тырпаеп чыккан. Мин аның телен ачарга теләп:

— Бик арыдым, әгәр рөхсәт булса, сездә бераз ял итеп, җылынып чыгар идем, — дидем.

— Җал ит, җылын... Тик өебез салкын безнең.

Тавышы моңлы, зәгыйфь иде аның.

— Ник якмыйсыз соң?

— Утын юк.

Шунда гына мин бу гөнаһсыз җанның күзләре кайгылы, хәсрәтле икәнен күреп алдым.

— Әниегез кайда соң?

— Әниме? — дип кайтарып сорады бала, ләкин миңа җавап бирәсе урында пыскылдап елап җибәрде. Шуны гына көткән сыман мич башыннан да елаган тавышлар ишетелде. Анда кечкенәләр ята икән. Икәү булса кирәк.

Мин, бернәрсә аңламыйча, аптырап калдым. Тик бераздан, күз яше белән әйтелгән аерым сүзләрдән чыгып шуны аңладым: моннан ике атна элек әниләре, берәр ашлык он юнәтеп булмасмы икән дигән өмет белән, Аланбаш авылына, ерак туганнарына киткән икән. Бәхетсезлеккә каршы, ул чыгып китүгә күп тә үтмәгән, күз ача алмаслык каты

буран күтәрелгән. Ана кеше туганнары янына да барып җитмәгән, авылга да әйләнеп кайтмаган. Кая киткән, кайда югалган? Әлегәчә белүчеләр юк икән. Эзләп тә караганнар, әмма тапмаганнар. Ә балалар һаман көтәләр, өметләнеп көтәләр, чоланда берәр аяк тавышы ишетелү белән үк, шатланып, ишек янына йөгерешеп киләләр. Мине дә әниләре дип уйлаганнар икән алар.

Йөрәгемне нәрсәдер чеметеп алды, сулышым кысылды. Аркамдагы капчыкны да салмыйча, хәлсезләнеп, ян сәкегә утырдым. Фаҗигале хәлнең ни белән бетүен белергә теләсәм дә, тәфсилләбрәк сорашырга көчем җитмәде.

Күпмедер вакыт узды... Балалар инде еламыйлар, бары ара-тирә үксеп-үксеп кенә куялар иде.

Кызчык яңадан почмак якка кереп китте. Ул анда казан тирәсендә нидер эшләп маташа иде.

Түрдә мин калдым да, бакавыз калды. Аның тычкан күзе сыман елтырап торган саргылт уты бер секунд та тынып тормый, сүнәргә теләгәндәй талпына, бөтерелә, сүрән яктысы белән өйнең әле бер урынын, әле икенче урынын ялаштыргалап ала. Өй эче ярлы, күзгә ташланырлык, игътибарны җәлеп итәрлек бернәрсә юк.

Бу өйгә килеп кереп, аның салкын, ягылмаган икәнен сизгәч үк мин, аякларымны бераз ял иттерермен дә чыгып китәрмен, берәр җылы урын табармын, дип уйлаган идем, шуның өчен шинелемне дә, хәтта аркамдагы капчыкны да салмаган идем. Ләкин сабыйларның елауларын, аһ-зарларын ишеткәч, чамасыз кайгыларын төшенгәч, күңелем тетрәнеп китте, караңгы төндә бу өйне, мескен балаларны ташлап чыгып китәрлек көчем калмады — ян сәкедә, башымны иеп, хәлсезләнеп утыруымда дәвам иттем.

Ахырда капчыгымны да салдым, таягымны бер читкә сөяп куйдым. Берәр кружка кайнар су булмасмы икән дигән өмет белән почмактагы әлеге кызга эндәштем:

— Сеңлем, нишлисең син анда?

— Аш пешермәкче идем дә...

— Ник пешермисең?

— Оным аз. Бүген пешерсәм, иртәгегә калмый.

Бу сүзләрне ишеткәч, мич башындагы балаларның берсе, иң кечкенәсе булса кирәк, яңадан пыскылдап елап җибәрде. Үзе елый, үзе авызы эченнән нидер такмаклый.

— Нигә елый ул?

Чыннан да, нигә елый? Әллә янындагы туганы кыерсытамы? Кулыма бакавызны алып, мич башы тирәсен яктырттым. Анда, шаламалар арасында, җиде-сигез яшендәге бер малай белән бер кечкенә кыз ята икән, — ут яктысында күзләре генә җемелди.

— Ник елыйсың, акыллым? Әллә абыең кыерсытамы?

Ул арада минем янга почмактагы кыз килеп басты:

— Берәү дә тими аңа, абый. Ашыйсы килгәнгә елый ул... Иртәдән бирле берни ашаганы юк.

Мин ни әйтергә белмичә тынып калдым. Апасы кечкенә кызны юатырга керешге:

— Җылама, Сәкинә, җылама... Йокларга кара. Йоклагач, ашыйсы килми ул... Әнә Сәмит еламый ич. Аның да ашыйсы килә, шулай да җыламый.

Мин, кызчыкның сүзен бүлеп:

— Тукта әле, оның күпме синең? — дип сорадым. — Бәлки аз булса да, аш пешереп булыр?

Оны бер-ике уч кына икән. Ул да булса — алабута оны.

Мин ян сәкедәге капчыгымны кулыма алдым.

— Кара әле, сеңелем, табак сыман берәр нәрсә алып кил әле бирегә, — дидем кызыйга. — Минем бераз тары ярмам бар. Хәзер без синең белән бергәләп шуннан ботка пешерәбез... Бик тәмләп ашыйбыз. Ярыймы? Исемең ничек синең? Фәһимә дисеңме? Әй, бик матур исем икән! Шулаймы?.. Кил әле, табагыңны тот әле, Фәһимә.

Капчыгымда бик кадерләп саклап тоткан дүрт кружка чамасы тары ярмам бар иде. Шуның төгәл яртысын кыз кулындагы табакка салдым:

— Сөтең бармы?

— Юк.

— Ә тозың?

— Тоз да юк.

Мин, балаларның күңелен күтәрергә теләп, мөмкин чаклы көр тавыш белән:

— Булмаса да ярый, — дидем. — Тары боткасы ул сөтсез дә, майсыз да тәмле була! Тозлап пешерәбез аны. Миндә тоз бар. Мин әле аны сезгә дә күп итеп биреп калдырырмын.

Фәһимә, кечкенә булса да, миңа караганда хуҗарак җанлы булып чыкты:

— Без моннан ботка пешермик, абый,— диде ул.— Аш пешерик.— Моны берничә ашка җиткереп була. Ә ботканы аны ни... бер утыруда ашыйсың да бетерәсең.

Каршы килмәдем.

— Бәрәңгең бармы соң?

Бик яшереп саклап тоткан берничә бәрәңгесе бар икән, Фәһимә шуның икесен китереп куйды.

Кызчыкның киңәше белән, читәннәрен сүтеп, тыштан бер кочак чыбык-чабык алып кердем.

Казан асты күңелле генә булып гөрләп яна башлады. Җылыга, учак янына балалар җыелды, мин дә бер почмакка сыендым.

Керүемнән бирле күңелемне борчып торган берничә соравым бар иде: нигә үзләре генә болар? Әллә авылда якын туганнары юкмы? Булса, нигә бу нарасыйларны карамыйлар, нигә алар янына килеп кунмыйлар?

Аш янында сораштым, телләре ачылды. Әтисе белән бертуган Хәбибә исемле апалары алар янына һәр көнне килеп куна торган булган, көч-хәл белән юнәтеп алып килгән азыклардан аш та пешергәләгән, ашаткан да, иркәләгән дә; тик, кызганычка каршы, соңгы көннәрдә үзе, аяктан язып, каты авырып ята икән. Ә башка туганнары? Алары, кызның әйтүенчә, ерак туганнар, килеп тә карамаганнар.

Ашаганнан соң балалар мич башына менеп яттылар, озакламыйча йоклап та киттеләр шикелле, тавыш-тыннары басылды.

Мин түр сәкегә урнаштым, җылынып өчен шинелемне башымнан ук бөркәндем, бик арыган булуыма да карамастан, күземә тиз генә йокы кермәде. Ягылмаган өй, ярлылык, мич башында бергә өелешеп яткан балалар, аларның кайгылары, моңнары — барысы да йөрәгемне тырный, борчый. Бу сабыйларны нигә шундый аяныч хәлдә калдырганнар? Ярый, Хәбибә апаларына бик зур рәхмәт! Таза чакта ул аларны караган, тәрбияләгән, үз балаларының авызыннан өзеп булса да, аларга ашарга алып килгәләгән, төнлә яннарында кунган, кайгыларын уртаклашкан. Хәзер ул авырып ята, килә алмый, карый алмый. Ә ерак туганнары, кардәшләре? Нигә килмиләр алар, нигә бу нарасыйларны, сабыйларны үз канатлары астына алмыйлар? Әтиләре сугышта... Әниләре буранлы төндә югалган. Бөтенләй ятим калганнар... Алайса, авыл советы ни карый? Нигә берәр чара күрми?.. Нишләргә, ничек аларны бу хәлдән коткарырга?.. Шунда ук күңелемнең бер почмагыннан җавап килде: нишли алам мин? Кулымнан ни килә минем? Мин, гарип

солдат, әле кеше шикелле аягыма да баса алмыйм, хәтта, авылыма кайтып житә алмыйча, ярты юлда аунап ятам... Алар гынамы икән монда ач балалар? Күрше йортларда, күрше авылларда?.. Бөтен Идел буенда?.. Шулай да, нишләргә?..

Ниһаять, йоклап киткәнмен булса кирәк. Бераздан, күпмедер вакыттан соң янымда, сәкедә, нәрсәнеңдер мышнавын, кыштырдавын ишетеп, күземне ачтым. Аяк очымда, чыннан да, нидер кыймылдый. Нәрсә булуы мөмкин моның? Мәчеме?.. Мәчеләре юк иде кебек. Алайса, кем соң бу? Игътибар белән

рәк карасам, тәрәзәдән төшкән сүрән ай яктысында, аяк очымда, сәкедә, шалама бишмәтенә төренеп, балаларның берсе утыра. Кайсысы? Малаймы, әллә кечкенә кызмы?

— Нишләп утырасың монда? — дидем мин аңа пышылдап кына.— Ник йокламыйсың? Туңасыңмы әллә?

— Юк, туңмыйм, — диде бала. Малай тавышы — Сәмит икән.

— Эчәсең киләме әллә?

— Юк, килми.

— Алайса, нишләп утырасың? Бар, менеп ят. Йокла.

Малай җавап бирмәде, борынын гына тартып куйды.

Йоклый алмаслыгымны белсәм дә, шинелемне яңадан башымнан ук ябынып, күземне йомдым. Бераз ял итәсе иде.

Берничә минуттан соң баланың еламсырап эндәшкән тавышы ишетелде:

— Абый... абый дим...

Башымны шинель астыннан чыгардым. Бала һаман шунда, аяк очында.

— Нәрсә кирәк сиңа? Ник әйтмисең?.. Йокым килә минем. Бар, ят.

Бала, пыскылдап, күз яше аралаш нидер әйтте, аңлап җиткермәдем, кайтарып сорадым, әтине күрмәдеңме, дип сорый икән.

— Кайда?

— Сугышта.

Йокым качты. Яткан җиремнән торып утырдым. Ни дип әйтим мин бу балага, ничек җавап бирим? Сугышны ни дип белә, ничек итеп күз алдына китерә икән ул аны? Мин сугышта булгач, әтисен күргәнмендер, дип уйлый, ахры. Бала, бала, гөнаһсыз җан! Ничек итеп мин күңелеңне кырмаслык, рәнҗетмәслек җавап табыйм?

— Күрмәдем, матурым, күрмәдем шул, — дидем мин аңа. — Кил әле, янымарак килеп утыр. Икәү бергә җылырак булыр. Туңгансың. Күрәсең, ничек калтырыйсың.— Шул сүзләр белән мин аны үз яныма тартып китердем дә, ятсынуына, карышуына карамастан, кочагыма алдым. Бик ябык, шыр сөяк кенә иде ул. Бераздан, бер-ике җылы сүз әйтеп башыннан сыйпагач, бала тынып калды, хәтта миңа бераз сыена да төште, чөнки бик туңган, бөтен тәне белән калтырый иде. — Юк шул, очратмадым әтиеңне, акыллым, күрмәдем.

— Ә мин тагы күргәнсеңдер дип торам. Апа әйтә: күргәндер, ди. Икесе дә сугышта булган ич, ди.

— Бик зур сугыш булды, бәгърем, бик зур сугыш. Халык бик күп иде анда. Күргән булсам, әйтер идем: күрдем, дияр идем. Күрмәдем шул. Бәлки әле әтиең юлдадыр... Сезнең янга кайтып киләдер... Сезгә күчтәнәчләре дә бардыр...

Бала бер сүз дә әйтмәде, бары борынын тартканы гына ишетелде. Бала, бала, сугышның зурлыгын, аның дәһшәтен, андагы канны, анда һәлак булып, җирне кочып, ятып калган абыйларның, аталарның, меңнәрчә-меңнәрчә икәнен ничек аңлатып бирим сиңа? Нарасый, нарасый...

Тамагыма нидер тыгылды, сүземне әйтә алмас булдым.

Бераздан бала үз-үзе белән сөйләшкәндәй әйтте:

— Әти кайтмый да кайтмый... Хат та язмый үзе...

— Кәгазе юктыр, акыллым, шуңа язмый торгандыр. Кәгазе булса,

язар иде, язмый калмас иде. Бәлки, карандашы да юктыр... Сугышта анда кәгазь дә, карандаш та юк... Мылтык кына бар...

— Әни әйтә, кайта ул, ди, кайтмыйча калмый, ди... Кайтыр бит?

— Нигә кайтмасын? — дидем мин, тавышымны мөмкин чаклы тынычрак чыгарырга тырышып. — Кайтыр, кайтмыйча калмас, акыллым... Менә мин, аягым яраланган булса да, кайтып киләмич... Бар, ят, матурым, йокла.

Малай бераз тынычланды булса кирәк, сәкедән төшеп, мич башына менеп китте.

Иртә белән, бу салкын, күңелсез өйдән чыгып китәр алдыннан, мин капчыгымны яңадан кулыма алдым, ярманың калган өлешен Фәһимә китереп биргән табакка бушаттым, ипинең дә бар хәтлесен сәкегә алып куйдым. Капчыгым бушап, җиңеләеп китте. Тукта, капчык төбендә берничә конфет бар бит әле. Кызыл Армия көнендә безгә аны шәһәр эшчеләре күчтәнәч итеп алып килгәннәр иде. Авызыма кабып карамыйча, әни карчыкка дип саклый идем. Берәрне нәниләр кулына тоттырдым. Конфет дигән нәрсәне күргәннәре юк икән. Бирүем булды, бу нәрсә икән дип гаҗәпләнеп, бер конфетка, бер миңа караштыргалап алдылар. Нәрсә икәнен аңлатып бирергә туры килде.

Капчыгымны аркага кидем, таягымны кулыма алдым. Тыныч кына чыгып китәрмен дип уйлаган идем, булмады, саубуллашканда бугазыма тагын нидер тыгылды.

Балалар, тәрәзәгә сарылышып, артымнан карап калдылар.

Аякларым бераз ял иткән булса да, күңелем, җаным ял итмәгән, тыныч түгел, әрни иде. Шул әрнү мине авыл советы председателе өенә таба алып китте. Кызганычка каршы, аны очрата алмадым, волостька китте, диделәр. Аның белән бергә секретарь да киткән икән. Инде нишләргә, кая барырга, кем белән киңәшергә? Бу сабыйлар турында берике сүз әйтмичә, авылдан чыгып китәсем килми.

Минем урам буйлап аксый-аксый килеп, авыл советы председателе өенә кереп китүемне һәм аннан шунда ук әйләнеп чыгуымны күрше йортларның берсендә яшәүче бер агай җил капкалы ишегалдыннан карап торган икән. Урам уртасында туктап, нишләргә белмичә, аптырап басып торганда, ишегалдыннан чыгып, туп-туры миңа таба килә башлады ул, мин дә аңа таба юнәлдем, сәлам бирдем. Агай, бик күптәнге таныш кебек, ике кулын биреп күреште дә, исән-саулыгымны сорашканнан соң, бер-бер артлы бирелгән сораулары белән күмеп ташлады: каян кайтып килеш, сугышта кайларда булдым, кайда яралан дым, госпитальдә күпме яттым, ялга ничә айга кайттым, кайсы авылныкы, кем улы һәм башка шуның кебекләрнең берсен дә калдырмады. Сакалына шактый чал кергән, кыршылган сары тунлы, мескен бүрекле бу агай дөнья хәлләре белән дә бик кызыксына икән. Бу турыда да берничә сорау бирде. Миңа әлеге балалар турында авылның берәр күренекле кешесе белән сөйләшергә кирәк иде. Бу турыда агай миңа ярдәм итмәсме икән дигән өмет белән мин аның барлык сорауларына кыскача гына булса да җавап бирүне кирәк таптым. Ахырда ул авыл советы председателенә булган йомышымның нидән гыйбарәт икәнен белгәч, башын кашып, бераз уйланып торды да:

— Беләбез ул балаларны, беләбез, — диде. — Әтиләре сугышта үлгән. Әниләре... Бик күп бездә ятимнәр хәзер... Бик күп! Перчиләтелебез шулар турында сөйләшергә дип китте дә булыска. Дөрес булса, калада балалар йорты ачыла икән. Ятимнәрне җыялар, ди... Боларны шунда урнаштырып булмасмы икән, дибез.

Ахырда мин аңардан:

— Әллә син, абзый кеше, авыл советы идарәсе әгъзасымы? — дип сорадым.

Абзый җавапны көттермәде:

— Әгъза түгел, мондый гына кеше... Сәвиткә булышып йөрүче генә. Булышмыйча ярамый, энем. Ярамый. Заманы шундый. Бик авыр заманда яшибез. Ил өстенә бәла артыннан бәла кара болыт булып килеп кенә тора... Сугыш дисеңме, ачлык дисеңме, барысы да... Булышмыйча ярамый. Шундый гына кеше мин, әгъза түгел.

— Ачлар күпмени шулай?

— Бик күп! — диде агай, ачларның күплеген белдерергә теләп, башын чайкап торды, аннары, басым ясап, кабатлап әйтте: — Бик күп! Ачлыктан җәфа чикмәгән йорт юк хәзер. Шөкер, соңгы айларда сәвит балаларга ярдәм итә башлады. Авызыннан өзеп булса да, бирә. Бик рәхмәт аңа! Көненә бер аш, бер телем ипи дигәндәй, бик ярап куя ул хәзергесе көндә. Әгәр ул булмаса, эш харап иде, энем. Чебен кебек кырылыр иде балалар. Рәхмәт сәвит власына! Рәхмәт! Әти-әниләре булганнарга җан асрарлык бар.

Бу хәтлесен белми идем, ишетмәгән идем. Җаныма бераз җылы кереп китте. Балалар харап булмаслар...

Юл кешесенең юлда булуы яхшы. Саубуллашып, китеп бардым.

Аякларым һаман сызлый, яралысы белән чак кына басам.

Кырык-илле адым чамасы китәргә дә өлгермәдем, артымнан әлеге агайның миңа кычкырган тавышын ишеттем:

— Әй, энекәш, тукта әле!

Тагын нинди соравы калды икән бу агайның дип уйлап, баруымнан туктадым.

— Юк, энем, бу хәлдә авылдан чыгып китәргә ярамый сиңа, — диде ул, яныма килеп җиткәч. — Ярамый! Күреп торам, чак атлыйсың. Юлда бөтенләй аяксыз калуың бар...

— Нишлим, олау ялларлык хәлем юк. Станциядә ялларга маташып караган идем дә, бик күп сорадылар.

— Һе-е, эне кеше, син әле безне белеп бетермисең икән. Белмәсәң, әйтим: сугыштан яраланып кайтучы кызылармисларне без авылдан-авылга ат белән озатабыз. Заманы авыр булса да, озатабыз. Сезнең кебекләр бик кадерле безгә. Ребәлүтсия өчен сугышып йөрүчеләр бит сез. Безнең авылныкы булмасаң да — илнеке син. Шулай менә, энем.

Агайның сүзләренә бик шатландым. Чыннан да, бу аякларым белән өйгә кайтып җитәр идемме икән?

Ул мине үз өенә алып китте:

— Хәзергә миндә утырып тор. Җылын, җал ит. Ә мин ул арада олау ягын карыйм.

Агай бер улының Кавказ ягында сугышта икәнен әйткән иде инде. Хәзер ул аны яңадан исенә төшерде:

— Кем белә, бәлки, минем Әхмәтем дә, бу сәгатьләрдә кайда булса да, сезнең кебек, аксый-аксый, җәфа чигеп, каңгырап йөри торгандыр... Белмәссең, белмәссең... Я алла, барлык бәла-казалардан, дошман пуляләреннән үзең сакла аны!..

Агай, чыннан да, авыл советына булышып йөрүче кешеләрнең берсе икән. Сүзен тыңладылар, бер сәгать чамасы вакыт узмады, аның капка төбенә миңа дигән җигүле ат килеп туктады. Мин инде кунакчыл хуҗаның җылы өендә, сәке кырыена утырып, бәрәңге кушып пешерелгән алабута ипиенең кадерен белеп, кечкенә-кечкенә генә капкалап, чәй эчеп бетергән идем. Чәе дә тәмле иде — кишер чәе.

Көрмәсез чанага утырып, авылдан чыгып киттем. Юл яхшы, тауга түбән, олаучы да яшүсмер, җирән кашка да елдам.

Авылдан ераклашканнан-ераклаша барам, ә күңелем, җаным шул авылда, салкын өйдә, ятим балалар янында. Алар һаман шулай, өчесе бергә тәрәзәгә сарылышып, әниләренең кайтуларын зарыгышып көтеп торалардыр шикелле...

# Роберт Миңнуллин

## ҖАЙДАКЛАР БЕЗ

### Вакыт

Вакыт төшенчәсе
Хәзер инде бүтән.
Һич өлгереп булмый —
Хәлдән таеп бетәм.

Гасыр белән сәгать
Тәңгәлләшер беркөн.
Эшләр шуңа бара —
Туктаталмас беркем.

Тыгызлана Вакыт —
Тора-бара нишләр?
Бер елга да җитми
Бер гасырлык эшләр.

Кысылмасмы соң ул
Шартлар дәрәҗәгә?!
...Чиртеп узды Вакыт
Минем тәрәзәгә.

### Таулар. Диңгез.

Бер ягымда — таулар минем,
Бер ягымда — диңгез.
Хыял җитми — төнлә белән,
Караш җитми — көндез.

Кайсысына — тауларгамы,
Диңгезгәме тиң без?
Көнләштерә мине таулар,
Кызыктыра — диңгез.

Биеклекләре — буй җитмәс,
Киңлекләре — тиңсез.
Акылымны таулар тарта,
Күңелемне — диңгез.

Мин үзгәрдем. Бик үзгәрдем.
Һәм аңладым: кем без?!
Әллә таулар шулай итте,
Әллә инде — диңгез...

* * *

Зәңгәр күкләргә карыйм мин —
Йолдыз калка.
Зәңгәр гөлләргә карыйм мин —
Чәчәк ата.

Зәңгәр диңгезгә карыйм мин —
Дулкынлана.

Зәңгәр учакка карыйм мин —
Ялкынлана.

Бу, билгеле, сихер-тылсым
Эше түгел.
Ахры, үзем бик үк гади
Кеше түгел!

## Үзгәреш

Әле генә җылы иде.
Салкынайтты кинәт.
Өйрәнеп тә булыр иде —
Миңа җылы кирәк!

Әллә нәрсә булды әле —
Минем сәер чагым:
Җылыны да, салкынны да
Бик тиз сизә җаным.

Бу салкыннар бетәрме бер?
Дәвам итәр гелме?—
Йолдызларны кырау сукты,
Салкын алды гөлне.

Үзем — ир уртасы, үзем —
Һаман бала кебек.
Дәртнең кайнарлыгы гына
Кимеп бара кебек.

Салкын күз карашларын да
Хәзер бик тиз тоям.
Шушыларны уйлыймын да,
Мин сискәнеп куям.

Күнеккән идем җылыга,
Салкынайтты кинәт:
Я дөнья, я минем белән
Нидер булган, димәк.

## Көрәшче

Мәйданның кыл уртасына
Яшь малай башлап чыга.
Башлап чыккан малай ләкин
Мәйданны ташлап чыга.

Җиңе белән сөртә яшен —
Хәле түгел җиңелдән.
Беренче кат көрәшкән ул,
Беренче кат җиңелгән.

Батыр булып өлгергәнче
Күз яше күп түгелер.
Тик бүген күрше кызына
Малай ничек күренер?!

Кысыла аның тешләре,
Йодрыклары — төйнәлә.
Кысылсын, әйдә, төйнәлсен —
Ул җиңәргә өйрәнә!

Ул җиңәргә тиеш әле —
Карар инде кылынган.
Җиңелсә дә, сөлгесе бит
Ычкынмаган кулыннан.

Ә сөлгесен җиңгәч кенә
Җиргә ташлаячак ул —
Бүгеннән яңа сабантуй
Көтә башлаячак ул!

## Кояш

Бик үзгәргән бүген кояш.
Хикмәт, белмим, нидәдер?
Ул нигәдер җылытмый да,
Яктыртмый да нигәдер?

Чыкканда да чыкмады ул
Элек чыккан урыннан.
Очып узды ул көндез дә
Икенче бер урыннан.

Икенчерәк — нурлары да,
Төсе дә башка төстә.

Алыштырганнардыр аны,
Башка кояштыр — өстә!

Чыннан да, чын кояшмы ул?
Кичәгеме, түгелме?—
Кайчаннан бирле шул сорау
Тырнап тора күңелне.

Нигә борчылам соң әле?
Ул — шул кояш бугай ла!
Юк, барыбер тикшерергә
Кирәк аны шулай да!

## Туган ягым моңы

Туган яктан, балачактан
Иярә килгән моңым
Тынгы бирми миңа. Берәр
Чиге булырмы моның?

Йөрәгемдә йөри ул моң.
Ничә еллар. Кимеми.
Ул һәрвакыт үзем белән —
Яңа откан көймени?!

Өйрәндем инде ул моңга,
Ул һәрчак кирәк кебек.
Кирәк ул миңа җан кебек,
Кирәк ул йөрәк кебек.

Моңсыз була ташлар гына.
Кеше моңсыз — имансыз!
Яшәү юк миңа ул моңсыз,
Кеше түгел мин ансыз.

Ярый ул бар! Нишләр идең
Әгәр ул моң булмаса?
Уйласам да туган якны,
Күңелемне моң баса.

Туган ягым моңы! Әллә
Ул мәңгелек моң микән?!.
Күңелгә сыя туган җир —
Үзем сыярмын микән?!

## Каен суы

Каен суы, кайгы суы —
Каенның күз яшьләре.
«Кыенмы?» — диеп сорадым,
Каеннар сүз дәшмәде.

Мин дә бит каен күңелле,
Яралы каеннарым —
Минем ак куанычларым,
Минем ак кайгыларым.

Үзебезнең каеннар сез!
Каеннар, сез — бәясез.

Сезгә кем кул күтәрәдер? —
Сез дә сирәгәясез.

Сезнең белән бергәләшеп,
Утырып елыймммыни?
Берәрегез урынына
Каеннар булыйммыни?!

Әйдәгез, бергә йөгерик!—
Мине дә җитәкләгез.
Телисез икән, мине дә
Каен дип исәпләгез!

## Шулай кирәк булган

Сугыш беткәннән соң нәкъ өч елдан
Мин туганмын. Шулай кирәк булган!
Мин туганмын. Туган илем минсез
Бер егеткә әле кимрәк булган.

Японнарны җиңеп кайткан Әткәй
Яңгыратып көлгән улын күргәч.
Рәхәтләнеп бер елаган Әнкәй
Бишегендә яткан улы көлгәч.

Гаиләдә — мин беренче бала.
Бабамнарга — мин беренче онык.
Нәселемнең яңа буынын мин
Башлаганмын иң беренче булып.

Тугансыңдыр син көлмәкчән диләр.
Андый бәхет тия кемгә генә?
Мин көлмәкчән тумасам да, мине
Биләгәннәр әткәй көлмәгенә.

Бик кадерле кеше булганмындыр —
Затлы көлмәкләргә биләрлек мин.
Шулай булгач, бу дөньяга инде
Көлмәк белән туган диярлек мин.

Икмәк белән бергә өлгергәнмен —
Туганмын бит урак өстендә мин.
Мине Илем көткән, Җирем көткән,
Шуның өчен тизрәк үстем дә мин.

Кемдер иртә туган, кемдер соңрак,
Ул чаклысы нигә минем өчен?
Ә мин үзем вакытында тудым,
Нәкъ кирәктә тудым Илем өчен!

Ә бабамнар мине зур бер кеше
Булыр диеп өмет иткәннәрдер.
Аклап булмас, ахры, өметләрен —
Алар миннән күбрәк көткәннәрдер...

Тик дөньяның утын-суын мин бит
Ахыргача әле кичмәгәнмен.
Ә шулай да бу дөньяга туып,
Миңа калса, дөрес эшләгәнмен.

Мин туганда асыл ир-егетләр
Туган илдә әле сирәк булган.
Сугыш беткәннән соң нәкъ өч елдан
Мин туганмын. Шулай кирәк булган!

## Җирсү

*Мин әткәй эшләп киткән авылда — Нәҗәдедә туганмын. Ул авыл күптән юк инде.*

Мин анда туганмын гына —
Мин аны хәтерләмим.
Күпме генә җирсесәм дә,
Ул хакта хәтер — ләм-мим.

Тик барыбер оныталмыйм
Мин туган нигеземне.
Ул таралганга — гаепле
Саныймын мин үземне.

Чөнки башлап мин киткәнмен,
Ә калганнар — миннән соң.
Авылымның таралырын
Ул чакта кем белгән соң?!

Китмәс идем, калыр идем
Белсәм болай булырын...
Нигезем изге булгандыр —
Иген кыры ул урын.

Юк инде мин туган нигез,
Юк инде туган авыл.
Туган авылсыз калулар
Бик авыр икән, авыр!

Табалмадым ашыксам да,
Кайтсам да туры гына...
Чәчәкләр салып калдырдым
Авылым урынына.

## Җайдаклар без

Буйга бәләкәй идем мин,
Көчсез идем. Аннары
Тия иде атларның гел
Баш бирми торганнары...

Карап торуга тыңлаучан,
Түгел үзе кыргый да.
Атлануга үрә баса,
Кинәт кенә ыргый да,

Алып сала сине җиргә —
Җилләр исә атыңнан.
Йөгерәсең елый-елый
Качкан атың артыннан...

Соңыннан егылмаска да
Өйрәндем мин. Нишлисең?!
Дуласа да, аттан инде
Син егылып төшмисең.

Алдан беләсең — атыңның
Ярсыйсын, котырасын.
Шуңа күрә тезгенеңә
Ныгытып тотынасың.

Ат, әлбәттә, юашланмый,
Бик тә егып чабасы...
Тик егылмый. Шул чагында
Калмагачтын чарасы

Каера да читкә алып
Кереп китә андый ат.
Ә аннары бер ярсыса
Юк, тыела алмый ат.

Син дә, хәтта ат үзе дә
Белми кайчан туктасын.
Сыртында бәргәләнәсең
Һәм беләсең — екмасын.

Ат та бата ак күбеккә!
Канга бата... учларың...
Әлегедәй хәтеремдә
Шулай атта очканым.

Яралар инде төзәлде.
Тик мин атта... мәңгегә! —
Учлар — кысылган. Юк бары
Кулда тезгенем генә...


-----------------



# КАЗАНДА ТУКАЙ УРЫННАРЫ

**Бер заман бардым Печән базарына,**
**Шунда мин таптым азык язарыма...**

Г. Тукай. «Печән базары яхуд Яңа Кисекбаш».




Печән базарының «Көфер почмагы» (хәзерге Париж Коммунасы һәм Киров урамнары чаты).

Татьяна Зуева рәсеме.

# ГАБДУЛЛА ТУКАЙ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘР

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының фольклор фондында культура тарихына караган, шул исәптән, татар әдәбиятына кагылышлы материаллар да бар: татар язучылары турында истәлекләр, фоторәсемнәр, хатлар, телеграммалар, язучыларның кульъязмалары һ. б. Алар арасында татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай турындагы истәлекләрнең зур хәзинә буларак саклануын әйтергә кирәк. Алар фондка төрле елларда кергәннәр. Шуларның икесен журнал укучыларына тәкъдим итәбез. Беренче истәлек Хәйрулла Рәхмәтуллиннан 1958 елда Х. Ярми тарафыннан Пенза өлкәсе Сосновобор районы Индерка авылында язып алына. Икенчесен Х. Гатина 1961 елда Астрахань өлкәсенә оештырылган фольклор экспедициясе вакытында язып алган. Ул артистка Гайшә Камаеваның Габдулла Тукай белән очрашу хатирәсе. Бу истәлекләр матбугатка беренче тапкыр тәкъдим ителә.

**Асия ГЫЙЛӘҖЕТДИНОВА.**

## Беренче истәлек

Мин кече яшьтән 1912 елларга хәтле Эргәземдә[1] Дебердеевларның (алар өч туган — Ишмөхәммәт, Әхмәтҗан, Мәхмүд, аннан соң Йосыф Хаҗи иде) фабрикасында эшләдем.

Кайсы елны икәнен хәтерләмим, әллә 1908, әллә 1909 елны инде, җәй көне иде. Эргәзем фабрикасына Габдулла Тукай килеп чыкты. Ул Дебердеевларга килде. Ялгышмасам, ул Сембер ягыннан Тимербулат Акчуриннардан кайтышлый иде. Мин ул вакытта Дебердеевлар фабрикасы конторасында курьер булып эшли идем.

Тукайны яхшы гына каршы алдылар. Шулай да байлар Тукайны үз өйләренә алмадылар. Контор каршында, аппаратный цех янында бер бүлмә бар иде. Анда өчме, дүртме караваг бар иде. Фабрикага килгән кешеләр шунда керәләр, шунда куныл чыгалар иде. Безнең квартир ерак булганлыктан, кайчак мин дә конторда куна идем. Шул сәбәпле, мин килгән кешеләр белән аралаша идем. Тукайны да шунда күрдем. Ул шул бүлмәдә өч көнләп торды, шуннан бик күңелсез генә китеп барды. Мин Тукай белән, үзе гади генә кеше булгач, сөйләштем. Ул миңа: «Мин монда китапханәләр ачарга килдем, болар белән килешә алмадым. Мин җәмгыять эше белән, халык эше белән йөрим, болар белән килешеп булмады»,— диде. Мин аңар: «Ярар, хат язышып торырбыз»,— дидем. Ул: «Мин синең хатыңа җавап бирә алмам шул...»— диде.

Фольклор фонды, коллекция 64, папка 1, саклау берәмлеге 19.

## Икенче истәлек

Габдулла Тукай 1911 елда Астраханьга килгән иде. Г. Тукай килүенә багышлап С. Рәмиев әсәре буенча «Яшә, Зөбәйдә, яшим мин!» исемле спектакль куйдылар. Тукай башына кара маһмалдан (бәрхет) кәләпүш кигән иде. Астраханьда Сабир Бикмабетов дигән бер кеше бар иде. Трамвай йөртүче. Бер вакытны шул Сабир абый

---

[1] Эргәзем — революциягә кадәр Саратов губернасының Кузнецк өязе Верхозимо авылы.

мине чакырырга килгән. Мин ул вакытта бик оялам. Ул вакытны без чапан белән генә йөри идек. Сабир абый әйтә: «Ул бик матур итеп татар көйләрен уйный белә»,— ди. «Без аны өеннән тартып чыгара алсак, артистка булырга да ярый торган кеше ул»,— ди. Мин инде үзем белән сазымны да (бу якта гармунны шулай диләр) алып барам. Башта мин «Баламишкин» көен уйнадым. Аннан Тукай әйтә:

— Син, ди, авыл көйләрен дә уйный белә торгансыңдыр, туташ,— ди.

— Минем исемем «туташ» түгел, Гайшә,— дим мин.

— Ярар алай булгач, авыл көйләрен дә уйный белә торгансыңдыр, Гайшә,— ди.

— Мин көйләрне уйный беләм, исемнәрен белмим,— дим.

— Уйнап кара әле,— ди Тукай.

Уйный башлаган идем, мин уйнаган көйгә Тукай ике җыр җырлады. Хәзер сүзләрен хәтерләмим, Бөрсенең башын болай дип башлаган иде:

*Уйсу җирнең сазы мин*
*Сулы җирнең казы мин...*

Тукай әйтә миңа шуннан соң:

— Син бу көйләрне оныгма, сазда уйный тор, ди. Син кечкенә генә тальянка алып җибәр,— ди.

Мин әйтәм:

— Бездә тальянка мут [1] түгел,— дим.

— Без сине скрипкага уйнарга өйрәтербез,— ди Тукай.

— Әй, аны ирләр генә уйный, кызлар уйнамый,— дим. Аннан мин әйтәм:— Мине бит өйдән чыгармыйлар,— дим.

Тукай әйтә:

— Без сине тагы да чакырырбыз, килергә тырыш,— ди.

Мин бер сүз дә әйтмичә, өйгә кайтып киттем. Мине Сабир абый озата барды. Ул вакытта бездә шулай иде бит, чакырып алып киткән кеше өйгә китереп әниләргә тапшырып китә иде.

Шуннан соң инде мин Сара Байкиналар белән катнашып, шәһәрнең кышкы театрында куела торган спектакльләргә катнаша башладым.

Фольклор фонды, коллекция 71, папка 1, саклау берәмлеге 31.

# ТУКАЙ АВТОГРАФЫ

Габдулла Тукай бу фоторәсемне «Мөхтәрәм Әхмәтгәрәй вә Габдрахман әфәнделәргә ядкарь, 5 нче август, 1912 сәнә. Г. Тукаев»,— дип язып үзенең якын дуслары «Гасыр» нәшриятын һәм «Аң» журналын оештыручылар Әхмәтгәрәй Хәсәни һәм Габдрахман Рәхмәтуллинга (Габдрахман Кәрам) бүләк иткән. Тукай тарафыннан үзләренә бүләк ителгән фоторәсемне Әхмәтгәрәй Хәсәни һәм Габдрахман Рәхмәтуллиннар, шагыйрь вафат булгач, «почтовая карточка» итеп бастырып таратканнар. Моның шулай икәнен бу фотоның артына татарча: «Габдулла Тукаев», русча «Абдулла Тукаев. Собственность изд. «Гасыр» дигән язулар да күрсәтеп тора.

Бу «почтовая карточка»ны «Галия» мәдрәсәсе шәкерте Әбүбәкер Җәгъфәрев мәдрәсәнең хуҗалык эшләре мөдире Гариф Сәйфуллинга 1913 елда бүләк иткән. «Почтовая карточка» артына русча: «Уфа, Медресе «Галия». Зав. Гарифу Сайфуллину»,— дип язылган. Уфа почтасының мөһерендә: «26.10.13» — дип күрсәтелгән. Ләкин бу «почтовая карточка»ның кайдан җибәрелгәнлеген әйтүе читен, чөнки мөһере бозылган.

[1] Мут — мода.

Әгәр дә бу автографлы фоторәсем бер генә нөсхәдә булса, ул «Галия» шәкерте кулына кермәс иде. Димәк, без уйлаганча ул Г. Тукайның автографлы фоторәсеменнән, шагыйрь вафат булгач, күбәйтеп бастырылган. Бу фоторәсемне беренче булып бастырган Д. Баһаутдинова икенче карашта тора. («Социалистик Татарстан», 1978, 23 апрель).





«Почтовая карточка»ның артында искә алынган Гариф Сәйфуллин — үз дәверендә Уфаның алдынгы татар яшьләреннән берсе. Г. Коләхметовның аңа 1918 елда язган хаты «Казан утлары»ның 1981 ел бишенче санында басылып чыккан иде.

Шулай ук Астрахань укытучысы Шәһит Гайфинең дә Тукайның кайбер шигырьләренә фотомонтаж ясаганлыгы тарихта билгеле факт. Мәсәлән: шагыйрьнең «Бер шәехнең мөнаҗәте» исемле шигыренә ясалган инсценировканың фоторәсеме, шулай ук Г. Тукай, С. Рәмиев һәм Ш. Гайфи көймәдә утырып төшкән итеп ясалган фоторәсем дә бар.

Менә безнең кулыбызда тагын бер фотомонтаж. Г. Тукайның күктә болытлар арасында башы гына күренә. Аска исә шагыйрьнең «Өзелгән өмид» шигыреннән өзек китерелгән:

Очты дөнья читлегеннән тарсынып күңлем кошы,
Шат яратса да, җиһанга ят яраткан раббысы.

Әлбәттә, мондый фотомонтажның шагыйрь исән вакытында чыгуы мөмкин түгел. Бу тик шагыйрь үлгәч, 1913 елдан соң эшләнгән фотомонтаж булырга тиеш. Открытканың артында кайсы матбага тарафыннан эшләнүе язылмаган. Тукай иҗатына бәйле фотомонтажларның бары тик Шәһит Гайфи тарафыннан гына эшләнүен искә алсак, бу да аның тарафыннан чыгарылган булса кирәк дип уйларга нигез бар.

**Хәсән ГОБӘЙДУЛЛИН.**

**Кави Латыйпов**

# ТОРМЫШ ИЯРЕ — ҺӨНӘР

ОЧЕРК

Бабасы белән әбисе тәрбиясендә үскән Хәйдәр балачагыннан ук олы дәрьяда ал җилкәнле көймәдә йөзәргә хыялланган иде. Шул өметтеләгән тормышка ашыру нияте беләнме, ун классны тәмамлагач, ул Васильевода яшәүче әнисе янына күчеп килде һәм олы дәрья — Иделгә гашыйк булды: пароходлар, судноларны күзәтте. Үсмерне бигрәк тә двигательләр тавышы, аларның ритмлы эшләүләре җәлеп итте. Иделдә йөзгән пароходлар Хәйдәргә җанлы сыман тоелды. Алар белән ул дулкыннар аша сөйләшкәндәй, аңлашкандай булды. «Әйе, син уйлаганча, Идел — олы дәрья, ләкин тормыш аңардан олырак, җилкәнеңне шунда җибәр»,— диделәр кебек дулкыннар. «Чын романтика — тормышта, хакыйкатьтә»,— ди иде дөнья ачысын-төчесен татыган бабасы — Ватан сугышы инвалиды. Димәк, тизрәк тормыш итә башларга кирәк. Атта иярсез йөреп була, ә иярсез-һөнәрсез яшәп булмый. Хәйдәр тормыш иярләүне һөнәр үзләштерүдән башлады. Казандагы техник училищега укырга керде, теоретик яктан белем алды, металл белән эш итәргә өйрәнде, беренче көннәрдән үк җайланмалар, станоклар белән уртак тел тапты.

— Беренче адымнарың ышанычлы күренә, күз тимәгәе,— диде мастер үз шәкертенә.

Юк, әтисез үскән Хәйдәр күз тия торганнардан түгел иде, киресенчә, көн саен аның хезмәткә сәләтле икәнлеге ачыла барды, слесарьлык һөнәрен үзләштерүдә ышанычы тагын да артты. Училищеда уздырылган конкурс-ярышларда призлы урыннар яулап алды. Тырышлыклар бушка китмәде. Техник училищены тәмамлагач, өченче разрядлы һөнәр иясе слесарь-җыючы булып, мәшһүр мотор төзү берләшмәсенә эшкә килде. Мастер Габделфәт Кәримов үзе яшь эшчене завод белән таныштырып йөрде. Кая гына кермәсеннәр, «көрәк» дигән деталь белән маташтылар.

— Нинди «көрәк» ул? — диде Хәйдәр.

— Самолет моторына куела торган калакны «көрәк» дип атый халык.

— Нәни генә деталь шушындый мәһабәт станокта эшләнә дип һич уйламаган идем.

— Программалы станок ул, электроникага корылган. Ә нинди операция башкарыласы тасмага язылган.

— Шәп!

— Әйтәсе дә юк инде. Ләкин зарланучылар да бар. Бер киреләнсә, чыгымчы ат белән бер икән.

Тимерчеләр цехында да әлеге деталь күзгә ташланды. Хәер, авылда булганда, тимерче алачыгын күргәне бар иде Хәйдәрнең. Ә монда, заводта, дүрт тонналы чүкеч «көрәк» ясый икән, цех гөрселдәп тора.

— Сандалларда сугалар,— диде мастер.— «Көрәк» титан дигән бик чыдамлы металлдан коела. Җир казыр өчен түгел, ә самолет двигателе өчен. Болары элек-

трик мичләр! Ничек дөрләп яналар! Шулай да могҗиза тудыручылар тимерчеләр үзләре. Мәсәлән, Вилдан абыең. Таныштырыйммы?

— Башка вакытта.

— Бүгенге эшне иртәгә калдырма!

— Танышу — эш түгел бит ул.

— Хөрмәтле кеше белән танышудан да зур эш бар микән?!.

Мастер яшь эшчене әлеге абый янына алып килде:

— Вилдан, таныш бул, Хәйдәр дигән егет бу!

Вилдан кулларын әйбәтләп кенә сөрткәч, яшь эшчегә сузды:

— Исәнме, алмаш!.. ГПТУданмы?

Аннары мастер яшь эшчене җыю цехына алып килде. Иркен, киң, якты. Шушы иркенлектә, яктылыкта эшчеләрнең киң күңеллелеге сизелә, якты йөзләре чагыла. Аларның күпчелеге яшьләр икән. Мыеклары да чыкмаган. Ак халатлы эшчеләр җылы хисләрен детальләрдә сурәтләп бирәләр кебек.

— Чәчәкләр бәйләме ясыйм,— ди слесарь-җыючы.— Үз эшемне мин сәнгать дип таныйм. Үзең уйлап кара: безнең өстәлдә йөз төрле инструмент. Һәр эшче катлаулы операция белән мәшгуль. «ИЛ-86» аэробусы өчен мәһабәт мотор ясала. 350 пассажирны һавага күтәрерлек. Бер деталь туксан тугыз кеше кулы аша үзә. Йөзгә бер генә тулмый икән дип көләләр. Йөзенчесе дә бар аның. Генеральный конструктор үзе — кырыкмаса кырык тапкыр тикшерә... Безнең цехта еш була, эшчеләр белән сөйләшә, киңәшә. Үзе генерал, үзе академик.

— Бу цехта иң әйбәт кешеләр эшли — олылар да, яшьләр дә шундыйлар. Айныткычка эләксәң, җыю цехы белән саубуллаш инде.

Көнләшеп куйды Хәйдәр ак халатлы мыексыз яшьләрдән.

Ниһаять, музейга да чират җитте.

— Хезмәт даны музеена халык сукмагы өзелми,— диде мастер.— Чын мәгънәсендә тәрбия мәктәбе!

Гади эшчеләр, атаклы конструкторлар турында язылган кыска һәм тыйнак җөмләләр яшь эшче күңелендә горурлык хисләре уятты. Мотор төзү берләшмәсе — Социалистик Хезмәт Геройлары, Ленин һәм Октябрь революциясе ордены кавалерларын үстергән урын икән.

— Тыныч хезмәт фронтында да герой булырга мөмкин,— диде мастер.

Музейда утызынчы елларда эшләнгән беренче мотордан алып, иң соңгысы — реактив двигательгә кадәр бар. Кешеләр күрмәгәндә генә Хәйдәр аларны куллары белән капшап та карады.

— Я, кайсы цехта эшләргә исәп? — диде мастер.

— Җыю цехында, әлбәттә, мин бит җыючы-слесарь.

Хәйдәр көймә моторлары җыя торган группада эшли башлады. «Привет» маркалы мотор җыела иде.

— Ә минем самолет моторы белән эш итәсем килгән иде,— диде Хәйдәр.

— Сабыр иткән — морадына җиткән. Башта көймә моторы җыярга өйрән!

— Көймәнең җилкәнлесен хуп күрәмен мин. Аннары, көймә моторы җыеп кына тамак туйдырып булыр микән?

— Аңлаешлырак итеп әйт.

— Сатып алучылар бармы дип әйтүем.

— Ничек кенә әле! Заказлар килә генә тора. Алай гынамы соң, сатып алучы аерым кешеләр заводта үзләре була. Бер иптәш хәтта Хабаровск шәһәреннән килгән иде. Нәрсә өчен дисеңме? Мотор алыштырыр өчен. Төрле хәлләр булгалый, дөнья бу. Әйе, рекламацияләр килгәләп...

— Анысы нәрсә тагын?

— Моторны яраксызга чыгара торган рәсми документ. Ул кәгазь аркасында акча чыгарып түләүчеләр дә булгалады.

Аннары мастер яшь эшчене көймә моторы белән таныштырды.

«Привет» маркалы моторны җентекләп өйрәнергә керешкән Хәйдәр, двигательдәге һәр детальне хәтеренә сеңдерде. Тора-бара Хәйдәр Гайнетдинов үз эшенең остасына әверелде, үз эшендә генә түгел, көйләүче-җайлаучы буларак та. Деталь-

ләрдә кимчелек табылды исә, җыючы-слесарьлар «алтын куллы» Хәйдәргә мөрәҗәгать иттеләр, ә егет һәммәсенә ярдәмгә килде, яшьләрдән дә, олылардан да рәхмәт сүзләре ишетте.

Совет Армиясендә хезмәт итеп кайткач, Хәйдәр кабат үз цехына кайтты. Ул хезмәттәшләре арасында шул «Привет» маркалы моторлар җыя. Әйе, цехның исеме җисеменә туры килә, ачык йөз белән, сәламләп каршы алды коллектив үзенең элеккеге эшчесен. Кичәге солдат-командир, бүгенге эшче җиң сызганып эшкә керешә: мотор җыйды һәм механик вазифаларын башкарды, соңгысын акча алып түгел, ә бушлай, йөрәге кушканга, җәмәгать тәртибендә генә. Гади эшче цехның классы механигына әверелде, бер үк вакытта балта остасы һөнәрен дә үзләштерде.

Хәйдәр Гайнетдиновның белгән эшләре, аның төрле һөнәргә ия булуы цехка самолет двигательләренең бер узелын ремонтлау эше тапшырылгач кирәк булды. Хәйдәр кулы белән яңа корпуста йөздән артык төрледән-төрле станоклар көйләнде, эш урыннары җайланды. Ә бит баштарак, инде бөтен цех коллективы белән җитәкчелек итүче, Габделфәт Мөхәмматович Кәримов яңа хезмәт заданиеләрен үтәп булыр микән дип тирән уйга калган иде: «Күрше цехтан вакытлыча гына эшләргә килгән унике кеше белән генә шушындый җаваплы, четерекле эшне башкарып булыр микән? Гадәттә, вакытлыча эшләргә килүчеләр күбрәк акча хакында гына уйлыйлар...» Цех начальнигы аларның һәрберсе белән күзгә күз сөйләште һәм шушындый нәтиҗәгә килде: «Төрлесе бар икән, акча турында уйлаучылар да, производство хакында кайгыртучылар да. Димәк, көймә моторын җыючы элеккеге слесарьларны самолет моторын җыярга да өйрәтергә кирәк. «Көймәчеләр» үзләре дә самолет двигательләре белән эш итәргә атлыгып торалар. Ә менә вакытлыча цехка килүчеләр арасында станоклар телен аңлаучы, аларны көйләүче, җиһазлар һәм җайланмалар белән эш итүче кеше, ягъни механик, күренми. Самолет узелына кергән детальләрне җыяр өчен, беренче нәүбәттә, станокларны җайлау, көйләү кирәк. Моны тик Хәйдәр Гайнетдинов кына булдыра ала. Хәйдәргә шул ук группада эшләүче Иван Ракутько булыша ала.

Әллә ничә айлап, 1982 елның маеннан алып, шул ук елның октябренә кадәр, Хәйдәр белән Иван станоклар белән «җенләнделәр», станокларны, эш урыннарын самолет двигательләрен җыюга әзерләделәр. Хәер, Иван Данилович цехта вакытлыча эшләде, ул пенсионер иде. Шуңа күрә таякның юан башы Хәйдәргә эләкте. Ниһаять, Хәйдәр кулы белән көйләнгән йөз егерме станокта цех коллективы яңа заданиене үтәүгә керешә. Ә хәзерге вакытта цехта стартерлар эшләп чыгару, узган елның шул чоры белән чагыштырганда, өчләтә артты. Әйе, хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә Хәйдәр өлеше әйтеп бетергесез. Ул һәр станокның «холкын» белә. Хәйдәр җайлаган, көйләгән станоклар тигез эшлиләр. Гүя алар ияләренең кәефләрен бозмаска телиләр. Эшчеләрнең уртача айлык хезмәт хакы 250 сумга җитә. Цехта балта, тәпке, бөтерчек кебек көнкүреш кирәк-яраклары да җитештерелде. Хәйдәр Гайнетдинов планны арттырып үтәү өчен, җанын аямый эшли. Ул менә дигән балта остасы да. Цехтагы стенка, гардероб, шкаф, стеллажлар — барысы да аның кулы белән ясалган. Хәйдәр уйлаганча, тормыш — аргамак булса, аның ияре — һөнәр. Шуңа күрә ир-егет тормыш-аргамакны һөнәр белән иярли. Язучы Александр Грин тасвирлаган капитан кебек, Хәйдәр, кайчандыр, ал җилкәндә дәрьялар гизәргә хыялланган иде. Шушы ният белән ул корабль модельләре ясый торган түгәрәккә дә йөрде. Инде егерме алты яшьлек ир-егет Хәйдәр ал җилкәннәрне иҗат итә, һава океанына аэробус очыра, үзе шикелле хезмәт капитаннары бишьеллык алдынгылары Р. Сафин, Г. Иванов, Ф. Ваккасов, В. Доронинннар белән бергә.

Солдат онысы, эшче Хәйдәр Гайнетдиновның ун айлык улына өйрәткән беренче хакыйкате: «Хезмәт иясе — кеше», ә икенчесе — «Тормыш ияре — һөнәр». Нәкъ шигырьдәгечә:

*Хезмәт иясе — кеше,*
*тормыш ияре — һөнәр.*
*Иялене,*
*иярлене*
*бөтен тереклек сөяр,*
*кешеләр куккә чөяр.*

Мария Елизарова

# «ӘТИ КЕБЕК БУЛЫР ИДЕМ!»

Энҗе сокланып та, гаҗәпләнеп тә күккә карап торды. Күрсәнә: юргандай кар катламы нинди нәфис кар бөртекләреннән җыела икән! Кыз кулларын алга сузды, бөртекләр аның учын каплап алдылар. Үзләре шундый вак, үзләре мең төрле, үзләре бик тә җиңелләр — өрсәң, очып таралырга гына торалар. Ул сорауларына җавапны күктән көткән кебек тагын югарыга текәлде.

— Кызым, биеклектән ни эзлисең?

— Күрче, әни, бу кар бөртекләренең матурлыгын! Кем ясый соң аларны?

— Сөйләрмен, кызым, барын да аңлатырмын, әүвәл бар, аптекага кереп, миңа шушы даруларны алып кайт әле! Озак торма, мәктәбеңә соңга калырсың. Минем дә эшкә китәсем бар.

Эш турындагы сүз кызга тиз тәэсир итте. Эшкә соңга калырга ярамаганлыкны Энҗе яхшы аңлый. Сугыш бара. Эшкә соңга калу — дошман тегермененә су кою белән бер ул, шуңа күрә кыз аптека юлында да тоткарланып тормады. Хәтта йөгерде дә әле. Бит алмалары алсуланып чыкты.

— И-и, кызым,— дип каршылады аны әнисе.— Син һич тыныч кына була алмыйсың: я урам уртасында күкне күзәтергә тотынасың, я йөгерәсең. Инде менә тирләп чыккансың. Кил, ятып тор бераз, җылырак булыр, төрен!.

Исхаковлар гаиләсе шәһәр читендәге шактый дымлы тар бүлмәдә яши иде. Әти кешенең фронтта һәлак булганлыгын ишеткәч, алар районнан Казанга күчеп килделәр. Әнисенең абыйсы аларны шушы бүлмәгә урнаштырды.

Энҗе сугышка кадәр Буада яшәгән рәхәт көннәрен мәҗаралы әкият кебек искә төшерә. Андагы җылы, якты өйнең бүлмәләре берсеннән-берсе чиста, җылы иде. Әтисе — баш врач, әнисе — аптека мөдире. Өйдә алар көндез башкарган эшләр хакында сөйләшәләр. Энҗе аларның үзара, без кешеләрнең сәламәтлеген сакларга тиешбез, дип, үзара ант итешкәндәй сөйләшүләрен бик яхшы хәтерли. Больницадан терелеп чыккан һәр кеше алар өенә шатлык өсти, ә авыр хәлдәгеләр аларның уртак хәсрәтенә әйләнә торган иде...

Энҗе, башыннан ук томаланып, юрган астында ята, тын алу өчен калдырылган төштән күзләре генә ялтырый. Ул әнисен күзәтә. Әтиләреннән кайгылы хәбәр килгәннән бирле, әнисе бик нык үзгәрде, суырылып калды, йөрешендәге житезлек, ашкыну сүнгәндәй булды, зур, коңгырт күзләрен сагыш пәрдәсе каплады, елмаюы качты.

Куллары гына нәкъ элеккечә һаман эштә аның. Әнисенең куллары ни генә башкармый: карап торырга, авызга якын да китермәслек нәрсәләрдән тәмле аш пешерә — телеңне йотарсың. Әтиләренең иске кием-салымнарыннан Энҗегә җыпҗылы бишмәт тегеп киертте, гап-гади мамыкны эрләп, башлык бәйләде, иске бумази белән бәрхет кисәкләреннән гаҗәеп матур бияләйләр эмалләде. Әллә ниләр ясый белә ул...

— Әни, минем куллар да синекеләр кебек булыр микән? — Кыз, кулларын юрган астыннан чыгарып, әнисенә сузды.

— Бик теләсәң, булырлар, кызым. Мәктәбеңне әйбәтләп тәмамласаң, миңа булышкаласаң... Куллар эшкә шулай өйрәнәләр инде алар.

— Ә син хәтерлисеңме, әни: әтинең кулларын «алтын» дип йөртәләр иде?

— Әйе шул.— Ана елмаерга тырышты.— Ул бик авыр операцияләрне дә бик яхшы ясый иде. «Алтын куллы Закир» кушаматын шуннан чыгардылар.

— Үзен генә коткарып кала алмаган.

— Сугыш бит, балам.— Әни кеше бераз туктап торды.— Бәлки, әле исәндер дә...

Кыз башкача эндәшмәде. Әнисе озын бер көй суза башлады. Ул гел шулай, сүзләре әтиләренең һәлак булуына килеп терәлсә, тирән иттереп бер сулап куя да, әкрен генә көйләргә тотына.

Кызы аңа сокланып карап торды: үзе матур, үзенең чәче-башы да, киемнәре дә пөхтә. Нинди генә чагында да аның әнисе гел шундый җыйнак була. «Мин дә әни кебек ук тырышырмын, эшкә өйрәнермен, дип уйлый Энҗе. Урта мәктәптән соң да укырмын, әтием кебек врач булырмын. Авыру кешеләрне бик бирелеп дәвалармын. Бәлки, әле минем турыда да «алтын куллы» диярләр...»

— Әни, бөтен авыруларны да терелтеп булыр иде микән?

— Терелтергә кирәк иде шул, кызым. Тик хәзерге медицинаның көче барына җитенкерәми.

— Миңа калса, врач терелтергә тиеш. Менә мин врач булсам...

— Ай, алай алдан сөйләнмә әле, кызым. Теләгеңнең изгелектә булуы яхшы үзе, әле син институтлар тәмамлаганчы, фән дә алга китәр. Врачның үзенә генә бәйле нәрсәләр дә шактый. Ул шәфкатьле булырга да тиеш, шул ук вакытта сүзен дә үткәрә белсен. Кайчак авыруга кичекмәс операция кирәк була, мөмкинлекләр юк. Әйтик, аны тиз арада больницага алып китәргә тиешләр, транспортын-фәләнен табарга туры килә. Шундый чакта җебеп төшсәң, врачлыгыңның кыйммәте калмый инде. Әтиең мондый вакытларда бик тәвәккәл иде. Кешеләр аны шуның өчен дә яраттылар. Авырулар гына түгел, сәламәтләре дә аны үз итәләр, аңа киңәшкә киләләр иде.

* * *

Энҗе медицина институтын уңышлы тәмамлап чыкты. Аны кечкенә генә бер авылга эшкә җибәрделәр. Салам түбәле, бер-ике тәрәзәле өйләр арасында иске генә бинага урнашкан больница иде ул. Коймалары җимерелеп беткән, капкасы кыйшайган. Бинасының тышкы кыяфәтеннән үк нинди җиргә эләгүен чамалап өлгерде Энҗе. Эчке якта исә аны тагын да аянычрак хәлләр көтә иде. Рентген юк, барлык бүлмәләрдә үзәккә үтәрдәй суык.

Больницага баш врач итеп Энҗенең ирен — хирург Әкъмал Сабировны билгеләгәннәр иде. Әкъмал тәҗрибәле. Бөек Ватан сугышының беренче көненнән соңгы сәгатенә кадәр фронтта булган кеше. Дәвалау осталыгында да, оештыру эшләренә дә сугышта өйрәнгән. Әмма әлеге больницаның эшләрен тиз генә җайлап җибәрергә мондый сәләтләр генә дә җитми. Алда торган бурычларны берәмләп-берәмләп үтәргә карар кылалар. Иң башта авырулар ята торган палаталарны җылыту мәсьәләсе алга куелды. Аннан соң кирәкле җиһазлар, дәвалау әсбаплары табу чарасына керештеләр. Энҗе авыруларны һәрьяклап тикшерүне җайга салды. Диагнозларны билгеләгәндә ялгышмаска иде! Диагноз ачыкланса, чиргә каршы көрәшү җиңеләячәк.

Энҗенең эше монда күп төрле тармакларга җәелде, чөнки больницада һәр авыруга кирәкле белгечләр юк. Терапевт Энҗегә колак авыруын да, күзнекен дә, тиренекен дә, эчке чирләрне дә карарга кирәк иде. Берсендә аңа:

— Ашыгыч операциягә әзерләнегез! — дип хәбәр иттеләр.— Бик авыр хәлдәге кеше киләчәк.

— Диагнозы?

— Ашказанында.

— Нәрсә соң ул ашказанында?

— Нәрсә булсын, язва инде!

«Ичмасам, рентгены гына да юк бит!» дип ачынып куйды Энҗе. Авыруны, юллар начар булу сәбәпле, трактор арбасында алып килгәннәр иде. Хәле, чыннан да, ифрат авыр. Шулай да Энҗе аны операциягә салырга ашыкмады. Төрле яклап тикшерергә кирәк тапты. Нәтиҗәдә, авыруда инфаркт-миокарда булуы ачыкланды. Димәк, аңа операция ясарга ярамый. Энҗенең диагнозы расланды. Әмма беренче көннәрдә, бу кешенең гомере өчен көрәшкәндә, нинди генә сүзләр ишетмәде ул!?

Четерекле очракларда Энҗе китапларга, институтта язылган лекцияләренә мөрәҗәгать итә иде. Төннәр буе укый, уйлана, иртән иртүк авыру белән киңәшергә

ашыга, сораша. Тырышлыгы аның шифалы куллары турындагы данны бу авылдан шактый еракларга тараттылар. Энҗе исемле докторны эзләп күрше районнардан да килә башладылар.

Авыл больницасы Энҗе Исхаковага искиткеч файдалы өйрәнү чыганагы да иде. Монда ул ундүрт ел эшләде. Аннары аны Казанга ординатурага чакырып алдылар.

Энҗе Закировна Казанда да тиз арада ышаныч казанды. Менә ул ординаторскида дежур тора. Төн якынлашып килә. Энҗе ачык тәрәзә аша күккә карап тынып калган. Кояш баеп, озак та үтмәде, күк йөзенә йолдызлар калка башлады. Берәү, икәү, өчәү... Энҗенең карашын җәлеп иткән тагын бер йолдыз балкып кабынды да, аклы-зәңгәрле киңлектә йөзеп китте, аннары... юкка чыкты. Сүнгән йолдыз врачның фикерен кеше гомеренә, үз һөнәренә китереп тоташтырды. Ул, ашыгып, урыныннан кузгалды. Дүртенче палатадагы авыруның хәле начарланып китте. Нигә икән? Энҗе авыруның хәле теркәлгән кәгазьләрне кабат күздән кичерде. «Йокысызлыктан интегә» дигән сүзләр врачта яңа сораулар уятты. «Хәзер йоклый микән ул?» Барып караудан да яхшысы юк. Энҗе биек үкчәле туфлиләрен йомшак башмакларга алмаштырып киде. Озын коридор буйлап китте. Моннан үткән саен Энҗенең хәтеренә күңелсез бер сөйләшүгә шаһит булуы искә төшә. Баш врач бүлмәсе янында, ихтыярсыздан, ишетергә туры килгән иде. Нестерева фамилияле врач, Энҗенең якындалыгын абайламыйча, җитәкчегә гел кирәкмәгән сүзләр тезеп китте. Баш врач аңардан:

— Яңа килгән иптәш сездә нинди тәэсир тудырды? — дип сораган иде.

Нестеревага шул гына кирәк булган икән.

— Минемчә, ординатурага кабул итү вакытында врачның тышкы кыяфәтенә дә күз йомарга ярамый,— диде ул.

— Тышкы кыяфәт? — Баш врач аның тел төбен аңлап җиткермәде.— Энҗе Закировнаны ямьсез дип булмый бит инде?!

— Беренче карашка, матур ул, тик сез аның буена игътибар итегез! Бер ише курчаклар да аннан буйчанрак була. Әйтик, Захаров кебек эзмәвердәй авыруны ничек карый ала инде ул? Әйләндерергә кирәк булса? Энҗенең андый зур гәүдәле кешенең кулын күтәреп, пульсын үлчәрлек тә хәле юк бит!

— Кара, Захаров нәкъ Энҗе Закировнада түгелме соң?

— Харап итәчәк ул аны. Сез — җитәкче, уйлагыз, әлегә соң түгел! Исхакова сынау шарты белән генә алынган. Сезнең урында булсам, мин аңардан котылу ягын карар идем.

— Сынау-сыналу вакыты эшкә яңа килгән һәр кешегә билгеләнә.— Баш врачның тавышы кырыслана төште.— Ил күләмендә кабул ителгән тәртип ул.

Шул көтелмәгән сөйләшүне ишеткәннән бирле Энҗе Захаров фамилияле авыру кеше турында аерым бер игътибар белән кайгырта башлады. Төнге дежурга калган көннәрендә исә Захаров яткан палатага төнлә дә берничә тапкыр керә торган иде. Янына килә дә:

— Йокы алмыймы һаман? — дип сорый.

— Юк, доктор, юк. Йокы дигәннең рәхәте миңа тәтеми. Әле керүегез яхшы булды: миңа аякка басарга ярамас микән, коридорда гына булса да йөрер идем, ичмасам.

— Юк, юк, Захаров, хәзергә ул турыда уйламый торыгыз! Хирург кушмый. Йомышларыгызны, әнә, Полина апага гына әйтегез!

Нәкъ шул вакытта ишектә Поля түтинең ягымлы йөзе күренде. Аны больницада бик яраталар. Башкача була да алмый: аның бөтен торышы, күз карашлары авыруларга яхшылык эшләргә атлыгып торуын күрсәтәләр шикелле. Үзенең тавышын да ишетмәссең. «Туганкай!» дигән кендәлек сүзе генә колакта эленеп тора. «Кая, мендәреңне рәтлик әле, туганкай!», «Хә-ә-әзер, туганкай, хәзер! Бары да әйбәт булыр, менә күрерсең!», «И-и алай сабырсызланма, туганкай, терелерсең син, менә, ялар гына җитсен! Күзгә күренеп әйбәтләнә хәлең...»

«Туганкай» сүзен аңа кушамат итеп тактылар. Больницага ул килеп керсә, палаталарга хәбәр тарала: «Бүген «Туганкай» эшли, рәхәтләнәбез, боерган булса»,— диләр. Бу сүзләр авыруларның үзара шатлык уртаклашулары кебек яңгы-

рый. Авыру кешене шатландырырга күп кирәкмени соң?! Бүлмә чиста торса, тәмле телләрен кызганмасалар, күңелләр күтәрелә дә китә инде.

Әмма бу юлы Захаров, хәтта Поля түтине күргәч тә, ачылып китмәде. Кулындагы бер тартмачыкны әйләндергәләп ятуында булды. Энҗе аңардан:

— Сезнең кулда ни ул? — дип сорады.

— Уенчык. Фронтта ясаган идем дә... аерылышырга туры килә инде менә.

— Нигә? Ташларга булдыгызмыни?

— Гүргә кергәндә, уенчык ни лычагыма соң ул?

— Бусы ни дигән сүз тагын?

— Минем белән балаларча уйнап азапланмагыз, доктор!

— Миңа, барыннан да бигрәк, үз хезмәтемнең нәтиҗәләре кыйммәтле. Бөтен анализлар хәлегез әйбәтләнүен күрсәтә. Шуңа күрә дә кәефегезнең начарлануын һичничек аңлый алмыйм мин.

— Алай, бик өметле булгач, мине ник дәвалаудан туктадыгыз соң?

— Дәвалыйм ич мин сезне, Захаров!

— Врач Нестерева, сездә өмет юк дип, ташлап китте.

— Булмаганны уйлап чыгармагыз, Захаров! Врачларга ышана белергә кирәк! Шатланыгыз, Иван Андреевич, бөтен анализлар да бик әйбәт чыкты!

— Белмим инде...

— Менә мин беләм, Иван Андреевич: иң күп дигәндә, ай ярымнан гаиләгез белән рәхәтләнеп яши башлаячаксыз.

Ниһаять, Захаров Энҗегә карады:

— Чынлапмы, доктор?

— Ялган сөйләшә торган гадәтем юк, Иван Андреевич.

Энҗе шул ук палатага яңадан күз салганда, Захаров, тирән-тирән сулыш алып, йоклый башлаган иде инде. Ул хәтта врач тәкъдим иткән йокы даруын да капмаган, таблетка тумбочка өстендә ята.

* * *

Энҗе, җанына урын таба алмаудан аптырап, бакчага чыкты. Яңгыр сибәли иде. Плащ кигән, зонтик бөркәнгән врач аны әллә ни сизми дә кебек. Күңелең тулы шомлы уйлар булганда, табигатьнең холыксызлануы тоелмый да икән ул.

Соңгы вакытта Энҗе карамагындагы Надя исемле авыру кыз дөньядан китте. Аны башка палатадан күчергәннәр иде. «Сезнең палаталарга кояш карый, авыру кызга шуның файдасы тиячәк», дигәннәр иде дә, бу авыштыруның сәбәбе башкада булып чыкты. Энҗе кызның ятагы яныннан китмәде дә диярлек. Аны ялгыз тоту мөмкин дә түгел иде: сулышын кечкә ала, күзләре төпкә батканнар, гәүдәсе сузаеп калган. Энҗе, аны беренче күрүдән үк, шиккә төште. «Бу баланы саклап калу мөмкин микән?» дигән уй аның бөтен тынычлыгын алды.

Кичен, врач, аның пульсын чамалар өчен, кулларын капшагач, кыз керфекләрен күтәрде. Бит алмалары дертләп куйды, ул нидер әйтмәкче иде, бугай. Тик аңардан һичнинди аваз да ишетелмәде, карашлары әллә кая еракка төбәлделәр дә... шул килеш катып калдылар. Энҗе кызның күзләрен йомдырды.

Инде менә врач, кеше күзенә күренергә оялгандай, тын бакчаның аулак почмагына поскан. Яшь-яшь кызның үлеме аның ачуын чыгарган: «Ник мондый хезмәткә намуссыз кешеләр алына? — дип уйлый ул.— Ник медицина институтына шәфкатьсез, сәләтсез студентлар кереп тула? Ник больницаларда Нестерева кебек түбән җаннарга урын бүленә? Яшь-яшь кыз бала нәкъ аның игътибарсызлыгы аркасында вакытсыз дөньядан китте...»

Энҗе белән Нестерева арасындагы мөнәсәбәтләр кискенләшкәннән-кискенләшә барды. Берсендә алар Энҗенең куен дәфтәре аркасында әйткәләштеләр. Энҗенең үзе өчен генә йөртә торган куен дәфтәре бар. Аңа ул иң кирәкле эшләрен, авыруларга кичекмәстән күрсәтелергә тиешле чараларны, шәфкать туташларына кушарга теләгән йомышларын теркәп куя. Үз карамагына тапшырылган кешеләрнең авыру тарихын да Энҗе палатада ук, аны тикшергәндә үк язып бара.

Нестерева Энҗене палатада, авыру тарихын язып торганда, ачуланырга тотынды:

— Ник сез бу эшне «ординаторский»да, язу өстәле янына утырып, иркенләп башкармыйсыз?

— Миңа монда уңайлырак,— диде Энҗе.— Мин бит бер генә кешене карамыйм. Кабинетка әйләнеп кергәләгәнче, онытылуы ихтимал. Монда, авыру белән киңәшеп карарга да, сораулар биреп, мәсьәләне ачыклый барырга да була.

— Алай яза башласаң, бөтен авыруларны карап чыгарга вакыт җитмәячәк.

— Бер мәртәбә җентекләп карасаң, һәр авыру янына минут саен кереп йөрмәскә дә мөмкин. Минем авырулар врач игътибарсызлыгыннан зарланмыйлардыр, дип уйлыйм. Үз алымымның дөреслегенә иманым камил минем.

— Сезнең иман гел камил инде!..

Энҗе икенче палатага күчте. Монысында Петров белән Михайлов ята. Күптән түгел врач аларның үзара «килешү»ләре турында белде. Хәзер шуның нәтиҗәсен тикшереп карыйсы бар.

Башта Энҗе Петровның сәламәтлеге белән кызыксынды, җентекләп тыңлады, тикшерде.

— Котлыйм сезне, Петров, тәмам сәламәтләнеп җиттегез бит! — диде.— Инде нерв системасын да бераз ныгыта төшсәк, йокы алдыннан бирелә торган уколларны туктатабыз.

— Аларны бирмәсәгез, сызлануга ничек чыдармын мин?!

— Сезнең хәзер һичнинди сызлануыгыз да юк, дарулардан башка яшәргә өйрәнә башлагыз!

— Ничек инде?

— Чөнки хәзер сезнең бер җирегез дә сызламый.— Доктор Михайлов ягына карап куйды.— Элек кенә авырта иде, хәзер юк, бетте!

Петров, Михайлов врач белән шыпырт кына сөйләшкән, дип уйлап алды. Энҗе исә Михайловка үзеп әйтеп салды:

— Сез, иптәш Михайлов, Петровны гел укол сорарга өйрәтеп ятмагыз. Артык даруның өч тиенлек тә файдасы юк аның! Киресенчә, зыян ясап куюы мөмкин. Сез әнә күрше ятактагы иптәшегездән үрнәк алыгыз. Аның бөтен тәне авырта, бер мәртәбә ыңгырашканын ишеткәнегез бармы? Врачны алдап артык дару алудан ни тәм табасыз?

Энҗенең бу сүзләре дә врач Нестеровага барып ирешкән булып чыкты.

— Авырулар белән ягымлы итеп сөйләшергә кирәк, Энҗе Закировна! — дип, кисәтеп калырга ашыкты ул.— Сезне «ординаторский»да көтәләр.

— Минем сүзләрнең кырыслык сәбәбен Михайлов кебекләр үзләре бик яхшы аңлый. Ул бу хакта башка авыз да ачмаячак — мин беләм...

«Ординаторский»да больницаның хезмәткәрләре җыелган иде. Баш врач, кырык яшьләр чамасындагы ир кеше, җыелышны ачып җибәрде:

— Без бүген монда хезмәт дисциплинасы турында сөйләшергә җыелдык,— диде ул.— Ачыктан-ачык эшкә нилләр комачаулавы турында сөйләшик әле! Мин башта сезнең фикерләрне ишетергә теләр идем!

Энҗе аның сүзләрен ихластан кабул итте һәм күңелендә җыелган канәгатьсезлекләр турында сөйләргә тотынды:

— Безнең больницада...

Энҗенең сүзен бүлеп, Нестерева кычкырды:

— Кара син аны, больницаны «безнеке» дип үк атый башлаган инде бу!

Энҗе каушамады, хәтта Нестеревага җавап та бирде әле ул:

— Әйе, әйе, «безнең больница»! — диде— һәркем эшләгән җирен үз күрергә, якын итәргә тиеш! Шулай булмаса, ул аны ярата алмый, күңел биреп эшләми.

— Дөрес, иптәш Исхакова! — диде баш врач.— Дәвам итегез!

— Мин бу җыелышта врачларның һәм шәфкать туташларының авыруларга карата ягымлы мөнәсәбәтенә басым ясамакчы идем. Безнең халыкта, яхшы сүз — җан азыгы, диләр. Кайчак ачык йөз, тәмле сүз белән генә дә кешенең кәефен күтәрергә мөмкин. Игътибарсызлык сизсәләр исә, терелә башлаганы да борчылырга тотына. Авыруларның җан тынычлыгын тәэмин итү өчен, без барыбыз да үз

бурычларыбызны намус белән үтәргә, низагларыбызны онытып торырга кешбез. Авыруларны терелтү хакына, үз мәнфәгатьләреннән баш тарта белмәгән кешегә медицинада, гомумән, урын булмасын иде! Дөньяда кеше гомереннән дә кыйммәтрәк нәрсә юк, ә хезмәтнең төрлесен табарга була.

— Юлын да белеп торгач, тот та кит инде син! — Нестерева Энҗенең сүзен тагын бүлде.

— Мин үз язмышымны больницадан башка күз алдыма да китерә алмыйм. Дөрес, бәлки, мине бу коллективта калдырмаслар, әмма, кешеләр гомерен озайту хакына, мин җәһәннәмдә дә эшләргә риза!

Энҗе больницадагы кимчелекләргә дә кагылды: хезмәткәрләрнең коридорларда кычкырып-кычкырып сөйләшүләрен туктатырга, тупсалары шыгырдый торгач ишекләрне кичекмәстән төзәтергә кирәклеген искәртте. Коллективтагы мөнәсәбәтләрнең киеренкелеге яхшыга илтмәвен дә читләтеп үтмәде.

Энҗе Исхакованың урынлы әйтелгән һәр сүзе Нестереваны кысасыннан чыгара бара иде. Баш врач аңа берничә тапкыр кисәтү дә ясады. Күпчелек исә Энҗенең туры әйтелгән сүзләре белән килешеп утыра иде. Чыгып сөйләүчеләр дә аны хупладылар. Врач Әхмәтова, Энҗе кисәтүләренә өстәп, профсоюз оешмасының пассивлыгына тукталды. Энҗе түзмәде:

— Әйе шул,— дип, тагын кушылып китте.— Әнә няня Вафина ничә көннән бирле авырып ята, хәлен белергә бара алганыбыз юк,— диде.

Нестерева:

— Сиңа гына җитми инде! — дип, усалланып, аңа каршы төште.

Кемдер аңа:

— Бу Нестерева, урман мәчесе кебек,— дип пышылдап куйды.— Сикерергә генә тора.

Шул чак берәү, ишектән башын тыгып, кычкырды:

— Энҗе Закировнаны дүртенче палатага чакыралар!

Энҗе баш врачка карады:

— Рөхсәтме?

Энҗе чыгып киткәч, ике няня үзара:

— Исемен дә белеп кушканнар моның, чын энҗе инде, валлаһи! Тирә-юньне яктыртып тора! — дип гәп сатып алдылар.

— Сез нәрсә пышылдашасыз анда? — Баш врач аларның телен аңламый иде.

Нянялар төшендереп бирделәр:

— Бу Исхакова дигән врачны мактыйбыз әле, исеменә җисеме туры килгән, дибез. Кеше энҗене буыннан-буынга саклый, нәселенә мирас итеп калдыра. Безгә дә аны сакларга кирәк, дибез...

Баш врач елмаеп җибәрде:

— Карасана, нәкъ минем фикерне әйтәсез бит! Кадерен белик без аның!

— Ул чагында миңа моннан китәргә туры киләчәген дә уйлагыз! — Монысы Нестерева иде.

Баш врачка шул гына кирәк булган икән.

— Минем сезгә тәкъдимем бар иде, иптәш Нестерева,— диде ул.— Сезнең өчен больница эше — ят хезмәт...

* * *

Ординатураны тәмамлаганнан соң Энҗе Закировнаны республика больницасында калдырдылар. Бу терапевтның осталыгыннан бик күп яшь медиклар үрнәк ала. Тәҗрибәгә бай булуын истә тотып, аны больницаның терапия бүлегенә мөдир итеп тә билгеләделәр. Бу вазифасын башкарганда Энҗе Закировна үзенең оештыру сәләтен дә күрсәтте.

Ул үз кул астында хезмәт итүче яшь врачларга да, хәтта башка больницалардагы коллегаларына да киңәш бирергә шат. Энҗе Закировна тырышлыгының иң зур нәтиҗәсе шул — аның бүлегендә диагнозларны дөрес билгелиләр, дәвалаганда фәнгә таяналар, савыктыру вакытын кыскарталар.

*Илебез тәнкыйтьчеләре*
*татар язучылары турында*

**Алия Кулумбетова**

# ӘХЛАК ПРОБЛЕМАСЫ — ҮЗӘКТӘ

Кешенең үз-үзен тотуы, җәмгыятькә, башка кешеләргә мөнәсәбәте. Әхлак. Бу проблема борын-борыннан әдәбиятның үзәгендә торган, дистәләрчә буын язучыларның язарына азык булган. Мәхәббәтме, ватандарлыкмы, дуслыкмы, хезмәткә мөнәсәбәтме, яшьләрне тәрбияләүме — нинди генә теманы алма, алар барысы да чорның алдынгы әхлагы позициясеннән торып хәл ителә, кешенең бөтен гамәле шуннан чыгып бәяләнә.

Замандашыбызның әхлакый чыганакларын эзләп, совет язучылары сугыштан соңгы героик чорга да (А. Гыйләҗев, «Язгы кәрваннар»), җәмгыятебезнең коллективлашу чорыннан башлап хәзерге космос эпопеясына кадәр сузылган үсү этапларына да (Ч. Айтматов, «Буранлы станциясе»), урта гасырлардагы бер вакыт аралыгына да (Ә. Әлимҗанов, «Остазның кайтуы») мөрәҗәгать итәләр. Һәм һәр эпоханың үзәгендә кеше тора. Ул я үзен коллективның бер члены, коллектив исеменнән сөйләрлек кешә итеп сизә, яисә ул үз заманына гына сыймый, шунлыктан соңгырак буыннарның да замандашына әверелә.

Телгә алынган әсәрләрнең һәркайсында хәзерге заман үткәннәр истәлеге белән органик рәвештә үрелеп бара: кешеләргә үз-үзеңне аямый хезмәт итү турындагы халык җыры — «Язгы кәрваннар»да, манкортлар һәм Раймалы ага турындагы, кешенең изге бәйләнешләрен һәм тойгыларын онытуны һәм аяк астына салып таптауны гаепли торган легендалар — «Буранлы станциясе»ндә, Әбу-Насрның төшендә кеше акылына һәйкәл булган меңьяшәр пирамидалар белән сөйләшүе — «Остазның кайтуы»нда.

Өч әсәрнең дә исемнәрендә юлның — мәңгелек хәрәкәтнең — метафоралы сурәте чагылыш тапкан. Геройларга — урта гасырлардагы фикер иясе әл-Фарабига, замандашларыбыз Ибраһимга һәм Идегәй Җангилдинга әхлакый яктан күз ачылу, башкалар өчен җаваплылык, үз-үзеңне, үз рәхәтеңне башкалар өчен корбан итү теләге юлда килә. Юл бетмәс-төкәнмәс рухи эзләнүләрнең сынланышы булып тора (Кәсләдән чәчүлек орлык алып кайту юлы — «Язгы кәрваннар», Идегәйнең Буранлы Каранар артыннан Ау-Муйнакка килүе — «Буранлы станциясе», Әбу-Насрның гыйлем эстәп ил гизүе — «Остазның кайтуы»).

«Язгы кәрваннар» повестеның исемендә үк совет халкының оптимистик рухын, яшәү көченең асылын чагылдыра торган лирик башлангыч сизелә.

Повестьның юл картинасы белән тәгалләнүе дә юкка гына түгел: кешеләр салмак кына алга бара, «кызыл балчыктан өелгән бәләкәй генә таучык ак карда уйнаган кызыл төлке кебек кенә күренеп тора». Бу лирик картинада Сабираттәйнең — фронтта үлгән иренең кайгысы бәгырен киссә дә, язгы юл өзеклегендә бәләкәй чана белән ерак авылга орлыкка барып, соңгы мәртәбә фидакарьлек һәм батырлык үрнәге күрсәткән хатынның — каберен карда уйнаган кызыл төлке белән чагыштыру бөтен кешене үзенә тарткан бу хатынның тормышка мәхәббәтен күрсәтә.

Лирик герой өчен кабер өстендәге әле дымы да кибәргә өлгермәгән балчык — Сабираттәйнең башыннан төшмәгән, авыл кешеләре бергәләп эшләгәндә һәрвакыт

уртада күрергә гадәтләнелгән сары-кызыл бизәкле яулык төсле балчык — ирексездән кызыл төлке төсе белән ассоциацияләшә.

Бу картина бөтен лирик хикәяләүнең иң югары идея-мәгънә ноктасы, чөнки бер бәләкәй генә татар авылында яшәүчеләрнең берсен дә читләтеп үтмәгән (бөтен илгә килгән!) авырлыклар һәммәсе тормыш хакына җиңеп үтелгән бит.

Сабирәттәй — повестьның яшүсмер герое өчен халыкның вөҗданын, фидакярьлеген, игелеклелеген гәүдәләндерә. Әмма халыкны бербөтен итеп берләштерә торган көчне тою, аңлау аңа Әдилә авызыннан ишеткән халык җырының мәгънәсенә төшену белән генә килә. «...Көмеш булып тамаем» диме? Зарлану, кайгыру түгел ич моңысы, кешегә, дөньяга, җиргә яхшылык теләү! Изгелеккә, юмартлыкка омтылып җирсенә бит кыз күңеле.

Кызның тавышы аермачык ишетелә, кызның тавышы йөрәкне өзәрлек моңлы, ягымлы. «Җыры бөтен барлыгымны, арба-атымны, юлымны, барырымны һәм кайтырымны, каралып-куерып килгән офыкларны күмеп китте, онытылдым! Ташкын иде аның тавышы, моң дөньясы иде!» Алтын булып агаем ла... көмеш булып тамаем!.. Бу сүзләр үсмер егет өчен, Чаллыга тракторчылар курсына китеп барышлый, үзенең уртак эшкә, бөтен халык эшенә катнашы барлыгын тою белән, кышын да тургай җырын ишеттерерлек тылсым булып әверелә: «Бу юлдан байтак кешеләрне әле сугышка, әле бәхет эзләргә Пермь, Ярослау якларына озатканым бар, хәзер үзем китеп барам, хәерлегәме? Дөнья безнең кулга күчеп бара торгандыр шул...»

Хикәячене сугышта авыр контузия алган Габбас абый гаиләсе үзенең күңел юмартлыгы белән таң калдыра, шул җырның сүзләрен, мәгънәсен тагын исенә төшерә: «Юк, бу теләкләре уртак аларның, алар өй эчләре белән чиксез бәхет тоеп, сөенешеп-сөешеп яшиләр, үз бәхетләре белән кешеләрне дә шатландырырга телиләр. Яшәүнең иң бөек максаты, кешенең иң гади сыйфаты шул түгелмени? Шушы җырдагы кебек ич аларның тормышлары...»

Әлеге җыр, халыкның буыннарны бер итеп бәйли торган рухи, әхлакый байлыгы повестьның лейтмотивына әверелә, геройларның эчке мәгънәсен аңларга ярдәм итә.

Җырчы Раймалы аганың соңгы фаҗигале мәхәббәте турындагы борынгы дала риваяте Идегәйнең тыштан караганда вакыйгаларга әллә ни бай булмаган рухи тормышында буыннарның аерылгысызлыгы турындагы фикергә куәт бирә. Идегәй бу турыда ишеткән, яшь-яшь кызны сөяргә җөрьәт иткән карт Раймалы аганы тәрләчә гаепләүләрен дә, аклауларын да белгән. Аның станциягә Әбуталип Коттыбаев эше буенча килгән «карчыгакүз» тикшерүче белән сөйләшүеннән менә шул күренеп тора. Әбуталипның гаебе шунда: ул үзенең балалары өчен дип әсирдә, Югославиядә башыннан кичергәннәрен һәм дала риваятьләрен кәгазьгә язган, шул исәптән Раймалы ага турындагысын да язып куйган. Менә шуныс|ын «карчыгакүз» бозык һәм маразматик нәрсә дип бәяли. Ә Идегәй легенда белән Әбуталипны икесен ике нәрсә итеп аера. Әбуталип, аның фикеренчә, яхшы ата, гаилә башы. Ә риваять ул риваять инде, ул чакта Идегәй аның бүгенге белән бәйләнешен танымый, күрми әле. Әмма халыкның рухи мирасы белән хәзерге чор арасындагы бердәмлекне герой думбра тыңлаганда Әбуталипның тол хатыны Зарипага булган тыелгысыз хисе үзгеен өзгәндә һәм үз-үзе белән көрәшнең иң киеренке ноктасында гына нык итеп тоя. «Бу музыканы тыңлауның үзе өчен җиңел генә, болай гына үтеп китмәслеген аңлады Буранлы Идегәй. Чөнки ул кунакта бераз гына башка нәрсә уйлап: онытылып торган икән, ләкин думбраның беренче авазлары ук аны яңадан үзенә кайтарды, яңадан кайгыхәсрәт упкынына атты. Аңарда бу кайдан килде соң әле? Бу музыканы тудырган кешеләр Буранлы Идегәй белән нәрсә һәм ничек буласын, аңа нинди кыенлыклар һәм михнәтләр күрергә язганын әллә кайчан белеп торганнар булып чыгамы? Югыйсә, Эрлепесның уйнавында үз-үзен ишеткәч, аның нәрсә тоясын алар каян белсеннәрди? Идегәйнең күңеле талпынып куйды, канат җәйде һәм сыкрады, һәм аның өчен дөньяның бөтен ишекләре — шатлыгы да, сагышы да, уйлану да, тонык теләкләр һәм шөбһәләр дә дәррәү ачылып китте... Музыка аның уен күз ачып йомганчы үткәннән бүгенгегә һәм янә үткәнгә күчереп куйды. Иртәгә булачакка да. Шул чагында сәер бер теләк туды — үзенә кадерле булган бөтен нәрсәне, күз алдындагы бөтен дөньяны хәвефтән сакларга, каплап алырга, беркемгә, бернәрсәгә кыен кылмаслык итәргә.

һәм шушылай үз тормышына бәйле булганнарның һәммәсе каршында үзенең ниндидер гаебе барлыгын тойган кебек булу аңарда ышерен бер сагыш уятты».

Үзе өйдә юкта Зарипа балалары белән качып киткәч, Идегәй чиксез сагышка чумып йөргәндә Казангапның, тыштан сиздермәсә дә, Раймалы аганы һәм аның явыз җанлы туганын искә төшерүе дә шуңа. Шул чакта Идегәй сагыш һәм моң тулы, җанының әллә кай төшләрен кузгата торган дала поэмасын тагын бер кат күңеленнән кичерә.

Күп еллар үткәч, Әбуталипның әзсез югалган семьясын һәм Зарипаны сагынудан туктамаган Идегәй, инде күрешүдән өмет өзеп диярлек, Әбуталипның балалары тыныч булсын өчен. аның намуслы исемен реабилитацияләп кайтып килә. Шул чакта ул ирексездән Раймалы аганың Бегимайга атап җырлаган хушлашу җырын искә төшерә.

Ә. Әлимҗанов өчен исә буыннарның бу аерылгысыз бәйләнеше поэтик мирасга түгел, хыялый төштәге Акыл образында ачыла. Төштә ул Чүл һәм Күк авазы белән, шулай ук Сфинкс белән сөйләшә. Урта гасырларда яшәгән галим һәм фикер иясе өчен хакыйкатьнең мәңгелеге һәм тормыш мәгънәсе турындагы мәсьәләне хәл итү мөһим. Бу бәхәс аны шуңа ышандыра: «фикер беркемгә дә — фиргавеннәргә дә, вакытның үзенә дә буйсынмый, чөнки киләчәк — ул үткәннең һәм бүгенгенең дәвамы һәм ул чиксез. Киләчәк хакына «сафлык туганнары» үзләренең ялкынлы хатларын язалар, ә ул, Әбу Наср «Игелекле шәһәр һәм аның изге җанлы кешеләре турында» дигән трактатын яза.

Геройларның һәркайсы, үзенең рухи үсешендә җанлы мисалларга таянган хәлдә, үзе өчен кыйммәт булган башлангычларның алга таба үсеше дә булып тора.

Мәсәлән, үсмер егет Ибраһим өчен А. Гыйләҗевның герое Сабирәттәй образы — сугыш көннәре ачысын җиңәргә ярдәм итә торган әхлакый көч үрнәге.

Бу образның лирик яңгыраш алуы кеше характерларындагы контрастларны: берәүләрнең фидакарьлеген һәм игелеклеген, икенчеләрнең эгоизмын яшьләрчә нечкә тоючы геройдан да килә. Көз көне элеваторда һәм иртә язда Кәсле юлында булган күренешләрне искә төшерик. Дәүләткә тапшыру өчен ашлыгы бөртегенә кадәр себереп алынган «амбарлар җылашып утырганда» Гыймай Фатихы утыз ике килограмм ашлыкны йомып кала. Ә Кәслегә барышлый уртак табындагы «алабута кушып пешерелгән, кайрактай кара катламалар, бәрәңге кушып, шуңа сыңар уч кына әремле арыш оны салып пешерелгән ләчтә ипиләр, тәгәрәткән бәрәңгеләр» янына Фатих кызы бер кыерчык чын бодай ипие куйса да, аңа ник бер кеше кул тидерсен, шул килеш ашъяулыкта торып кала. Бу юлы да халык, инде дәшмичә, шул дәшмәве белән, бердәй булып эгоизмны гаепли.

Сабирәттәй — халыкта булган бөтен яхшы нәрсәнең гәүдәләнеше, без авыл кешеләренең төп массасын аның образы аша кабул итәбез. Бөтен халык исеменнән сөйләп, аның үзен халык белән аерылгысыз итеп бәйләү характерлы. Хәкимҗан абзыйның председательлеккә сайлануын хәтергә төшерик: «Без, Хәкимҗан абзый,— ди Сабирәттәй ул чакта,— барыннан да бигрәк түмле телне сагындык. Тәмам аптыраш бит хәзер: үзебез дә сүгенәбез, безне дә сүгәләр! Нәсел-нәсәбегез белән тәмле телле булдыгыз, кулыгыздан эш тә килде, әйдә, дилбегәне кулыңа тот әле! Безгә камчы кирәкми, дилбегә каксаң да эшлибез без!» Совет крестьяннарының рухын шуннан да үтемлерәк һәм гадирәк итеп әйтеп булмый торгандыр!

Хикәя итүченең рухи дөньясы хәзерге заманны хәтердә яңарта торган үткәннәр белән катлаулы үрелдерү алымы ярдәмендә ачыла. Бу сюжеттан тыш элементлар повесть геройларының эчке дөньясын гына түгел, ә бәлки барыннан да элек Ибраһимны якыннанрак белергә ярдәм итә, чөнки төп идея-әхлак нагрузкасы Ибраһимда. Ул, кушылдыкларыннан көч алып, бүгенгене киләчәк белән бәйли торган элгәгә охшый. Язгы ташуда Олысу бозларында учаклар ягып җибәрү турында сөйләү дә, һәлак булганнарның семьяларын кайгырту, әле мәктәп баласы булган Әдиләгә балалык хисе турындагы хатирәләре дә шуңа хезмәт итә.

Хикәяләүдәге лирик чигенешләр гүя сюжетның рамкаларын киңәйтә, авыл кешеләренең көндәлек мәшәкатьләре турында сөйләүнең драматик тонына оптимизм бирә. Үзенең шунда булуы белән язгы кәрванның искиткеч авыр юлын бәйрәмгә

әверелдергән Әдилә бар. Үсмер егетнең дөньяны шулай нечкә кабул итүе Әдиләгә булган хис белән бәйле.

Шул рәвешчә, Гыйләҗев повестенда әхлак проблемасын хәл итү хикәянең төп герое, рухи байлыкларның чыганагы һәм иясе булган халыкның җанын шигърияте итеп ачып бирүче халык җыры белән бәйләнгән.

Ч. Айтматовның герое Идегәй өчен дусты Казангап — халыкның зирәклеге гәүдәләнеше, «риваять сөйләүче», үз җиреннән аерып алгысыз, тавышсыз-өнсез Сарүзәк киңлегендә ярты гасыр буена үз бурычын тайчанмый үтәп килгән кеше. Бер карасаң, аларның Идегәй белән бергә үткән озак гомерендә, көндәлек хезмәтендә искитәрлек берни юк кебек. «Сез карт юләрләрне җиккәннәр, юләр килеш үләрсез дә!» — «яңача бәяләүчеләр» аларның тыштан тыйнак күренгән героик хезмәтен әнә шулай сызып ташлыйлар. Ләкин Идегәй белән бергә без дә бер вакыйганы искә төшерик. Тимер юлны туктаусыз яуган кар көртләреннән чистарткanda Казангаптан башка бөтенесе дә арып эштән туктый. Башкалар кебек үк хәлдән тайган Идегәй дусты Казангапның һаман тукталмавына, үз бурычын шулай тирән аңлавына таң кала. Шулай итеп башкаларга җаваплылык үрнәге күрсәтү, үз-үзеңне корбан итә белү соңрак герой өчен дә төп сыйфатка әверелә. Станциядәге карт эшче Казангапның рухи олылыгы Сарүзәк чүленең мәһабәтлегенә тиң. Шуңа күрә дә чүлнең мәңгелек юлдашы — дала төлкесен Идегәй һич икеләнүсез-нисез мәрхүм Казангапның җаны дип кабул итә.

Идегәйнең үз-үзен тотышы аның үзен гаделлек хакына җаваплы, мөстәкыйль карар кабул итәргә сәләтле шәхес итеп тоюыннан килә. Шул аны кешелек прогрессы хакына, үзләре кебек үк акыллы затларга ярдәм итү теләге белән Конвенция җитәкчеләре ризалыгыннан башка Урмантүш планетасына очкан «Паритет» космонавтлары белән якынайта.

Шунысы мөһим: Идегәй үзендә кеше кайгысын кайгырту сәләте булганга күрә, Зарипаның батыр характерын үз иткәнгә күрә Әбуталип семьясының тарихын йөрәге аша үткәрә. «һәм Идегәй тагын үз-үзенә, аларның тарихы турыдан-туры үзенә кагылган кебек, шушы семья өчен рәнҗүенә һәм сызлануына гаҗәпләнә иде. Кем соң әле алар аның өчен. Бу минем акыл җитәрлек эш түгел, миңа нәрсәгә кирәк соң әле бу дип ул үз-үзенә әйтә алыр иде бит. Үзенә тиеш булмаган нәрсәләр турында хөкем йөртерлек кем соң әле ул? Эштән башы чыкмаган дала кешесе. Андыйларның бит дөньяда исәбе-саны юк. Тормышта бу гадел дә, бу гадел түгел дип аңамы соң ачынырга, нәфрәтләнергә? Бу нәрсәләрне аңардан, Буранлы Идегәйдән мең тапкыр күбрәк белүчеләр бардыр бит. Сарүзәктә ул күргәнгә караганда анда яхшырак күренә торгандыр бит. Аның эшемени бу? Шулай да тынычлана алмады. һәм ни өчендер күбрәк аның өчен, Зарипа өчен йөрәге әрнеде. Аның турылыклылыгы, чыдамлыгы, кыенлыкларга җан көченә каршы торуы гаҗәпләндерә дә, әсир дә итә иде. Ул оясын давылдан канаты белән капларга тырышкан кошка охшый. Икенче берәү булса, елар-елар иде дә, буйсыныр, туганнарына барып башияр иде. Ә ул сугыш авырлыклары өчен ире белән бертигез нужа күрә. һәм нәкъ менә шунысы бөтенесеннән ныграк, бернигә карамыйча, Идегәйнең тынычлыгын ала да, чөнки бит ул аның балаларын да, ирен дә берничек тә яклый алмый... Соңыннан язмышның бу семьяны Буранлыга китерүенә бик үкенгән минутлары да булды. Бу көенечләр нигә аңа? Берни дә күрмәсә, белмәсә, әүвәлгечә тыныч кына яшәр иде...»

Коттыбаевлар семьясының тарихы һәм үзенең газаплы кичерешләре Идегәйнең рухи тормышында кульминация ноктасына әверелә. Шунысы характерлы, Әбуталипның исеме аклангач кына тынычланып яши башлый Идегәй.

Бу уңайдан Идегәй Җангилдинга үзенең үткән тормышында сугыштан соңгы, станциягә килеп чыккан еллары бигрәк тә истәлекле. Вакытка шул рәвешчә бәйләү геройның шәхси драмасы ил тормышындагы драматик вакыйгалардан аерылгысыз икәнен ассызыклап күрсәтә: «Әмма Идегәй ни белән генә шөгыльләнмәсен, аңа ничек кенә кыенга килмәсен, Әбуталип Коттыбаев тарихы башыннан чыкмый иде. Идегәйнең җанын кыйнап торды ул».

Яхшылык белән яманлыкның мәңгелек көрәшендә Идегәй Найман Ана, Раймалы ага, Казангап, Әбуталип, Елизаров, Укубала, Озын Әдилбәй, «Паритет»ның 1 нче һәм

2 нче космонавтлары белән бер якта. Ул манкортларга, «карчыгакүз» Тансыкбаевларга, «яңадан бәяләүчеләргә», Сабитҗаннарга каршы тора.

Язучының дөньяны тоюындагы фаҗигалелек манкортлыкның җиңүе рәвешендә чагыла. Моның мисаллары — Найман Ана белән аның улы, Раймалы ага белән аның туганнары, Әбуталип семьясы белән «карчыгакүзләр» тарихы, романның космик линиясендә җирдәге ике системаның үзара дошманлыгы кешелекнең, Җирдәге тормышның үсешендә яңа адымнан баш тартуга китерү. Романның космик линиясен тәгәлләгән соңгы юлларда бу сызлану тагын да көчәя: «Ракеталар ерак космоска, бәтенесе шул килеш калсын өчен, Җир шары тирәсендә даими чик булдырырга дип очалар иде». Шул килеш, ягъни системаара ызгышлар, дошманлык сакланып калсын өчен.

Ләкин кешелек хәтере улына ялваруы бушка гына булган Найман ананы һәм үз туганнары кимсеткән Раймалы аганы саклый. Үткәннәр, шул исәптән дала риваятьләренең дә елъязмачысы булган.

Әбуталипны саклый хәтер. Зур өмет баглап үстергән улыннан хөрмәт күрмәгән Казангапны да саклый ул.

Ч. Айтматов үз романында кешенең әхлакый идеяләренең диалектик үсешен бирә алган. Ике космонавт масштаблы итеп, бөтен җир шары исеменнән, аның Галәмдәге урыны турында уйлый алган кебек, дала киңлегендә югалып калган сигез өйле станциядәге эшче Идегәй Җангилдин дә җирдәге бөтен нәрсә өчен җаваплылыкны үз өстенә алырга тели: «Үлгәннән соң жанның нәрсәгә дә булса күчүе хак икән, нигә миңа кырмыска булырга, мин ак койрыклы тилгәнгә әверелер идем. Сарүзәк өстендә менә шулай очып, җиремә югарыдан карап туймас идем».

Көнбатыш белән көнчыгыш арасында сузылган тимер юлда поездлар хәрәкәте тынып тормаган кебек, кеше тормышында яхшылык белән яманлык көрәше дә туктап тормый — романда кабатлана торган рефренның мәгънәсе әнә шундый. Кеше язмышының бәясе дә аның шушы көрәштә актив катнашуы белән үлчәнә. Һәр меридианның озынлыгы нуль итеп алынган Гринвич ноктасыннан исәпләнгән кебек, теләсә кайсы кешенең дә тормыш кыйммәте шушы конфликтка катнашы белән үлчәнә.

Ә. Әлимҗанов повестенда урта гасырлар чоры белән тигезсез көрәштә чыккан Әбу Наср тормышы да әнә шуңа мисал. Аристотель һәм Сократ, Платон һәм Птолемей, Гераклит һәм Гиппократ тәгълиматларының эчке мәгънәсен кешеләргә яңадан ачкан Әбу Наср Игелекле шәһәр турында трактат яза. Ул үз заманын узып китә, шәкертләре аны «сөер кеше», «зирәк», «яхшы күңелле әкиятче» дип атыйлар.

Әбу Насрның рухи тормышы туган Отарыннан башлана. Шушында үсмер вакытта аның күңелендә тамыр җибәргән шытым ватаныннан читтә фаҗигалар-азаплар күреп йөргәндә дә исән кала. «Кеше беркайчан да үз-үзеннән, ә иң мөһиме — кеше мәшәкатьләреннән, кешеләр җәмгыятеннән качып китә алмый. Шулай булды һәм һәрвакыт шулай булыр. Кеше үз чорының законнарына буйсына, әмма аның карашы һәрвакыт киләчәккә төбәлгән».

Герой көчтән яки залимлектән башка Акыл берни дә түгел дип раслаган Сфинкс белән бәхәскә керә. Әбу Наср Акылга үз урынын алыр өчен көч кирәклеген яхшы аңлый, әмма ул залимлекнең Акылга таяныч булуы белән риза булмый. Бу очракта Акыл халыкка газап-михнәт булып әверелә, меңнәрчә тормышны корбан итеп пирамидалар төзү процессы шуны раслый. Әбу Насрның тирән ышануынча залимлек булган җирдә гаделлеккә урын юк.

Һәм ул Акыл таянырлык көч Игелек икәнлеген раслап, үзенең трактатын яза: «Халыклар бәхеткә ирешү өчен бер-берсенә ярдәм итешсәләр, бөтен җир игелекле булачак. Кеше өчен кирәкле байлыкларның иң специфик булганы акыл, чөнки кеше нәкъ менә акыл аркасында кеше булган да...»

Аның ил гизеп йөрүе дә үз акылын хөкемдарлар көченә буйсындырырга теләмәү белән аңлатыла. Ләкин үз чорыңнан качып булмый, күпкә булмаса да, трактатларын язу хакында гына да алар кул астында эшләргә туры килә. Шул трактатлары аша ул үз заманы чикләреннән атлап чыга.

Шул рәвешчә, хәзерге совет язучылары әхлак проблемасын хәл иткәндә, предметлары никадәр генә төрле булса да, әсәрләрдәге тенденцияләрнең уртаклыгы сизелеп тора.

Әйтик, композиция элементы буларак юл, реалистик функция үтәү белән бергә идея эчтәлеге дә ала, әхлак проблемасын ачуга булышлык итә. Һәр әсәрдәге вакыйгаларның конкрет вакыты һәм пространствосы хәтирәләр формасы кулланып киңәйтелә. Аларны геройның рухи үсеш процессы бергә бәйли.

Сурәтләү предметы һәм хикәяләүченең образы нинди булуга карап, геройларның рухи дөньясындагы әхлакый идеалның шул заман чынбарлыгына нисбәте чагыла. Мәсәлән, А. Гыйләҗевның «Язгы кәрваннар»ында яшүсмер Ибраһим вакыйгаларга мөнәсәбәтен бөтен авыл исеменнән белдерә. Ул совет кешесенең әхлакый кыйммәтләргә нигезләнгән, халыкның бөтен тарихы буена тупланып килгән коллектив аңын чагылдыра. Яшьләр өчен юл күрсәтүче йолдыз буларак, бу рухи кыйммәтләр заман сынавын үтәләр. Шунлыктан сугыштан соңгы елларның кырыс чынбарлыгы (район җитәкчеләренең хуҗасызлыгы, Сабирәттәйнең үлеме) повестьның оптимизмын басып китми. Бу оптимизм художество ягыннан алганда аклана, чөнки язучы коллектив аңны чагылдыручы итеп көч һәм өмет ташып торган, әле тормышка яңа кергән кешене сайлый.

Ч. Айтматов «Буранлы станциясе» романында сигез өйле бәләкәй разъездда яшәүче алтмыш бер яшьлек эшчене герой итә. Совет халкының коллективлашу чорыннан алып безнең көннәргә кадәрге тарихына шуның күзе белән карап әхлакый бәя бирелә. Идегәй совет кешесенең коллектив аңын чагылдыручы буларак чыга, бүгенге көндә киләчәкне кайгыртып, манкортлар — үткәнен оныткан коллар — белән актив рәвештә конфликтка керә.

Киләчәк турында кайгырту тойгысы Ә. Әлимҗанов повестеның героен Ч. Айтматов һәм А. Гыйләҗев геройлары белән туганлаштыра. Хикәянең үзәге итеп геройның гражданлык батырлыгын күрсәтү —«Игелекле шәһәрләр... турында» трактат язуны сөйләү шулай ук юкка түгел. Ул рәхимсезлектән, халыкның хокуксызлыгыннан, фәнне һәм акылны сөймәүдән, әзәрлекләүдән гыйбарәт булган шәһәрләргә, шул исәптән туган шәһәре Отрарга да охшамаган шәһәрне ничек күз алдына китерүен бәян итә.

Кыргыз, казакъ һәм татар язучылары иҗат иткән әсәрләрдә акыл һәм белем дәртс, үз бурычыңны һәм газаплылыгыңны тою, үз-үзеңне корбан итәргә әзер тору һәм игелеклелек тойгысы, туган илеңә һәм хатын-кызга мәхәббәт шигъриятле итеп тасвирлана. Болар һәммәсе дә бер буын кешелекнең икенче буынга калдыра торган рухи мирасы. Аларга санламыйча карау әхлакның йомшаруына китерә, ягъни манкортлыкка сәбәп була.

Шулай итеп, авторлар башка, әсәрләр төрле, ә үзәккә алынган, нечкәләп тикшерелә торган проблема уртак. Кеше бүгенге көн өчен генә түгел, ә киләчәк алдында да җаваплы — авторлар үз геройлары тормышы мисалында әнә шул фикерне басым ясап күрсәтәләр.

*Чимкент шәһәре*

## Вадим Дементьев

# ЯЛКЫНЛАНУ БӘХЕТЕ

Равил Фәйзуллинның китабын беренче мәртәбә кайчан һәм кайда кулга алганымны инде хәтерләмим. Тик шунысы истә: моңа Мостай Кәримнең мәкаләсе этәргеч булган иде. Ул бик үзенчәлекле башланып китә: «Аның шигырьләре турында болай гына сөйләшү кыен. Аларны өйрәнергә, тикшерергә кирәк. Югыйсә, җилдә җилфердәүче керләр җырын ничек ишетәсең, йөзеннән сарай кәрнизенә пәрәвез җебе сузылган тутыккан иске балтаның моңсу уйларын каян беләсең, иреннәрдән ялгыш тәгәрәгән оят сүзләрнең идән ярыгына яшерену мизгелен ничек күрәсең, язгы суларның зәңгәр шавын үз тамырларыңда ничек тоясың? Ничек?»

Олы шагыйрьнең бу сүзләрен укыганда инде минем үземнең дә Татарстанда берничә тапкыр булганым бар иде, татарларның сузынкы моңлы җырларын тыңлаганым булды. Равилнең үзен дә яхшырак белергә өлгердем, аңа игътибар беләнрәк карый башладым. Һәм аның шигырьләре минем аңымда яңгыраш тапты:

*Чәчмим, тапмыйм,*
*Чапмыйм, коймыйм...*
*Шулай да*
*миндә дә соңармый чәчүләр,*
*шытымнар сау-имин чыгалар,*
*өлгергәч башаклар,*
*минем дә багырьга тартела,*
*йөрәгем төбендә шау тынмый:*
*чабалар кумерен,*
*коялар корычын...*

Ә үзәк матбугатта Р. Фәйзуллинның исеме беренче тапкыр, ихтимал, тәнкыйтьче һәм публицист Әнвәр Бикчәнтәев тарафыннан телгә алынгандыр («Литературная Россия», 18 декабрь, 1964 ел). «Яшь шагыйрьнең шигырьләрен укып бик тәэсирләнеп йөрдем», дип язган иде ул. Әлбәттә, әлегә сүз татар телендә дөнья күргән шигырьләр турында бара иде.

Шул ук елны «Московский комсомолец» газетасында аның русчага беренче тәрҗемәләре басылды. «Ул чагында шигърияткә Рәдиф Гатауллин, Ренат Харис, Гәрәй Рәхим, Зөлфәт, Мөдәррис Әгъләмов килеп керде,— дип яза Мостай Кәрим.— Алардан чак кына алдарак Равил Фәйзуллин килде. Бу шагыйрьләр иң элек талантлы булулары белән бер-берсенә охшаш. Ә поэтик индивидуальлекләре ягыннан җир белән күк арасы. Шул ук вакытта алар ниндидер кыйммәтле һәм зарур яклары белән бер-берсен тулыландыралар. Шунлыктан шагыйрь Равил Фәйзуллинның үзенчәлекле фигурасын мин ялгыз итеп тоймыйм. Әмма ул, бу фигура, ерактан ук күренеп һәм аерылып тора».

Р. Фәйзуллинның Мәскәүдә «Молодая гвардия» нәшриятында чыккан беренче китабы (1974) «Минем телем» дигән шигырь белән ачылуын укучылар бәлки искәрми дә калгандыр. Ә бу очраклы хәл түгел иде. Татарстанда Габдулла Тукайның «Туган тел» дигән атаклы шигырен белмәгән кеше юктыр. Аның тәрҗемәләре күп. Әмма Тукайның васыять-шигыренең чын моңын тәҗрибәле тәрҗемәчеләрнең дә әле башка халык укучыларына илтеп җиткерә алганы юк. Шагыйрьнең «әнкәсе бишектә көйләгән, әбкәсе хикәя сөйләгән, кечкенәдән шатлыгы-кайгысы аңлашылган» туган телне сакларга дип, киләчәк буыннарга калдырган васыять бит ул.

Р. Фәйзуллин шигыренең Тукай тексты белән туры авываздашлыгы бар. Әмма иң әһәмиятлесе башкада — варислыкта, шигърият өчен җаваплылыкта. Тукай Фәйзуллинга китап аша килеп ирешкән. Гасыр башы белән 60 нчы елларны чагыштыра торган да түгел. Ләкин кайдадыр бер җирдә традициянең «тапшырылу» пункты бар, булырга тиеш. Мин аны яшь Фәйзуллинны иң беренче адымнарыннан ук яклап чыккан Сибгат

Хәким шигъриятендә күрәм. Равилнең олы шагыйрьгә багышланган шундый юллары исемдә. Аларда символика сизелеп тора:

*Бу йөзләрнең күбесе онытылыр,*
*гел хәтердә тормас бу табын.*
*Әмма онытмам Сибгат Хәкимнең*
*«Туган тел»не җырлаган чагын.*

Татарстан Язучылар союзының Әлмәт бүлекчәсенә җитәкчелек итә башлагач Р. Фәйзуллин язучылар съездларына, фикер алышуларга һәм конференцияләргә ешрак йөри. Бу аңа тугандаш халыкларның язучылары белән якыннанрак танышырга мөмкинлек бирә.

Шушы урында аның удмурт шагыйре Флор Васильев белән дуслыгын искә төшерми мөмкин түгел. «Дружба народов» журналының күптәнге бер санында мин Ф. Васильевның Р. Фәйзуллин китабына язган рецензиясен таптым. Ул игелекле күл белән, нәкъ менә шагыйрь турында шагыйрь язарга тиеш булганча язылган... Шул уңайдан удмурт халкының олы лиригы турында Равил Фәйзуллин фикерен китерү дә артык булмас: «Ул 1965—1975 елларда безнең Урал һәм Идел буйларында үсеп чыккан әйбәт шагыйрьләрнең берсе иде. Н. Рубцов кебек, В. Колумб кебек шулай иртә китүе бик үкенеч...» Миңа исә Флор Васильевның үзенең татар шигърияте һәм, аерым алганда, Р. Фәйзуллин иҗаты белән кызыксынуы турында әллә ничә тапкыр әйткәне бар иде. Аларның иҗатында якын торган тамырлар, охшаш сурәтләр табуы да кыен түгел. Әйтик, Флор Васильевның «Судан кайтучы кыз» шигыре.

*Женщина воду несет,*
*Словно петь затевая,*
*Встречных не задевая,*
*Сердце мое разрывая.*
*Женщина воду несет...*

*(Е. Храмов тәрҗемәсе).*

Хәзер менә Р. Фәйзуллинның шигъри юлларын карыйк:

*Кер чайкыйлар кызлар.*
*Тезләрендә — кояш!*
*Күзләрендә — яз!*
*Ярым ачык күкрәкләре*
*Оялган күк бераз...*

...Яшь талантлар үсеп чыгуга татар әдәбиятындагы атмосфера, әйбәт шартлар булышлык иткәндер дию генә җитми. Шартлар нинди генә булмасын, талантлар кирәк, исемнәр кирәк. Татар әдәбияты үсешендәге мөһим факторларның берсе — аның дәвамлы һәм үзенчәлекле традициясе. Безнең көннәргә хәтле килеп җиткән «Кыйссаи Йосыф» поэмасының җиде йөз илле еллык тарихы бар. Габдулла Тукай да бу әсәрнең халык арасында искиткеч популяр булганлыгы турында язып калдырган. Туган телеңә, аны барлыкка китерүчеләргә мәхәббәт — хәзерге тормышның да характерлы үзенчәлеге. Мәсәлән, Казанда татар әдәбияты классиклары хөрмәтенә, китаплары чын мәгънәсендә бөтенхалык байлыгы булып әверелгән кешеләр хөрмәтенә куелган мемориаль такталарны бик күп күрәсең.

Моннан тыш, республиканың экономик яктан моңарчы күрелмәгән дәрәҗәдә күтәрелеп китүе дә яшьләрнең рухи үсешенә сәбәп булды. Брежневтагы завод-гигант, Түбән Кама нефтехимия комбинаты, Европада иң зурлардан булган Казан елга порты, авыллардагы заманча төзелгән терлекчелек комплекслары... Татарстанның «нефть башкаласы» дип аталган Әлмәт тә шулар арасында (Р. Фәйзуллинның берничә ел гомере шушы шәһәр белән бәйле). Культура традицияләре зур булган як (мәшһүр Казан университетын гына искә төшерик), экономик бәйләнешләр, юллар чаты, Идел буеның бәрәкәтле туфрагы — татар әдәбиятының күтәрелүе, чәчәк атуы соңгы исәптә менә шуларның һәммәсе белән дә билгеләнә бит.

Әнә шуларның барысын да әйтмәү Р. Фәйзуллин шигъриятенең нәрсәсендер төшенеп җитмәү кебек булыр иде. Чөнки бу иҗатта чор хәрәкәтен тоемлау бар. Гомумән, шагыйрьнең иҗаты заман турында, дәвернең конкрет бер тарихи өлеше турында сөйләшүгә сәбәп була ала.

Укучы инде искәрми калмагандыр, Р. Фәйзуллинның шигырьләрен күп кенә рус шагыйрьләре тәрҗемә итә. Русча чыккан китапларының берсен шагыйрь шулай бик үзенчәлекле итеп төзегән дә: шигырьләрен тәрҗемәчеләр буенча циклләп бүлеп чыккан. Әмма, рецензияләрнең берсендә билгеләп үтелгәнчә, китапта автор үзе югалып калган. Бәлки җыентыкны бу принцип белән төзегәндә Фәйзуллин шигъриятенең «йөзе» төрлечә булу күзгә бәреләдер? Югыйсә, тулаем алганда, рус тәрҗемәчеләре шагыйрь сөйләменең төсмерләрен, үлчәмен, сурәтләр системасын дөрес бирәләр бит.

Фәйзуллин шигырьләрен күптән тәрҗемә итүче Мария Аввакумова турында аерым әйтәсе килә. Ул, авторның интонациясен дә, сулышын да саклаган хәлдә, шигырьнең тукымасына үтеп керә белә. Тәрҗемә итүе дә үзенчәлекле: эшкә керешкәнче, шигырьнең җанлы укылышын тыңлап карый яисә оригиналны җентекләп өйрәнә. Шунлыктан аның тәрҗемәләрендә үзенчәлекле музыкальлек сакланып кала, ул башка тәрҗемәләрдән әнә шуның белән аерылып тора да. М. Аввакумова бик әйбәт тәрҗемәче һәм Р. Фәйзуллин өчен шундый иптәш-теләктәш табылу зур бәхет. Чөнки бердәнбер дөрес сүзне аларга бергәләп эзлисе.

Заман факторы, үткәнне, бүгенгене һәм киләчәкне бик үткен итеп тою Р. Фәйзуллинның «Мой звездный час» һәм «Миг возвращения» кебек китапларының исемендә үк чагылыш таба. Шагыйрьнең әле үткән заманнарга, әле бүгенге көнгә шулай җиңел мөрәҗәгать итүе аның гасырлар арасындагы тарихи бәйләнешне тирәнтен аңлавы хакында сөйли. Шагыйрь үзе яулап алган, үзе тапкан хакыйкатьләрне яза:

*Кеше ирекле...*
*Яланаяк*
*салкын, юеш ташта торамы ул,*
*үлән-чәчәк өстендәме,*
*һавадамы,*
*судамы,*
*җир куеныдамы —*
*ул ирекле.*

Фәйзуллинның күп кенә шигырьләрен әнә шундый канатландыра, җилкендерә торган тойгыдан башка күз алдына китерү кыен. Ә иреклелек тойгысы үзе кешенең эчке азатлыгы, бәйсезлеге белән бәйләнгән. К. Марксча әйткәндә, «аңланган зарурлык» шагыйрьне яңа офыклар ачу юлыннан алып бара.

Минем уемча, Фәйзуллин шигырьләрендә яңгырый торган горур «мин» әнә шуннан килә. Ул һич тә үзенә генә гашыйк кешенең мин-минлеге түгел. «Кеше ирекле» ди шагыйрь һәм шунда ук болай дип өсти:

*Хәятыма тигән*
*шул зур бәхет өчен*
*көрәшергә бөек хакым бар.*

Үзенчәлекле һәм киң мәгънәле метафораларда чагылыш тапкан гражданлык пафосы да әнә шуннан, дөнья язмышы өчен шәхси җаваплылыктан килә. Ярылган карбыз кисәге шагыйрьгә җирнең юк ителү куркынычын искәртә, ә күпер эш кешесенең кытыршы кулын хәтерләтә.

Менә шушында инде безгә Р. Фәйзуллинның үзенә бер төрле язу манерасы, шигъриятнең яңалыгы турында сүз кузгатырга була. Иң дөресе, шулай язу өчен шулай күрергә, шулай фикер йөртергә кирәктер (Мостай Кәрим хаклы). Ләкин бит шигырь үзең өчен генә язылмый, ул укучы аңласын өчен, авторга ышансын, аның хаклыгын тойсын өчен языла. Бирелә һәртөрле ышанмау драмага әверелә. Ләкин менә шунысы кызык: новаторларча шигырьләр белән беррәттән бу шагыйрьдә бөтенләй традицион булганнары да очрый. Р. Мостафин язганча: «Р. Фәйзуллинның новаторлыгы формаль эзләнүләргә генә кайтып калмый, өстәвенә ул үзе дә соңгы елларда традицион рифмалы шигырьгә һаман ешрак мөрәҗәгать итә, шул ук вакытта үзе булып та кала бирә». Әлеге фикер бик әһәмиятле, чөнки дөньяны гармонияле күрә белгән чын художникта, минем уемча, башта «яңача», аннары «искечә» яза торган төрле-төрле «чорлар» була алмый. Андый «эзләнүләр» эчке стилизация, икенчеләр шаукымы гына ул. Р. Фәйзуллин үзенең шигырьләрендә (алар ничек кенә язылган булса да) үзе булып кала. Аның сыйфатлары шул: ачыклык, намуслылык, югары шигърилек һәм ниндидер... әйтик, тыңлау өчен гадәти, күнегелгән булмау.

Р. Фәйзуллин күңел, тойгы, фикер хәрәкәтен мәгънәле, кыска итеп тасвирлый белә! Аның күп кенә шигырьләре иң элек менә шулай кысынкы язылуы, берничә генә сүзгә тирән мәгънә сыйдыруы белән кызыксындыра да. Менә бер генә мисал:

*Җирдә — аклык, җанда — шатлык,*
*Беренче кар, беренче кар!*
*Баш — бүректә, бүрек — күктә!*
*Беренче кар, беренче кар!..*

Мондый кыскалык, лаконизм ике генә очракта булырга мөмкин: яки шагыйрь газапланып сүз сайлый, яисә ул һәрвакыт ниндидер бер рухи киеренкелектә яши. Миңа калса, Фәйзуллинга соңгысы ныграк туры килә. Шундый киеренкелекне тою Фәйзуллинга шигърияттә иронияга бирелергә, тикмәгә шаярырга, юк-бар нәрсәләр язарга мөмкинлек бирми. Бөтенесе дә җитди, төптән уйланган, күңелдән кичерелгән.

Игътибарның таралуы һәм кинәт бер нәрсәгә туплана алуы, фотоаппарат «күзе» кебек бер фокус сайлый алу — Р. Фәйзуллин шигъриятенең шулай ук үзенчәлеге. Ул япон һәм гомумән шәрык миниатюрасын хәтерләтә: анда да бит кайчакта бер штрих бөтен бер полотноның дидактик идеясенә караганда күбрәк мәгънә бирә.

Шагыйрьнең баштарак чорда язылган кайбер шигырьләрендә гомуми дидактика «чире» сизелә иде. Соңга таба ул моны җиңә алды. Әйбәт шигырьләрендәге метафораларның күп мәгънәлелеге гүя кыска юлларга иркенлек, киңлек ачты, анда сулыш иркенәеп китте һәм тойгылар да сизгерләшә төште кебек.

«...Равил Фәйзуллин шигырьләре күп сүзле түгел. Ул сурәт ясаганда аның фикере кайвакыт шигырь юлларын да узып китә. Әйтерсең лә автор күргән-белгән нәрсәсен әйтеп бирергә, бүлешергә тәкатьсезләнә. Киеренке пульс кебек «өзек-өзек» стильдә язу, бераз гасаби эмоциональлек әнә шуннан килә»,— Флор Васильевның бу фикерендә югарыда телгә алынганнарның күбесе әйтелә.

Шагыйрь иҗатында еш кына чагыла торган бер «гөнаһ» турында «Дружба народов»та чыккан рецензиянең авторы шулай ук төгәл әйтеп бирә: «Вакыты белән шигырьләрнең алдан исәпләп, программалаштырып куелганлыгы сизелә. Кайчакта салкын фикерләүне тоясың». Чыннан да, Р. Фәйзуллинның кайбер шигырьләрендә хисләр лирикасы белән акыл бер-берсенә органик рәвештә кушылып бетми.

Моның ышандырырлык мисалы — «Көрәшчеләр» поэмасы. Бу әсәрдә шагыйрьнең уңышсызлыкка очрау сәбәбе — поэманың алдан схематик рәвештә уйлап куелуында. Бередә очсыз-кырыйсыз пафослы өндәмәләр тезелеп китә: «Ә хәвеф бар! Ә хәвеф бар!! Ә хәвеф бар!!! Гуманизм, әйдә саф алдына, чакыру уйна! Көрәшчеләр, тезелегез!» Бу сүзләр ялыктыргыч тәэсир калдыра, сюжет бәйләнешен йомшарта, поэма озынга сузылган дигән тәэсир кала. Ә һәммәсе бергә укучыны поэманың гомуми уй-нияте абстракт, җансыз дигән фикергә китерә.

Бередә Р. Фәйзуллинны «Көрәшчеләр» поэмасының яшьли язылган булуы гына «аклый». Анда яшүсмерләрчә максимализм да, беркатлылык та, дөньяны үзенчә үзгәртеп кору теләгенең үтә көчле булуы да сизелеп тора. Шагыйрь җитлегә төшү белән бу сыйфатлар, әлбәттә, үзгәрде, әмма яшьлек дәрте, хәзер дә шагыйрьнең язганнарын аерып тора торган сыйфатлардан берсе.

Әйе, Р. Фәйзуллинның бик күп шигырьләрендә әле һаман да яшьлек тавышы ишетелә. «Мич тулып шигырьләр яна» дип башланган шигырьдә ул бигрәк тә көчле:

*Мич тулып шигырьләр яна.*
*Күгем яна,*
*Йолдызларым,*
*аем яна...*
*Яңу-ягу — шагыйрьләр эше.*
*Вак җаннарга кая!*
*Теләсә кемгә*
*тәтемәгән*
*яну бәхете!*

Мәскәү.

**Фатыйх Урманчиев**

# ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ — ВЕНГРИЯДӘ

Бу мәкаләне язу өчен беркадәр материал җыеп, библиографик белешмәләр, венгр телендә басылган әдәби энциклопедияләр, бирдә татарча чыккан китапларның байтагы белән танышкач та, М. Горькийның мәгълүм сүзләре хәтергә килде: сүз сәнгатенең башы фольклорда. Татар әдәбияты дигәч тә, венгр укучылары, барыннан да элек, безнең халык иҗаты әсәрләре белән танышалар, һәм бу эш ярыйсы ук иртә, 1838 елда, ягъни гасыр ярым элек башлана. Бу өлкәдә беренче адымны әдәбият әһелләреннән Габор Казинцзи (1818—1864) ясый. Ул Франциядә чыккан бер китаптан татар халкының берничә әкият-легендасын табып, шуларны венгр теленә тәрҗемә итеп бастыра.

Танылган галим Матиаш Александери Кастрен 1848 елгы революциядән соң әдәби журнал редакциясендә Алтай телләре буенча төрле укулар, докладлар һәм лекцияләр оештыра. Шул уңайдан 1858 елда әлеге журналда татар халкының батырлык әкият-дастаннары басылып чыга. Биш елдан соң бирдә беренче тапкыр безнең халык иҗаты әсәрләре татар телендә дөнья күрә. Атаклы сәяхәтче һәм галим Вамбери Арним Казанда 1852 елда чыккан «Урыс-татар әлифбасы»ннан алынган дүртьюллык җырларны (барлыгы 34) гарәп хәрефләре белән татарча һәм сүзгә-сүз тәрҗемәдә венгр телендә бастыра.

Сенткатолнаи Балинт Габор (1844 — 1913) — безгә татар телен һәм әдәбиятын өйрәнү өчен Венгриядән фәнни командировкага килгән беренче галим. Безнең якларга ул ике тапкыр — 1871 һәм 1875 елларда килеп китә, чын фәнни нигездә татар телен һәм әдәбиятын өйрәнә. Командировкадан кайткач, Татарстанда җыйган материаллары нигезендә, зур күләмле фәнни китап әзерли. Г. Балинт җыентыгы XIX йөздә Венгриядә басылып чыккан һәм татар халкының теленә һәм әдәбиятына багышланган китапларның иң зурысы һәм җитдие, шуңа күрә аңа киңрәк тукталырга кирәктер. Бу китап татар фольклорының XIX йөздәге үсеш формаларын, халык арасында таралуын, җырчы-әкиятчеләрнең репертуарын өйрәнү өчен әле хәзер дә әһәмиятле чыганакларның берсе булып тора. Җыентыктагы материаллар нигездә керәшен татарлары авызыннан һәм халык арасында таралган төрле язма чыганаклардан алынган. Халык иҗаты үрнәкләрен тапшыручылар арасында Симон Гаврила улы Борис исеме аеруча еш очрый.

Китап өч зур бүлектән тора. Ярыйсы ук күләмле беренче бүлек (170 бит) халык иҗатына багышланган, һәм ул «Борынгылар әйткән сүзләр» белән ачыла. Бүлекчәдә «Акрын баскан ат булган, ашыкмый оарган ир булган», «Кемнең итәгенә ут төшсә, шул яна», «Яхшы исем малдан артык» кебек латин хәрефләре белән татарча язылган 144 мәкаль урнаштырылган. «Йомаклар» исеме астында «Кәкре агачта кар тормас», «Аты бара, тәртәсе кала» шикелле 46 табышмак бирелгән. «Ерлар» битләрендә 64 кыска җыр урын алган. Барысы да мәхәббәт турында. Тик берсе генә социаль эчтәлеккә ия:

*Шыбыр да гына шыбыр яңгыр ява*
*Яшь үлән башларын чылатып;*
*Патша солдат ник ала икән*
*Яшь кенә егетләрне елатып.*

«Бәетләр» бүлекчәсендә урын алган дүрт әсәрнең өчесе шәхси фаҗигалар, берсе — «Солдатка китү» дип исемләнгәне — авыр тормыш шартлары турында сөйли:

*Имән агач каты агач,*
*Каен агач, җир агач;*
*Писер язды, мин киттем,*
*Падишага ярагач.*

Китапның әкиятләргә багышланган өлеше әйруча бай. Биредә 34 әсәр урнаштырылган. Арада мәзәкләр дә, мәсәлләр дә, тылсымлы һәм тормыш-көнкүреш әкиятләре дә бар. Аларның байтагы нинди дер язма чыганаклардан алынган булса кирәк. Шунысы үзенчәлекле: кайбер әкиятләргә түбәндәгечә эпиграфлар бирелгән: «Белмәгән мең бәладән котылган», «Әйткәнне тыңла, яхшыны кыл, дигән ди кызына бер карчык үзе үлгән чагында»...

Беренче бүлектә урнаштырылган материалларның «Керәшеннәрнең ышана торган кирәмәтләре» дип исемләнгән өлеше дә әһәмияткә ия. Чөнки татар мифологиясе гомумән акрын өйрәнелә. Балинт китабында исә сүз керәшеннәр арасында таралган төрле ышанулар, шулай ук Өй иясе, Сарай иясе, Су иясе, Шүрәлеләр турында бара. Бу материалларга таянып, Казан татарлары, мишәрләр һәм керәшен татарлары мифологиясе бер үк социаль-экономик һәм рухи-идеологик шартлар нигезендә, бик борынгы чорларда формалашкан, дип әйтергә мөмкин.

Биредә шулай ук язма чыганаклардан алынган легендаларның татарча вариантлары китерелгән. Шулар арасында Тәүраттә һәм Корьәндә чагылыш тапкан Йосыф исеме белән бәйле легендалар игътибарга лаек. Хезмәтнең икенче зур өлешен татарча-венгрча-немецча сүзлек тәшкил итте. Өченче бүлек исә татар теле грамматикасына багышланган.

Бу китап турындагы сүзне йомгаклап, шуны әйтергә кирәк: Балинт җыентыгы басылып чыккан чорында гына түгел, хәзер дә гаять югары бәяләнә. Сегед университетының Алтай телләре кафедрасында (мөдире — танылган тюрколог Андраш Рона-таш) Г. Балинт китабы нигезендә «Керәшен татарларының теле» дигән темага җитди мәкаләләр, зур фәнни хезмәтләр языла.

Безнең фольклор фәнендә халык иҗатын этник төркемнәр буенча өйрәнү әле тиешенчә башланмаган да. Хәлбуки, XIX йөзнең 70 нче елларында фольклор әсәрләрен нәкъ шул юнәлештә тикшерү мәсьәләсе ярыйсы ук югары дәрәҗәдә торган. 1872 елда академик В. В. Радловның Себер татарлары фольклоры әсәрләреннән торган китабы басылып чыкса, өч елдан соң Г. Балинтның керәшен татарларына багышланган җыентыгы дөнья күрә...

Балинт китабы чыкканнан соң озак та үтми, фин галиме, археолог Барна Фердинанд (1825—1895) Венгриядә «Алтай халыкларының борынгы ватаннары буйлап» дигән исем белән фәнни-популяр мәкалә бастыра. Анда сүз XVIII йөз тарихчысы Шәрәф-эд-диннең елъязмасы һәм башка кайбер борынгы чыганаклар турында бара.

Сәяхәтче һәм галим Арним Вамбериның 1885 елда басылып чыккан бер хезмәтендә шундый сүзләр бар: «Казан татарлары әдәбияты ислам дине йогынтысы астында торган башка төрки халыкларның әдәбиятыннан әллә ни аерылмый... Тик табигый, гади, искиткеч матур халык әдәбияты гына бернинди йогынтыга бирелми һәм үзенең гүзәллеген югалтмый саклап килә». Бу сүзләрнең беренче өлеше белән бик үк килешәсе килмәсә дә, алар Венгриядә халык иҗатына, шул исәптән татар фольклорына да игътибар елдан-ел арта баруын аңлата булса кирәк. Бу эш XX гасыр башында да дәвам иттерелә. 1906 елда Казанга тюрколог Месарош Дьюла фәнни командировкага килә. Ә 1907 елның язында ул Түбән Коршаба авылына бара һәм төрле әкиятләр, җырлар язып ала. Алар арасында күңелле мәҗлес җырлары да, мәет озату белән бәйле моңсу җырлар да була. Үз иленә кайткач, ул «Чувашлар һәм татарлар» дигән темага фәнни доклад ясый, соңыннан аны бастырып та чыгара.

Татар халык иҗатына игътибар артканнан-арта бара. 1908 елда «Пешт көндәлеге» газетасында дүрт әкият басыла: «Хәйләкәр дус», «Акыллы җавап», «Хәйләгә — хәйлә», «Яшьлек бар дип, картлыкны хурлама»[1]. Ике елдан соң Себер татарларыннан язып алынган «Ата-ана» исемле баллада һәм «Әдәпле хатын» дип аталган шигъри әкият дөнья күрә.

Билгеле булганча, беренче бөтендөнья сугышы вакытында, рус солдатлары белән бергә, татарлар да әсирлеккә эләгә. Аларның Венгриядәгеләре ике төркемгә бүленеп, берсе — Эгер, икенчесе Эстергом янындагы лагерьларга җибәреләләр. Венгр чыганак-

---

[1] Мәкаләдә телгә алынган әсәр исемнәре турыдан-туры венгр теленнән тәрҗемә итеп бирелә. Аларның кайберсе Казанда чыккан китапларда башкача булуы да мөмкин. Автор искәрмәсе.

ларындагы сүзләр белән әйтсәк, тел галиме Кунош Игнац «бу мөмкинлектән файдаланмакчы була», Венгрия Фәннәр Академиясе тәкъдиме һәм ярдәме белән әлеге татар әсирләреннән күп кенә җырлар язып ала. Әнә шул материаллар нигезендә ул татар һәм немец телләрендә матур гына җыентык әзерли һәм махсус очерк язып чыгара. Бу уңайдан шуны әйтеп узыйк: Игнац җыентыгы бер-ике ел элек Будапештта тагын бер тапкыр басылып чыкты. Матбугатка аны университетның төрки телләр кафедрасында эшләүче Жужа Каккук әзерләгән. Әлеге китапның берничә нөсхәсе Татарстанга — Казанга да кайтып җитте...

Безгә мәгълүм булганча, Кунош Игнац татар әсирләре белән якыннан аралаша. Әсирләр арасында татарча «Кечкенә җуаткыч» дип исемләнгән дәфтәрчекләр, бит-бит кәгазьләр йөрүен ишетеп, шул язмалар белән дә таныша, шуннан алынган берничә җырны, әйтик, «Моңлы хатын» җырын венгр теленә тәрҗемә итеп чыгара.

Әлегә кадәр сүз халык иҗаты турында гына барды. Чөнки агымдагы гасырның егерменче елларына кадәр венгр укучылары татар язучылары турында матбугатта бер генә сүз дә очрата алмыйлар. Ниһаять, егерменче еллар башында бирелә бөек шагыйребез Тукай турында мәкаләләр чыга башлый: беренчесе 1921 елда француз телендә, икенчесе 1922 елда венгр телендә. Борынгы татар әдәбияты фарсы әдәбияты йогынтысында үскән, дигән фикер уздырыла әлеге мәкаләләрдә. Хәзерге татар әдәбияты исә барыннан да элек милли традицияләргә таяна һәм шул нигездә горурланырлык казанышларга ирешә; бу юнәлештә армый-талмый эшләгән шагыйрьләрдән гадәттә Тукай исеме күрсәтелә...

Утызынчы еллар башында венгр телендә чыга торган «Туран» журналында Г. Тукай турында профессиональ әдәбиятчы каләме белән язылган мәкалә басыла. Анда бөек шагыйрь иҗатына искиткеч югары бәя бирелә. Тукай әсәрләренең гади һәм нәфис булуы, сатирик әсәрләренең җор, йөгерек, шул ук вакытта үткен тел белән язылуы турында әйтелә. «Тукай үз заманы өчен алдынгы, прогрессив шагыйрь иде. Хәтта алай гына да түгел, Тукай революцион шагыйрь иде»,— диелә мәкаләдә.

Ә менә утызынчы елларның икенче яртысыннан кырыгынчы еллар ахырына кадәр Венгрия матбугатында татар язучыларының исеме күренми. Халык иҗаты әсәрләре дә басылмый. Тик 1949 елда гына венгр матбугатында безнең танылган прозаикларыдан Фатих Хөснинең бер хикәясе дөнья күрә — «Яңа чор» журналында «Кабын» хикәясе басыла.

Илленче еллар башыннан исә безнең әдипләр исеме бирелә ярыйсы ук еш күренә башлый. Венгр әдәбиятчылары язуынча һәм төрле библиографик белешмәләрдән күренгәнчә, илленче еллар башында бирелә Әхмәт Ерикәйнең шигырь һәм җырлары ярыйсы ук еш басыла, газета һәм журналларда, төрле җыентыкларда чыгып тора. Ә 1952 елда Венгриядә Гомәр Бәшировның «Намус» романы Магош Ласло тәрҗемәсендә басылып чыга. Китапка 5—6 рецензия языла. Татар романнарыннан Венгриядә беренче үрнәк буларак басылып чыккан «Намус» әсәре һәм тәрҗемәсенең эшләнеше җирле матбугатта уңай бәя ала.

Шул ук 1952 елда Будапештта «Совет поэзиясе антологиясе»нең беренче басмасы чыга. Зур күләмле бу китапта татар шагыйрьләре Һади Такташның «Киләчәккә хатлар»ыннан беренче хат, Әхмәт Ерикәйнең «Исәнме, яшьлек», «Теләк» әсәрләре басыла. Шуның белән бергә, җыентыкта әлеге шагыйрьләр турында кыскача мәгълүматлар да бирелә. Шул ук шагыйрьләр антологиянең 1955 елда чыккан икенче басмасында да урын алалар. Тик Ә. Ерикәйнең «Исәнме, яшьлек» җыры урынына «Көзге яфраклар» алына.

Ә 1953 елда венгр телендә татар драматургиясеннән беренче үрнәк — Гариф Галиевның «Хаттан башланды» исемле бер пәрдәлек пьесасы басылып чыга һәм режиссер Балинт Лайош тарафыннан сәхнәгә дә куела.

Алдагы 1954 ел исә бигрәк тә татар халык иҗаты өчен уңдырышлы була. «Оча торган кораб» дип аталган зур күләмле әкиятләр һәм мәзәкләр җыентыгында Раб Жужа тәрҗемәсендә татар фольклорыннан алты әсәр басыла: «Кәкре каен тераткан» мәзәге, «Ак бүре», «Гөлчәчәк», «Алмай-батыр белән Сандугач» әкиятләре. Әйтергә кирәк, җыентыкка кертү өчен татар халык иҗаты әсәрләре уңышлы сайланган. Алар безнең әкиятләр турында венгр укучысына ярыйсы ук яхшы мәгълүмат бирәләр.

Татар халык әкиятләре, гомумән, безнең фольклор әсәрләре Венгриядә моннан соң да басылып тора. Мәсәлән, 1955 елда әле генә әйтелгән җыентыкның икенче, 1960 елда өченче басмасы дөнья күрә. Югарыда күрсәтелгән һәм шулай ук башка әкиятләр китапның һәрбер басмасында урын алып бара. Мәктәп балалары өчен чыгарылган махсус китапларда, башка кайбер җыентыкларда да безнең әкиятләргә лаеклы урын бирелеп килә.

Югарыда искәртелгәнчә, Будапештның Өтвөш Лоранд исемендәге университетында төрки телләр кафедрасы эшли. Шул кафедраның хезмәткәре Жужа Кәккүк 1980 елда «Хәзерге төрки телләр» дип исемләнгән ике томлык фәнни җыентык бастырып чыгарды. Китапта татарча чыганаклардан алынган һәм татар телендә басылган житди генә әсәрләр дә бар. Әйтик, җыентыкны әзерләүче Казанда басылган «Татар халык әкиятләре» китабыннан «Алтын балдак»ны ала; керәшен татарлары фольклор үрнәге итеп, югарыда күрсәтелгән Г. Балинт китабыннан ике әкият кертелә. Ике томлыкны төзүче, мишәр фольклорына караган материаллар табу өчен, һ. Паасоненның мәгълүм китабына мөрәҗәгать итә. Тобол, Түмән һәм Бараба татарларының иҗатын, дәресрәге, телен беркадәр күз алдына китерү өчен материаллар В. В. Радлов җыентыгыннан алына.

Китапта татар халык иҗаты әсәрләре күп түгел. Әмма аларны урнаштыру принциплары игътибарга лаек. Биредә татар халкының төп этник төркемнәренә хас фольклор әсәрләре урын алган. XIX йөзнең житмешенче елларында В. В. Радлов һәм Габор Балинт сайлаган юнәлеш биредә дә дәвам иттерелә.

Татар халык әкиятләрен дөньяга чыгару эшенең үзенчәлекле йомгагы буларак, 1981 елда Будапештта венгр телендә «Бүген бардым, иртәгә кайттым. Казан татарлары әкиятләре» исемле җыентык басылып чыга. Иң әлек китапның почта эшләнгән тышкы күренеше матур тәэсир калдыра. Аны Сегед университетында, югарыда телгә алынган тюрколог Андраш Рона-таш житәкчелегендә Алтай телләре кафедрасында эшләүче Клара Адягаши әзерләгән. Татар халык әкиятләренә багышланган матур гына мәкаләне дә ул язган. Китапта «Дутан батыр», «Әйгәли батыр», «Камыр батыр» кебек батырлык әкиятләре дә, сатирик пландагы тормыш-көнкүреш әкиятләре дә урын алган. Тулаем алганда, алар татар халык иҗатының бу төре турында ярыйсы ук киң мәгълүмат бирәләр. Җыентыкның исемендә сүз казан татарлары турында гына барса да, анда башка якларда, әйтик, Омск, Новосибирск өлкәләрендә язып алынган әкиятләрдән дә аерым үрнәкләр кертелгән. Әкиятләрне кайчан, кайда, кем язып алуы турында аңлатмалар, татар халкы һәм фольклор хакында кыскача библиография дә бирелгән. Китапны венгр телендә әзерләүдә тәҗрибәле тәрҗемәчеләр Адягаши Клара, Берта Арпад, Андраш Рона-таш, Ласло Захемски һ. б. лар катнашкан.

Вакытлы матбугат битләрендә дә татар халык иҗаты әсәрләре әледән-әле күренгәләп тора. Мәсәлән, 1959 елда «Тисса буе» журналында «Бай карт» әкияте, 1968 һәм 1970 елларда «Халык азатлыгы» газетасында «Кәкре каен тераткән», «Апалысеңелле өч туган», шул ук 1970 елда «Хатын-кызлар» журналында «Зур тавышлы кечкенә әтәч», 1969—1970 елларда «Факел»да «Өч ялкау», «Ишетмәс колак», ә «Чишмә» журналында (1980 ел) татар халык җырларыннан «Шундый авыр безнең тормыш», «Фатыйманың үлеме», «Ак каеннар гүзәллеге», «Аллы-гөлле бакчаларда йөрим», шул ук 1980 елда «Совет әдәбияты»нда Себер татарлары җырлары һ. б.лар дөнья күрә. Будапештта венгр телендә дә чыга торган «Совет әдәбияты» журналы безнең шагыйрьләр иҗатына да урын биреп килә. СССР төзелүгә алтмыш ел тулу уңае белән журналның 1982 елгы соңгы санында 118 шагыйрьнең әсәрләре басылып чыкты: рус, казах, кыргыз, үзбәк... Арада безнең поэзиядән дә бер әсәр — Зәки Нуриның Олаһ Янош тәрҗемәсендә «Бу кышта...» шигыре бар. Шул ук журналның 1976 елгы 5 санында исә Г. Тукайның берничә әсәре — «Өзелгән өмид», «Туган илемә», «Китап», «Өмид» һәм башкалар Дьери Имре, Калноки Ласло, Кормош Иштван, Симон Лайош тәрҗемәләрендә дөнья күрә...

Татар прозасының хәзерге торышын чагылдырган әсәрләрдән 1977 елда венгр телендә Г. Бәшировның «Туган ягым — яшел бишек» китабыннан өзек Буда Ференц тәрҗемәсендә басыла. 1982 елда исә әсәр тулысынча аерым китап булып чыга (венгр телендә ул «Туган җирем...» дип кенә бирелгән). Әсәр Дьюла Фюзеши тарафыннан нигездә уңышлы тәрҗемә ителгән. Венгр әдәбиятчыларының хәзерге татар прозасыннан бу әсәргә тукталуының билгеле бер сәре дә бар. Мәгълүм булганча, Г. Бәширов әсәрендә татарларның борынгыдан килгән изге гореф-гадәтләре, ышану-йолалары, милли тормыш-көнкүреш үзенчәлекләре, гади агай-апайларның чисталыгы-пакьлеге, кунакчыллыгы һәм киң күңеллелеге, халык күңелендә сакланган әкият-дастан яки җыр-бәетләрнең чаткылары ярыйсы ук тулы чагыла. Гомумән, әсәр татар халкының үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән таныштыра. Гадәти романнар хәзерге укучыны беркадәр ялыктыргангамы, венгр әдәбиятчыларының Г. Бәширов әсәренә тукталуы табигый, әлбәттә. Өстәп шуны гына әйтим: әсәр җирле матбугатта да уңай бәя алды. 1983 елда «Советлар Союзы» журналының Венгрия өчен чыгарыла торган нөсхәсендә журналның венгрча басмасы редакторы Винтермантель Иштванның әлеге китапка югары бәя биргән рецензиясе чыкты.

* * *

1980 елның көзендә Венгриягә килеп эшли башлагач, югарыда телгә алынган Ласло Захемски белән Будапештка барып, «Европа» нәшриятына кердек. Ласло мине совет әдәбияты редакциясе мөдире Жигмонд Геренчер белән таныштырды. Жигмонд минем белән танышуына нигәдер балаларча шатланды. (Редакция мөдирләре практикасында сирәк була торган хәл!) Эш менә нәрсәдә икән: кырыгынчы елларның икенче яртысында ул Казанда укыган, университетның юридик факультетын тәмамлаган. Казанны бик яхшы белә. Кайчандыр мәшһүр булган Маркиз утравын сагынып искә ала. Үзенең дусларын — татар егетләрен исем-фамилияләре белән хәтерли. Студент еллары турында ул махсус очерк та язып бастырган...

Яшьлек елларын, Казанны искә алып озак кына утыргач, Жигмонд эш мәсьәләләренә күчте, татар язучылары алдында зур бурычлы булуы турында борчылып сөйләде. Казанда басылган «Татар поэзиясе антологиясе» үрнәгендә Будапештта венгр телендә зур күләмле җыентык чыгару турында сүз булган икән. Хәтта ул җыентыкның татарча варианты да төзелгән... Ләкин нишләптер җыентык венгр телендә әле дә әзерләнеп бетә алмый икән. Менә шулар турында сөйләгәч, Жигмонд: «Безнең өчен иң әһәмиятлесе — татар әдәбияты әсәрләрен венгр теленә татар теленнән турыдан-туры тәрҗемә итү. Бу мәсьәләдә безгә Сегед университетының алтай телләре, Будапешт университетының төрки телләр кафедралары зур ярдәм күрсәтә», — диде. Аннары ул басылып чыккан китаплар турында сөйли башлады, зур күләмле бик матур җыентык күрсәтте — «Бәхетле минутлар. Совет республикалары поэзиясеннән сайланма әсәрләр». Бу китапта безнең шагыйрьләрдән Муса Җәлил һәм Сибгат Хәким шигырьләре дә бар икән. Соңгы битләрендә урын алган «Эчтәлек»тә әсәр исемнәре латин хәрефләре белән татарча да бирелгән. Биредә С. Хәкимнең Тандори Дежо һәм Буда Ференц тәрҗемәләрендә «Фатыйма», «Язмышым, рәхмәттән башка...», «Исәплəсәң, истәлекләр шактый», «Нигезләрдә безнең гасыр буе» һ. б. шигырьләре тәкъдим ителгән. Рецензияләргә караганда, тәрҗемәләр нигездә уңышлы һәм С. Хәким поэзиясенең шигъри үзенчәлекләрен беркадәр күз алдына китерергә мөмкинлек бирәләр.

«Моабит дәфтәрләре»ннән җыентыкка Урбан Эстер, Пете Миклош, Буда Ференц тәрҗемәләрендә «Җырларым», «Соңгы җыр», «Була кайчак», «Ышанма», «Ишек төбендә» шигырьләре кертелгән. Дөрес, Муса Җәлил исемен телгә алгач та, чирек гасыр чамасы артка чигенергә туры килә. Чөнки үзенең каһарманлыгы белән таң калдырган Җәлил поэзиясе шул чорда ук бирегә зур бер ташкын булып килеп керә. 1956 елда «Совет культурасы» журналында «Җырларым», «Катыйльгә», «Соңгы җыр», «Ышанма» венгр телендә басылып чыга. Ә 1957 елда Будапештта М. Җәлилнең «Ялгыз учак» дип исемләнгән җыентыгы дөнья күрә. Китапта шагыйрьнең илледән артык әсәре урын ала. Җыентыкны әзерләүдә танылган тәрҗемәчеләр Пете Миклош, Гурски Иштван, Пакозди Ференц, Янош Иштван катнаша. Шагыйрьнең «Алман илендә», «Вәхшәт», «Җырларым» кебек публицистик яңгырашлы шигырьләре белән бергә, китапта «Томаулы гыйшык» шикелле шаян шигырьләр дә, шулай ук бер-ике баллада да бар. Бу җыентык һәм, гомумән, Муса Җәлил шигырьләре вакытлы матбугатта гаять югары бәя ала. Танылган шагыйрь Имре Дьери 1958 елда «Зур дөнья» журналында түбәндәгечә яза: «Муса Җәлил белән очрашу бәхете — борыңгыдан килгән тылсымлы бер сәнгать, ниндидер серле-сихерле осталык белән очрашу кебек... Бу шундый сәнгать ки, ул, барыннан да элек, таң калырлык талант белән иҗат ителгән шедеврлар тудыра; шул ук вакытта ул үзенең гүзәллеге һәм гадилеге белән классик поэзиядән дә аерылмый, музыка һәм җыр кебек яңгырый. Хәтта бер-ике шигырьнең тәрҗемәсе әллә ни уңышлы булмаса да, алар Җәлил поэзиясенең шигъри көчен, укучыга гомуми йогынтысын, тәэсир көчен киметә алмыйлар...»

Шуннан соң М. Җәлил шигырьләре биредә әледән-әле басылып тора. «Халык азатлыгы», «Хәбәрләр», «Венгр халкы» кебек газеталарда, «Тормыш һәм әдәбият», «Тисса ягы», «Хатын-кызлар» шикелле журналларда, аерым җыентыкларда чыгалар. Хәтта шагыйрьнең бер үк әсәре бер үк елда берничә басмада чыгу очраклары да бар. Әйтик, 1957 елда «Алман илендә», «Төрмәдә төш», «Ирек», «Кошчык» һ. б. шигырьләр югарыда күрсәтелгән «Ялгыз учак» җыентыгында да, шулай ук «Тормыш һәм әдәбият», «Тисса ягы» журналларында һәм «Халык азатлыгы» газетасында да басылып чыга. Бу эш алга таба да дәвам иттерелә. 1977 һәм 1982 елларда шагыйрьнең аерым әсәрләре төрле антологияләрдә басыла. Хәтта болай әйтергә дә мөмкин: совет халыклары поэзиясенә багышланган бер генә зур җыентык та Муса Җәлил

шигырьләреннән башка чыкмый. Югарыда телгә алынган китаплар әнә шул хакта сөйли.

Язучының әсәрләрен бастырып чыгару, никадәрле әһәмиятле булса да, бу әле мәсьәләнең бер генә ягы. Икенчесе һәм шулай ук әһәмиятлесе — әдипнең тормышын һәм иҗатын өйрәнү, аерым мәкаләләр яки китаплар язу. Венгриядә Җәлил исеме хәзер бу яктан да безнең әдипләр арасында беренче урында тора, дисәм, ялгыш булмас. 1957 елда ук «Тормыш һәм әдәбият» журналында «Ленин премиясе лауреаты Муса Җәлил — татар халкының Фучигы» исемле мәкалә басылып чыга. 1958 елда «Азат ил» журналында Фейер Палның аңа багышланган «Чын большевик-солдат» исемле мәкаләсе дөнья күрә. Шул ук автор «Хатын-кызлар» журналында шагыйрьнең үлүенә 15 ел тулу уңаеннан махсус мәкалә белән чыга. 1970 елда Будапештта басылып чыккан «Дөнья поэзиясе антологиясе»ндә шагыйрьгә аерым мәкалә багышлана һәм аерым шигырьләренә дә урын бирелә. Мондый материалларны санап чыгу гына да ярыйсы ук зур урын алыр иде. Хәзер инде биредә басылып килгән библиографик белешмәләрдә Муса Җәлилгә махсус бүлекләр багышлана. Анда, гадәттә, Җәлил әсәрләренең Венгриядә нинди газета һәм журналларда яки җыентыкларда кайчан басылып чыгуы, шагыйрь турында нинди мәкалә һәм очерклар яки фәнни хезмәтләр язылуы күрсәтелә. Мәсәлән, Будапештның М. Горький исемендәге китапханәсе «Библиография»сендә (1967 ел) шагыйрьнең әсәрләре һәм аның турында басылып чыккан материаллар исемлеге 5 биткә сузылган. Бүген ул тагын да зуррак булыр иде...

Татар телен өйрәнү һәм әдәбиятын популярлаштыру, гомумән алганда, Венгриядә шактый югары дәрәҗәдә тора. Биредә сүз бу эшнең төп юнәлешләре хакында гына барды. Мәсьәләгә тирәнрәк кереп, дәвамлы махсус тикшеренүләр, эзләнүләр алып барганда, «Венгриядә татар халык иҗатын өйрәнү», «Венгр галимнәренең татар теленә караган хезмәтләре», «Муса Җәлил — Венгриядә» кебек темаларга аерым мәкаләләр, хезмәтләр язып булыр иде.

Соңгы сүз итеп шуны әйтим: хәзер Будапештта «Дөнья әдәбияты энциклопедиясе» басыла. Әлеге хезмәттә татар әдипләреннән Акмулла, Гафур Коләхметов, Мәҗит Гафури, Галимҗан Ибраһимов, Муса Җәлил һәм башка кайбер язучыларга багышланган махсус мәкаләләр бирелеп барыла. Аларда, гадәттә, язучы турында энциклопедик характердагы мәгълүматлар китерелә: кыскача тормыш юлы, әдәби эшчәнлегенең төп юнәлешләре һәм игътибарга лаек әсәрләре. Кагыйдә буларак, әсәр исемнәре латин хәрефләре белән татарча да бирелә.

Энциклопедиянең инде 8 томы басылып чыкты (соңгысы «М» хәрефе белән тәмамлана). Татар әдәбиятына багышланган күләмле махсус мәкаләгә әлегә чират килеп җитмәде. Киләчәктә андый мәкалә дә басылыр һәм венгр әдәбиятчылары, гомумән, укучылар, сүз сәнгатебез турында тулырак, төгәлрәк һәм хронологик яктан эзлеклерәк мәгълүматлар алырлар дип ышанырга кирәк.

Библиография

# ПАРТИЯ СОЛДАТЫ

Тарих фәннәре кандидаты Шәмси Хамматовның шул исемдәге китабы[1] беренче карашка публицистик җыентыкны хәтерләтә. Җәлилнең илгә, партиягә зур тугрылык белән үтелгән якты гомер юлы күз алдына килә. Әйе, ул — чынлап та, партия солдаты иде...

Ләкин, китапның исеме күбрәк публицистикага якын булса да, чынлыкта безнең алда — бик күп эзләнүләрне, зур фактик материалны эченә алган җитди фәнни хезмәт. Ул герой-шагыйрьнең егерме еллык тормышын — 1922 елдан алып 1942 елга кадәр булган чорны эченә ала. Бүтән тикшеренүчеләр кулы кагылмаган яңа өлкә — Җәлилнең журналистлык, публицистлык һәм җәмәгать эшчәнлеге игътибар үзәгенә куела.

Җәлил эшчәнлегенең менә шушы тармагы белән танышу авторны түбәндәге нәтиҗәгә китерә: герой-шагыйрьнең сугышка хәтле чорда язылып, төрле газета-журналларда басылган язмалары әле киң җәмәгатьчелеккә билгеле түгел икән... Һәм автор тикшеренү эшенә алына — Мәскәү, Курск, Белгород шәһәрләренә юл тота, Татарстанның Җәлил исеме белән бәйле бөтен почмакларын диярлек айкап чыга. Тикшеренүче алдында архив материаллары өелә, күп газета-журналларның еллык тегелмәләре кузгала. Җәлилне якыннан белгән кешеләргә хатлар языла, алар белән очрашулар була...

Хәзер безнең алда яткан хезмәт әнә шулай туган. Ш. Хамматов үзенең эзләнүләре аркасында Җәлилне политработниклар курсы буенча белгән 15 кешене таба, турыдан-туры герой-шагыйрьгә кагылган 40 яңа документ ача. Аларның барысы турында да бу китапта языла.

Китап ике өлештән тора. Аның беренчесе «Хәбәрче, журналист, җәмәгать эшлеклесе» дип исемләнгән һәм ул шагыйрьнең сугышка кадәрге эшчәнлеген яктырта.

Җәлилнең хәбәрчелек эшчәнлегенең башлануы «Татарстан» газетасы белән бәйле. 1922 елдан Муса бу газетага төрле хәбәрләр язып тора һәм моны педагогия институтының рабфагында укыганда да ташламый. Җәлил каләменнән чыккан язмаларның кайберләре әлеге китапта да китерелгән. Алар тикшеренүчегә геройшагыйрьнең ничек итеп әкренләп чыныгуын, өлгерүен күрергә мөмкинлек бирәләр.

Китапның Мәскәү чорына багышланган өлеше фактларга бигрәк тә бай. Җәлил Мәскәү дәүләт университетында уку белән бергә, «Кечкенә иптәшләр» һәм «Октябрь баласы» журналларының җаваплы редакторы була. «Ударниклар» дип аталган яшьләр журналының редколлегия члены вазифаларын башкара, «Фән һәм дин» журналында, «Эшче» һәм «Игенчеләр» газеталарында бик еш катнаша. Җәлилнең бу чордагы иҗат активлыгы хакында шундый бер факт бик ачык сөйли — 1927 елдан алып 1932 елга кадәр газета-журналларда аның йөздән артык язмасы дөнья күргән. Ә 1933 елда, «Эшче» һәм «Игенчеләр» газеталары берләшеп, «Коммунист» исемендә чыга башлый. Җәлил бу газетаның әдәбият-сәнгать бүлеген җитәкли.

«Коммунист» газетасы татар хезмәт ияләрен социализм идеяләре буенча тәрбияләүдә бик зур роль уйный. Ул Татарстан һәм Башкортстаннан кала тагын Ерак Көнчыгышта һәм Үзбәкстанда, Уралда һәм Себердә, Идел буе өлкәләрендә һәм Белоруссиядә, Мәскәүдә һәм Ленинградта тарала.

Автор Җәлилнең журналист буларак талантының ачылуның иң югары ноктасы дип тә нәкъ менә шушы басма органны атый. Мусаның эшче-авыл хәбәрчеләре хәрәкәтен үстерүдәге онытылмас эшчәнлегенә дә нык-лы басым ясала.

---

[1] Хамматов Шәмси. «Муса Җәлил — партия солдаты». Татарстан китап нәшрияты. 1982

Ш. Хамматов хезмәтенең бу өлеше бер яктан М. Җәлил шәхесенең шагыйрь һәм һәм герой буларак формалаша баруын күрсәтсә, икенче яктан анда бүгенге матбугат өчен дә кыйммәтле булган мисаллар, эш алымнары бар. Үзе дә тәҗрибәле журналист булган автор бу өлкәне нык белеп, материалның эченә кереп яза.

Хезмәтнең икенче өлеше «Муса Җәлил— өлкән политрук» дип исемләнгән. Бу бүлеккә Җәлил гомеренең чагыштырмача кыска өлеше туры килә. Ул 1941 елның июленнән, Җәлилнең армиягә алынуыннан башланып, Волхов фронтыннан язган соңгы хатларының берсенә (1942 елның 3 июне) кадәр дәвам итә. Ләкин вакыт ягыннан караганда бу период шулай кыска булса да, укучы китапта бик күп кызыклы фактлар белән таныша. Бүлек политработниклар курсында уку чорын өйрәнүдән башлана. Автор Җәлил эзеннән Курск өлкәсенең Марьино авылына бара, анннары Минзәләгә юл тота. Шагыйрьне белгән кешеләрне эзләп таба, алардан яңа мәгълүматлар ала. Җәлил биредә дә курсант тормышының үтә кысан булуына да карамыйча, каләменнән аерылмаган. Аның бу чорда язылган әсәрләрендә совет халкының тылдагы батырлыклары, дошманны җиңүгә тирән ышанычы сурәтләнә. Шулай итеп Җәлилнең үзенең дә көчле омтылышы, нык ышанычы бирелә. Китап авторы Җәлилнең батырлыгы халык батырлыгы белән бергә үрелгән булуын дәлилләп, раслап бара.

Йомгак ясап шуны әйтик: Ш. Хамматовның «Муса Җәлил — партия солдаты» дип исемләнгән бу китабы герой-шагыйрь тормышының моңарчы билгеле булмаган яңа өлкәсен яктыртуы белән генә кыйммәтле түгел. Китапта татар журналистикасының да яңа сәхифәләре ачыла, тулаем совет матбугаты тормышына мәгълүматлар, мисаллар өстәлә. Менә шул сыйфатларның барысын бергә үзендә туплавы белән кыйммәт бу хезмәт.

Әлбәттә, яңа тикшеренүчеләр бу юлны тагын да дәвам итәрләр, укучы өчен тагын да кызыклырак ачышлар ясарлар...

**Рафис ИЗМАЙЛОВ**
Мәскәү.

# ӨМЕТЛӘР АКЛАНУ

Флера Гыйззәтуллинаның «Акчарлагым — асыл кошым»[1] исемле китабы белән танышкач, күңелгә иң беренче, бу — өметләрнең аклануы инде, дигән уй килә. «Өметләр» төшенчәсендә иң әүвәл шагыйрәнең үз өметен күздә тотыйк. Билгеле булганча, Флера безнең шигъриятькә бик катлаулы тормыш кичеп килде. Ул биш яшендә әнисеннән ятим калган. Кызга ун яшь чагында, Бөек Ватан сугышына киткән әтисе турында батырларча һәлак булуы хәбәре килә. Шулай итеп, кыз баланың мөстәкыйль тормышы башланган: колхоз эше, урман кисү, аннан соң — шахта, тегүчелек...

Табигатенә салынган шигъри сәләт исә, авторның, тукта инде, илгә кирәк мәшәкатьләрнең очын очка ялгыйм әле, дигән сүзен тыңлагандай, түл җыеп торган. Гүя бөркеп чыгар җай көтеп утырган.

Шигырь сөючеләр аның үзенә генә хас тавышын ишеткәндә, Флера Гыйззәтуллинаның илле яше якынлаша иде инде. Әдәби офыкта калыккан яңа исем төрле кешедә төрле фикер уятты. Авторның иҗатына хас тормышчанлык, кызлар каләменнән гел дә түгелә алучан нечкә лиризм, әсәрләрдәге көчле гражданлык пафосы — барысы да Флера Гыйззәтуллина иҗатының бай киләчәгенә ишарәле иде.

Быел без Ф. Гыйззәтуллина иҗатының әр-яңа һәм мул үрнәкләре белән танышу бәхетенә ирештек. «Казан утлары» журналының 5 нче санында аның яңа поэмасы дөнья күрде, аннан соң озак та үтмәде, «Акчарлагым — асыл кошым» китабы басылып чыкты. Алдан ук, һич шикләнмичә, өздереп әйтергә кирәк: шагыйрәнең бу адымнары — аның иҗатында яңа баскыч, үсеш. Уңышларның үзегендә авторның ихласлыгы, әсәрләр өчен җирлек итеп алган материалның тормышчанлыгы, отышлы образлылык һәм, әлбәттә, табигатьтән килгән сәләт ята.

Ф. Гыйззәтуллина, сугыш елларында үскән һәм аннан соңгы елларны кичергән шагыйрә буларак, күп әсәрләрендә кешелеккә зур хәсрәтләр китергән сугыш те-

[1] Гыйззәтуллина Флера. «Акчарлагым — асыл кошым». Татарстан китап нәшрияты, 1983.

...масына кагыла. Бу җәһәттән аның «Дүрт кыз» поэмасы игътибарга аеруча лаек. Хикмәт урман кисүче кызларның моңа кадәр безнең шигърияттә тулысынча сурәтләнмәвендә генә дә түгел. Автор, барыннан да бигрәк, халык язмышына мөрәҗәгать итүе, гаделлекнең җиңүенә ышанган халыкның нинди фидакарьлекләргә сәләтле икәнен шагыйрәнә оста тасвирлавы белән укучы җанына үтеп керә. Яңа сугыш чыгу ихтималы дөньяны өзлексез киеренкелектә тоткан бүгенге көннәрдә әсәрнең мондый яңгырашы аеруча кыйммәтле. Шагыйрә, дүрт кыз кичергән хәлләрне тасвирлау алымы белән, безнең бай тарихка бәя бирергә дә, илнең бөек Ленин васыятьләрен үтәп яшәвенә дә мәгънәле ишарә ясарга да җай таба.

Китапта фашизмга, ул алып килгән кара кайгыга карата нәфрәт хисе белән сугарылган шигырьләр байтак. Бу хис шагыйрә иҗатының нигезен тәшкил итә һәм бөтенләй көтелмәгәндә дә үзен ап-ачык сиздереп-сиздереп. куя. Башкача була да алмый, чөнки, Флера сүзләре белән әйткәндә:

*...Ул чор безгә ни бәягә төште?*
*Сораш илнең ятим, толыннан...*
*Ятимне мин күз яшеннән таныйм,*
*Тол ананы — боеклыгыннан.*

Туган илдә толлар, ятимнәр бар чакта, шул ук чорны, шул ук югалтуларны үзе дә кичергән шигъри җан бер генә минутка аларны онытып тора алырмы? Юк, әлбәттә. Һәм аның шигырьләре дә үткән сугышка ләгънәт укучы меңнәрчә кешеләр күңелендә хуплау таба, сугышның ни икәнен белмәгәннәрне исә яңа сугыш дәрләтергә маташучыларга каршы туплый. Бусы — Флера Гыйззәтуллина әсәрләренә хас иң кыйммәтле сыйфат.

Шигырьләрнең йөгерек тел белән язылган булуын, һәр сүзнең образлы файдаланылуын, кыска гына юлларга тирән мәгънә сыйганлыгын да, отышлы чагыштыруларны да, бизәкләрне дә авторның уңышыннан, үсешеннән санарга кирәк. Әйтик:

*Күз алдымда күкрәп күк чатнады,*
*Кечерәйде, сулды «тау-мышты»...*
*Мин бер куркак җанлы ир кисәген*
*Янар тауга тиңләп ялгыштым.*

Яисә:

*...Төн карасы мәхәббәттән эреде,*
*Таш уалды минем бәхеттән...*

кебек юллар шагыйрәнең шактый остарганлыгын раслап торалар.

Китап бер тын белән укыла. Монда, мөгаен, шигырьләрнең төрле үлчәмдә язылган булуы һәм аларның дөрес чиратлашуы да роль уйныйдыр.

Инде автор һәм редакторның игътибары җитенкерәмәгән кайбер якларга да күз салыйк. Флера Гыйззәтуллина әсәрләрендә мең төрле исем телгә алына. Алар арасында кеше исемнәре дә, тау, елга, урман, авыл атамалары да бар. Кайбер шигырьләр тоташы белән географик җисемнәргә багышланган. Мәгълүм ки, әдәби әсәр, иҗади хезмәт буларак, һәр укучыга, әйтик, Әсәй авылын белмәгән кешегә дә, аңлашылырга тиеш. Аны һичнинди картаатласлардан эзләп таба алмаслык исем һәм атамалар белән чуарлауның нигә кирәге бар?! Шагыйрә генә күргән, аңа гына бик кадерле авыл, елга яки тауның укучы өчен бик кыйммәте булмавы ихтимал. Шунлыктан ниндидер конкрет исемгә таянып язылган шигырьдә гомумиләштерү көче кими, ул еш кына гади репортажга охшап кала.

Кайбер шигырьләрдә кеше хисенә, тойгыларга гына хас сыйфатлар белән матди билгеләмәләр бер рәткә куела. Мәсәлән, «...Сөюнең бит очы аллана» кебек юллар укучының фикерен шактый бутый. Авторның ашыгуы нәтиҗәсендә кереп киткән кайбер чатаклыкларны да таләпчәнлек җитенкерәмәүдән санарга була. «Яшьлек эзләре» шигырендәге — «ярлыкай» кебек сүзләрнең китапка элэгүе башкача һич аңлашылмый. «Аем күлгә йолдыз сибәлми» («Аерылмабыз, җанкай») җөмләсе дә дөрес төзелмәгән. Яңгырның, карның сибәләве мөмкин, ә ай сибәли алмый, ул бары тик яктырта яки, шагыйрьләрчә әйтсәк, тәгәрәп җиргә килеп төшә ала, үз тирәсендәге йолдызларны җыеп, учлап-учлап сибә ала.

Китапны моңа охшаш вак-төяк кимчелекләрдән арындыру гына әллә ни кыен булмас. Иң куанычлысы шул: шагыйрәбез иҗатындагы яңа әсәрләр аңа яңа уңыш китергән.

**Кояш ТИМБИКОВА.**

## Туфан Миңнуллин

# КЫЗЫЛ ТЫШЛЫ ДӘФТӘРДӘН

### Бүген кемне сөендерим икән?

Тәтеш пристанендa «Ракета»га утырдым. Анда Олы Карамалы егете Хәмит Вәлиевне очраттым. Шагыйрь җанлы егет, дөньяны һәрьяклап камил итеп күрергә омтылган егет. Бу юлы кәефе юк.

— Кама тамагы пристанена Тәтештән килүче «Метеор» туктады, — ди, — яртылаш буш, ә пристаньда йөзләгән кеше китәргә ашыга. Ләкин «Метеор» капитаны берәүне дә утыртмады. Җыелышып калган кешеләрне, бала-чагаларны күреп ничек йөрәге түзде икән, оятына аз гына көч килмәде микән?

Кайбер кешеләрдәге җансызлык, рәхимсезлек турында озак итеп борчылып сөйләде Хәмит.

— Ә бит, Туфан абый, кеше җир йөзенә яхшылык кына эшләр өчен килергә тиеш. Һәр адәм баласы иртән уянганда яхшылык эшләп бүген кемне сөендерим икән дип уянырга тиеш. Шулай уянсаң көн буе рәхәтләнеп яшисең, кемнәрнеңдер рәхмәтен ишеткәннән соң җанга рәхәт була, күңел киңәя, сулышлар иркенәя, йөгереп кенә йөрисең.

Шулай шул, Хәмит туган. Ләкин, кызганычка каршы, шулай икәнлеген аңлап бетермибез, мәрхәмәтлелек җитеп бетми. Синең нык дулкынланганыңны күреп, мин сиңа үзем белән булган хәлне сөйләмәгән идем, искә төшкәч менә хәзер сөйлим әле.

Казан елга портында булды бу хәл. Узган ел. Билет алырга чират торабыз. Мин бишенчеме, алтынчымы кеше. Билет ун-унбиштән артмаячак, алдан сатып бетергәннәр, дигән сүз йөри. Касса ачылганны көткәндә бер төркем егет минем янга килделәр, исәнләштеләр, төрле мактау сүзләре әйттеләр. Сезнең театрларны карап барабыз диделәр, сезнең белән горурланабыз дигән сүзне дә ычкындырдылар шикелле. Әлбәттә, яшьләрнең мине мактап сүз әйтүләре минем күңелгә хуш килде — рәхмәт, рәхмәт, дип тордым. Якташларымның, бигрәк тә яшьләрнең, мине олылавын ишетеп, эчтән генә горурландым.

Менә берзаман касса ачылды. Чират буталды, барысы да касса тәрәзәсенә ыргылдылар. Иң көчлеләр алга үрмәләде, көчләре азлар артка калды. Алдагылар арасында әлеге яшьләр дә бар иде, билгеле. Кассада булган билетларны алып бетереп, алар көлешә-көлешә «Ракета»га утырып китеп бардылар. Мин һаман бишенчеме-алтынчымы кеше булып басып калдым. Миңа билет җитмәде, киләсе рейсны көтәргә туры килде.

Менә сиңа хөрмәт. Күңелем рәнҗеп, эчтән генә җыладым ул чакта. Шундый мәгънәсезлекнең, юк мәгънәсезлек түгел, мәрхәмәтсезлекнең сәбәбен эзләдем. Нормаль егетләр бит, югыйсә, карап торышка. Ә күңел буш, җан юк.

Уйлана торгач үземне гаепләргә тотындым. Алар бит мин язганнарны театрда карап барабыз диделәр. Димәк, мин аларның күңелен җылытырлык нәрсә язмаганмын. Язган булсам, касса тәрәзәсенә ташланганда җаннары аз гына булса да кыймылдап куяр иде. Туктале, хатын-кызларны этеп-төртеп, Туфан абый һәм аның кебекләрне чираттан сытып чыгарып билет алу оят түгелме икән дип уйлап алырлар иде. Димәк, без язганнар — комга су сибү генә? Мәрхәмәтле булыйк дип язуыбыз

сүзе генә? Нигә соң ул вакытта язып маташырга? Тимердәй мускул булдырырга да, терсәк белән уңга-сулга төрткәләп, үзеңә юл ярып яшәргә кирәктер бәлки?

Ул хәлдән соң озак аңга килә алмый йөрдем. Язуымның тәме бетте... Бераздан әкренләп онытa башлаган идем, «Ракета»да Хәмит яңадан искә төшерде.

Әй бит, Хәмит туган, ни әйтсәк тә тормышта изгелек яши. Изгелек шактый күп тормышта. Югыйсә, дөнья алга түгел, артка тәгәрәр иде. Менә син бар, синең кебекләр бар.

— Әгәр мин берәүне сөендерсәм, ул икенче берәүне сөендерәчәк. Димәк, сөендерергә әзер торучы ике кеше була дөньяда, — дидең син, — сезнең әсәрләрне укып, карап барам, сез кешеләрне яратып язасыз, — дип тә өстәдең. Рәхмәт! Ничек инде кешеләрне яратмаска мөмкин. Нишләтәсең инде теге егетләрне дә... Мин аларны да яратмыйм дип әйтә алмыйм, ялгышканнардыр ул юлы, икенче тапкыр ялгышмаслар дип өмет итәм.

Кешеләр начар түгел, чүтеки. Әле бер көн, тәгәлрәге 7 май көнне, колхоз базары аша узып барганда сыра эчәргә тукталдым. Чират шактый. Чиратта торучыларны күзәтергә керештем. Ходаем, нинди генә кыяфәт юк анда.

Шул чак чиратка бер агай килеп басты. Кызмача. Түшендә «Кызыл Йолдыз», ике «Дан» ордены, медальләр, кәефе шәп. Чираттагы күршесенә кызмача булуының сәбәбен аңлата.

— Дуслар белән Җиңү көнен билгеләп үттек, ди. Без шулай, Җиңү көнен 7-8 майда билгеләп үтәбез, ә 9 ында бер грамм каптым юк, ярамый ул изге көндә аракы эчәргә, ди. Авыз кибеп китте әле, менә сыра эчәргә туктадым, ди.

— Барыгыз, чиратсыз алыгыз, сезгә чиратсыз да мөмкин, — ди күршесе.

— Ю-у-к... Мин андый тү-ге-ел. Мин чиратсыз эчәр өчен сугышмадым, — ди абзый.

Шуннан башланды: исерәге, айныгы, махмырдан интегүчесе, болай гына сусаганы, таушалганы, кырынмаганы, джинси чалбарлысы, чиратта торучысы, чиратсыз керергә маташучысы — барысы бердәм булып абзыйны кыстарга тотындылар, юл бирделәр, абзыйны чиратсыз сыра эчәргә мәҗбүр иттеләр.

— Рәхмәт, егетләр, — дип китеп барды абзый.

Менә монысы да бар бит әле дөньяда, аллага шөкер! Болай булганда әле яшәп була. Мәрхәмәт дигән нәрсә яши кешеләрнең күңелләрендә. Мәрхәмәтсезлек белән очрашып җан өшегәндә, мәрхәмәт очрап өшегән җанны җылытып куя. Кемнәрнедер сөендерәсе килә башлый.

*10 май, 1982*

## Төш

Төш күрдем: бер яшь язучы бурычка акча сорап тора, имеш. Бирергә дип кесәләргә тыгылам, акчам күп, әмма барысы да вак акча икән. Вакларның да бакырлары.

— Мин сиңа вак акча бирә алмыйм, ул сине мыскыл итү кебегрәк була,— дим, имеш.

Теге үпкәли. Ләкин мин барыбер бирмәдем.

— Саран дип уйласаң уйла, әмма бирә алмыйм. Әйдә, кибеткә кереп эреләтәбез, шунда бирермен,— дидем.

Уянып киттем. Гадәттә, күп төшләрне уянганда хәтерләмисең, кайберләре хәтердә калсалар да аларны юрап-анализлап маташмыйсың. Бу төшне әллә нигә анализларга керештем.

Вак акчаны (бакырларны) гайбәткә, ваклыкка, гомумән начарлыкка юрыйлар. Кесәләрем тулы бакыр акча булуы яхшы фал түгел, әлбәттә... Ярый, анысы калып торсын...

Кесәм тулы бакыр акчалар (эчем тулы начарлык) булса да, мин аларны кешегә бирмәдем ләбаса, үземдә калдырдым. Начарлыгыңны бүтәннәргә өләшеп йөрсәң, куркыныч булыр иде. Кеше кеше инде ул — күңелендә әллә ниләр бардыр — яхшысы да, яхшы ук булмаганы да. Яхшысын кешеләргә биреп, яхшы ук булмаганын һәр кеше үзендә калдырса, начар булмас иде дә бит...

Язучыларга бу аеруча кагыла. Тормышта без төрле хәлләр белән очрашабыз. Аларның барысы да хәтердә туплана. Менә шул хәтер янчыгыннан кайсыларын кешеләргә өләшергә? Әлбәттә, яхшыларын гына. Әдәбият үрнәк һәм гыйбрәт белән тәрбияли. Гыйбрәтле хәлләрне сөйләп биргән очракта да, минемчә, аның янында гыйбрәттән өстенрәк үрнәк булырга тиеш. Кешеләрнең күңелен үрнәк яктырта, гыйбрәт — тәрбия чарасы булса да, күңелне баса, ул, ни әйтсәң дә, шомлы...

*15 сентябрь, 1982*

# Макуха

Күңелнең бушап калган чаклары була. Дөнья әллә ничек ямьсезләнеп китә... Андый чакта язылмый да.

Беләм, бу вакытлыча гына халәт. Шуңа мин ул халәттән ычкынуның ысулларын эзлим. Бер ысулны таптым да шикелле. Тормышның ыгы-зыгыларыннан, вак-төякләреннән арынып, алардан өстен булырга, зуррак әйберләр турында уйларга өйрәнергә кирәк. Аның өчен иң яхшысы тормыш юлында очраган күңелле вакыйгаларны, яхшы кешеләрне искә төшерәсең. Ә булган бит алар, бар иде алар.

Менә, мәсәлән, мин бүген моннан сигез-тугыз еллар элек булган бер вакыйганы искә алам...

Ворошиловград өлкәсенә татар әдәбияты һәм сәнгате атналыгы үткәрергә бардык. Атналык атналык инде, анда официаль очрашулар да, сәхнәдән чыгыш ясаучылар да, кунак өстәле артында тостлар әйтешү дә булды. Барысы да әйбәт... Тик иң истәлеклесе базарда Дон казачкалары белән очрашу һәм аның дәвамы иде.

Хәсән Сарьян белән базарга көнбагыш түбере эзләп бардык. Ишетүебезчә, түбергә балык шәп килә имеш һәм ул түберне Дон ягының базарларында табып була, имеш. Чөнки ул якларда көнбагышны күп игәләр, көнбагышның маен сыгалар, май сыккан-да, табигый, түбере дә кала.

Көнбагыш мае сатучы апалар янына килдек, түбер сорадык. Алар жмых дигән рус сүзен белмиләр икән, түберне макуха диләр икән. Ләкин макуханы сатмыйлар икән алар, бу якларда чөнки ул бик арзан икән.

Шуннан без апага (берсенең исемен дә яхшы хәтерлим — Степанида иде, Шолохов яшәгән яктагы станицадан иде) унар сум акча биреп, шул акчага посылка белән макуха җибәрүләрен үтендек. Апалар башта аптырап калдылар, үтенә, ялына торгач акчаны алдылар.

Дөресен әйтергә кирәк, аларның посылка җибәрүенә ышаныч әллә ни түгел иде. Базарда очраган хатыннарга акча тоттырып җибәрү генә иде бугай. Булса соң, дидек без, ун сум каян килеп кая китмәгән.

Казанга кайттык, һәм безнең арттан озак та тормый безгә унар килолы ике посылка килеп төшмәсенме, миңа килгән посылкада Степанида түтинең хаты да бар иде. Хатны сүзгә сүз хәтерләмим. Әмманиләр язылганын, хатның эчтәлеген яхшы хәтерлим. Посылканы җибәрү өчен почтага фәлән кадәр акчагызны түләдем, калганын үзегезгә кире җибәрәм, макуха өчен акча алырга оялдым, бездә ул бик күп дип язылган иде хатта һәм акчаның калганы да тиеннәре белән шунда иде.

Сөенеп туялмадым. Макухасы өчен түгел, Степанида түтинең һәм Хәсән Сарьянга посылка җибәргән түтинең гаделлекләре, сафлыклары, намуслылыклары сөендерде. Болай булса яшәп була, мондый кешеләр барында нәрсә ул тормышның вак-төякләре. Вак-төяк ыгы-зыгы үтә дә китә, кешенең намусы, изгелеге — мәңгелек.

Язучының бурычы шушы кешеләр турында бүтәннәргә сөйләү. Күңел бушлыгыннан арынырга өйрәнеп, вак-төякләр арасында күмелеп калмыйча, изгелекне эзләү. Юк, эзләргә кирәкми, искә генә төшерергә кирәк. Адәм баласы яшәгәндә изгелек яшәячәк!

*14 сентябрь, 1982*

# Телсез

Бик әшәке телле кеше бар иде безнең авылда. Хатын-кыз димәс, бала-чага димәс — адәм рәтле сүзе саен ике әшәке сүз кыстыра иде. Урысча да сүгенә, татарча да сүгенә. Кайвакытта икесен бергә кушып, унбишәр минут гел әшәке сүз генә кычкырып тора. Үгетләп тә карадылар аны авылда, оялтып та карадылар, авыл советына чакыртып куркыттылар да. Юк, исе дә китми, сүгенә дә сүгенә. Аптырагач милициягә хәбәр иттеләр. Милициядә моңа штраф салганнар. Штрафны түләде, сүгенүдән туктамады. Шуннан нишләсеннәр инде, авыл халкы чарасыз калды...

Тик әшәке телле кешенең әбисе, ягъни хатынының әнисе генә киявенең сүгенүенә иләшә алмады. Кияве өенә килмәс үк булды. Кияү үзе килсә дә, кертмичә борып җибәрә башлады. Юк, аңарга карамады тегесе, сүгенә-сүгенә өенә кайтып китә иде.

Бер дә бер көнне тагын әбисе өенә бара бу. Әбисе ишекне ачмагач ничәдер этәжлы итеп сүгенә. Шуннан әбисе тәрәзәне ача да:

— Телең генә корысын иде, имансыз,— ди.

Кияү җавап итеп сүгенергә тели, тавышы чыкмый, теле әйләнми...

— Әб-бә-бә-бә— дип тик тора, ди. Чынлап әйтәм менә, телсез калды шул. Авыл халкы инде каргыш төште дип сөйләнде. Мин аңа ышанмыйм, әмма факт — теле юк абыйның. Кешене ишетә, җавап бирә алмый.

— Сөйләшмәсә, кирәге дә юк теленең,— дип әйткән ди хатыны да.

Ике-өч еллап йөрде бу телсез. Больницаларга да барып карады шикелле. Мин авылдан чыгып киткәндә дә юк иде әле теле.

Бервакыт авылга кайтсам, урамда очрады бу.

— Саумы, агай-эне,— ди.— Җәйнең матур вакытларында туган үскән иленә кайтып, әти-әниеңне шатландырып әйбәт иткәнсең, рәхмәт,— ди.

Шаккаттым. Бер генә дә сүгенү сүзе юк. Шундый да матур итеп сөйли, җыр көйли диярсең. Соңыннан сорашып белдем, бөтен кеше белән дә шулай сөйләшә башлаган икән ул. Телендә гел «матурым», «күз нурым», «сандугачым», «кадерлем», «әбикәем», «балакаем», «хатынкаем» дигән сүзләр генә икән.

Мондый үзгәрешнең сәбәбен дә сөйләделәр. Телсез йөреп интеккәч, сүгенә торган абзабыз, әбисе янына барган да икән: «Әгәр дә телем чыкса, бер генә сүгенү сүзе дә кыстырмас идем, матур сүзләр генә сөйләп йөрермен»,— дип әйтмәкче булган икән һәм шулай дип әйтеп тә җибәргән имеш. Дөрестерме, юктырмы, анысын белмим, әмма иң әшәке телле абзыйның бүген иң тәмле телле абзый икәнлегенә үзем шаһит. Бер тапкыр ул абзыйның үзеннән дә:

— Дөресме шул хәл? Шулай булдымы?— дип сораган идем:

— Булгандыр инде, матурым,— дип елмаеп кына җавап бирде.

*20 декабрь, 1982*

**Сәлам Алишев**

# МӘГЪРИФӘТ УЧАКЛАРЫ

*Унсигезенче йөздә татар крестьяннарына аң-белем бирүнең торышы*

Урта Идел төбәгендә яшәгән татарларга мәктәп белеме бирүнең ерак заманнардан килә торган зур тарихы бар. Ул болгар чорыннан ук башланган һәм феодализмның үсеше, ислам диненең кабул ителүе, таралуы белән бәйләнгән. Унынчы гасырның беренче яртысында гарәп галиме, географ Ибн Рустә болай дип язып калдырган: «Болгарларның күпчелек өлеше ислам динен тота, аларның авылларында үзләренең мөәзиннәре, имамнары булган мәчетләр һәм махсус башлангыч мәктәпләр бар». Шулай ук, Болгар патшасы Алмышның Багдад хәлифеннән укытучылар һәм дин әһелләре җибәрүен сораганлыгы да билгеле. Әлеге мәктәпләрдә дин сабагы укытылган. Шул ук нәрсә традиция буенча Казан ханлыгына күчкән. Унбишенче-уналтынчы йөзләрдә Казанда шундый мәктәпләр булганлыгын күренекле тарихчы Шиһабетдин Мәрҗани үзенең «Мөстафад-эл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән китабында да телгә алып уза. Безнең фикеребезчә, Казан ханлыгы чорында ук инде: «һәр мәчет каршында мәктәп булырга тиеш»,— дигән кагыйдә яшәп килгән.

Татар крестьяннары мәктәпләрдә һәм мәдрәсәләрдә кулъязма дәреслекләрдән файдаланырга рөхсәт ителүен сорап 1893 елда патша исеменә җибәргән үтенеч хатларында, үз тарихларын Казан ханлыгы белән бәйләп, бу мәктәпләрнең инде менә 300 елдан артык яшәп килүләре турында язалар.

Сәяхәтче-галим Г. Георгиның «Россия дәүләтендә яшәүче барлык халыкларның тасвирланмасы» дип аталган 1799 елгы язмаларында түбәндәге сүзләрне укыйбыз: «Казан татарлары... үзләренең балаларын тырышлыкка, сакчыллыкка һәм ата-бабаларыннан калган башка шундый гадәтләргә генә түгел, аларны укырга-язарга, гарәп теленә һәм дингә өйрәтү турында да кайгырталар. Мондый нәрсәләрдән баш тартуны ата-аналар зур гөнаһ саныйлар. Шуңа күрә дә алар яшәгән һәр авылда гыйбадәтханә һәм мәктәп бар...»

Әнә шундый мисалларга таянып без XVIII йөздә күпчелек татар авылларында мәчетләр карамагында дини мәктәп-мәдрәсәләр булган, дип раслый алабыз. Югарыда санап узылган фактларны исәпләмәгәндә, XVIII гасырга кадәр татар мәктәпләре тарихы бөтенләй диярлек тикшерелмәгән һәм ачыкланмаган. Әмма соңга табарак бу темага карата язылган кайбер хезмәтләрнең дөнья күрүен әйтеп үтмичә булмый. Унтугызынчы йөздә һәм егерменче йөз башында Ш. Мәрҗани, Р. Фәхретдиневнең хезмәтләрендә Идел һәм Урал буе татарларында мәктәп-мәдрәсә тарихының кайбер яклары шактый тулы яктыртыла. Миссионер Я. Д. Коблов бу мәктәпләрдә укытуның тәртипләре турында махсус китап яза. Бу китабында автор унтугызынчы йөзгә һәм егерменче йөзнең башларына кагылышлы нәрсәләрне генә тикшерүенә карамастан, анда күтәрелгән мәсьәләләр элеккерәк чорны да күз алдына китереп бастырырга һәм аңларга ярдәм итә, чөнки әлеге мәктәпләр XVIII йөздән соң әллә ни үзгәреш кичерми. Китап-

ның авторы үзе дә шуны ук раслый. Анық, татар крестьяннарының аң-белем дәрәҗәләренә биргән гомуми бәясе дә кызыклы гына. Ул бәя Георги әйткән фикерләргә туры килә. «Казан татарлары,— дип яза Я. Д. Коблов,— укуга гадәттән тыш мәхәббәт һәм бирелгәнлек күрсәтәләр... Мәчет һәм мәктәп мөселман авылларының һәр кайсында иң кирәкле учреждение булып санала. Россиядә уку-язуның Казан татарларындагы кебек киң таралган башка халыкны күрсәтүе бик кыен. Укый-яза белмәгән татар кешесен бик сирәк очратасың. Ә бу исә һәр мөселманга грамотага өйрәнү өчен тулы мөмкинлек булуы белән аңлатыла. Нинди генә кечкенә һәм ярлы булмасын, һәр авылда мәктәп барлыгын күрәсең».

М. Рыбушкинның «Казан шәһәренең кыскача тарихы» дигән китабына 1835 елда язган рецензиясендә бөек рус тәнкыйтьчесе В. Г. Белинский болай дип билгеләп үтә: «Рыбушкин әфәндененң китабыннан без Казан татарларының күпмедер дәрәҗәдә цивилизацияле һәм хәтта грамоталы булулары белән аерылып торганлыкларын күрәбез. Алар тәрбияле, ихтирамлы, илтифатлы, милләттәшләренең кимсетүенә дучар ителергә тиләмиләр икән, аларның һәркайсы укый һәм яза белергә тиеш. Аларның ким дигәндә 5 ел буена дәвам иткән уку курслары бар».

Күреп үткәнебезчә, өч гасырда яшәгән өч автор бер үк нәрсә — казан татарларының мәктәпләре булуы һәм аларның укый-яза белүләре турында сөйлиләр.

Совет тарихчылары татар авылларындагы мәктәп-мәдрәсәләрнең эшчәнлегенә принципиаль һәм сыйнфый күзлектән карап бәя бирергә тырыштылар. Безнең гасырның егерменче елларында ук инде кайбер авторлар Урта Идел буе татарларының культурасы һәм аң-белем дәрәҗәләре турында язып чыктылар. М. Худяковның 1922 елда дөнья күргән «Урта Иделдә мөселман культурасы» исемле китабында, мәсәлән, татарларда мөселман культурасының үсешенә болгар чорыннан алып характеристика бирелә һәм өлешчә мәктәп белеме мәсьәләсе яктыртыла. 1912 елда ук инде татар культура тормышының кайбер яклары турында яза башлаган Җ. Вәлиди 1923 елда Мәскәүдә «Татарларның аң-белем һәм әдәбият тарихы очеркы» китабын рус телендә бастырып чыгара. Анда ул укучыларны иҗтимагый аңның һәм культураның үсеше, шулай ук татар мәктәпләре һәм мәдрәсәләренең эше белән таныштыра. Бу хезмәт мәктәп һәм мәдрәсәләрнең эчке тормышын, алардагы укыту системасын ачып бирүе белән кызыклы. Татар мәктәпләре тарихы белән кызыксынган А. Н. Григорьев һәм В. М. Горохов хезмәтләреннән дә кайбер мәгълүматлар алырга мөмкин. Татар мәктәпләре һәм мәдрәсәләре мәсьәләсе 1951, 1955, 1968 елларда басылып чыккан «Татарстан АССР тарихы» китабында да шактый чагылыш тапкан.

Без бу мәкаләбездә XVIII йөздә гомумән уку-укыту эшләренең торышын, беренче нәүбәттә татар мәктәпләренең һәм мәдрәсәләренең эшен яктыртуны бурыч итеп куябыз. Мәсьәләне ачыграк аңлау өчен мәктәп һәм мәдрәсәләр үсешенең баштагы һәм аннан соңгы тарихыннан кайбер мисаллар китереп үзү сорала. Кызганычка каршы, бу өлкәдә XVIII йөзгә караган материаллар бик аз сакланган. Ләкин, шулай булса да, ул мәсьәләдә күпмедер дәрәҗәдә фикер йөртерлек нигезебез юк түгел.

Мәктәпләр һәм мәдрәсәләрнең саны турындагы мәгълүматлар унтугызынчы йөзнең урталарында күренә башлый. Тулы булмаган саннарга караганда, ул вакытта Казан губернасында 430 татар мәктәбе исәпләнгән, 1858 елда Оренбург губернасында 418 мәктәп эшләгән. Татарлар яшәгән башка губерналарда татар мәктәпләренең саны, халыкның күпме булуына карап, бер белән илле арасында тирбәлә. Бу очракта, күрәсең, укыту өчен махсус бинасы булган мәктәпләр генә исәпкә алынган. 1744 елда Казан губернасындагы 536 мәчетнең 418 е җимерелгән. Әгәр мәчет каршында мәктәп булганлыгын искә алсак, аларның саны унтугызынчы йөз урталарындагы ким булмаган дип әйтә алабыз. Унтугызынчы йөздә һәм егерменче йөз башында мәктәпләр челтәренең киңәюе турындагы мәгълүматларны без дин эшләре департаменты фонды материалларыннан алдык. 1912 елда бу департамент Казан губернасында 83824 кеше укыган 24 мәдрәсә һәм 1067 мәктәп булганлыгын бәян итә. Кайбер мәгълүматларның, әлбәттә, бик үк төгәл булмаулары да ихтимал. Мәсәлән, кайбер мәдрәсәләр мәктәпләр исәбендә саналып йөртелгән, үз бинасы булмаган кайбер мәктәпләр исә бөтенләй исәпкә алынмаган. Әмма 1857 елга мәдрәсәләрнең иллегә җиткәнлеге билгеле.

Унсигезенче йөз мәктәпләре махсус төзелгән яки арендага алынган гап-гади авыл

өйләреннән гыйбарәт булган. Кечкенә авылларда укытучы-мулла еш кына очракларда үз йортын да башлангыч мәктәп итеп файдаланган. Моның өчен ул йортның аерым бер бүлмәсен билгеләгән. Андый типтагы мәктәпләр киң таралган булган, ләкин алда язып үткәнебезчә, аларны исәпкә алмаганнар.

Мәдрәсә мәчет тирәсендәге берничә йортка урнашкан, кайберләренең аерым аш-су өе булган. Унсигезенче йөздә таштан интернатлы мәдрәсәләр салына башлый. Ш. Мәрҗани язмаларыннан күренгәнчә, Ташкичү мәдрәсәсе, мәсәлән, бер-берсенә каратып салынган ике зур бинадан торган. Мәдрәсәләр һәм мәктәпләр классларга бүленмәгәннәр. Һәр авылда җиде-ундүрт яшьлек балалар мәктәпкә җыелган. Укулар шимбәдән пәнҗешәмбегә кадәр уздырылган. Балаларның бер өлеше шунда ук яшәгән, бер өлеше иртән килеп, кич кайтып йөргән. Пәнҗешәмбе көнне көндезге сәгать уникедән соң ялга таралганнар. Шимбә көнне үзләре белән азык-төлек, мулла һәм хәлфәгә (укытучыга) шулай ук мәктәпнең үзенә бүләкләр алып килгәннәр.

Мәктәп-мәдрәсәләр крестьяннар җәмгыятьләренең хисабына тотылганнар. Зуррак мәктәпләр аерым очракларда бай сәүдәгәр-меценатлар тарафыннан тәэмин ителгән. Муллалар, хәлфә һәм казыйлар махсус хезмәт хакы алмаганнар. Шәкертләр, аларның ата-аналары алып килгән күчтәнәч-бүләкләр хисабына яшәгәннәр. Күп кенә авылларның укытучы-муллалары үз җирләрендә крестьян хезмәте белән шөгыльләнгәннәр.

Җ. Вәлиди мәдрәсәнең эчке күренешен түбәндәгечә тасвирлый: «Стеналар буйлап пәрдәләр тартылган һәм алар хасил иткән аралык һәркайсына берәр тәрәзә туры килерлек итеп кечкенә бүлмәләргә бүленгән. Пәрдәләр алдына «җәмәгать сәкесе» дип аталган шактый киң урын калдырылган. Ул бер үк вакытта зал булып та, коридор һәм класс булып та хезмәт иткән. Лекцияләр вакытында пәрдәләр күтәрелгән һәм шәкертләр, мәдрәсәне яртылаш әйләндереп алып, тезелешеп утырганнар. Кайчагында «җәмәгать сәкесе» бүлмәләргә урнаштырылмаган кече яшьтәге һәм ярлырак шәкертләр өчен яшәү урыны булып хезмәт иткән. Алгы ике почмакта гадәттә такталардан ясалган ике бүлмә булып, аларда хәлфәләр һәм казыйлар яшәгән».

Башлангыч мәктәпләрдә боларның берсе дә булмаган. Мәктәп гомуми бер бүлмәдән торган. Шунда укыганнар да, ә кайчакта яшәгәннәр дә. Махсус бүлеп алынган кухняда һәркем үзенә-үзе ашарга хәзерләгән. Мәктәп-мәдрәсәдә укулар нинди тәртиптә алып барылганлыгы турында сөйләгәннән соң Н. Д. Коблов мондый нәтиҗә ясый: «Гадәттә әллә ни зур булмаган бүлмә уртасында, түгәрәкләнеп, идәндә төрле яшьтәге егерме-утыз укучы утыра. Ничә яшьтә булуларына карап аларның бер ишесе корьән, икенчеләре грамматика, өченчеләре мантыйк[1] укый. Өлкәннәре кечкенәләргә ярдәм итәләр. Аудиториянең башлыгы саналган мөдәррис, үз шәкертләренең уртасына яки берьяк читкәрәк басып, аларны бик җентекләп күзәтә, ул күбесенчә өлкәнрәк яшьтәге укучыларның дәресләренә җитәкчелек итә».

Мәктәптә укучыларның саны авылда күпме гаилә һәм ир бала булуга карап үзгәреп тора. Кайчагында алар дистәгә якын җыела, ә кайчагында илледән дә артып китә.

Мәктәпләрдә гигиена мәсьәләсенә килгәндә, бу яктан эшләр бик үк шәптән тормый. Тар һәм кысан бүлмәләрдә һава җитми, тынчулык хөкем сөрә, шәкертләр арасында төрле авырулар таралу очраклары да була.

Мәктәп һәм мәдрәсәләрдә бары тик малайларны гына укытканнар. Кызлар, кагыйдә буларак, мулла өендә укыганнар. Сабакны аларга мулла хатыны тыңлаткан. Олылау һәм хөрмәтләү йөзеннән аны остабикә дип йөрткәннәр.

Уку елының төгәл билгеләнгән бер вакыты булмаган. Ураза аенда һәм уракка төшкәч, кыр эшләрендә малайларның ата-аналарына ярдәмнәре аеруча кирәк вакытта, укулар тукталып торган. Уку тулаем алганда елына сигез ай чамасы дәвам иткән. Мәктәп һәм мәдрәсәләрдә укуның бөтен курсын узу өчен күпме вакыт кирәклеге шулай ук бер кайда да һәм беркем тарафыннан да расланмаган. Билгеләр кую да, журнал ише нәрсәләр дә, нинди дә булса программа да, имтиханнар алу да гамәлгә кертелмәгән. Әмма укытуның үзенә күрә системасы, дәрес бирүнең урта гасырлардан бирле яшәп килгән традицион ысуллары, тәртип һәм үзара мөнәсәбәт нормалары булган.

---

[1] Мантыйк — логика.

Укыту дингә нигезләп алып барылган һәм дини-эстетик тәрбия бирүгә хезмәт иткән. Укучы башта гарәп алфавитын ятлаган, аннары әлифба хезмәтен үтәгән «Иман шарты»на күчкән. Алфавиттан, иҗекләр һәм саннардан соң догалар, Адәмнән башлап Мөхәммәткә кадәр булган 23 пәйгамбәрнең исемнәре, мөселман динендәге кешенең 40 төрле бурычы өйрәтелгән. Җиде яшьлек баладан, мәгънәләрен бөтенләй аңламаган килеш, әнә шуларның бөтенесен яттан белү таләп ителгән. Укырга өйрәтүдә гадәттә хәреф кушу ысулы кулланылган. Балалар 29 хәрефтән торган гарәп алфавитын күңелдән ятларга тиеш булганнар. Аннан соң укучы ике, өч яки тагын да күбрәк хәрефләрдән торган иҗекләр төзи башлаган. Ел ахырында аңа Коръәннең бер бүлеге булган «Ясин»ны биргәннәр. Шәкертнең укырга өйрәнүе, бернинди мәгънәсен аңламыйча-нитмичә, гарәп текстын башта мулла яки хәлфә артыннан, тора-бара яттан кабатлап чыгуга кайтып калган. Берүк нәрсәне күп тапкырлар кабатлый торгач ул акрынлап хәрефләрдән сүзләр, сүзләрдән җөмләләр оештырырга, ягъни гарәпчә текстын үзлегеннән чагыштырмача җиңелрәк укырга өйрәнә.

Икенче елны баланың кулына Коръәннең җиденче бүлеген «һәфтияк»не тоттыралар. Өченче һәм дүртенче елларда инде шәкерт үзенең букчасында тулысы белән ятлап бирергә тиеш булган бөтен коръәнне йөртә. Элементар белемнәрне үзләштереп бетергәннән соң, дини китаплар белән бергә, аңа гарәп грамматикасын, тел һәм башка кайбер дөньяви фәннәрне өйрәтә башлыйлар. Татар телен өйрәтүгә әллә ни әһәмият бирмиләр. Шулай да гамәлдә аны читләтеп узә алмыйлар. Язма күнегүләрне шәкертләр берничә ысул белән алып баралар. Башта хәлфә, мәсәлән, менә мондыйрак эчтәлектәге кайбер үрнәкләрне үзе язып күрсәтә: «Мин биш тиенгә куян тиресе, илле тиенгә төлке, бер сумга бүре тиресе сатып алдым. Шуларның бөтенесе өчен күпме акча түләнгән?» Укучылар шуны күчереп алырга һәм сорауга җавап бирергә тиеш булганнар.

Үзлекләреннән башкару өчен шәкертләргә катлаулырак язма күнегүләр бирелгән. Буш вакытларында, бигрәк тә дәресләр беткән пәнҗешәмбе көннең икенче яртысында алар китап күчерү яки шигырь-бәетләр чыгару белән шөгыльләнгәннәр. Ул чорда типографиядә басылган китаплар булмаган, шуңа күрә китап күчереп язу, китап төпләү киң таралган һәм ул савaплы эш дип саналган. Унсигезенче йөздә кайбер кешеләрнең кырыгар һәм аннан да артыграк китап күчергәнлеген раслаучы мәгълүматлар бар. Язу-сызу кирәк-яракларын шәкерт сандыгының аерым бер бүлемендә йөрткәннәр. Күчереп язылган китаплар белән сәүдә итү киң таралган. Мәктәпләрдә шәкертләр үзләре файдаланудан тыш, аларны башка җирләргә дә илтеп сатканнар. 1773 елда, мәсәлән, хөкүмәт отрядлары Казан губернасыннан Пугачев восстаниесендә катнашкан һәм әсир төшкән татарлар кулыннан: Якубовтан ун сумлык тугыз китап, Мостаевтан унсигез сумлык унике, бер сумлык бер китап тартып алганнар. Аларның бу китапларны Оренбург губернасында сатып йөргән чаклары булган.

Башлангыч мәктәп шәкертләреннән, Коръәннән тыш тагын биш-алты китап, шулар арасыннан гарәп грамматикасын, гарәп теле этимологиясен һәм ислам дине тарихының кыскача курсын яттан белү таләп ителгән. Арифметика буенча йөзгә кадәр санарга, йөз эчендә кушарга һәм алырга, тапкырларга һәм бүләргә өйрәнгәннәр. Меңгә кадәр саннар белән бик сирәк очракларда гына эш иткәннәр. Укытуның сыйфаты хәлфәләрнең ни дәрәҗәдә укымышлы булуларына бәйле булган. Шул сәбәпле мәктәпләрдә кайчагында мәктәп-мәдрәсәләрнең урта һәм югары баскычларына гына хас булган фәннәр дә укытылган. Шулай итеп, кайбер очракларда мәктәп һәм мәдрәсәләр арасындагы аерымлылык кими-югала барган. Мәктәп дип аталып йөртелсәләр дә, кайбер башлангыч мәктәпләр мәдрәсә вазифасын үти башлаганнар. Күп кенә мәдрәсәләр, кагыйдә буларак, үз карамакларында башлангыч мәктәп тә тотканнар. Мәдрәсәдә дә укытуның характерын һәм сыйфатын мулла-мөдәрриснең укымышлылыгы билгеләгән.

Шул рәвешле, крестьян малае башлангыч мәктәптә өч төрле белем: дин, гарәп теле һәм әдәбияты, шулай ук дөньяви фәннәр буенча кайбер мәгълүматлар алып чыккан. Ләкин берничә елдан соң бер караңгыдан икенче караңгыга хәтле дәвам иткән крестьян хезмәтенең авырлыгы боларның күбесен җилгә очырган. Нәтиҗәдә унсигезенче йөздә күпчелек крестьяннар аң-белемсез калганнар.

Мәктәп-мәдрәсәләр шәһәрләрдә дә, авылларда да төп ике шарт үтәлгәндә генә яши алганнар. Аларның беренчесе — балаларга тәпле гыйлем бирә алырлык югары

аң-белемгә ия имам-мөдәррис булу, икенчесе — мәдрәсәнең дин тотучы байлар, сәүдәгәр-меценатлар яки хәлле крестьяннар җәмгыятьләре тарафыннан материаль яктан тәэмин ителүе. Мәктәпләрдән аермалы буларак, мәдрәсәләрдә укучылар төрле авыллардан, хәтта ерактагы чит өлкәләрдән җыелганнар. Мәктәптә укучы шәкертләр күп саен үз өйләреннән килеп йөргәннәр. Мәдрәсәдәгеләр исә даими рәвештә шунда яшәгәннәр, өлкән яшьтәге шәкертләргә үзлекләреннән укырга да мөмкинлек бирелгән.

Мәдрәсәгә укырга теләге булган һәр кешене кабул итәләр. Ә шулай да шәкертләрнең күпчелеген шул ук крестьян балалары тәшкил итә. Аларны укыту һәм тәрбияләү элек-электән килгән традицияләрдә алып барыла. Гарәп теле һәм әдәбияты корьәнне яхшырак уку һәм аңлау өчен өйрәтелә. Шәкертләр тарафыннан өйрәнелергә тиешле калын-калын томнардан торган төрле сүзлекләр, аңлатма-китаплар ислам динен нигезле һәм һәрьяклап үзләштерү коралы хезмәтен үти. Мәдрәсәдә укуның беренче елында шәкертләр гарәп теле грамматикасын һәм этимологиясен фарсы телендә язылган китап буенча өйрәнәләр. Укыту алга таба да шул ук характерда дәвам иттерелә. Икенче һәм өченче елларда гарәп синтаксисы өйрәнелә. Дүртенче елда «акыл фәннәре»нә — башта «мантыйк»ка (логика), аннары «хикмәт»кә (философиягә) күчәләр. Борынгы грек философлары хезмәтләренә нигезләнгән һәм урта гасыр гарәп галимнәренең һәртөрле искәрмәләре белән кулланма итеп алынган бу фәннәр шәкерттән акыл сәләтен соң чиккәчә эшкә җигәргә мәҗбүр иткән һәм тәнкыйди анализның үсүенә китергән. Шуның аркасында шәкертнең теле байый һәм эзлеклерәк, эчтәлеклерәк була барган. Соңга таба ислам диненең төп кануннарын, мөселман кешесенең хокукларын һәм мирасны бүлү турындагы «фән»не укытканнар. Бу дини фәннәрнең барысы да ислам шәригатенең эчтәлеген аңлаган мәхәллә муллалары хәзерләүне күздә тотып өйрәтелгән. Әлеге фәннәр буенча дәреслек китаплары нигездә уникенче-унҗиденче гасырларда язылганнар һәм унтугызынчы гасырга кадәр һичбер нинди үзгәрешсез файдаланылганнар. Бу китапларны кат-кат күчереп язганнар, күңелдән ятлаганнар, аларга багышлап һич кирәге булмаган гомуми бәхәсләр — дискуссияләр уздырганнар. Мәдрәсәдә укучы шәкерт төрле өлкәгә караган фәннәр буенча бер китаптан икенчесенә, төп китаптан аның аңлатмасына һәм искәрмәләренә күчкән. Югарыда без мәктәпләрнең классларга бүленмәгән булуларын искәртеп узган идек. Ә шулай да укучылар, бигрәк тә мәдрәсә шәкертләре материалны үткәндә аерым төркемнәргә бүленгәннәр. Бер төркем синтаксис, икенчесе мантыйк, өченчесе исә нинди дә булса дәреслек-китап укыган.

Зур булмаган мәктәпләрдә барлык укучылар һәм төркемнәр белән бер укытучы, ягъни мулла җитәкчелек иткән. Ә зур мәктәпләрдә имам-мөдәррис кул астында бернichә кече остаз-хәлфә эшләгән. Аерым бер очракларда мөдәрриснең ярдәмчеләре итеп өлкән яшьтәге укучы-шәкертләр билгеләнгән. Аларның һәркайсы укуның башыннан ахырына кадәр, нинди төркемдә булуларына карамастан, бер үк төркем укучылары белән шөгыльләнгән. Хәлфә үзенең дәресләрен түбәндәге тәртиптә алып барган: бер төркемдәге барлык шәкертләрне үз янына чакырып, элек узылган дәресләрне сораган. Әзерләнми килүчеләр яки дөрес җавап бирмәүчеләр булса, аларны бик каты тиргәгән һәм кулына ни эләксә, шуның белән кыйнаган. Яңа материал үткәндә, элек узылганнарны кабатлау һәм үзләренә йөкләнгән бурычны үтәү йөзеннән кечкенәләргә булышу өчен дәрестә өлкән яшьтәге барлык укучылар катнашкан. Уку елының билгеле бер регламенты булмаса да, көндәлек дәресләр, киресенчә, мәҗбүри үтәлергә тиешле төгәл тәртип буенча алып барылган. Шәкертләр мәктәптә дә, мәдрәсәдә дә иртәнге намазны башкаргач сәгать сигездән алып уникегә кадәр дәрес тыңлаганнар. Көндезге сәгать уникедән соң ял иткәннәр һәм үзләренә төшке аш әзерләгәннәр. Башлангыч мәктәпкә йөрүчеләр ашарга өйләренә кайтканнар. Уналты сәгатьтә кичке дәресләр башланган. Кич белән мәдрәсәгә имам-мөдәррис килеп өлкән яшьтәге шәкертләргә һәм кече остазларга лекцияләр укыган. Уку көне егерме бер сәгатьтә тәмамланган. Кичке ашны ашап, биш вакыт намазның соңгысын укыганнан соң шәкертләр йокларга ятканнар.

Гадәттә егерме-егерме ике яшендә шәкерт, үзен аны тәмамлаган санап, мәдрәсәдән чыккан. Укуы һәм мәктәпне тәмамлавы турында аңа берничи дә документ бирелмәгән. Мәдрәсәне бетереп чыгучыларның алдагы язмышлары аларның үз кулларына тапшырылган. Берәүләре укытучы-хәлфәләр булып урнашканнар, икенчеләре,

әгәр аларны крестьян җәмгыятьләре үзләренең җыелышларында сайлап куйсалар, авыл яки мәхәллә муллалары итеп билгеләнгәннәр. Чит якларга — Урал буйларына, Оренбург һәм Казахстанга китүчеләр дә булган. Балаларны татар грамотасына өйрәтү өчен Оренбург ягына киткән Абдул Әпсәләмов, Габдрахман Хәсәнов, Мөслимов, Хәлилов һәм башкалар, мәсәлән, 1773 елда пугачевчы булуда гаепләнеп хөкүмәт гаскәрләре тарафыннан кулга алынганнар. Зөя өязендәге Олы Шырдан мәдрәсәсендә укыган Әмир Ишимевның исә Воскресенскида урнашкан Твердышев заводында 1770—1773 елларда татар балаларын укырга-язарга өйрәтүе билгеле. Мәдрәсә тәмамлап чыккан укымышлы кешеләр мөселманнар күпләп яшәгән урыннарда, хәтта мәчет булмаган җирләрдә дә мәктәпләр ачканнар. Мәдрәсәдән чыгучыларның бик күпләре үз авылларында крестьяннар булып калганнар.

Унсигезенче йөздә Казан, Оренбург янындагы Каргалы, Борындык, Кышкар, Бәрәскә, Минзәлә, Эстәрлебаш, Урә, Мәчкәрә, Тайсуган, Ташкичү, Саба, Әгерҗе, Шырдан мәдрәсәләре үз заманнары өчен зур һәм күренекле мәдрәсәләр булып исәпләнгәннәр. 1730—1740 елларда хәзерге Әлмәт районындагы Тайсуган мәдрәсәсенең имам-мөдәррисе Габдрахманның исеме бөтен тирә-якка билгеле булган. Ул күп кенә көнчыгыш телләрен белгән, шигырьләр язган, мәдрәсәсенә үз заманы өчен хәзерлекле укытучыларны тарткан, китаплар күчереп язган һәм аларны матур итеп бизәгән. Китапларында һәм васыятьнамәсендә ул наданлыктан качарга, төрле фәннәр һәм һөнәрләр белән шөгыльләнергә кирәклеген язып калдырган. Аның мәдрәсәсенә укырга якын-тирә авыллардан гына түгел, Казанның үзеннән, Оренбурдан, Урал буйларыннан һәм Казахстан якларыннан килгәннәр. 1773 елдан алып берничә ел буена бу мәдрәсәдә Башкортстанда күтәрелгән 1755 елгы восстаниенең идеологы һәм җитәкчесе Батырша (Абдулла Галиев) укыган. Белем алуын ул вакытта исеме киң таралган ахун Габделсәлам Ураев кул астында дәвам итәр өчен Батырша, Арча төбәгендәге Ташкичү мәдрәсәсенә күчеп килгән. Нәтиҗәдә, соңыннан ул зур укымышлы имам булып киткән. Замандашлары аны тирән акыллы, гадел, мөселман шәригатен һәм аның кануннарын яхшы белүче кеше буларак искә алганнар. Патша хөкүмәте аны Уфа провинциясенә ахун итеп билгеләмәкче булган. Шунысы кызыклы, 100 елдан соң шул ук Ташкичү мәдрәсәсендә күренекле татар тарихчысы һәм мәгърифәтчесе Шиһабетдин Мәрҗани белем алган. Мәдрәсәнең бай китапханәсе һәм уку-укыту өлкәсендә нык урнашкан үз традицияләре булган.

Мөдәррисләр арасыннан шактый үзенчәлекле, камил акыллы кешеләр дә үсеп чыккан. Шундыйлардан без күренекле шагыйрьләрдән унҗиденче йөздә яшәгән Мәүлә Колыйны, 1754—1834 елларда яшәгән Утыз Имәнине, скрипкачы-музыкантлардан Мөхәммәт бине Галине, Ишмөхәммәт бине Заһидны, төрле дәреслекләр төзегән авторларны һәм башкаларны беләбез. Унсигезенче йөз башында Мортаза бине Котлыгыш Симети егерменче йөз башларына кадәр кулланма булып хезмәт иткән әлифба төзегән, Юныс Ыруви математика буенча махсус хезмәт язган. Кайбер мөдәррисләр үзләренең дәресләрен татар телендә алып барганнар. Риза Фәхретдиневнең язуынча, балаларны алар гарәп телендә түгел, «төрки» ягъни татар телендә укытканнар. Шәкертләр алардан риторика һәм поэзия, тарих һәм география, шулай ук башка фәннәр буенча кирәкле мәгълүмат алганнар, әйбәт язарга һәм укырга өйрәнгәннәр.

Татар телендә язылган һәм безнең көннәргә кадәр сакланып калган архив материалларыннан күренгәнчә, күп кенә крестьяннар грамоталы булганнар, документларга үзләренең имзаларын куя белгәннәр. Мәсәлән, 1770 елда хөкүмәт крестьяннар исеменнән Петербургка барырга тиешле вәкилнең чыннан да сайланган булуын һәм вәкаләтле икәнлеген раслануны таләп итә. Бөтен Казан губернасы буенча уздырылган авыл җыеннарында кабул ителгән карарларны һәм ышаныч кәгазьләрен бергә туплыйлар. Ул документларга үз имзаларын куючыларның саны тамга салучыларның, ягъни укый-яза белмәүчеләрнең, санынннан аз булмый.

Архив материаллары арасында Емельян Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышында катнашкан татар крестьяннарының хатлары һәм документлары әһәмиятле урын алып тора. Пугачевчы татарлар мөхитендә русча укый-яза белүчеләр дә очраштырган. Юскәй Кудашев һәм Тумашевлар Пугачев манифестларын русчадан татарчага тәрҗемә иткәннәр. Осип Енгалычев, Тангачев һәм башкалар бу манифестларны крестьяннарга рус телендә укыганнар. Казан губернасының Хөсәен авылы крестьянкрестьяннарына

яны Юлдаш Мәтмәткулов әтисенең тырышлыгы белән татарча һәм русча укырга-язарга өйрәнгән, чит ил эшләре дәүләт коллегиясендә хезмәттә торган. Ул 1771 елда Зөя провинция канцеляриясендә тылмач булып эшләгән. Унсигезенче йөзнең алтмышынчы елларында Сөбханкул Якупов атлы икенче бер крестьян шулай ук татарча-русча укырга-язарга өйрәнеп, һәр ике телдән тәрҗемә итә алу осталыгына ирешкән.

1758 елда провинциональ Россиядә беренче буларак, Казанда, Мәскәү университетының инициативасы буенча, гимназия ачыла. Ун елдан соң анда татар теле укытыла башлый. 1778 елда шул ук университетта гимназиянең татар теле укытучысы С. Хәлфин төзегән һәм Казан муллалары тарафыннан тикшерелеп расланган «Әлифбаи татар» басылып чыга. Бу беренче дөньяви басма әлифба русча-татарча төзелә.

Кайбер крестьяннарның балалары русча укырга-язарга Казандагы керәшен һәм Уфадагы тылмач-тәрҗемәчеләр, күчереп язучылар хәзерләү буенча 1744 елда эшли башлаган мәктәпләрдә өйрәнәләр. Унсигезенче йөздә татарча язылган документларда татар халкының сөйләм теленә үтеп кергән рус сүзләрен еш очратырга мөмкин. Ана теле белән беррәттән, үзләре яшәгән дәүләт телен һәм законнарын өйрәнү кирәклеген аңлаучы кешеләр, әлбәттә, булган. Шундыйларның берсе — Зөя өязенең Шәмәк авылы кешесе Гайса Кашаев. Ул ясак түләүче татарларның балаларын төрле телләргә, шул исәптән рус теленә, өйрәтү өчен мәктәп ачарга рөхсәт сорап 1731 елда Мәскәүгә бара. Ләкин хөкүмәт аның үтенечен канәгатьләндерми, татар мәктәпләрен ул гомумән чит күрә, аларга бернинди ярдәм күрсәтми.

Дини характерда булсалар да мөселман мәктәпләренең уңай якларын инкяр итү дөрес булмас иде. Аларда балалар билгеле бер тәртип нормаларында тәрбияләнгәннәр һәм кайбер фәннәр буенча ярыйсы гына мәгълүмат алганнар, ә иң әһәмиятлесе — укырга-язарга өйрәнгәннәр. Моның шулай икәнлеген танымый торып, без ул чорда татар язуының киң таралуы сәбәпләрен аңлата алмаячакбыз. Әмма мулла-мөдәррисләргә килгәндә, аларның төп массасының аңы катып калган схоластика, урта гасырга хас торгынлык идеяләре белән сугарылган булган.

Унсигезенче йөздә Бохара һәм Сәмәрканд мәдрәсәләрендә белем алган муллалар аеруча зур абруй белән файдаланганнар. Ул мәдрәсәләрдә нәкъ менә феодаль мөнәсәбәтләргә нигезләнгән һәм торгынлык хөкем сөргән тормыш өчен характерлы булган тәртипләр өстенлек иткән. Шул ук гасырның урталарында Идел буеннан мөселманнарның Бохара мәдрәсәләренә укырга барганлыклары мәгълүм. Фанатиклар һәм схоластларга әверелеп кайткач, әлеге тәртипләрне алар Идел-Урал төбәгендәге мәдрәсәләрдә дә урнаштырганнар. Ләкин унсигезенче йөзнең икенче яртысында мәктәпләрдәге урта гасыр тәртипләреннән риза булмаган укытучы-мөдәррисләр үсеп чыккан. Гасыр ахырында Габденнасыйр Курсавый (1776—1812) мәктәп-мәдрәсәләрдә моңарчы яшәп килгән догматларга каршы икәнлеген язма рәвештә ачыктан-ачык белдергән. Кулъязма китапларында һәм башка төр хезмәтләрендә ул ислам диненең гасырлар буена катып калган кайбер өйрәтүләрен фаш иткән. Шушындый башбаштаклыгы һәм дәһрилеге өчен Бохара әмире һәм аның казыйлары Курсавыйны үлем җәзасына хөкем иткәннәр. Ул дуслары ярдәмендә үзенең туган ягына кача һәм хәзерге Татарстанның Арча районындагы Корса авылында зур гына мәдрәсә ачып, анда балаларны үз чоры өчен яңача укытырга тырышкан. Заманында аның исеме һәм идеяләре тирәсендә мулла-мөдәррисләр арасында кискен көрәш барган. Күпчелек Курсавыйга каршы чыккан, шул ук вакытта аны яклаучылар да аз булмаган. Шулай итеп, унсигезенче йөзнең икенче яртысыннан башлап мәктәпләрдә иске тәртипләргә карата ризасызлык туа һәм акрынлап аларга каршы көрәш башлана. Бу көрәш Октябрь революциясенә кадәр дәвам иткән.

# *Самат Шакирга 60 яшь*



*Каләмдәшебез, 1953 елдан КПСС члены, шагыйрь, танылган очеркист, СССР Язучылар Союзы әгъзасы Самат Шакирга 60 яшь тулды.*

*Самат Фәтхерахман улы Шакиров 1924 елның 15 апрелендә Татарстанның Әтнә (хәзерге Арча) районы Күәм авылында туа. Тулы булмаган урта мәктәп тәмамлагач, Арча педагогия училищесына укырга керә. Аннары авыл мәктәпләрендә укытучы, мөдир, Әтнә район газетасында әдәби хезмәткәр булып эшли, бер үк вакытта колхозда хисапчы һәм комсомол секретаре да була.*

*1943—45 елларда Совет Армиясендә хезмәт итеп кайткач, «Кызыл Татарстан» газетасында әдәби хезмәткәр, Дөбъяз район газетасында җаваплы секретарь вазифаларын башкара. 1950—51 елларда исә язучылык эшенә күчеп, «Очрашу» һәм «Бәхетле көнем» исемле беренче шигырь китапларын бастырып чыгара.*

*1951 елда В. И. Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университетының тел-әдәбият бүлегенә керә, соңыннан читтән торып укуга күчә (университетны 1957 елда тәмамлый), тагын мәктәпләрдә укытучы, директор, Татарстан китап нәшриятында редактор булып эшли. 1962 елдан, Язучылар союзына кабул ителгәч, профессиональ язучы булып ныклап иҗат эшенә керешә...*

*Беренче шигырьләре әле сугышка кадәр «Пионер каләме»ндә басылган шагыйрь хәзер — авыл, бүгенге чор, замандашларына багышланган уннан артык шигырь китабы авторы. Аларның берничәсе рус, төркмән, үзбәк, башкорт, мари һәм казах телләрендә дә басылып чыкты, аерым шигырьләре исә унбиштән артык телдә яңгыраш тапты... С. Шакир — шулай ук, балалар өчен шигырь китаплары белән дә билгеле шагыйрь.*

*Соңгы елларда ул хәрби-патриотик темага күп санлы очерклары, документаль повестьлары белән укучыларыбызга киң танылды; аның «Легенда егетләре» исемле повесте аеруча уңыш казанды. Бөек Ватан өчен һәлак булган өч батыр — испанлы Рубен Ибаррури Руис, рус егете, очучы, майор Владимир Каменьщиков һәм татар халкының баһадир улы, артиллерист, капитан Хафиз Фәттахетдинов (алар бергә күмелгәннәр) турында ул повесть. Китапны автор Испаниягә, испан батырының әнисе — Долорес Ибаррурига да җибәрә һәм аңардан шундый җавап ала:*

*«Кадерле Самат Шакир иптәш!*

*Сезнең китабыгызны алдым һәм яратып укып чыктым. Бу яшь-яшь егетләр — әле малайлыктан да арынып бетмәгән батырлар турында язылган китап мине дә дулкынландырды. Шундый китап язганыгыз өчен сезгә чын күңелдән зур рәхмәтемне белдерәм...» Испания Коммунистлар партиясе җитәкчесе, көрәш ветеранының бу хаты илнең күп газеталарында басылды.*

*С. Шакирның «Һәйкәл итәгендәге чәчәкләр» повесте да каһарманнар — ун Советлар Союзы Герое турында, «Үлемсезләр» китабы исә легендар панфиловчыларга багышланган. Татар халкының батыр улы, язучы Х. Мөҗәй турындагы «Үлемнән көчлерәк» исемле повестен да күп телләрдә укып беләләр. Сугышта һәлак булган татар совет язучылары турында ул «Алар сафта» исемле китабында да сөйли. «Кече җир»дә сугышып һәлак булган парторг — данлы якташыбыз С. Вәлиуллин турында һәм Идел буе укчы татар бригадасы турында очерклары да укучыга яхшы таныш.*

*Бу темага актив һәм нәтиҗәле язган өчен С. Шакир СССР сугыш ветераннары комитетының Почет грамотасы, ДОСААФ Үзәк комитеты һәм өлкә комитетының берничә Почет грамотасы белән бүләкләнде. Шулай ук шагыйрьнең җырлары Бөтенсоюз хәрби-патриотик җырлар конкурсында Диплом белән бүләкләнде. Аның «Чирәм җирләрне үзләштергән өчен» медале дә бар. КамАЗ, БАМ төзелешләрендә дә язучыны яхшы беләләр.*

*Үзенең 60 яшен иҗат дәрте белән яныл каршылаучы тынгысыз каләмдәшебезне редакция һәм укучыларыбыз исеменнән кайнар котлап, бу санда аның төрле елларда язылган берничә шигырен тәкъдим итәбез.*

# Самат Шакир

## Яңгыр тамчысы

Күк күкрәп, яшен басуда
Селтәде утлы камчы.
Яңгыр ява. Бер башакта
Тирбәлә эре тамчы.

Җир белән һава тоташкан,
Үләннәр иркен сулый.
Җил дә юашланган ахры,
Зур болытларны кумый.

Каерылып үсәр арышлар,
Шатланып һәрбер кеше,
Алмаз бөртегедәй тамчы
Җемелдәп төпкә төште.

Челтәр тамырлар
шул вакыт
Аны үзенә алды.
...Бал булып та,
май булып та
Эре тамчылар яуды.

## Килмә, килмә кичен бакчага

Күкнең йолдызлары энҗе булып
Сибелгәннәр гүя юлыңа...
Син киләсең... Озын кара чәчләр
Үрелгәннәр ике толымга.
Син киләсең әкрен генә атлап,
Әллә нишләп китте күңелләр.
Сиңа карый гүя алмагачлар,
Баш ияләр гүя сөмбелләр.
Көлгән чакта битең уелып китсә,
Уелып китә минем йөрәгем.
Бу мәхәббәт нигә кинәт кабына?
Белсәң әгәр, әйтеп бир әле.
Күз карашың... Ах, ул серле күзләр
Тибрәндерер тын су өсләрен.
Тибрәнгән су кебек булырмын дип
Куркам, куркам. Аннан нишләрмен?

Зифа таллар бөгелә, юк, тал түгел,
Синең билең нәфис тал кебек.
Сине күргәч, бик-бик якын килеп
Әйтер сүзләрем дә бар кебек.
Белмәгәнмен: күңелем яшь икән шул,
Чәчләремә көмеш якса да...
Дәртле яшьлегемне чакырып син
Килмә, килмә кичен бакчага.

## Башын иеп тора өч нарат

Өч төз нарат — болын буенда,
Без өч малай аны яраттык.
Урак айлы җәйге кичләрдә
Атларны без шунда тараттык.
Без өч малай атлар яраттык.

Атлар тешләсә дә, типсә дә,
Яшь агызып өйгә кайтмадык,
Чишмә суы белән юдык та
Ат өстендә атлар сакладык,
Без мендәрдә йоклап ятмадык.

Учак яктык... Авыз күмерле
Бәрәңгеләр ашап каралды.
Йолдызларга карап, сөйләшеп,
Әкиятләр шытты, яралды.
Без чыгара идек аларны.

...Өч наратның, имеш, төбендә
Бик борыннан алтын күмелгән.
Ялган икәнлеген белсәк тә,
Безгә шуннан ләззәт бирелгән...
Алтын — учактагы күмердә.

Кинәт шунда яшен яшьнәде.
Болыт чыкты аклы-каралы.
Яңгыр ява — пуля яңгыры,
Атлар төрле якка таралды,
Кабат күрәлмадык аларны.

Солдат булып кайттык өйләргә...
Каршылады болын, өч нарат,
Өч малайның кайда икесе?
Таныш җиргә килдем мин кабат,
Башын иеп тора өч нарат.

## Бабайлардан килгән моң

*«Татар моңлы җырын сузды.»*
А. С. Пушкин

Фин култыгы. Салкын җилләр исә,
Дулкын бәрә гранит ярларга.
Ленинград моннан күренеп тора,
Мин сокланып карыйм аңарга.
Керәбез без сугыш елларында
Ут яудырган кораб эченә.
Карт ветеран батырларча үлгән
Морякларны искә төшерә.
Палубага чыктык. Кинәт шунда
Бик таныш җыр, дуслар, ишеттем.
Онытылып озак тыңлап тордым,
Барыр җиремә дә кичектем.
Йөрәк кылларына чиртә моряк,
Моңлы итеп җырлый «Сакмар»ны.
Бу таныш көй мине сихерләде,
Искә алдым туган якларны.
Балачактан үлеп гашыйк җырга,
Бабайлардан килгән моң ич бу!
Бөек Тукай әйткән җәүһәр ич бу,
Бөек Пушкин белгән моң ич бу!
Французларны җиңгәч, Парижда да
Җырланылып йөргән җыр ич бу!
Татар моңы...
Бөек Ленин үзе бик яраткан,
Бәһавидан килгән моң ич бу!
Җанга якын көй бу.
Берлинда да
Яңгырады татар көйләре...
Моряк җырлый, аны тыңлау өчен
Тынды гүя Балтик җилләре.

## Бер легенда

Юлчы чүлдән бара...
Алда — бакча.
Шау чәчәктә утыра бананнар.
Күл читендә мәрмәр нәфис сыннар
Су аттырып уйга калганнар.
Сары комның монда бөртеге дә
Җилләр белән очып кермәгән.
Эссе чүлдә мондый күренешне
Бәлки әле беркем күрмәгән.
Аллы-гөлле бизәк төшерелгән
Келәм кебек бакча итәге.
Кул изиләр гүя зур пальмалар:
«Тизрәк, тизрәк килеп җит әле».
Юлчы уйлый: «Бу бакчага кадәр
Күпме авыр юллар үтелде...»
Алда мираж торганлыгын белми,
Запас суны эчеп бетерде.

# *Энҗе Мөэминовага 60 яшь*



*Шушы елның май аенда укучыларыбызга яхшы таныш шагыйрә, публицист, 1963 елдан СССР Язучылар союзы әгъзасы Энҗе Мөэминовага 60 яшь тула.*

*Энҗе Илалетдин кызы Мөэминова 1924 елның 18 маенда Әлмәт районының Яңа Кәшер авылында тимерче гаиләсендә туган. 1941 елда Әлмәт урта мәктәбен тәмамлый, Югары Мактама, Мәмәт һәм Габдрахман авылы мәктәпләрендә математика укыта; шул ук вакытта читтән торып Казан педагогия институтында, 1945—48 елларда Ташкент педагогия институтында укый. Югары белем алгач, кабат Габдрахман авылына кайта, 1974 елга кадәр урта мәктәптә математика укытучысы булып эшли. 1962 елдан КПСС члены.*

*Э. Мөэминова исеме республиканың газета-журналларында 1957 елдан башлап күренә башлый; шуннан бирле ул даими рәвештә үзенең югары пафослы, гражданлык хисләре белән сугарылган шигырь һәм поэмаларын, мәктәп, тәрбия мәсьәләләренә, чорыбыз яңалыкларына багышланган мәкалә һәм очеркларын бастыра килде.*

*1962 елда исә шагыйрәнең укучылар җылы каршылаган «Ефәк яулыгым» исемле шигырьләр һәм поэма китабы дөнья күрде. Аннары Татарстан китап нәшрияты Э. Мөэминованың зурлар һәм балалар өчен «Синең өчен язам», «Шигырьләр», «Бүләгем», «Исемдә», «Әниләргә һәм нәниләргә», «Үрдәгем үпкәләде», «Әйдәгез танышыйк» дип исемләнгән шигырь китапларын бастырып чыгарды.*

*Үзенең зур юбилеен иҗат дәрте белән янып яңа әсәрләр язып каршылаучы танылган шагыйрәбезне укучыларыбыз исеменнән алдан ук котлап, бу санда аның шигырьләреннән бер бәйләм урнаштырабыз.*

# Энҗе Мөэминова

## Көзге чәчәк

Иртә белән әрәмәдә
йөргән чакта,
Ирексездән гөлҗимешкә
күзем төште:
Пешеп җиткән җимешләре
арасында
Бик матур бер чәчкәсе бар —
мәрҗән төсле.
Мескен чәчәк!..

Аңа ялгыз күңелсездер:
Бал кортлары үбеп китми
таҗларыннан,
Иркәләнми аңа кунып
күбәләкләр,
Кошлар җырын ишетми ул
таң алдыннан.
Көз җитәсен, кыш киләсен
хәбәр итеп,
Җилләр исә сары яфрак
арасыннан.
Ләкин чәчәк шиңми, яшәү
өмет итә,
Күңеле көтә:
кемдер килеп карар сыман...

*1957*

## Син һәм мин

Ел буена чәчәк атып
кына гөл,
Якты тәрәзә төбендә
тора гел.
Тәрәзәгә кайчак бозлар
чиртәләр.
Чиртәләр дә, тайпылышып
китәләр.
Җил-яңгырны тәрәзәләр
этәрә.
Якты нурны, матур җырны
үткәрә.
Син дә минем тәрәзәм бит,
мин — гөлең.
Син булганга якты минем
һәр көнем.
Син туңасың,
мине туңдырмас өчен.
Син янасың,
мине сулдырмас өчен.

*1969*

## Юл ярам

Көзге төн. Мин ялгыз.
Юл ярам.
Юлымнан туктарга
юк чарам:
Үземнән соң килер
берәүгә
Ай нуры яктырткан
эз салам.

Каршымда биек тау,
кыялар.
Юк кире чигену!—
Мин барам:
Кыя таш кукрәген
уеп, мин
Яраткан кешемә
җыр язам.

Диңгезләр төбенә
чумам да
Энҗеле, мәрҗәнле
сүз табам:
Күңелем байлыгын
бүлешеп,
Сер сыяр кешемә
сер салам.

*1979*

## Май

Туй күлмәген киеп алды шомыртларым,
Кызганмыйча сипте алар хушбуйларын.
Сиреньнәрнең өсләрендә купшы кием,
Хуш ис белән тулды минем бөтен өем.
Таҗларына кояш иңде тюльпаннарның,
Энҗе чәчәк тагып алды алкаларын.
Ак ефәккә төренделәр алмагачлар,
Гөлбакчама җыр китерде сандугачлар.
Сукмагымда җете-яшел хәтфә келәм,
Бизәкләнде төрле төсле гөлләр белән,
Киләчәккә тоташтырган уйлар белән,
Шул келәмгә йомшак кына басып киләм.
Табигатьнең гүзәл кызга охшаш чагы,
Мәк чәчкәсен хәтерләтә алсу таңы.
Өмет белән яши майда һәрбер кеше,
Түтәл казый — көз җыясы уңыш өчен.
Иң кадерле бәйрәмнәр бит шушы айда,
Җиргә орлык, орлык төшә җиргә майда!

*1982*

## Сөенечем артты

Алмагачым ап-ак чәчкә атты.
Бар дөньяма аклык сирпелде:
Йөз аклыгым булып тәрәзәдән
Балаларым карый шикелле.
Олы кызым минем — сер сандыгым.
Киңәшчем дә минем, дустым да.
Ерактан да җанны җылытучы
Кайгыртучан төпчек кызым бар.
Улым минем — алтын урталыгым —
Таянычым картлык көнемдә...

Бәхет бакчабызның иң түрендә
Әтиләре тора бүген дә.
Чәчкәнемне җыяр көнем җитте.
Алмагачым ап-ак чәчкәле.
Мул җимешле алмагачлар булып
Кайтасыман минем чәчкәнем.
Алмагачым ап-ак чәчкә атты,
Бар дөньяма аклык сирпелде.
Мул җимешле алмагачлар булып
Балаларым карый шикелле.

*18 май, 1983*

## Шагыйрь-ана

Йөрәгеннән өзелеп-өзелеп
сүзләр тама.
Күз нурлары хәреф булып
коела аңа.
Тынгысыз көн, йокысыз төн
хисләр үрә,
Яңа шигырь яшәү даулап
аваз бирә:
— Каләм кирәк!
Кәгазь кирәк!
Тизрәк, тизрәк!!!
Каләм йөгерә, чуарлана кәгазь бите,
Авазларны тезә-тезә
сүзләр итеп.
Һәрбер аваз, һәрбер сүздә
тибә йөрәк:
— Мәйдан кирәк!
Канат кирәк!!
Тизрәк, тизрәк!!!
Тере шигырь китап булып
канат яра.
Кәгазь бите мәйдан түгел
инде аңа
Моңсу гына карап кала
Шагыйрь-ана.

*1984*

## Балык шулпасы

Азнакайга баргач, Сибгат Хәким белән Хәсән Туфанны бер язучы кара таңнан уятып, балыкка алып китә. Вакытында ашап, вакытында йокларга күнеккән бу ике аксакал теләр-теләмәс кенә кузгалалар. Җәяү җәһәннәмдәге елгага алып барып, картларга ял итәргә кушып, прозаик егермеләп кармак салып куя.

— Сибгат абый! Хәсән ага! Мин сезне тәмле балык шулпасы белән сыйлыйм әле. Үтергеч тәмле була мин пешергән шулпа, телегезне йотачаксыз, валлаһи! — дип, ул күтәрә килгән ярты пот борчакны суга сибеп чыга.

Таңнар ата — чиертми. Җилләр чыга, көн суыта — чиертми. Балык эләгү түгел, егерме кармакның ник берсенең калкавычы селкенеп карасын! Ике шагыйрь ачыга, сабыр гына зарлана башлыйлар болар.

— Төш авышкач чиертә ул, — дип, прозаик ач-хәлсез кунакларын юата.

Төшләр авыша, кичләр җитеп, шәфәкъ баеса да, сукыр шыртлака да каптыра алмыйлар болар. Кайтырга чыгалар. Сибгат Хәким белән Хәсән Туфан салмак кына авылга таба атлый. Әлеге язучы балык шулпасы пешерергә дип алган ике буш чиләкне, егерме кармакны күтәргән килеш, ике шагыйрь арасында чабып йөри, үзе аклана, юатырга тырыша:

— Әлегә иде, менә мондый-мондый кызыл канатлар каба торган иде. Балык шулпасын шәп пешерәм мин, мин пешергән балык шулпасын ашасаң, телеңне йотасың, валлаһи!

Хәсән Туфаң дәшми, ач карынга тәмәке тартып кайта. Сибгат Хәким исә кайта торгач әйтеп куя:

— Энекәш... син борчакны күбрәк сиптең бугай!

## Ат ите һәм Отелло

Отеллоны уйнар алдыннан Мохтар Мутин сәхнә артында кәефсез генә репетиция ясап азаплана икән. Театрның режиссеры Риза Ишморат килеп аңа дәшә:

— Нигә кәефең юк, Мохтар абзый? — ди.

— Гомерем буе мин Отеллоны уйнар алдыннан ике кило ат ите ашый торган идем. Шунсыз Отеллоны уйнап чыгып булмый. Бүген мин ат ите ашамадым — сәхнәгә чыга алмам, ахрысы, чыксам да егылып, аяк сузачакмын! — ди Мохтар ага.

Шуннан соң Р. Ишморат бухгалтериягә кереп, ялынып акча алып чыга. Ат ите сатып алып пешерәләр. М. Мутин һәйбәтләп ашый. Кичен «Отелло» спектакле өзелми кала.



## ЯЗУЧЫЛАР СОЮЗЫ ПАРТИЯ ОЕШМАСЫНДА

Язучыларның 24 январьда узган ачык партия җыелышында КПСС Үзәк Комитетының июнь (1983 ел) Пленумы карарлары яктылыгында иҗат яшьләре белән эшләү мәсьәләләре тикшерелде. Иҗат яшьләре белән алып барылган күп төрле эшләр һәм алда торган бурычлар турындагы доклад белән Татарстан Язучылар союзы правлениесе председателе урынбасары И. Юзеев чыкты. Фикер алышуларда драматург Т. Миңнуллин, тәнкыйтьче Ф. Миңнуллин, шагыйрьләр Н. Дәүли, Р. Гатауллин, К. Латыйпов, Язучылар союзы партия оешмасы секретаре Р. Мөхәммәдиев һ. б. чыгыш ясап, киләчәктә яшь иҗатчылар белән тагын да нәтиҗәлерәк эшләү турында үзләренең эшлекле тәкъдимнәрен керттеләр.

## КОМПОЗИТОРНЫ ИСКӘ АЛУ ТАНТАНАСЫ

28 февральдә М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры бинасында атаклы совет композиторы Фәрит Яруллинның тууына 70 ел тулуга багышланган юбилей кичәсе булды. Аны СССРның халык артисты, Социалистик Хезмәт Герое композитор Н. Г. Җиһанов ачты.

Юбилярның тормыш һәм иҗат юлы турында ТАССР культура министры И. Н. Алиев сөйләде.

Аннары тантанага килүчеләр Фәрит Яруллинның «Шүрәле» балетын карадылар.

Кичәгә юбилярның кызы Наилә Яруллина, полкташлары: элекке рота командиры, хәзерге вакытта техник фәннәр докторы, профессор Д. С. Самойлов, запастагы подполковник М. Н. Тихненко, композиторның замандашлары, күрше республикалардан кунаклар да килгән иде.

Юбилей кичәсендә КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев, ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнаштылар.

## СОЛДАТ ШАГЫЙРЬГӘ БАГЫШЛАП

24 февральдә язучыларның Г. Тукай исемендәге клубында солдат шагыйрь Фатих Кәрим истәлегенә багышлап, «Штыкка тиңләп каләмне...» дигән кичә үткәрелде. Филология фәннәре кандидаты З. Мәҗитов Фатих Кәримнең иҗаты, тормыш юлы турында сөйләде.

Аннары фронтовик шагыйрь М. Садри, яшь шагыйрь Р. Низамиев яңа шигырьләрен укыдылар.

Кичәнең икенче бүлегендә Фатих Кәрим шигырьләренә язылган җырлар яңгырады. Аларны Татарстанның халык артисткасы В. Гыйззәтуллина, Татарстанның атказанган артисты М. Галиев, яшь җырчы Л. Хәсәнова башкарды. Татарстанның атказанган артисты Х. Җәләлов шагыйрьнең «Кыңгыраулы яшел гармун» әсәрен сөйләде. Фатих Кәримне күреп белгән замандашлары шагыйрь турында истәлекләр сөйләделәр. Кичәдә шагыйрьнең якташлары, туганнары катнашты.

Башкортстанның Бәләбәй шәһәре педагогия училищесы коллективы Ф. Кәримнең 75 еллыгын киң билгеләп үтте. Кайчандыр шагыйрь укыган бу уку йорты бинасына Ф. Кәрим истәлегенә мемориаль такта куелды һәм аның исемендәге китап сөючеләр клубы ачылды. Тирә-як районнардан килгән укытучылар катнашлыгында «Шагыйрь-гражданин, шагыйрь-сугышчы» дигән темага конференция үткәрелде.

Кичен училищеда шагыйрь юбилеена багышланган тантаналы кичә булды.

Кичәдә Казаннан килгән язучылар М. Мәһдиев, З. Мәҗитов, башкорт язучылары шагыйрь шәхесе, аның шигърияте турындагы уй-фикерләре белән уртаклаштылар. Кичәдә Фатих Кәримнең кызы Ләйлә катнашты.

## РӘССАМНЫ ХӨРМӘТЛӘҮ

24 февральдә Казанның Актерлар йортында ТАССР Художниклар союзы идарәсе председателе, РСФСРның атказанган, ТАССРның халык художнигы, республикабызның Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Әнәс Ибраһимович Тумашевны 60 яше тулу уңаеннан хөрмәтләү кичәсе булды.

КПСС өлкә комитеты секретаре М. Ф. Вәлиев Ә. И. Тумашевка КПСС өлкә комитеты һәм ТАССР Министрлар Советының Мактау грамотасын тапшырды һәм аңа зур иҗат уңышлары теләде.

Ә. И. Тумашевның иҗаты турында РСФСРның атказанган художнигы В. И. Куделькин сөйләде. Юбилярны партия, совет, профсоюз оешмалары, хезмәт коллективлары, иҗат союзлары вәкилләре, Мәскәүдән һәм күрше республикалардан килгән кунаклар котлады.

Аннары Татарстан Художниклар союзының күргәзмә залында Ә. И. Тумашевның персональ күргәзмәсе ачылды.

Кичәдә ТАССР Министрлар Советы Председателенең беренче урынбасары М. Х. Хәсәнов катнашты.

## ЯҢА КҮРГӘЗМӘЛӘР

2 мартта ТАССР Художниклар союзының күргәзмә залында Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, күренекле рәссам Тавил Хаҗиәхмәтовның шәхси күргәзмәсе эшли башлады. Сәнгать сөючеләр игътибарына Т. Хаҗиәхмәтовның китап графикасы буенча чирек гасыр дәвамында иҗат иткән рәсемнәре, портретлар, театр костюмнары, станлы графика әсәрләре тәкъдим ителгән.

Шул ук көнне ТАССР Художниклар союзының күргәзмә залында «Почет билгесе» орденлы «Ялкын» журналының 60 еллык юбилеена багышланган журнал графикасы һәм балалар иҗаты күргәзмәсе ачылу тантанасы булды. Күргәзмәгә дистәдән артык рәссамның эшләре куелган иде.

Күргәзмә ачылу тантанасында КПСС ның Татарстан өлкә комитеты культура бүлеге мөдире М. М. Мусин, ТАССР Культура министры И. Н. Алиев нитәшләр катнашты.

## КОЛ ГАЛИ ИСТӘЛЕГЕНӘ

28 январьда Түбән Кама шәһәренең Техника йортында болгар-татар язма шигъриятенә нигез салучы шагыйрь Кол Галинең тууына 800 ел тулуга багышланган әдәби-музыкаль кичә булды. Традицион «Җидегән чишмә» кичәсе булып узган бу әдәби мәҗлестә Казан дәүләт университеты профессоры, тарих фәннәре докторы М. Госманов, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының өлкән фәнни хезмәткәре, тарих фәннәре кандидаты Р. Фәхретдинов, РСФСРның халык артисты Р. Таҗетдинов, ТАССРның атказанган артисткасы Д. Нуруллина катнаштылар.

## ЖУРНАЛ АЭС ТӨЗЕШӘ

Укучыларга мәгълүм булганча, 1983 елның язында «Казан утлары» журналы һәм Татарстан атом электр станциясен төзүчеләр коллективлары арасында хезмәттәшлек килешүе төзелгән иде. КПСС Үзәк Комитетының «Әдәби-нәфис журналларның коммунистик төзелеш практикасы белән элемтәсе турында»гы карарын тормышка ашыру йөзеннән төзелгән бу килешү нигезендә редакция АЭСта үзенең әдәби постын булдырды. Журналда «Әдәби пост — АЭС» дигән даими рубрика белән төзелешнең иң мөһим мәсьәләләрен күтәргән язмалар басылып килә, «Казан утлары» редакциясе ярдәме белән былтыр Г. Тукайның туган көнендә беренче тапкыр АЭСта шигырь бәйрәме уздырылды.

Хезмәттәшлек килешүе төзелүгә бер ел тулу уңаеннан быел 27 февральдә төзелешкә «Казан утлары»ның баш редакторы Р. Харис, журнал хезмәткәрләре Р. Гатауллин, Р. Әхмәтҗанов, З. Мансуров, «Социалистик Татарстан» газетасының бүлек мөдире М. Әмирханов, Брежнев шәһәрендә яшәүче язучылар Э. Касыймов, Г. Кашапов килделәр. Алар төзелеш объектларында булдылар, төзүчеләрнең тормышкөнкүреш һәм хезмәт шартлары белән таныштылар.

Кичен Кама Аланы клубында төзүчеләр белән очрашу кичәсе булды. Кичәне «Камгэсэнергострой»ның йортлар салу комбинаты начальнигы М. Ш. Бибишев ачты. Ренат Харис ике арадагы иҗади хезмәттәшлекнең бер еллык эшенә йомгак ясады. Ул АЭС төзүчеләренең иҗат кешеләренә яңа әсәрләр тудыруда ышанычлы стимул бирүен һәм илһам чыганагы булуын билгеләп үтте.

Бер төркем алдынгы төзүчеләр редакциянең Почет грамоталары һәм «Казан утлары»на еллык подписка белән бүләкләнделәр. Бу бүләкләргә 12 нче төзү-монтаж идарәсе начальнигы Рәис Сәләхов, төзүчеләр Илфар Гайнуллин, Сания Мифтахова, Нәгыйм Хәбибуллин, Хатип Моратов лаек булды. М. Ш. Бибишев төзүчеләр алдында торган бүгенге бурычларның, яңа төзелештә хәл ителәсе проблемаларның әдәбият-сәнгатьтән башка, төпле тәрбияви эшләрдән башка хәл ителә алмавы турында сөйләде һәм редакциягә АЭС төзелешен тасвирлаучы фотоальбом бүләк итте. Килешү шартларында күрсәтелгәнчә, «Казан утлары» журналының АЭСка багышланган иң яхшы әсәрләре акчалата премия белән билгеләп үтелә. Быел бу бүләккә Г. Кашаповның « һәм башланды яңа көрәш», М. Әмирхановның «Тарихи көн» очерклары лаек булды.

Язучылар, шагыйрьләр АЭС төзүчеләренә үзләренең яңа әсәрләрен укыдылар, сорауларга җавап бирделәр.

# «КҮҢЕЛЕМ ЛЕНИН БЕЛӘН СӨЙЛӘШӘ...»

РСФСРның атказанган художнигы, Ленин комсомолы премиясе лауреаты Әмир Мәҗитов картиналары илебез сәнгать сөючеләренә күптәннән таныш. Ә менә Казанда оештырыла торган күргәзмәләрдә аның нәкыш әсәрләре 1979 елдан соң гына күренә башлады. Сәбәп шунда: В. И. Суриков исемендәге Мәскәү художество институтын тәмамлагач, ул шактый еллар Ярославльдә яшәп иҗат итте. Ә аннары туган каласына кайтты.

Әмир Мәҗитов сюжетлы-тематик картиналар остасы буларак танылды. Менә инде утыз ел буе ул яшьләр темасына тугрылыклы булып кала. Совет яшьләренең данлы үткәне һәм бүгенгесе рәссам өчен бетмәс-төкәнмәс илһам чыганагы булып хезмәт итә, һәм ул әлеге тематика буенча үзенең иҗат концепциясен барлыкка китерде. Идея-эстетик кредосы аеруча ачык гәүдәләнгән шигъри-патетик әсәрләр, аерым алганда, гражданнар сугышы геройларына багышланган «Барабанчы», беренче хатын-кыз космонавт образын гәүдәләндергән «Акчарлак», бүгенге яшьләрнең бәхетле тормышы турында сөйләүче «Привалда», «Финиш янында» кебек картиналар авторның күренекле уңышлары буларак кабул ителде, Ленин комсомолы премиясенә лаек булды.

Идея эчтәлегенең ачыклыгы, композиция төгәллеге Ә. Мәҗитов пейзажларына картиналылык характеры бирә. Рәссам шәхси кичерешләрен, табигатьнең халәтен генә биреп калмый, ә гомумиләштерүле тирән образ тудыра. Мәсәлән, «Ленино-Кокушкино» пейзажы шундый әсәрләрдән санала. Тантаналы күтәренке рух биредә үстерелешле композиция аша бирелгән. Һәркем өчен дә газиз саналган йорт шундый пространствода сурәтләнгән ки, ул күз алдында зурайганнан-зурая бара шикелле. Озаграк караган саен, эчкәрәк үтеп кергәндәй буласың.

...Боз тоткынлыгын җимереп чыккан елга ташкыны дәртле омтылыш белән алга ашкына. Яр өстендә — ара-тирә соңгы кар утраучыклары. Кышкы йокыдан уянган агач ябалдашлары кояш нурларында коена. Манзараның үзәгендә — гадәти агач йорт. Гадәти дә, изге дә. Биредә яшь Ульяновның аяк эзләре саклана. Һәм аларга планетабызның төрле почмакларыннан, юлбашчы сайлаган юлдан тайпылмауларын белдерергә килгән кешеләрнең эзләре кушыла. Тып-тын гына атлыйлар, ә күңелләре Ленин белән сөйләшә. Халык ташкыны кимеми, кешеләр сукмагы өзелми, Ильичка мәхәббәт хисләре саекмый — артканнан-арта бара.

**Диләра САДЫЙКОВА,**
Татарстан сынлы сәнгать музееның фәнни хезмәткәре.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** М. Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театрында И. Кальманның «Чегән-премьер» опереттасы буенча куелган спектакльдән күренеш.

**Рөстәм МАНСУРОВ** фотолары.

Бәясе 90 тиен.
Цена 90 коп.

Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
(ОГНИ КАЗАНИ)

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
ОРГАН СОЮЗА ПИСАТЕЛЕЙ ТАТАРИИ
(на татарском языке)